ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

6.2010



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## «Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында



Әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык иҗади хезмәте өчен шагыйрь **Мингалимов Рөстәм Гали улына** «Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

*Казан, Кремль 6 май, 2010 ел.*

**Казан утлары**
**Qazan utları**

2010

# 6
**(1052)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур.; 2*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
✆: **Факс**—(843) 562-11-28.
🖳: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхмәт РӘШИТ. Йолдыз белән йолдыз арасы. *Шигырьләр.* ... 5
Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Эзләмәгез җирдән... *Бәян.* ... 10
Лена ШАГЫЙРЬҖАН. «Шигъри тамчылар» циклыннан. *Афоризмнар һәм хикмәтле фәлсәфи сүзләр.* ... 42
Мәдинә МАЛИКОВА. Юка чәчәк аткан чак иде. *Роман.* ... 47
Сирень ЯКУПОВА. Сүзгә төреп, җыр-сер иттем... *Шигырьләр.* ... 78
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Тау артында кояш бар. *Роман.* ... 81
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Син һаман шул сандугач. *Кыска бәян.* ... 126

**БӨЕК ҖИҢҮГӘ 65 ЕЛ**

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләре ... 37

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Эльвира ҺАДИЕВА. Минем йола. *Шигырьләр.* ... 124

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рөстәм ЗАРИПОВ. Кояшка каршы һөҗүм... ... 145

**ХӘТЕР**

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Халыкка багышланган гомер *(Мансур Хәсәновның тууына 80 ел).* ... 154
Миркасыйм ГОСМАНОВ. Уйландыра торган уйлар ... 163
Җамал ВӘЛИДИ. Милли мәктәп вә милли тел ... 164
Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Тынгысыз җан иде... *(Нәби Дәүлинең туууна 100 ел)* ... 173

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ... 170

**АК ҖИЛКӘН**

Равил ШӘРӘФИЕВ. Бәләкәй Шәрәфи ... 180

Котлыйбыз! *(Мәрзия Фәйзуллинага 80 яшь)* ... 179
«Казан утлары» — интернетта ... 185
«Казан утлары» архивыннан ... 186
Берлекнең яңа әгъзалары ... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы М. МАЛИКОВОЙ «И сад был в цвету» (окончание), Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ «За горою солнце» (продолжение); повесть Н. ГИМАТДИНОВОЙ «Странник»; маленькая повесть Г. БАЙРАМОВОЙ «Ты моя соловушка»; стихи А. РАШИТА, Л. ШАГИРЗЯНА, С. ЯКУПОВОЙ.
«К 65-летию Великой Победы»: «Татарские писатели—участники войны».
«Творчество молодых»: стихи Э. ХАДИЕВОЙ.
«Публицистика»: Р. ЗАРИПОВ. «Наступление на солнце».
«Память»: статьи Ф. ГАЛИМУЛЛИНА к 80-летию М. Хасанова и М. ВАЛИЕВА к 100-летию Н. Давли; Дж. ВАЛИДИ. «Национальная школа и национальный язык». (с предисловием М. Усманова).
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.)
«Белый парус»: Р. ШАРАФИЕВ. «Маленький Шарафи».
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Древний сабантуй». Работа Р. КАДЫРОВА и С. ГИЛЯЗЕТДИНОВА; писатель Ринат БАТТАЛ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novels by M. MALIKOVA «And the garden was in bloom»(ending), R. GABDULHAKOVA «Over mountain there is sun» (continuation); story by N. GIMATDINOVA «Wanderer»; story by G. BAYRAMOVA «You are my Nightingale»; poetry by A. RASHIT, L. SHAGIRZYAN, S. YAKUPOVA.
«To 65th anniversary of Great Victory»: «Tatar writers - participants in war».
«Creation of youth: poems by E. HADIEVA.
«Journalism»: R. ZARIPOV. «Attack on sun».
Memory: article by F. GALIMULLIN to 80th anniversary of M. Hasanov and M. VALIEV, to 100th anniversary of N. Davli, J. VALIDI. «National school and national language» (With foreword by M. USMANOV).
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
«White Sail»: R. SHARAFIEV. «Little Sharafi».
New members of Writers Union.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Ancient Sabantuy». Work by R. KADYROV and S. GILYAZETDINOV; writer Rinat BATTAL.

★ **Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.**
★ **Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
★ **Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.**

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.06.2010, график буенча 1.06.2010.
Офсет ысулы белән басылд. Кәгазь форматы 70Х108$^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–695. Тираж 4436.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

**«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.**
**Казан, Декабристлар урамы, 2**

© **«Казан утлары», 2010 ел.**



Әхмәт
Рәшит

# ЙОЛДЫЗ БЕЛӘН ЙОЛДЫЗ АРАСЫ

## Төнге күккә карап

**Хыялның да була азак чиге—**
**Яшәүгә дә хастыр ул хаклык;**
**Чиге чиксез, без яшәгән галәм—**
**Хыял үлчи алмас ераклык.**

**Уйның чиге янәшәдә генә—**
**Уза аны хәтта яктылык;**
**Яктылык та ерак араларга**
**Җитәдер шул фәкать нур булып.**

**Суфыйлардан көлгән булабыз да ...**
**Имеш, алар тиле—хыялый,**
**Ул мәңгелек белән чиксезлекне**
**Күңелләр соң дөрес тоямы?!**

**Әһле Ислам, әйе, белеп торды,**
**Кырыс түгел иде шартлары,**
**Европа күк утта яндырмады**
**Хакыйкатьне тапкан затларны.**

**Кырыс иде, әйе, кануннары,**
**Тик юл калды азат фикергә—**
**Ул хакыйкать эзләп, җиде кат Күк**
**Гөмбәзенәмени сикерә?!**

**Җитә генә алмый—уйлар чикле,**
**Юлны дәвам итә варисы;**
**Ачкыч табар өчен тылсым эзләп,**
**Хыялланып мәллә карыйсы?!**

---

Әхмәт РӘШИТ (1936) – *шагыйрь, публицист; «Сәяхәтнамә», «Таң илчесе», «Язмыш җилләре» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгының һәм Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Ә хыялсыз Кеше яши алмый—
Дәшә аны, дәшә гел хаклык.
Чакрым белән түгел, парсек белән
Чикләнгән шул сихри ераклык.

Әле анысы, әле монысы тарта—
Дин белән Фән мәңге ярышта.
Хакыйкатькә илтер юллар ябык—
Атлап булмый сыңар карыш та.
Без барабыз,
Без— мәңгелек юлда,—
Юк, куркытмый ерак аралар;
Йолдызлар да, әнә...
Балкып... сүнеп...
Шул тарафка таба баралар.

Тууымы,
Әллә үлүеме
Без барасы ерак җисемнең;
Чиге юк шул ашкын фаразларның,
Чиге юк шул күрү хисенең.

## Суфыйларга мәдхия

*Синагога, хөжрә, монастырьның*
*Тәмуг, җәннәт булыр бар җыры.*
*Алла серен белгән күңелләрдә*
*Андый уйдырмага юк урын.*
Гомәр Хәйәм

Үртәмәгез, суган суфые, дип—
Баш тартмавын тартмыйм суганнан,
Дөреслектә хәтта мин үзем дә
Суфыймындыр ахры, туганнар.

Ник булмаска! Әйдә, көлсен гавам—
Хөкемдары бүген мин аның,
Укый-укый инде белдем бугай
Чын тарихын фани дөньяның.

Без—шәрабсыз аек, ризыксыз тук,
Сәламәдән безнең патша да,
Йөзләрчә ай, кояш көлә безгә,
Исләр китми данга, акчага.

Китаплардан түгел безнең акыл,
Хакыйкатьтән килгән акыл ул.
Әллә кайлардагы хәзинәгә
Комсызланып һич тә сузмый кул.

Гарәп, фарсы, юнан буласыңмы—
Мөһим түгел. Байлык—чүп аңа,
Тик камиллек калсын яшәештә,
Тик камиллек килсен дөньяга.

Гасыр арты гасыр—сәрхуш заман,
Ни кояшлы түгел, ни җилле,

Зарланабыз, дөнья шундый, диеп,—
Кайчан булыр аның... камиле?!

Югыйсә бит бөтен кыйтталарда
Ничә гасыр исә гел саф җил;
Суфыйлыкка хәтта дәгъва итте
Муллий, Гете, де Голль, Хаммаршельд.

Дарвин диеп, Эйнштейн диеп
Күкрәк какса бүген кемнәрдер,
Суфыйларның даһи ачышлары
Меңәр еллар алдан килгәндер.

Суфыйлыкта без дә калышмаган
(Татаргамы бу эш ярамый!)—
Язган Бакыргани һәм Кол Гали,
Язган Кятип, язган Сараи.

Бәхәсләшсен дөнья—кем соң алда,
Кем соң артта бүген санала.
Европа күк талап бар дөньяны
Кайсы кыйтга әле дан ала?!

Саный китсәң, хәтер хәтәр түгел,
Мактанырлык эшләр җитәрлек;
Без аларны, кат-кат искә алып,
Байрак итеп өскә күтәрик.

Дөньякүләм бөек ачышларны
Кем ясаган, дисәң, бу җирдә,
Шаһит булып күкләр баш күтәрер—
Ачыкланыр катгый дәлил дә.

***

Бу дөнья— каты бәгырьле,
Бу дөнья—артык кырыс;
Бишектән кабергә чаклы
Ярарга, имеш, тырыш.

Үзеңчә яшәп булмый шул—
Төрлегә төрләнәсең,
Пакъ булып яшим, дисәң дә,
Барыбер керләнәсең.

Гөрзиен тоткан зобаный—
Сугарга гына тора,
Тырышсаң да, карышсаң да,
Егарга гына тора.

Суфыйдан булмый саф булып,
Дөнья бит—гөнаһ күптер;
Тәмугка ук булмаса да,
Җәннәткә юллар юктыр.

Буранлы карлар, яңгырлар,
Үләттән килгән яулар,
Су басулар, җир тетрәүләр,
Дәһшәтле янар таулар...

Түзәбез инде, түзәбез—
Яшәргә чөнки кирәк;
Каршылыйсың бәлаләрнең
Һәркайсын аяк терәп.

## Үз-үземә киңәш

Күп пеште авызым, телемнең
Тик кенә тормавы сәбәпле,
Ышанып, дус итсәм бирәрсен,
Йөгәнли алмыйм һич гадәтне.

Сөйлим дә шаярып, сүзләрем
Ирешә кирәкле кешегә;
Ул исә тырпайта сыртларын
Һәм миңа... озакка үчегә.

Соңыннан бик авыр аклану—
Бер сүзең ирешкән ун булып,
Шаян сүз шаян сүз кебек тә,
Ә аңа җитә ул... җен булып.

Шаярта белмимме мин үзем,
Дуслармы куерта сүземне.
Сүзеңнең рәте юк, диеп мин
Тиргим дә инде гел үземне.

Тик нишлим? Тел—ул бит сөяксез.
Сөйләшә белмәсәң, киңәш шул:
Беркемгә сөйләмә ачылып—
Үзеңә тик үзең «сердәш» бул».

## Серле йозак

Чибәрләрнең бар байлыгы үзе белән—
Кирәк түгел акча дигән тити-мити;
Матур кызлар үз кадерен үзе белә,
Һәркайсысы— иң кимендә Нефертити.

Йә булмаса Джоконда—Мона Лиза,
Кайсы ир-ат башын имәс аның алда;
Гарантия юк югында... тик нишлисең,
Ичмаса зур хурлык түгел алдансаң да!

Нишләргә соң?! Әйе, гомер итеп була
Җенгә генә тиңләшерлек җан белән дә—
Гомер кыска. Тәмлерәкне, татлыракны
Дәгъвалыйсың... Кайчагында кан белән дә.

Беләм, беләм, беркатлыдыр әйткәннәрем—
Ник соң тоташ ызгыш-талаш кайбер өйдә?!
Һич табылмый аңлашу һәм уртак фикер,
Уйлыйм-уйлыйм, җавап тапмыйм—сәбәп нидә?!

Шул чибәрләр генә уйлап чыгаргандыр
Бу үзара аңлашмауны һәм низагны;
Бары пошмас җаннар ача аладыр шул
Беркем ача алмый торган ул йозакны.

## Киңәш

Түрәнең дә кәефләнер чагы бар—
Штаттан тыш берәр кәнизәге бар.

Секретаре—анысы инде штатный,
Хатыны кук—кайчакта бесплатный.

Дөрес, кайчак бирәсең берәр бүләк—
Назны да кирәк алу кайчак түләп.

Дөнья бит бу, ә ул исә... куласа,
Әйләнеп тулгандыра да... бер баса.

Иң начары—күп күрүче «дус» та бар—
Кирәк чакта үч алу ягын табар.

Рәхәт булмас, карт көнендә карчыгың
Тезеп китсә берәм-берәм ачуын.

Нишләргә соң? Анысын инде үзең бел—
Элек көлдең бит... хәзер дә үзең көл.

***

Заманга заман тиң түгел,
Үзгәреп булмый, дисең,
Ничек үзгәрим соң, дисең,—
Мин үткән чор кешесе.

Хушлаштык ул дәвер белән,
Алда тора яңасы—
Анда шул ук мәшәкатьләр—
Көясе дә янасы,

Юк, алай түгел икән шул—
Нәрсәдер бүтән, үзгә;
Яшьләр дә һәрбер адымда
Карыйлар кырын безгә.

«Без яшь чакта...»—дибез дә бит...
Нәрсәгә андый яшьлек?..
Сталинлы һәм колхозлы
Чоргамы йөрик дәшеп?!

Капиталист белән мәллә
Сындырыйкмы... булмаса?!
Яңа чор дип ничә еллар
Газапланабыз ласа.

Әллә алга барабыз без,
Әллә артка барабыз—
Коммуналы заманага
Дәшә дә бит паровоз.

Хәзер аның юк бит инде
Паровоз дигәне дә...
Әллә кирәк без, әллә юк
Чал тарих иләнендә.

Барабыз шунда тирбәлеп—
Заман да, әйе, бара...
Әллә бар без, әллә юк  без
Киләчәк заманнарда.

***

Пәйгамбәрлек безгә кирәк түгел,
Шагыйрьлек тә кирәк түгелдер;
Ике икең—дүрт дип йөргәннәргә
Гомер итү, әйе, җиңелдер.

Шикләр туса, сана кампитрдa—
Хөкеме бик гади... тимернең;
Уйлыйсы юк, санап торасы юк—
Әйткәнен ул үти бар мирнең.

Ике икең—өч тә, биш тә була—
Безнең мидә генә ул чикләр;

Ә ни белән генә үлчәнә соң
Нурлар гына җитәр парсеклар?[1]

Ә ни белән генә үлчәнә соң
Йолдыз белән йолдыз арасы?!
Аларга бит миллиард еллар буе
Бертуктусыз... һаман барасы.

Андый язмыш безгә тәтемәстер—
Ятим итмик шуңа бу Җирне;
Еллар белән генә була санап
Ходай безгә язган гомерне.

[1] Парсек – 32 600 миллиард ел.



Нәбирә Гыйматдинова

# ЭЗЛӘМӘГЕЗ ҖИРДӘН...

БӘЯН

## 1

Нәрсә булды? Нәрсә булды?.. Йә, житте! Сез нишләп бертуктаусыз аның колагына пышылдыйсыз?! Төнге шәһәр давыл тоткынлыгында чәбәләнә: болыты белән ишеп-ишеп яңгыр коя. Аяктан егарлык көчле җил эре-эре тамчыларны тәрәзә пыяласына китереп сылый. Диварларда коточкыч сурәтләр биешә: алар әллә ничә төрле кыяфәткә кереп, ыржая-көлә. Менә елан сыман озынча хәшәрәт өстенә сикереп аны буарга тели. Чү, тилермә! Диварларда берни дә юк. Баядан бирле «Нәрсә булды?» дип тинтерәткән тавыш та юк! Болар барысы да саташу галәмәте. А-а, баш гүелди! Аны мендәр астына яшерәсе иде! Әнә, яшен дә, кая барып бәрелергә белмичә, әле йорт түбәләрендә ялтырый, әле зәһәрләнеп һаваны кисә. Менә ул бар ачуы белән кизәнеп төн йөзенә сукты. Шәһәр тетрәнеп куйды, гүя күк йөзе урталай бүленеп, җиһанның йөрәге ярылды. Аннан давыл капыл гына тынды... Гайрәт чәчкән болытлар, сулы итәкләрен җыеп, мыштым гына офыкларга табан шуышты.

Табигать чик-чамасын белә шул. Аңа да туктарга кирәк. Тән өшеп-туңып калтырана. Соңгы тапкыр бер йота да менә... Тамырларда оешып каткан канны сыегайтыр өчен генә... Нишләптер җимерек, шакшы, әшәке дөнья эчкәч яктыра-ачыла, ямьләнә-матурая, ә таш бәгырьле, миһербансыз бәндәләр фәрештәләргә әйләнә. Югыйсә алар җиргә канат очын да тидермәячәк. Аларның урыны—югарыда. Һәм син шушы баткаклыкта илһамланып кара! Нинди тимер йөрәк тә чыдамас иде. Ул да чыдамады. Әкәм-төкәм кебек кабыгына бикләнде. Бу, әлбәттә, шаккатарлык хәл иде. Талантлы дигән бәя ишет тә, читтә басып кал, дан-шөһрәт артыннан кума, бүләкләр даулама имеш. Акыллы адәм үзен болай җәберләргә тиеш түгел. Нәкъ менә үзен! Ә монда киресенчә килеп чыкты. Зөлфия Солтанова исемле диктатор Зөлфия Солтанова атлы рәссамның иҗатын изеп-сытып

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА—*прозаик; «Ак торна каргышы», «Талпыну», «Кыргый», «Сихерче», «Сәвилә», һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгатькәре. Казанда яши.*

ташлады. Бер үк кеше кинәт кенә икегә аерылды. Диктатор көчлерәк иде, ул рәссамны жинде, чөнки ана бу жәмгыятьтәге икейөзле бәндәләр «бетсен, бетсен» дип көч-дәрт биреп торды һәм ахырдан корбанына куштанланып: «Сиңа нәрсә булды?» дип төчеләнде.

«Нәрсә булды?» Хатын бу сораудан гел качып яшәде. Ә бит ул жәллад балтасыдай баш очында эленеп жавабын көтә. Зөлфия аны берничек тә сөртеп ташлый алмый иде инде, чөнки ул ана буйсынмаган мөстәкыйль билге иде, шуңа күрә һич югы тоныкланыр дип, рәссам сорауны кыйммәтле шәраблар белән юа башлады. Тик тегесе төссезләнмәде, кыскасы, бирешмәде, төннәрен колак төбендә гөжләде. Бу тавыш, вакыт-вакыт, ижатташларыныкына охшый иде. Югыйсә алар белән көрешмәгәненә дә биш былтыр.Тугызынчы каттагы остаханәләрнең озын коридорында утыз ишек. Шунын берсе ярты ел бикле. Зөлфиянеке ул. Анда ижат уты мәңгегә сүнгән... Бүлмәне бушат, дип берлектән кичә генә хат юлладылар. Бушат, бушат! Алайса, үзең дә Гайшә Алиева язмышын кабатларсың. Урын өчен акчасы да түләнмәгән ичмасам. Хәер, аңа хәзер ижат куышы кирәк микән? Гайшә язмышы дигәннән, әгәр ул бүген исән булса, Зөлфия анын аягына ятып, «кичерегез, кичер» дип ялварыр иде. Картаеп, бармаклары пумала тоталмаган Гайшә Ниловна бер жыелышта: «Остаханәгә йөрерлек рәтем юк, урынымны Зөлфиягә бирәм, кыз талантлы, әйдә, рәхәтен күрсен» дигәч, анын шатлыгы эченә сыймаган иде. Бүлмә! Көндез дә, төнлә дә синең карамактагы аерым бүлмә! Берәү дә сиңа комачауламаячак. Иске Бистәдәге ата йорты күптән тарайган иде инде: үги ана көенә басып яшәү туйдырган иде.

Тик тилмереп көткән бәхетле көннәр тиз генә якынлашмады. «Бирәм» әле ул «бирдем» түгел икән шул. Ай да узды, ел да узды. Ахырдан Гайшә Ниловна вәгъдәсен онытып, хастаханәгә кереп ятты. «Син күрше карчыкның хәтеренә ышанма, ачкыч ярат та, кер,»—диде тәрәзә төбендә тәмәке көйрәткән күршесе Васильич. Әллә юри әйтте, әллә чынлап. Анысы кеше котыртырга дисәң, ул бик оста иде инде. Яшьлек кайнарлыгы белән Зөлфия ишекне каерып ачты. Бүлмә шыплап әйбер белән тулган иде. Кыз көнозын шуны чистартты, ә картиналарны коридор башына илтеп өйде. Шул кичтә Ниловна үлгән... Их, хәзерге акылы булса! Һичьюгы күршесе мәгънәле булса! Кешенең жаны гәүдәсеннән арынгач та, фанилыкта үзе өчен газиз саналган жиренә ашыгыр һәм өстән генә шундагы тамашаларны күзәтер ди. Ижат кешесенең жаны тагын кайларга табан очсын?! (Ул бит ялгыз иде.) Билгеле, Ниловна тузанга буялып идәндә аунаган картиналарына карап сыкрангандыр. Мондый мәрхәмәтсезлек кайдан килде икән аңа?! Бу хакта ул егерме елдан соң уйлана менә.Жәмгыять каты бәгырьле икән, аны шул хәлгә житкерүче—адәми затлар үзләре бит. Уң кулын белән матурлык тудыр, сул кулың белән әшәкелек кыл. Бу ике нәрсә ничек бер гәүдәгә сыя икән ул? Күрәсең, сыядыр. Әнә үзендә ике Зөлфия көрәшә. Жинден, жиндең, диктатор Зөлфия! Син рәссам Зөлфияне туфракка салып таптадың. Ул, ниһаять ижатыннан ваз кичә. Бәлки, сиңа буйсыну хәерлерәктер дә. Бу гавам сәнгатькә багынган кеше өчен тәмугка тиң, ул нечкә күнелле димиләр, терелә́й яндыралар. Хәтта берни белән дә исәпләшмәгән хыял да анын каты маңгаена бәрелеп кисәкләргә уала.

Нәрсә булды?.. Житте, бүтән сорамагыз. Хәзер бер генә йота да...

Ул калтыранган кулы белән өстәлдәге шешәгә үрелде, әмма ипсез һәм хәлсез бармаклардагы шома пыяла тынламыйча идәнгә төшеп ватылды... Хатын сусавын басарга теләгәндәй краннан су агызып, йотлыгы-йотлыга эчте. Хлор исе аңкыган су анын баш миен уятып жибәргән төсле тоелды. Ә идәнгә хәмер жәелгән... Үзе нәни генә күлдәвек, ә үзенең кодрәте дәрьяга тиң: бер батырса—төпкә үк чумасың. Мөгаен, диктатор Зөлфиянең жиңүенә

сөенергә генә кирәктер. Акыл белән яшәгән кеше һәрвакыт ота ул, ә хис колы хыялый дивана исемен күтәреп көлкегә кала. Әтисе аның рәсем белән мавыгуын башта ук өнәмәгән иде. «Кеше балалары акыллы, алар акчалы һөнәрләргә укый, кызым,син нишләп кәкре сукмактан китәсен?»—диде ул. Кәкре сукмак—туры гына йөри белмәгән хыялыйлар юлы икән! Рәссам Зөлфия егерме ел буе шуннан атлаган түгелме соң?!

Ул көзге каршысына басты. Хәмер парыннан тоныкланган күзләрдә сагыш бар иде. Хушлашу сагышы... Сау бул һәм бәхил бул, ижат! Йә, яңа тормышыңны ни-нәрсәдән башлыйсың, диктатор Зөлфия? Әйе, сине: «Үзеңне тәртипкә китер дә, эшкә кил» дип кыстыйлар лабаса! Базарда чүпрәк-чапрак сатмыйсың—чыраеңны сытма! Үги анаң сине олы улының дәрәҗәле оешмасына урнаштыра. Мәрхүм атаң Ислам каберендә «кызым» дип борчылып ятмасын дип яхшылык эшли, янәсе. Үги ананың түрә малае нинди зур кәнәфи били (димәк, акчасы тау хәтле), ә карт әнкәсе мәчеттә идән юа, имеш. Боларны ишетеп кенә белә Зөлфия. Үги ана белән аралашканы юк. Ерактан гына күргән иде, ишегалдына ике катлы ташпулат төзегән түрә улы. Нишләптер иске агач өйне сүтмәгәннәр, ул, ятимлегенә әрнегәндәй, башын иеп, йокымсырап утыра шикелле...

Ай-һай йөзе таушалган икән. Ничек кенә тәртипкә китерәсе моны... Диана, бәлки, рәтләп бирер. Ул, матбугатта, минем салонда дәваланган туксан яшьлек әбиләр дә яшь кызларга өйләнә дип, мактанып яза иде. Ә аңа чиста, шома йөз нигә кирәк соң әле? Әйе, әйе, Зөлфия дөнья белән үзгәрергә җыена! Тукта, аның җанына тәңгәл килерлекме соң ул дөнья дигәнең? Зөлфия дә бүтәннәр кебек сөйләшергә, көләргә, еларга тиеш буламы? Кешеләр бер төсле көлә, бер төсле елый диләр. Ялган! Кемдер күңел белән, кемдер күз белән елый... Көлүләрдә дә аерма зур!

Ул таралырга торган аяк-кулларын көчкә селкетеп, ятагына ауды. Тәрәзәне ачып куясы иде... Яңгырдан соң һава сафлангандыр. Кара сөрем каплаган күк йөзен, бәлки, яшен чаткылары чистарткандыр. Хәл юк шул... Таң аткач ул ничек тә аякланырга тиеш. Үзгәрергә диләр, ләбаса.

Диана аны танымады. Теләнергә кергән хәерче дип уйлады бугай, ишектән арырак үрә катып торган сакчы егеткә ым белән генә «чүпне урамга түгәргә» кушты. Зөлфиянең үпкәләргә хакы юк иде. Өстә иске йон свитер (җәй аенда!), аякта кайчандыр кыйммәт булып та, хуҗасы кебек тәс җуйган туфлиләр. Үзе бизгәк тоткандай калтырана. Ул калтырау әзрәк тотсан—басыла да анысы... Бәлки, шулай итәргәдер, ә? Аның тагын фатирында сатылмаган өч шәп картинасы бар. Җүн генә бәягә аткарсаң да, берсе-берсе йөзәр «биш йолдызлы» коньяк! Дөньясына кул селтәп эч тә, кабыгыңда бөгәрләнеп ят!

—Диана, бу мин, Зөлфия Солтанова,—диде ул үзенә табан ыргылган әзмәверне карашы белән абындырып. Ерткычка төбәп карасаң—юашлана, имеш.

—Стоп, Вадим!—Салон бикәсенең күзенә җирәнү катыш гаҗәпләнү бәреп чыкты.—Зулямы? Шундый карачкы кыяфәттәме? Ужас!

—Курыкма, урындыгыңны буямам. Минем өс-башым юылган.—Зөлфия ишек төбендәге резин келәмгә кат-кат аягын сөртте.—Гафу, әллә бай клиентларымны өркетер дисеңме?

—Уф, теле! Уз, югалган серле кош. Парижда сәяхәт итәсең дип ишеттем. Йә, ни хәлләр анда?

—Әйбәт.

—Илдар чакырттымы? Арабыз өзелде дигән идең, ялганчы. Нишләп болай алама киендең син, Зуля? Ужас, битеңә кислота сиптеләр мәллә? Может, Париж һавасы килешмәгәндер.

—Мине рәтләп буламы, Диана?
—Ужас! Тиреңне тунап янасын ябыштырсаң гына инде.
—Син могҗиза белән яшәртәбез дисең бит.
—Әй, шулай алдамасаң, ангыра балыклар чиертәмени. Син совсем сәлперәймәгән әле. Ун сеанстан соң йөзең үтүкләнер, шәт. Әйдә!
Түшәме көзгедән эшләнгән салон чит ил карабы шикелле ялтырый иде. Шома идәндә таеп егылмас өчен үкчәсен без итеп кадый-кадый хуҗабикә артыннан иярде Зөлфия. Чәч, тырнак буявы исе борынны әчеттерә иде.
—Минем кабинетта бераз гайбәт тузаны кагыйк,—диде Диана. Мөгаен, ул, танышының тормышы мажаралар белән шыплап тулган дип ялгыша иде.—Йә, сиптер! Илдар белән бергә яшәдегезме?
—Кайда?
—Айда түгел, билгеле. Парижда!
Диана алтынсу тоткалы шкафтан чәркәләр чыгарып өстәлгә тезде. Йөрәк дәртләнеп типте. Салон хуҗасы статусына туры килер өчен иң кыйммәтле «Һеннесси» коньягы гына тота иде.Тәненең сөягенә кадәр өши. Мөгаен, дару урынына гына йотып куяргадыр. Соңгы мәртәбә! Теле дә чишелер. Әнә бит, үзе белән бергә сүзе дә кысылып беткән.
—Мин Казанда идем, Диана...
—Һы, кызык икән! Өй туена чакыртып мастерскоена кеше җибәргән идем. Андагылар сине чит илдә дигән. Нәрсә, Илдар белән янадан кавышуыңны бездән яшерәсеңмени?
—Яшермим, өйдә идем мин.
—Кем белән?!
—Җеннәр белән. Авырдым.
—Чирең нинди инде, ә?
—Аңламадым..
Диана күзне кыздырып чәркәләргә коньяк койды.
—Ярар, берәр суперкартина ясагансыңдыр әле. Сез иҗат дип ай-кояшны сүндереп, дөм караңгыда да яшәргә риза. Шуна син бетәшкән дә. Әйдә, күрешү хөрмәтенә, яме!
Зөлфиянең өстәл кырыена ябышкан кулы кыяр-кыймас кына чәркәгә үрелде дә, утта пешкәндәй, кире аска салынды. «Соңгы тапкыр, соңгы тапкыр!—диде эчтән ялварулы тавыш.—Дару итеп кенә!»
—Рәхмәт, без бит моның белән дошман...—Зөлфия йөзен читкә борды. Бу алдашу аның үзен ышандырыр өчен кирәк иде.
—Кыстамыйм,—диде Диана уймак иреннәренә сыланган коньяк тамчысын бармак очы белән сөртеп.—Алайса, вакытны сузмыйк, мин хәзер сине егет-кызларыма тапшырам. Сыларлар, буярлар, тигезләрләр.
—Кара әле, Диана. Акчасын бер-ике айдан бирәм, ярыймы ? Мин хәлле генә җиргә эшкә урнашам.
Салон хуҗасы аптырамады:
—Мин акчага тук, дустым,—диде.—Мәхәббәттә генә ач. Син безнең хезмәт өчен бүтәнчә бәхилләрсең. Ирем белән аерылыштык бит без. Мин аңардан ни наз, ни җылы сүз ишетмәдем. Исемемне дә бозып Дию ана дия иде. Берәүне йортыма ияләштердем мин. Яшь, дәртле, чибәр. Ике метр буй, чем-кара чәч, күпертмә иреннәр... Ужас чибәр! Менә син минә бәгырькәемнең портретын ясыйсың. Түләү шул сиңа.
Зөлфия ялгыз чәркәгә күз сирпеп алды. Ымсындыра, шайтан алгыры! Тәмен генә татыйсы мәллә?
—Бу альфонсның сурәте ниемә хаҗәт инде, Диана?
—Миннән баерак хатыннар бармак селкесә ташлар инде ул. Шул чакта картинасын кочаклап йоклармын. Әй, шаяртам ла! Үзенең никадәр матур

икәнен күрсен дим. Марсымның туган көненә шундый шаккатыргыч бүләк бирәсем килә. Ну, син тәкъдимемә ризамы?

Ялкауланган баш мие җавап әвәләгән арада Диана аны кызларга илтеп тә тапшырды. Башта Зөлфияне коры саунада тирләттеләр, аннары ниндидер майлар тамызып ваннада җебеттеләр. Бу процедураларны үткәч, үлән чәе эчертеп ак җәймәләргә урап, сәкегә салдылар. Кытай массажына өйрәтелгән тар маңгайлы егетнең җитез бармаклары каткан буыннарын уып йомшартканда гына ялкау баш мие «уянды»: «Рәссам Зөлфияне гамәлдән сыздылар лабаса! Альфонс портретын кем ясый?!»

Зөлфия бурычка батканчы ычкыныйм дип сикереп тормакчы иде, зәңгәрсу савыт тотып баш очына икенче бер оста килеп басты.

—Массаждан соң битегезгә керешәбез,—диде кыз, аның яңакларына җиңелчә генә кагылып.—Тирегез коры икән. Без сезгә майлы кремнар сайларбыз. Иртә-кич шуны сөртерсез.

Ул үзен куна тактадагы төче камыр кебек хис итте. Аны әвәлиләр, изәләр һәм шушы массадан нидер «пешерергә» өметләнәләр. Каш-күз, ирен-борын ясалыр, әлбәттә. Болар адәм баласының тышкы кабыгы. Ә эчтә? Анда кем генә шифалы һәм кодрәтле сүзләр индерер икән ? Кем җылы куллары белән иркәләп, җанның сулкылдавын басар?

—Йөриләрдер, иеме?

—Нәрсә дисез?—Косметолог кыз аның йөзенә иелде.

—Сездәге яшәртү сеансларына йөриләрдер дим.

—О! Диана Мурзаевна иң югары даирәдәге ханымнарга гына хезмәт күрсәтә. Бездә мэр хатыннары даими клиент. Ә сез кем?

—Диктатор Зөлфия Солтанова.

—Ә, түрә алайса. Сезнең исем-фамилиягез таныш, тик ул башка кешенеке. Тагын рәссам Солтанова да бар. Элек мин театрда грим салучы идем, күргәзмәгә дә еш бара идек, безгә Солтанованың картиналары ошый иде.

—Сәлимова!—Ишек төбендә Диананың зәһәр тавышы яңгырады.—Күпме кисәтергә була: клиентлар янында такылдама!

... Киенү бүлмәсендә аның иске киемнәрен чүп савытына бөгәрләп тыкканнар иде. Диана элгечтәге костюм-итәккә ымлады:

—Әнә, шуларны ки. Безнең гәүдә үлчәмнәре бер. Мәскәүдәге модельер Зайцевның күргәзмәсеннән бу. Эксклюзив әйбер. Төсе чәчемә килешмәгәнгә күрә яратмадым.

Зөлфиягә бик кыен иде. Шулай ук мескенлекнең чигенә килеп терәлде микәнни?! Аны кычкыртып сатып алалар! Ә ул карышмый!

—Кыйммәттер. Акчасын бирермен. Соңрак...

—Вәгъдәләштек бит инде. Синнән—сөеклемнең портреты!

«Мин иҗат дөньясы белән саубуллаштым инде!»—дип нишләп әйтмисең, җебегән?

—Бәлки, син аңа машина бүләк итәрсең, Диана?

—Җүләрем! Гаражда ике чит ил арбасы! Утырсын да чапсын. Бутиктан гына киендерәм, супермаркеттан гына ашатам, ефәктә генә йоклатам мин аны! Син бит әнә теге драматург абзыйны, кем әле ул, «Мәхәббәтем» авторын ничек оста чәпәдең! Тач үзе! Хәтерлисеңме, син шул абзыйны киндергә авыштырганда мин көн дә мастерскоеңа килеп, почмакка гына посып күзәтә идем. Гашыйк идем шул Мыекбайга. Аның самый популяр чагы иде. Үзем дә гади чәч кыркучы гына идем әле. «Миңа керегез, чәчегезне матурлап кисәм,»—дигәч, ул, мине түбәнсетеп көлде. Һаман яшь калырмын дигәндер, карт аю. Кстати, театрда пьесалары һаман уйналамы?

—Белмим, Диана.

—Хи, син үлә-үлә иҗат иткәнсең, Зуля! Дөньядагы яңалыклардан да бихәбәр икәнсең. Да, костюм сиңа таман гына, йөзеңне дә ача!

«Ник сырланасың син, ә?—диде диктатор Зөлфия.—Мә дигәндә ал. Бу ханымның байлыгы савытыннан ташып ага. Ярар, тиз генә халтура әтмәлләп бирерсең шунда. Бүген киндер буяучы урта куллар заманы.»

Бу әзрәк күңелне тынычландырды кебек. Рәссам заказлардан баш тартмый инде ул, тик объект кына күңелеңне тырнамасын. Остаханәдә дистәләгән иҗат әһелләренең сурәтен ничә еллар буе ник саклый икән ул. Барысы да өстәгеләрнең әмере белән эшләнгән. Арада теләр-теләмичә генә, теш кысып кына ясалганнары да күп.

Диана салонынннан Зөлфия тагын да авыраеп чыкты. Гүя ул үзе түгел: Зайцев киеме гәүдәсенә килешсә дә, хәрәкәтләрен чикли, ә аягындагы Диана чүәге очы белән асфальтка кадалып, тигез җирдә абындыра иде. Ул ике квартал җәяү баргач, җимерек йортлар аша узып Татар Бистәсенә табан борылды. Шәһәр кешесе өчен нигез төшенчәсе бар микән ул? Менә шушы урамнарда аның балачагы йөгереп йөри... Хатирәләр канат очы белән аның хәтеренә кагылып-кагылып ала. Ә ул—битараф. Ичмасам күңелнең бер кылы чыңласа икән! Авыллар гына ул: «ата-баба туфрагы» дип аһ итә. Әнә Васильч, киндергә күз яше тамыза-тамыза Киеклесен күчерә. Ауган коймаларны, картаеп янтайган өен, капка төбендәге ялгыз имән агачын... Фатирдан фатирга күченгән ташкала халкы кайда җанын утыртсын ди! Юкка гына космополитлар шәһәрдә тумыйдыр шул инде. Ә бит Зөлфиянең Татар Бистәсендәге йорты—төп нигез. Ул шунда туды, шунда үсте... Ә нигә хатын аны сагынмый икән соң? Моңа үги ана гаепле дисәң—әтисеннән ун яшькә олырак карчык кызны кыерсытмады лабаса! Ул хәтта мәрхүмә әнисе урынына да дәгъва кылмады шикелле. Раушания апаны әтисенә димләгәндә аның бердәнбер олы малае чит илдә эшли иде. Баш әйләнә... Ул бит, бик теләгән тәкъдирдә, кара яндырып чәй эчә ала. Хәер, аны хәлләндерсә, бары тик... Юк, юк, кайда син, ихтыяр көче?! Уйлатма хәмер турында, уйлатма! Үги анасы белән чәй эчә Зөлфия хәзер... Турларына килеп житкәч кенә ник туган йортын күрмәмешкә салышсын ди ул!

Хатын капка тоткасына орынган гына иде, ишегалдыннан йомшак тавыш ишетелде.

—Кер, кызым, кер, капка бикләмәгән.—Раушания апа бауга керләр элә иде.—Мәчет сөлгеләрен юып киптерәм,—диде карчык, күрешергә дип ике кулын сузып.—Мин сине ерактан ук шәйләдем, урам очыннан ук. Кайларда югалдың син, кызым?

Зөлфия бу күрешүне өнәмәгән кыяфәт чыгарып, иске өйнең нүешенә сөялде. Карчыкка авыз турсайту—көлке иде, билгеле. Кайдадыр офыклар артында калган үсмер кыз үртәлә шулай. Аңа килешә тагы!

—Әгәр керәм дисәң, ачкыч өйалды ишеге башында,—диде Раушания апа. Ул да каушаган иде кебек. Ничек каушамасын ди! Биш елдан соң үгиең белән йөзгә-йөз очраш әле син!

—Вакытым юк.—Зөлфия каядыр «ашыга» иде.

—Анда һәммәсе дә элеккечә, кызым. Инәсенә дә тимәдем.

—Нишләп сүтмәдегез? Ишегалдыгызны ямьсезләмәс иде...

—Аллам сакласын, сүтәмме соң, кызым. Исламымның ядкәре лә ул!

Бергә ун ел яшәп өлгермәделәр, «Исламым»га тәрләнгән. Кавышканда инде берсенең чәче агарган, икенчесенең биле кәкрәйгән «яшьләр»дә ярату булган микәнни?

—Газ торбаларын да кистермәдем, жылы торсын дип. Туып-үскән нигезең лә, кил дә яшә, кызым.

—Минем дә бу йортка дәгъвам юк инде. Фатирым бар чөнки,—дип Зөлфия

сүзен әзеп, кузгалып китмәкче иде, хәлсезлектән чак кына егылмады.

—Туктале, тукта, кызым,—дип үги ана беләгеннән тотмаса, мөгаен ул, йөзтүбән җиргә кадалыр иде.—Авырыйсың, ахры. Йөзең шикәр төсле ап-ак. Мин сине болай гына җибәрмим, уйлама да.—Карчык көчле иде, ул аны баскычтан култыклап менгезде. Зал бүлмәсендәге озын диванга капчык кебек сөяп утырткач, атлый-йөгерә, икенче ишеккә чумды, аннан нечкә билле касә белән ниндидер сыеклык алып килде.

—Мә, эч. Сукыр кычыткан суы. Тынычландыра ул. Кап-кайнар. Термостан гына агыздым.

—Рәхмәт, ни...

—Ярый, апа диген. Әни дияргә зур идең шул син. Мин сине эзләп фатирыңа кат-кат килдем. Безнең мәчеттә сезнең йорттан Халисә атлы хатын дин сабагын өйрәнә. Сүз җебе тартыла-тартыла йомгакка син чорналдың, Алланың рәхмәте. Беләм мин аны , ди, түлке ди, өеннән урамга сирәк чыга, бик нык авырый, ахры, килеш-килбәте тач сырхауныкы, ди. И-и, үзәкләрем өзелде синең өчен. Рәсем сырлап кына кем тамак туйдырсын икән! Ач ята инде, дим. Илшатым кайтып, Казанда зур оешма житәкли башлады.

—Мин улыңны бер тапкыр да күрмәдем...—Төнәтмә әче иде, телен бөрештерә иде. Их, әче каптырып кына адәми затка әверелсәң иде.

—Күрерсең, боерса. Улым мәрхәмәтле минем. Сеңелеңне эшкә ал дигәч тә, килсен, әни, диде. Шуңа хат язып, почта тартмаңа Халисә аркылы салдырдым, кызым.

—Мин аңа нинди сеңел инде... Җиде ят...

—Син Исламымның газиз баласы, Зөлфия. Илшат сиңа абыең, бел!—диде үги ана кистереп.

—Ә мин дөньясына төкердем бит әле. Алты ай туктаусыз эчтем.—Ни кылана инде, ә? Нишләп ул тиктомалдан гына эчендәге чүп-чарын түгәргә тотынды? Кем итәгенә диген?! Үги анасының! Әрнеп әйтсә иде ичмасам, көлеп сөйли бит!

—Ләхәүлә... Газиз Аллам, үзең иман баганаларын ныгыт!—диде карчык үзалдына. Аның тавышында бер гаҗизлек сизелә иде. Менә ул хәзер битәрләргә керешер. Әгәр кыюлыгы җитмәсә (үги кыз ла!), Зөлфия аны үзе котыртыр. Әйдә, рәхәтләнеп тиргәсен!

—...күрше Вера базарда чүпрәк сата иде. Эчәргә җитмәгәч, табак-савытларны аңа биреп саттырдым, киемнәремне, тунымны. Бу өстемдәге костюм бер танышымныкы... Бурычка, диде. Мин аның бойфрендының, ягъни яшь сөяркәсенең портретын сырларга тиеш.

—Кеше сурәте ясама! Теге дөньяда алар синнән җан сорарлар ди.

Үги анасы «эчәм» дигәнне ишетмәде мәллә?

—О, алайса минем бер җанымны ничәмә-ничә адәм бүлгәли икән. Остаханәдә җәмгысы ун портрет ята.

Юк, юк, карчык саңгырау түгел иде, ул барысын да ишетте. Аның көләч йөзе сүрәнләнеп, күзләренә шом инде. Ул ачуланып камчысын болгаган тәкъдирдә дә файдасыз иде. Зөлфияне йокы басты, чуен кебек авырайган баш кырыйга янтая да янтая иде. Артык тынычландырды моның сукыр кычытканы... Әллә өй һавасы килештеме? Ишегалдында һаман гөлләр үсә икән. Мәрхүмә әнисе казыган түтәл урыннары да күчмәгән икән... Керфекләрен йомарга гына курка менә. Диварларда эреле-ваклы җанварлар тагын җанланыр кебек.

Карчык пош-пош дога укып, аның өстенә калын шәл япты... Соңгы айларда Зөлфия тоташ өч сәгать тә йоклый алмый, саташып уяна иде. Беренче мәртәбә йокы аны тирбәтә-тирбәтә бишеккә салды... Ул хәтта төш

тә күрде. Матур, якты, илаһи төш иде бу. Ак болытлардан саркыгандай колакка тонык кына булып азан тавышы ишетелде. Аның моны туңып каткан йөрәкне сулкылдатып җибәргәндәй тоелды. Иҗаттан гына тукылган җан мәңгегә шушы төштә калырга теләгәндәй, тән кабыгыннан чыгарга дип бәргәләнде. Уянгач та берара ул, кымшанмыйча ятты. Тәрәзә артында куркыныч дөнья! Аның ташкыны язмышларны йомычка төсле дәрьяга ташлый. Анда йөзә белгәннәр дә бата...

—Уяндыңмы, кызым?

—Озак йокладыммы?

—Ярты сәгать. Тынычлыгың юк синең, кызым. Өшкерергә кирәк сине. Алла кушып, ярдәме тияр.

—Әкият!

—Чирен куәтле, чирен шайтаннан, кызым.

—Куәтсезләнер әле, көрәшәм бит менә шайтаның белән, икенче тәүлек иренемне дә чылатмыйм.—Зөлфия үги анасы белән тырпаеп, тупас кына сөйләшә иде. Капкадан кергәндә үк шуңа көйләнгән тавышны ничек йомшартасың ди! Ә күңелнен бер читендә чеметем генә яктылык шәйләнде. Бәлки терелер... Бәлки, хәшәрәтләр бүтән әзәрлекләмәс... Галлюцинация нәтиҗәсе ул, берни түгел. Чирен шайтаннан дип, үги ана әкият сөйли.

Капка төбендә Зөлфия шул чеметем яктылыкка сөенеп:

—Төшемдә кемдер азан кычкырды. Моны нәрсәгә юрарга икән?—диде. Үги ана белән коры гына саубуллашу унайсыз иде.

Карчык, яулыгын төзәткәләп:

—Илшатым ул, бүген җомга көн, мәчеттә җәмәгать намазына барышлый өйдә азан әйтеп чыга,—диде.—Абыеңа иртәгә үк сугыл, кызым.

... Ә Зөлфия абый кеше белән очрашырга ашкынмый иде. Аңа бит әле өр-яңадан туасы бар. Шешенгән йөз, нурсыз күзләр, чалшайган аяклар... Шуңа ул көзгегә артык карамаска тырыша. Абыйсының кырыс сакчылары: «Бу нинди убыр?»— дип, шикләнеп, тышкы ишектән дә уздырмас.

Өенә кайткач, хатын бәләкәй сумкасыннан төргәк тапты. Биш мең сум акча! Монысы нәрсә? Абау, дога! Ә бусы әтисенең машина ачкычы. Бармаклары шешкәч, ул машинасын Зөлфиягә биргән иде. Иске «Волга» нык иде әле. Кыз, чит ил арбасын анардан өстенрәк күргән иде дә, бәрелеп, алдын җимерде шул. Алты ай стоянкада җил ашап күгәргәндер, төзәтерлеге юктыр инде. Болар, һичшиксез, юмарт үги ана кучтәнәчләре иде. Зөлфия доганы көзге кырыена ябыштырды, ачкычларны кире сумкага салды, ә акчалар тиз генә куллан шумады, ул аларны бер урталай бөкте, бер турайтты. Ярыйсы гына байлык бит әле бу... Ипи-шикәргә дә җитә, тегесенә дә... Соңгы тапкыр дип ант итә ләбаса! Хәер, ул «соңгы»ларның башы-азагы күренми инде. Ә монысы, чын мәгәр, соңгы тапкыр. Кемдер әчтән аны куәтли: « Әйдә, соңгы тапкыр!»

Әйтерсең нииндидер көч аның муенын уң якка каерды. Күз үзеннән-үзе догага төште. Яшел җирлектәге аңлаешсыз хәрефләрдән нур сирпелә төсле иде. Ул сихерләнгәндәй карашы белән берәм-берәм аларны «чүпләде.» Әтисе кызының ир балалар кебек машинаны оста йөртүенә шатлана иде. Ул чакта Казан урамнарында руль боргалаган хатын-кызлар сирәк иде. Догадан җылы дулкын бәрелә... Түз, чыда... Башында, дөбер-дөбер күк күкри. Аның кайтавазы дан-доң лепкәгә суга: «Соңгы тапкы-ы-р...»

Ишек бикләнмәгән икән, күршесе Вера керде. Култык астына кыстырган шешәсен шык иттереп пианино өстенә бастыргач:

—Фу, арыдым, биш күлмәк саттым, бик удачный көн,—дип, диванга кырын ауды.—Икесен алама подружкам вечерга кигән иде, шәраб табы бар, тәки шуңа бәйләнде бер түтәй. Пычрак, ди. Менә этикеткасы, өр-яңа дип тәки күзен будым. Давай, уңышны юабыз, бүген үзем сыйлыйм.

Зөлфия язудагы хәрефләр тәэсиреннән айнымаган иде. Югыйсә ул бу тәкъдимне ишетү белән бәллүр чәркәләрне чынлатып, Вера каршысына тезәргә тиеш иде.

—Әй, бабье! Нишләп һаман сораясың син? Давай!—диде күршесе, түземсезләнеп.

Үги ана бу доганы ник аңа бирде икән? Ни-нәрсәгә ишарәләде икән ул? Син иманлы нәсел кыйпылчыгы дип хәтерен уятасы килдеме? Әтисе кайта-кайта сөйли иде шул: «Минем мөәзин бабайны кара елларда дин ялчысы дип гаепләп, атарга кушканнар. Моны авыл куштаны милисиәнер Гыйздулла башкарырга алынган. Аркасына мылтык түтәсе белән төя-төя япан кырга куган ул бабайны, үзеннән үк кабер дә казыткан. «Улым,—дигән бабай,—үләр алдыннан ике рәкәгать намаз укырга рөхсәт ит,»—дигән. Кансызның әзрәк мәрхәмәте уянгандырмы шунда, укы, түлке мин тәмәке тартып бетергәнче генә, дигән. Гыйздулла махрасын өч-дүрт суырып артына борылса, бабайдан җилләр искән, ди. Качкан дисәң—әйләнә-тирәдә тау юк, чокыр юк, кабер дә буш ди. Куштан акырып-бакырып авылга чапкан. Авызыннан күбек ага ди, күзләре шар ди моның, шуннан ул акылдан язган. Гыйбрәт бу, кызым.»

«Матур әкият...—дип көлемсери иде Зөлфия.—Бик матур әкият...»

—Бабье, әй!—Вера шап та шоп кул чапты.—Кая карап каттың син?

—Бар әле, тай моннан. Шешәңне дә ал!

—Нәр-сә?

—Вера, тай!

—Үзем сыйлыйм, ахмак! Бер әйбереңне дә сорамыйм. Похмель ярсыта сине, дускаем, сал әле миңа, кәефең момент күтәрелә,—дип сайраган хатынга ул тагын кычкырды:

—Тай!

—Ярар, ярар. Иртәгә үк өстеңдәге тәти күлмәгеңне тотып керәсен әле син миңа. Сатып, баш төзәтергә акча бир дип, күз яшеңне тамызасың әле син, киндер буяучы рәссам кисәге!

Зөлфия күршесенең базар теленә күнеккән иде, ләкин «рәссам кисәге» дип мыскыллау аның күңелен рәнҗетте. Ул Вера артыннан ишекне каты гына тартып япты, хәтта шкаф селкенде, хәтта догадагы бизәкле хәрефләр биеште. Бер уйласаң, хатын бары тик үзенә генә рәнҗергә тиеш иде. Рәссам исемен кем пычратты?—Зөлфия! Яшәү рәвеше белән кем аның дәрәҗәсен төшерде?—Зөлфия! Шуннан соң башкалардан нинди хөрмәт көтәсең ди! «Ярдәм ит,—диде ул билгесезлеккә пышылдап.—Рәсемнән бизеп өр-яңадан тормыш башларга ярдәм ит, зинһар!»

Җан сулкылдап җавап кайтарды: «Бизмә-ә-ә». Иҗат сагышы бәгырьне теләә иде. Буяу-киндерләрен сагына мәллә Зөлфия? Моңарчы хәмер белән күмелеп торган үзе рәхәт,үзе газаплы мизгелләр тагын кайтырга маташа мәллә? Ник, нигә?! Ул алардан китте бит инде, китте... Диктатор Зөлфия төзегән канун буенча яши хәзер. Төс-битен ыспайлагач, җитди ханым кыяфәтенә кергәч затлы офиска эшкә урнаша. Кем сыйфатында? Идән юдыртмаслар, мөгаен. Шуңа күрә «абый» ла ул. Көлке, әлбәттә. Юк, кызганыч! Юк, көлке дә, кызганыч та түгел! Бу—тормыш чынбарлыгы. Кешелек кыйммәтләре изепсытып корылган гарип җәмгыятькә киндер буячы кирәкми! Әйе, рәссамнарны шулай дип атыйлар бүген. Житте, күңеленне кызган, елатма...

## 2

Аркасын таш баганага терәгән малай янында ул туктап калды. Бала теләнә! Иске кәләпүш төбендә вак тиеннәр ята. Табыш әлегә бик сыек.

—Исәнме?—диде Зөлфия, якын танышына эндәшкәндәй.—Ник соранасың, энем?

—Әни авырый, ана даруга акча җитми.

—Беренче көн мәллә? Әлек күзгә чалынмадың.—«Чалынмадың» имеш. Әйтерсең кеше күрерлек хәлдә иде.—Мәктәп бакчасында җәйге практика үтмисеңмени?

—Төшкә кадәр су сибәм, аннары теләнәм.

—Әгәр мин сиңа кәгазь акчалар бирсәм, бу кәсебеңнән баш тартасыңмы?

—Синнән кем алган ди соң!

—Бәй, нишләп?!

—Акчаң хәрам синең, апа. Син хәзер генә «рюмочный»дан чыктың. Анда абый-апалар хәмер чөмерә.

Зөлфия кызара-кызара акланды:

—Сатучыга элеккеге бурычларымны түләдем. Мин ап-аек, энем. Син монда көнозын кояшта янып та дарулык акча җыялмассың. Мә, ике мең тәңкә. Тиз генә өеңә йөгер!

Үги анасының акчасына хуҗа табылды, шөкер.

Малай кулын күтәреп укыгач, битен сыпырды.

—Тукта, әз генә сабыр ит!—диде хатын, сумкасында актарынып.—Бу нинди дога? Син андагы хәрефләрне таныйсыңмы?

—Һе, танымыйча ни. «Лә-ә—иләһә илләләһү, Хаюл каюм, лә тәэхузү...» Аятелкөрси лә бу, апа. Җен-пәридән саклый ул. Мин апа, ел саен җәйге каникулларда мәчеттәге лагерьда гарәпчә укырга өйрәнәм,—диде малай горурланып.

—Алайса теләнү ярамастыр инде сиңа, энем.

—Әнине үтерәсе килми лә, апа-а,—дип сузды яңа танышы.

—Чү,—Зөлфия аның башыннан сыйпады.—Берүк савыксын анаң. Син алга табан ничек яшәмәкче буласың? Максатың бармы соң, дим.

Зөлфия, гүя үзенә теләктәш эзли иде. Ул да, малай кебек үк, җәмгыятьнең артык ботагы, аның да тамырларына балта чабалар. Зөлфия ичмасам әзрәк яшәп карады, ә бу бала ни инде, аның дөньяга күзе дә ачылмаган, ә алдында кап-кара пәрдә...

Малай чалбар балакларының тузанын какты.

—Үсим генә, апа. Мәктәпне тәмамлагач фиргавеннәр иленә китәм, бөтенләйгә, әнине алып. Анда мин ватылмый торган пирамидалар төзим.

Көлмәде Зөлфия. Чөнки танышының йөзе җитди иде.

—Бар, әниеңне зарыктырма,—диде ул, малайны җиңелчә генә этәреп.—Оч, энем!

Ул көләргә тиеш тә түгел иде. Кайсы җире мәзәк соң әле моның? Бала фиргавеннәр иленә китәргә хыяллана, бала хыялы әллә ничә катлы офыкларны ертып уза, киресенчә, Зөлфиянең хәле көлке.Менә ул киләчәген билгеләп сызган юл бик кыска: матурлык салоны һәм офис.

... Диана аның килеш-килбәтен өнәмәде.

—Тагын иске чүпрәкләргә төренгән!—диде.—Кайда минекеләр? Аулак тыкрыкта чишендерделәр мәллә?

—Мә!—Зөлфия төенчеген урындыкка атты.—Кичтән юып киптердем.—Һәм хатынның кулына акча сонды.—Кичәге дәвалау сеанслары өчен. Өч кенә мең, әз, билгеле. Соңрак бәхилләрмен, ямә?

—Ай-яй, хәтерең саеккан, дускаем. Онытты̆ңмы, син портрет белән түлисең. Без шулай килештек ләса.

—Түләмим, чөнки альфонсның сурәтен ясамыйм.

—Ужас! Ризалаштың ләса! Мин сиңа өстәп акча да бирәм, Зуля. Күпме, йә? Йөз мең, йөз илле мең?

Моңа ничек аңлатырга икән? Хикмәт бәядәмени! Байлар бөтен нәрсә

дә, шул исәптән иҗат кешеләре дә акчага сатыла дип уйлый. Анысы дөрес уйлый: дөньясы белән шул кәгазьгә табынгач ни...

Еларга җитешеп иреннәре дерелдәгән Диана тәкәбберлеген җинеп һаман аңа ялварды:

—Үтенәм, яса инде, Зуля. Марсның иң зур хыялы—портрет!

—Үзен күзгедән күрмимени?

—Мин сине алдадым, Зуля. Бүләккә түгел ул. Фәлән-фәләннәрне күргәзмә түренә чәпиләр, минем дә алар янәшәсендә торасым килә, ди. Яшь нәрсәкәем, мәйтәм, фәләннәр танылган шәхесләр, дим, халык аларны белә, дим. Мине дә танырлар, ди. Шартымны үтәмәсән, китәм, ди.

Зөлфиянең җен ачуы кузгалды. Башта байлык кирәк, аннары—дан-шөһрәт. Нишли бу адәм актыклары?!

—Китсен, тотма.

—Сиңа әйтүе җиңел. Син ирләр яратмыйсын. Илдарны да үзеннән биздерден,—дип шыңшыды Диана.

—Гафу ит, мин күргәзмә өчен альфонслар ясамыйм!—дип кырт кисте Зөлфия.

—Анысы минем хәсрәт, дускаем. Анысын үзем җайлыйм. Залдагы бөтен урынны сатып алам Марсым хакына! Йә, Зуля, ризалык бир!

—Авторын күрсәтмисез.

—Ә? Ну киребеткән син, Зуля. Хуп, хуп,—диде Диана, ул яңадан һавалы салон хуҗасына әйләнде. Бармак шартлатып кына кызларын чакырды.—Клиентның бүген вакыты тыгыз, сеанслар иртәгә күчерелә.—Һәм ул җитез генә өч меңне Зөлфиянең кесәсенә тыкты.

Иртәгә күрешәбез дип дустанә аерылышсалар да, ул әлеге заказга битараф иде. Җан да сызланмый хәтта. Халтура өчен ник сызлансын ди! Кан белән йөрәгең аша юдырган әсәр генә төн йоклатмый. Бала тудырырга әзерләнгән ана кебек, син аның дөньяга аваз салганын дулкынланып та, хафаланып та көтәсең... Кемдер сабыенның кимчелекләренә төртеп яманлар, кемдер мактар. Ә бала якын һәм газиз, аңа берәүдән дә тел-теш тидертәсе килми! Ләкин иҗатташлар авызыннан гадел бәя сирәк ишетелә. Әлегә көнчелек чиренә дару табылмаган. Бердәнбер фикердәше Илдар чит илдә. Ирләр ярата Зөлфия, тик ул күплек санда түгел, ул—берәү генә... Илдар биш ай элек аны ташлап, Парижга очты. Шуннан бирле аралар өзелде. Сагыну бар, юксыну бар, мәхәббәт бар, Илдар гына юк...

Бу юлы үги анасы тагын да ачылып каршылады.

—И кызым, син капкага орынган саен атаңның рухы кинәнәдер. Кызым нигезенә баш иядер дип.

—Әтинең машинасын алсам, ачуланмыйсыңмы?

—Бәрәкалла, ачкычың кулыңда, кызым. Рәхәтен күр! Гаражда шул килеш ул, Исламым төсе дип атна саен тузанын сөртәм.

Үзен хәлсез итеп тойган Зөлфия машина кузгатырлык көчем калмаган дип юкка борчылган икән, айгыр кебек зур «Волга» аңа бик тиз буйсынды: хатын аны кабызып, капка төбенә чыгарып та бастырды. Карчык янында кичәге кебек теленә салынмады ул. Юаш кына:

—Илшат абыйга сәлам әйт. Мин аның белән тиздән очрашам,—диде.

—Артык сузма, кызым.

—Дога өчен рәхмәт. Мөгаен, мине өшкерергәдер.

Бу теләк ничек кинәт кенә тел очыннан тамды соң әле? Әкият дип кәперәйгән иде бит...

—Өшкермичә ни! Мөслимә абыстай исән, диләр. Яшүсмер вакытымда уң аягым тартышкач, аңа күрендем мин. «Синең ике галушыңа да ырымлап кабер туфрагы сипкәннәр, сулын кагып кигәнсең, шуңар анысына бозым

зәхмәте тимәгән,»—дигән иде абыстай. Өч мәртәбә өшкергәч, тәки хутланды аяк. Мөслимә әбиеннең сулышы шифалы иде. И Аллам, карттыр инде үзе. Сез карендәшләр, кызым, Исламның бабасы белән Мөслимә абыстай—туганнар.

—Абыстай кайсы урамда яши?

—Әтиеннәр авылында, Суык Чишмәдә. Минем дә авыл инде дә... кайтыр идек бергә дә...—Карчык нәрсәдер әйтеп бетермәде, Зөлфия исә «әйт», дип куәтләмәде. Ул күпме генә тырышса да үги ана белән икесенең арасындагы бозны эретә алмый иде. Күнеленең иң читендә искерсә дә гел янарган үпкә елышкан... Югыйсә ул әллә кайчан җуелырга тиеш иде. Раушания апа алар йортына аяк баскан көнне үк көндәшенең күлмәген киде, яулыгын бәйләде. Әй шуна үртәлде дә соң Зөлфия! Сонра үртәлү рәнҗүгә әверелеп йөрәккә төенләнде. Хатынының башбаштаклыгын әтисе хуплады тагы!

—Әйберне сандыкта черетеп исраф итмәскә шул,—диде.

—Кума, сакланып йөр, кызым.

Карчык анын уйларын укыса икән!

Машина хужа әмере белән остаханәгә турылады. Коридорда тынлык, идәндәге тузан, пырылдап очар өчен аяклар көтә иде. Гадәттә, җәй борын төртүгә, рәссамнар кошлар кебек жим эзләп, кайсы кая тарала. Васильич, мөгаен, урмандадыр, чөнки табигать анын стихиясе. Бүлмәсен ачуга борынга кипсә дә дивар-түшәмнәргә сеңгән таныш буяу исе бәрелде. Таныш кынамы соң! Елатыр дәрәҗәдә тансык та иде ул. Шуна күрә хәлсез йөрәк кызу-кызу тибәргә кереште. Их, хәзер үк киндерне өстәл-тактага беркетеп сызасы-бозасы иде. «Хисләреңне ташытма,—диде диктатор Зөлфия. —Бүлмәнне чүп-чардан арындыр.»

«Чүп-чар... » Бала итеп күргән картиналар хәзер шулай атала микәнни? Диктатор кызды: « Атала, әйе,—диде.—Алар кемгә кирәк, ә? И үләсез инде халык дип жаныгызны фида кылып. Гавам бүген сезгә соклана, ә иртәгә шедеврларыгызны учакта яндыра!»

Яндыра? Менә бу ичмасам шәп идея! «Волга» иркен машина иде, ана берьюлы унбиш картина сыйды. Зөлфия әкрен генә шәһәр читенә чыгып китте. Эч пошканда үзенә сыендырып юаткан каенлыкта жил сындырган ботак-санак күп иде. Учак тергезер өчен коры-сары жыеп өйгән чакта гына анын янына тәбәнәк буйлы ир-ат килеп туктады. Зөлфия ашыкмыйча гына «кәҗә сукмагы»ннан бу тарафларга табан теркелдәгән кешене бая ук абайлаган иде, чөнки абзый дөньяны иңнәренә күтәргәндәй ярым бөгелеп атлый иде. Килеп баскач та ул гәүдәсен турайтты. Кулындагы сары бидонын жиргә куйды. Зөлфия картиналарны чирәмгә ташлаган иде, абзый аларга күз йөртеп алды. Шуннан соң гына:

—Ни хәл, сенел?—диде.—Каенлыктагы кош-кортлар өчен күргәзмә оештырасын мәллә?

Ана дорфа гына «әйдә, юлыңда бул» дияргә иде дә, тик әдәп чабудан тартты. Бу абзыйны кайдадыр күрде лә ул. Кайда?—анык кына хәтерләми. Эчү жүнлегә илтмәде, баш миен сыеклатты.

—Инквизиция учагы якмакчы идем...

—Егерме беренче гасырда кемне тәмуг утында көйдерәсең инде, сенел? Бездә хәзер ут төртмичә генә кисәүгә әйләндерәләр түгелме соң? Ни эзе, ни көле. Син бит рәссам, әйеме? Син—Рәшит Даниловичның шәкерте идең теге заманнарда, эһе. Без аны «матур бака» дия идек, авызы зур иде анын. Үзенә охшый иде кушаматы. «Мәңгелек йорт»ка иртәрәк күчте мәрхүм, эһе. Ул сине: «Иң өметле укучым», дип мактый иде, эһе. Менә хәтер иләге тишелмәгән икән әле безнең.

—Сез кичләрен анын мастерскоенда эчеп утыра идегез, әйеме?

—И, сеңел, эчү дип аталса икән ул! Без анда сүз сөйләп, шул сүз тәменнән, сүз ләззәтеннән исерешеп таңнар аттыра идек. Бүген бармы сездә андый кич утырулар?

—Юк.

—Беләм, юри генә сорыйм, эһе. Сүз тәме бетте шул. Җырлый-җырлый аккан күңел чишмәләре саекты шул. Һәркем үз эченә бикләнеп иҗат итә. Уртак сөенече генә юк...

—Син кем, абзый?

—Минме? Минем исем эчтәлексез, сеңел. Гап-гади шагыйрь без. Көнтөн язабыз да язабыз. Шигырьләр биш капчык, ә китап бирәү генә. Син инде йә бер китап белән шагыйрь буласың, йә... Йә, ниләр утка ыргытыла синең монда?

Шагыйрь арты белән яткан картиналарны берәм-берәм әйләндерде.

—Эһе, Заһир яшьти! Атаклы драматург! Түшенә медаль-орденнарын такса—Брежнев каберендә көнләшер иде. Теге чорларда партия заказы белән күп язды Заһир, эһе. Пьесалары сәхнәдән төшмәде, тик нишләптер бүген күренми алар. Бер көнлек иҗатның гомере кыска, эһе. Ә бусы Ралиф каләмдәш. Мыегы шәп! Ул мәктәптә укыганда ук атказанган пионер исеме даулаган иде. Без бергә укыдык, сыйныфташлар идек. Эһе, Гаян Алиев та синең герой икән. Зыянсыз кеше иде, мәрхүм. Ләкин ялагай иде. Түрәләрнең аяк табанын ятып яларга әзер иде. Шуңа иҗаты да бәләкәй булды, эһе. Бу шагыйрь абзый һәммәсен дә хурлый димә, сеңел. Эчемдәге—тышымда. Тел бәласе, эһе. Юксынып кына сөйлим. Аларның эресе дә, вагы да, талантлысы да, уртакулы да сагындыра бүген. Бергә чакларның кадерен белмибез шул.

—Ниндидер тантана уңаеннан махсус ясаттылар. Өстән кушып, безнең ихтыярдан тыш.

—Ярамый, сеңел.

—Нәрсә «ярамый?»

—Аларны яндырырга ярамый.

—Сурәтләр теге дөньяда да җан сорарлар ди.

—Калебең чиста икән, Ходай кичерер, сеңел.—Шагыйрь һаман рәсем өемен тикшерде.—Ә боларның ни гаебе бар?—диде ул натюрмортларны бер кырыйга аерып.—Нишлисең син, сеңел?! Йә, барысын да машинаңа ташыйк!—Кечкенә буйлы шагыйрьнең тавышы гайрәтле иде, ул Зөлфиянең кыймылдаганын көтеп тормады, картиналарны үзе багажникка тутырды.—Хәзер учагыңны яксаң да була.

Зөлфия коры-сары чүмәләсенә шырпы сызды.

—Йә, сеңел, хәзер сөйлә!

—Сөйләүдән ни файда? Сез бит мине исәргә чутлыйсыз.

Шагыйрь тыенкы гына көлде.

—Иҗат кешесенә акыл пычагымамы ул, ә? Ишәргә, ватарга, җимерергә акыллы башлар болай да күп.

Хатынның бу бәндәгә ачуы кабарды. Нигә җан талкый икән?

—Яшәүнең кызыгы юк... Күңелдә кризис... Җиңәлмим... Иҗатны ташларга, диләр,—дип тезде ул.

—Кемнәр ташла диләр

—Мин. Үзем.

—Эһе, син икегә бүленден, димәк. Безнең шулай үз-үзебез белән көрәшеп гомер уза, чөнки син дә мин ике дөньяда яшибез. Берсе анын—чынбарлык, икенчесе—хыял. Ә син нык бул, сеңел. Ишетәсеңме? Тыңлыйсың гына шул, ишетмисең.

—Акыл өйрәтүе җиңел, кем...

—Шагыйрь мин. Мулла колакка кычкырган исемем—Мингалим иде дә...

—Нигә яшерәсең соң? Кеше исемсез булмас.

—Кеше түгел, ахрысы, мин. Шагыйрь бит ул йөрәктән генә тора, ә йөрәк—хикмәт иясе. Бөтен әгъзаларга да яман шеш үсә, ә йөрәк чип-чиста. Ник дисеңме? Уйла әле, сеңел. Безнең кыйблалар уртак. Кризис дисең син, әйе, ил-көндә искән салкын җил башкаларга караганда безне ныграк өшетә. Чөнки безнең күңел нечкә. Ходай талантын шундыйрак адәм балаларына бирә шул, нишләтәсең. Без тиз ватылабыз, тиз өзеләбез. Каты бәгырьле җәмгыятьтә безгә яшәве чамасыз авыр. Мин, мәсәлән, үзгәреш елларында бу якка чыгалмадым, тегендә калдым. Ә бит шагыйрь өчен бернинди киртәләр булмаска тиеш, аның җаны теләсә кайсы чикне үтәргә тиеш, әһе. Төшенкелек үтерә, яшермим, ләкин мин язам, мин сыктамыйм, сеңел. Яна кавем үзенчә яшәсен, ә мин үземчә яшим, әһе. Үлгәч кешенең җаны күккә аша диләр, минеке исән килеш андадыр, бәлкем.

Эзләмәгез җирдән, сез тапмассыз аны—
Йолдызларга табан очты шагыйрь җаны.

Елмаясыңмы, сеңел! Бигрәк гади шигырь дисеңме? Һи, гадилек—бөеклек мисалы. Елмай, елмай! Ә мин юлыма кузгалам. Үзем кебек картайган этемә шәһәрдән сөт ташыйм, тешләре коелган, ботка пешерәм. Без ә-әнә теге бистәдәге агач йортта икәүләшеп җан асрыйбыз, әһе.

Ничәдер минут эчендә дөньясын бутап ташлаганнан соң җил-җил атлап китеп барган Мингалим абзыйга ничек кычкырганын сизмәде Зөлфия!

—Йә, мин сине ишеттем ди. Шуннан ни? Бер бәхетсезнең икенче бәхетсезгә акыл сатуы ич бу. Яндырма, имеш!

Шагыйрь артына борылмыйча гына:

—Ә син ул акылны ал, бушлай бит, әһе,—диде.—Бәхетсез дисеңме? Мин шушы бәхетсезлегем белән бәхетле, сеңел.

Хатын бермәлгә аңлаешсыз халәттә калды. Бу шагыйрьме соң? Хозер Ильястыр, бәлки. Менә ул әзрәк барыр-барыр да томандай эреп югалыр кебек иде. Әтисе бервакыт: «Буранда адашкач, ап-ак киемле, ак сакаллы карт миңа авыл юлын күрсәтте дә шунда ук гаип булды. И-и, ахырдан гына башыма сукты, ул бит Хозер Ильяс иде,»—дип сөйләгән иде. Юк, бара, эреми... Димәк, адәми зат. Юк, аңа да охшамаган... «Шагыйрь йөрәктән генә тора...» диде. Ике аяклы йөрәк алайса, йөрәк... Зөлфиянең уй-ниятләрен аркылы-торкылы сызды да, сөткә китте әнә. Картиналарны бушатып, иркенләп яндырыр иде, нигәдер теләк сүрелде.

Ничек диде әле ул?

Эзләмәгез җирдән, сез тапмассыз аны,
Йолдызларга табан очты шагыйрь җаны...

Элгәре рәссамнарның остаханәләрендә язучылар еш кунак була иде. Бүген һәркем тычкан төсле үз бүлмәсендә кыштырдый. Аның ишеге дә, күңеле дә бикле... Һәркем бүтәннәргә сиздермичә эчтән генә шәхси күргәзмә турында хыяллана.

Зөлфия машинасын аркан белән сөйрәтеп кайткандай остаханәгә юналде. Шагыйрь чынлап та аның дөньясын бутап ыргытты. Ул хәзер төгәл генә кая табан карарга да белми иде. Уңда—бай «абый»ның офисы, сулда—рәсем... Беренчесендә ул житди ханым кыяфәтендә житди сүзләр сөйләп төз басып йөрер. Ә икенчесендә—һәр туар таң аңа яңадан-яңа сюрпризлар әзерләр, чөнки иҗат илендә анык кына тәртип юк, ул сиңа Аллаһ канунын үтәп

һәрберсе үз урыныннан кымшанмаган, йолдызлы, айлы күк йөзе түгел, иртәгә күнел дигән дәрьяның кай тарафларга ургылып акканын берничек тә белә алмыйсың. Алай, кысаларга кертеп яшәтә торган булгач, ижат та түгел шул инде ул. Хәер, ник Зөлфия шагыйрьдән генә күрә әле? Аның үз күнеле дә үзгәрмәскә карыша лабаса!

...Остаханәдә хатын уйлардан уелып озак утырды. Менә кемдер дыкдык басып коридордан узды. Күршесе—Василыч ахрысы. Кулындагы ачкычлары күнелле чылтырый. Димәк, аучы аудан табыш белән кайткан. Ләкин күршесе үз оясына кереп чумарга ашыкмады, сызгыра-сызгыра Зөлфиянең ишеген ачты.

—Бәрәч! Сәяхәтче! Париж—Малмыж—Мамадыш! Французлар иленнән ычкындыңмыни?!

Зөлфия авызы ерылган Василычка кушылып елмайды.

—Ачуланмасаң, кайттым әле.

—Куышыңны якладык бит, жаный. Бурычы хәттин, диләр. Мәйтәм, Париждан зур акча белән озаталар аны, алдагы еллар өчен дә түләр, мәйтәм. Йә, Илдар нишли анда? Сәламнәр күндердеме? Кемнәр белән дуслаштың?

—Дуслар күп иде. Биш йолдызлы коньяклар, вискилар, кызыл шәраблар, ак аракылар,—диде Зөлфия, көлү өянәген басалмыйча. Гел шулай бит ул: дөресен әйтсәң—ышанмыйлар, шуңа күрә ялган белән вакланунын кирәге дә юк.

—Син хәтерлисең микән, бервакыт минем башыма чәкүшкә белән суккан идең. Мин бик каты эчүгә бирелгәч. Әкрен генә суктың анысы. Вәләкин сабак булды ул миңа. Шуннан бирле курка башладым синнән. Мин генәме, хәтта Рәшит ага да синнән шүрли иде. Шкаф артына этә иде шәрабен. И-и, эчү дигәч тә, беребез дә егылып аракы чөмермәдек, шөкер! Бүген әнә көчләп авызга салсалар да капмыйбыз. Исәнлек чамалы, йөрәк вакыт санаган сәгать төсле гомеренең соңгы минутларын текелдидер бәлки, жаный.

—Парижда ничек соң?

—Диварларда коточкыч сурәтләр. Әллә жен, әллә... Күрсәң—имәнәсең.

—Париж матур диләр тагы.

—Юк, ямьсез. Син бер генә көеме?—Зөлфия сүз буасын башка якка ерды. Юкса тагын Илдар турында сораштырыр.

—Минем ал да гөл, жаный. Күргәзмә хәстәре белән чабам.

—Котлыйм! Кайда була?

—Киекледә, агач клубта, жаный. Казан сарайларында аренда бәяләре тәмам чишендерә. Соңгы чалбарымны сатыймммыни. Мәдәният министрлыгына гариза язар идем, мин—гади рәссам, атказанган исемем юк. Ә авылдашлар бушлай эләбез, Галимжан малай, диләр. Кадак, чүкеч тотып килгән мөдир. Мәйтәм, бау белән генә асыгыз, зинһар, киндерләрне тишкәләмәгез! Ник көлмисең?—диде Василыч, күзен мөлдерәтеп.—Монда жегетләр ишеткәч тә идәнгә тәгәрәде.

—Авыл жанлы рәссам син, Василыч! Мин кайчакта синнән көнләшәм. Үз мәслэгеңә тугры булдың, шәһәрләшәм дип кала тормышына тыгылсаң, үзеңне югалтыр идең, мөгаен.

Василыч учына йөткерде.

—Мине бәйләнчекләр гел сүкте, жаный. Имеш, Гайнетдинов һаман тирестә казына. Ә фәлән-фәлән рәссамнар прогресска омтыла, аларга афәрин! диделәр. Рәшит ага мәрхүм стилемне үзгәртергә, ягъни модага ияреп шәһәрләшергә маташуымны сизенгәч, пыр туздырды: «Матри, жегет, адәм баласы—табигатьнең бер кисәге, ул индустриядән туячак әле, табигыйлекне сагыначак әле, син дөньяның вакытлы ялтыравыкларына

кызыгып хаталанма,»— диде. Шуннан бирле тәнкыйтьләүче агай-энегә игътибар итмим, аларны тынласаң—егылып үл.

Монысы хак, кем иренми, акыл сатып саташтыра. Зөлфиягә дә: «Хыялыйлар мөнбәреннән төш, чын тормышны чагылдырган картиналар яса,»—дип бәйләнделәр. Һәм ул ясады. Кызык өчен сатарга кибеткә куйды. Хыялый әйберләрен алып бетерделәр, ә «чын»ы калды, чөнки кеше урамдагы тормыштан болай да туйган, аны тагын фатирына да кайтарып әләсе килми иде.

—Авылдашларың өчен күргәзмә оештыруың искиткеч бит инде, Васильич!

—Карале, жаный, кәефең шәп синең. Мактауларны да кызганмыйсың.

—Мин бүген бик сәер бер кешене очраттым, Васильич! Шагыйрь атлы үзе. Син эшеңне эшлә, мин иртәгә остаханәгә сугылырмын.—Хатын шулай диде дә, икеләнеп кенә:—Бәлки,—дип өстәде.

### 3

Зөлфия икеләнмәскә тиеш иде югыйсә. Өзәргә икән, өзәргә кирәк! Ә икеләнү күңелгә кергән саен керә. Башта ул энә күзе кадәр генә иде, соңыннан үсә-үсә зурайды, дөньяга сыймый башлады. Каяндыр шагыйрь калкып чыга... Каяндыр иҗат сагышы баса... Инде ничә ай пумала тотмаган бармак очларына хәтле сызлап әрни. Остаханәдәге бүлмәсе үзенә суыра... Икеләнү дә шайтан галәмәте микән? Бу сиңа «алыргамы, алмаскамы?» дип кибеттә күлмәк сайлау гына түгел, бу—яшәү рәвешемне үзгәртәм дип уй-ниятләреңне утын әрдәнәседәй ыспайлап өйгәч, яңадан ишү һәм берәмтекләп киредән тезгәч, тагын тузгытып ташлау. Карарлар ансат кына кабул ителми икән. Әйдә, уй уйлатма әле баш! Менә Зөлфия авылга кайта. Әтисе авылына. Балачагында кыз кайсыдыр туганнарында кунак булган иде. Кемдә?—анык кына хәтерләми. Әти-әниләре яшьләй гүргә ингәч, әтисе туган нигез дип өзгәләнмәде. Зөлфия дә, әнә, әнисе үлгәннән соң Бистәдәге йорттан суынды.

Урман артындагы Суык Чишмә авылын ул интекмичә генә эзләп тапты. Туфракка сеңдереп яуган давыллы яңгыр юлларны сазлыкка әйләндергән иде. Зөлфия машинасын авыл башында туктатып, урамнан җәяү генә атлаганда аны кәҗә сөйрәгән бер хатын куып тотты. Шунда ике арада кызык кына сөйләшү булып алды.

—Кемнәргә турыладың, канатым,—диде хатын.

—Хәзер... Исемә төшерәм,—диде Зөлфия ерак бабасының туганын хәтереннән барлап.

—Быел бездә мәкнең әсәре дә юк, канатым.

—Нинди мәкнең?

—Атаң башы хәтле мәкнең! Үткән елда да бакчамны тигезләдегез. Чәчәм дип чәчәбезмени, орлыктан тишелә, хәерсез. Элек аны кем бәла дигән, җырларда җырлыйлар иде бит, мәк чәчәген өздем ялгыш кына дип. Наркоман яшьләр, паразитлар, каян шуңа ияләштеләр. Авыл борынча эзләнәләр.

—Мин наркоман түгел, апа.

—Түгелдер шул. Ник алайса күзләрең әрле-бирле тәгәри. Кем бакчасына сикерим икән дип. Берәрсенә турылап кайтсаң, исемнәрен атар идең.

—Мөслимә әби кайсы йортта яши? Исәнме ул?

—Исән, исән, йөз яшен бөкләп кесәсенә салды да, тәгәрәп кенә йөри. Өшкерергәдер инде сиңа, канатым.

Васильич: « Авыл кешесе күп лыгырдый, чөнки аның дала кебек киң күңелендә сүзнең очы-кырые юк,»—дип мактана иде. Чынлап та шулай

икән. Хатын итәккә тагылгандай артыннан теркелдәде. Кәҗә дә тизлеген арттырсын дигәндәй сыртыннан умырып-умырып чеметте.

—Кай җирең авырта соң, канатым?

—Әйтмим әле.

—Әйтмә дә. Син артык ябык. Шыр сөяк. Мөслимә әби өшкереп, тәненә ит кундырыр, шәт. Әнә, сине көтәләр!—дип сөйләнгән кәҗәле хатын тыкрыкка борылды.

Чынлап та, ул эзләгән йортның капка төбендә таягына таянган бер карчык тора иде. Җир астыннан калыкты мәллә ул? Урам буш иде ләбаса. Тагын саташа, ахрысы. Зөлфия шикләнеп адымын әкренәйтте. Күзенә күренә микән? Әбинең килеш-килбәте бигрәк әкәмәт. Үзе җирдән әз генә калку, үзенең уч хәтле генә түгәрәк йөзендә йолдыз кебек ике күз җемелди. Ник җемелдәргә тиеш соң әле йөз яшьлек карчыкның күзләре? Алар төссез һәм нурсыз булырга тиеш түгелмени? Сәнгать кануннары буенча—әйе. Әгәр син, рәссам, бу кемсәнең сурәтен ясыйсың икән, бу канунны боза алмыйсың: җемелдәгән күзләр урынына ботак тишеге утыртасың. Шулай итмисең икән, хәсрәт тәнкыйтьче синең эшеңне ясалма дип бәяләячәк.

Карчыкка якынлашкан саен гәүдәсе кечерәеп, җиргә сеңә төсле иде. Кырмыскага әверел дә, ярыкка чум!

—Исәнмесез, Мөслимә әби?!

—Сез, сез,—дип мыгырданды кәрлә.—Кемнәр бар тагы? Мин үзем генә монда. Атаң ни атлы ие?

—Ислам, тулы исеме—Исламгали.

—Төшемдә күрдем атаңны. Ап-ак келәм җәйде. Сиңа юл сабуы икән. Без вак гәүдәле нәсел. Абзый җинел сөякле ие, азан кычкырырга манара баскычларыннан очып кына менәр ие, кошлар күек, и-и. Син дә, Исламгали кызы, эрегә китмәгәнсең монау.

—Син мине каян таныдың, Мөслимә әби?

—Атаңның кызы синдер лә. Исламгали якын итмәде безне, аулдан эзен суытты. Мин синең, тасма чорнап, чәчеңне үргән ием. Туганлык җепләре черек ие Исламгалидә. Төшкә керә алай да.

«Димәк, балачагымда әти белән шушы әбиенә кунакка кайтканбыз икән,»—дип уйлады Зөлфия.

—Уз!—диде карчык, таягы белән капкага төртеп.

Ишегалдын ямь-яшел чирәм каплаган иде. И гүзәллек! Каз үләненең бер-берсенә чорналган нәзек сабакларына төркеме белән күбәләкләр кунган. Канат ялы... Арыганнар... Күңел әлеге ят, әмма матур күренештән нечкәрде.

Их, боларны киндергә күчерәсе иде! Кара инде син, авылны яратмыйча гел Васильчтан көлеп йөргән Зөлфиягә бер дә охшамаган ул бүген.

—Әйдә! Әүвәл пакьлән,—дип, карчык аны тәбәнәк кенә бина ишегенә китерде. Бина! Монысы шәһәр татарының сүзе инде! Ә авылда аны кара мунча диләр. Васильч картиналарыннан таныш ла инде ул.

—Мин пычранмадым, мин чиста,—диде Зөлфия, карышып. Бәй, ниндидер кәтәнә анын иреген кысып маташа!

—Дога ару тәнгә генә килешер! Тәһарәтсез син! Бауда күлмәк, юынгач, шуны ки!

Буйсынды тәкәббер Зөлфия. Мунча үзе дә анын горурлыгын сындыра: ул, хуҗасы кебек үк, җирдән әз генә күтәрелгән, тураеп бассаң, баш матчага бәрелә иде. Кул сыярлык кына тәрәзәчектән сирпелгән яктылыкка күз ияләшкәч, хатын, сәерсенеп, диварга бармагын ышкыды. Абау, нинди йомшак буяу! Табигать көчәнмичә генә үз төсен чыгарган. Ләгәннәрдә тум-тулы кайнар су... Пешмә, чү! Нишләптер курку юк... Кемдер аны саклый

кебек... » Дога ару тәнгә генә килешер...» Ул бик-бик каралды микәнни? Кара анын жанына да йокты микән?

Зөлфия карчык кушканнарны төгәл башкарып, озын ак күлмәк киде. Анын хәзер үзенә дә кызык иде. Бу сәяхәтнең ахыры ни белән тәмамланыр икән? Күнел буа кебек тулган, суын ерып агызыр өчен Алыплар көче дә житмәс иде, ә ул ябык, кәтәнә карчыкка сыена, анардан ярдәм өметләнә. Үги анасынын котырыгы белән юкны бушка аудара! Имеш әбекәй ана ерак туганы да икән: атасынын бабасынын сеңелесе! Нишләптер Зөлфия беркайчан да нәсел-нәсәбен барламады. Гүя аны Адәм ата белән Хәва ана турыдан-туры үзләре тудырган иде. Ә бит ул тарих китапларыннан атаклы рәссамнарның жиде буынына хәтле жентекләп өйрәнде, хыялы белән алар яшәгән гасырларны урады, бу даһиларның ни-нәрсә ашаганы, ни-нәрсә кигәне бер могжиза сыман кабул ителгән иде. Һәм ул, һич тартынмыйча шулай тиеш санап, үзен аларның дәвамы кебек тойды. Талант жебе шул бөекләрдән үк тартыла дип эчтән генә масая иде. Хәтта Васильч иске машинасына әйберләрен төяп: «Ял көннәренә авылга киттем әле»,—дип, мактанганда Зөлфия «мескен» дип анын артыннан көлемсерәп кала иде. Мескен! Чабаталы нәсел баласы шул! Читәненә тартылмыйча, Парижларга бармас инде! Зөлфия кебек цивилизация казанында кайнамас! Ә ник ул бүген Эйфель манаралары биеклегеннән генә дөньяны күзләр өчен гүзәллек иленә очмый, ник караңгы авылда, кара мунчада юынып, басу капкасыннан гайре берни күрмәгән шыр надан карчык йортында аңгыраеп йөри?! Баксан, анын карт бабасы да гап-гади мөәзин икән... Менә сиңа мә! «Мин-минлек» адәм баласын баскыч тездерә-тездерә болытларга кадәр менгезә, ә асылда исә ул үз буеннан ярты сүәм дә күтәрелә алмаган була...

Карчык сап-сары итеп юылган баскычта утыра иде.

—Йә, хәзер ни кылмак инде син, олан?—диде ул, Зөлфияне күздән кичереп.

Бу: «Сиңа нәрсә булды?» дигән сорауның дәвамы иде. Шуны ишетер өчен ул кырык биш чакрым килгән микән ? Хак, юкны бушка аудара!

—Утлы су белән эченә шайтан оялаган! Һи, сез бисмилласызлар. Яндырыгыз әүвәле ул суны, төтенсез генә зәнгәрләнеп яна. Иблис кавеменә шул гына кирәк, аңа ут якын батчи, ут. Куркуың шуннан гына, олан. Өшкерүче яшь ир заты булсын. Аларның сулышы киң, минеке батчи, тарая. Зәхмәтенне жиналмам, Исламгали кызы! «Юныс» сурәсе килешер сиңа, «Та-ха» сурәсенең шифасы тияр. Догаларда сихәт хәттин күп.

—Ник мунчага кудың соң үзең укымагач,—диде Зөлфия, вакытын жәлләп. Әйе, жәлләп! Менә монысы үзенә дә гажәп иде. Кая ашыга соң ул? Аны берәрсе тилмереп көтәме? Яисә остаханәдә кичектергесез эшләре сулкылдап ятамы? Әнә, алда күпме максатсыз, буш көннәр тезелгән.

—Пакьләнмичә мәсжедкә кырык адым якынаймагыз дияр иде мулла абзый.—Кояш нурын «урлаган» карчыкның жемелдәвек күзләре ана шелтә белән карый иде.—Ике жәпле адәм, батчи. Монысы да шайтан жинүе. Аллаһы Тәгалә адәмне бер жан илә бер рух белән яралткан, бер иман биргән. Нәмә сез «мин» дә тагын «мин» булмыш дия-дия, уң ягыгыз белән фәрештәләрне, сул ягыгыз белән иблисне сәламлисез.

Карчык буталчык сөйләсә дә, Зөлфия аңлады: ана төрттерәләр, ана... Ул бүленде ләбаса. Диктатор хатын жанына үрмәләде. Үзенең нияте дә изге кебек иде: яңа тормыш башларга өнди! Ә анын ижаты—ялгыз утрау. Хисләрдән генә хасил булган чишмә-күлләрендә көмеш су ага, урманнарында сандугачлар гына сайрый, жәяүле сукмакларына тузан кунмый, анда хөсетлек, мәкер, ялган юк, анда чисталык, аклык, гаделлек хөкем сөрә. Мөгаен, фәрештәләр вакыт-вакыт шул утрауга төшәдер. Нишләргә соң, ә? Кайсысын сайларга? Диктатор Зөлфия жәмгыяте ул бүгенге иртә, бүгенге кич, бүгенге көн...

Караклар, алдакчылар, ялагайлар, кансызлар рәхәт чиккән дөнья белән бик куркыныч зат—шайтан идарә итә. Ул күзгә күренми, ул бик хәйләкәр. Иманлы кешенең эченә оялап, аны юлдан яздыра, моның өчен башта аны икегә аера һәм үз өлешен көчлерәк ясап, калган ягын зәгыйфьләндерә. Ә мескеннәрне бармак белән дә сыталар. Әбиең шуңа ишарәли. Йә, Зөлфия, сиңа Эйфель манарасыннан шулай, өч-дүрт җөмлә белән фаҗигане аңлатканнары бармы? Надан карчык дип кимсетмә син.

—Әйдә!

Җинел сөякле әби җәлт кенә урыныннан купты. Әйтерсең, ул баскычка кунган бала кош иде, пыр итте дә урамга очты. Зөлфия озын күлмәк итәкләренә абына язып аңа иярде. Койма кырыеннан барып ниндидер хәрабә янына туктадылар. Карчык җиргә тезләнде һәм эре тарак тешенә охшаган нәзек бармаклары белән мүкләнгән ташларны сыйпарга кереште. Хәрабәне чүп үләне күмгән иде.

—Нәрсә бу?—диде хатын.

Карчык ишетерлек хәлдә түгел, аның нәзек иреннәре генә селкенә, ул эченнән генә пышылдап нәрсәнедер кабатлый иде. Аннары кортка кулын кушырып дога кылды, аңардан күрмәк Зөлфия дә битен сыпырды.

—Иске мәсҗед нигезе бу, олан. Асты таштан, өсте бурадан ие. И-и, авыл күрке ие. Осталар аның һәр тәрәзә капкачын бизәк уеп ясады. Житмеш жиде манара баскычының һәркаюсы «бисмилла» белән сугарылган ие. Мөәзин абзыкаемның тавышы моңлы ие, батчи. Ул көйләп укыганда аул этләре өрмәс, ат пошкырмас, мәче мияуламас, урындагы хасталар савыгып аякланыр ие. Зобанилар манарасын кисте шул, көмеш аен балта түтәсе белән кыйнап яньчеде. Инде гомерем очланадыр, иншалла. Мина да «мәңгелек йорт»ка күчәргә житәдер. Бер генә баксам кана терек чагымда шушы мәсҗедкә! Үкенечсез генә үләр ием. Ярамаган әйбер сорасам, гафу кыл, и кодрәтле Аллаһым!

Кинәт офык чите агарды һәм каяндыр еракган карчык искәргән мәчет сурәте саркылып чыкты. Зөлфия бармаклары белән йөзен яшерде. Кайта, авыруы тагын кайта! Инде төнге фатирында гына түгел, аяз көнне—урамда да тилертә. Шайтан кулы уйныймы, әллә табиблар галлюцинация дип атаган чирме бу? Хәер, нинди аермасы бар аның. Боларның икесе дә саташуга кертә.

Хатын карчык янәшәсенә тезләнде. Икенче тапкыр караганда офык чип-чиста иде. Нинди саташу, нинди чир ди! Бәгырьне актарып, йөрәкне канатып иҗат кайта, иҗат! Билгесезлектән калыккан мәчет аның хыялында гәүдәләнде ләбаса! Кичектермә, тот та яса! Кем кулыңны бәйләде соң, рәссам? Кем?!

Карчык сыктый, ул да аңа кушылып елый... Ник тиктомалдан күңел нечкәрде әле? Эйфель манарасы куенында еласа, француз җиле яшен тиз киптерер иде, ә монда ул гади авылда, гап-гади карчык ышыгында, күз яшьләре туп-туры җанга коела... Аның ерак бабасы нинди кеше иде икән соң? Нишләп буыннарны тоташтырган нәсел тамыры нәкъ менә Зөлфиягә җиткәч кенә өзелгән?

—Минем... Минем ерак мөәзин бабам ни исемле иде, әбекәй?

—Аллаh колы Камил ие, олан.

—Бабай турында сөйлә әле, әбекәй.

—Ни белмәк син миннән, олан?

—Имеш ул япа-ялан кырда гаип булган ди.

—Эһе, Ходайның кодрәте киң, ниләр булмас дөнҗада. Абзыкайны атарга әмер биреп, мылтыклы милсәнир Гыйздуллага тапшыралар. Гыйздулланың атасы имансыз адәм иде, мәчет манарасын шул бәндә аударды. Соңынтын кулы корыды моның. Угланы да атасыннан азган ие. Апчыга кырга абзыйны милсәнир, кабер казыта... Безгә шул гына мәгълүм, олан. Соңынтын Гыйздулла авылга акырып чаба. Мөәзин намаз укыганда югалды дип,

болыт суырды ахыры дип. Шуннан җүләрләнде жегет. Шуннан нәселенә бәрде җүләрлек чире бу кавемнең, туган бер бала анкыш-минкеш. Абзыкай каргышы төшкән, димәкләр. Тик Аллаһ хөкемдар икәнен онытталар. Бәндәгә тиеш җәзасын бер Раббыбыз гына тәгаенли, олан.

Карчык ана табан янтайды.

—Олан, серем бар ие,—диде ул, пышылдап. Әйтерсең, ташлар колагын сагайтып аларны тынлый, ә бил тиңентен үскән әрсез алабуталар, орлык белән бергә, авылга чәчә иде.

—Мин... Мин сер саклый беләм, әбекәй.

—Шул, олан. Камунислар заманында безнең авылга чит кешеләр килде. Фин татарлары, имештер. Таза-таза биш ир, шуларның берсе буйга тәбәнәк, гәүдәгә—нәзек. Тач абзый мона. Җимерек мәчет нигезе тирәли өч әйләнде. Миңа сүз катмак итенә дә, район кешесе арага кысыла. Соңынтын яшь муллабыз: «Чит мәмләкәт кешеләрен безнең белән аралаштырмыйлар, Мөслиматтәй, сәвитне яманларбыз дип өркәләр,»—диде. Абзый, мәйтәм, дога белән милсәнир Гыйздулланы оеткандыр. Син олан, Алла хакына, серемне тишмәсәнә. Финнәргә качкандыр абзый, өйләнгәндер. Белгертмәгәндер исәнлеген, безне сәвит дошман туганы дип өтермәгә ябар, дигәндер. Катыны Зәмзәмия үлгәнче көтте. Оланы да көтте атасын. Теге фин ире тәбәнәк ие, нәзек ие. Билләһи газыйм, абзый васыять әйткәндер, туган аулыма сәлам биреп үт, мәчеткә дога ирештер, дипләр. Мин гел күзлим моны, сәвитләр сизмәсен, мәйтәм. Ике-өч вак таш кисәге тыкты кесәсенә, кулъяулыгына төреп. Абзый каберенә алгандыр, мәйтәм.

—Бүген бу сереңне ачсаң да куркыныч түгел, әби. Коммунистлар фиркасе таралды бит инде.

—Һәр чор үзенчә куркыныч! Аждаһаның җиде башы, кискән саен үсә, Исламгали кызы.

...Карчыктан ул көчкә аерылды. Җемелдәвек күзләр сихерләгәндәй җибәрми иде. Киемен алмаштырырга да онытты Зөлфия. Ак күлмәк салкыннан бөрешкән йөрәген жылыта иде. Үги анасы мәчеттә идән юа иде. Гомере буе заводта чиләнгән кортка ял тансыкламый микәнни?

—Әстәгъфирулла!—диде Раушания апа, аны күргәч.—Синме соң, кызым?

—Мин.

—Танымыйча фирештә диярсең үзеңне. Ник болай киендең?

—Киендерделәр.Чиләгең авыр, суың салкын, бармакларың күшеккән. Акчага да тилмермисең инде...

—Әй, кызым, акчадамыни эш. Савап өчен юам, бер тиенсезгә, Алла боерса. Миндә йомышың бар мәллә?

Зөлфия мәчеттәге рәхәт тынлыкка шаккатты. Калын диварлар артында гүелдәгән дөньяның сынар авазы да ишетелми. Авылдан ук җанына сарылып кайткан илаһи сурәтнең ауган манарасы белән чүкелгән ае гына иңрәп колакны чыңлата. Нишләп мәчет фаҗигасе белән бабай язмышы аны бу хәтле тетрәндерде икән? Моңа охшаш хәлләрне элек тә белә иде. Үзенә кагылгангадыр, мөгаен.

—Йомышмы?—Хис өермәсендә кайнаган Зөлфия айныды.—Мине өшкертергә иде... «Юныс» сүрәсе, «Та-ха» сүрәсе... Булыш миңа, әни!

## 4

Юк, ычкындырмый! Йөрәк—акылны биләп, буйсындырган саен буйсындыра бара. Ул аны бик җиңәргә тырышты: «бай абыйсы»ның офисына эшкә урнашырга китте, әмма ишек төбеннән кире борылды. Сурәт шымчы кебек эзәрлекли иде... Җаны да сатлык бит аның: газаплы

һәм татлы иҗат мизгелләрен көтеп сулкылдый... Ичмасам, ул төн карасы белән каплансын иде. Һичьюгы вакытлыча күз алдыннан сөртелер иде. Ләкин аның кодрәтле көченә каршы куярлык берни дә юк! Әнә манара очы күк гөмбәзенә тигән, орынып-кагылып узган болытлар аен ялтыратып бетергән... Мөәзин бабасы азан әйтә... Дога көмеш нурга әверелеп, авыл өстенә ява...

—Исәнме, сеңел?!—Абау, каенлыкта агачлар җанланды мәллә? «Сенел» дип аңа бары тик шагыйрь генә эндәшә иде.—Унга кара, унга. Кушкаен кочагында мин. Исәрләндем, ахры, ботакка кунып сайрамакчы идем дә, тавышым карлыккан.

—Шагыйрьләрнең күңеле җырлый диләр.

—Нинди уй-ният белән киләсең, сеңел?

—Борчылма, көн тәртибендә яндыру ише нәрсәләр каралмаган. Үземнеке куәтле әле. Бер сурәт белән саташам. И Алла, ди йөз яшьлек әби сүз саен, мин дә хәзер «И Алла» дим. Бүтән иҗатка багынмам дигәч кенә ник җәзалыйсың, дим.

—Шыпырт!—диде шагыйрь, бармагын иренәнә тидереп.—Яфраклар арасында пар сандугач пырхылдый! Үткән ел юк иде алар, ә быел килгәннәр. Җан тарта, димәк. Син дә кайт үз асылыңа. Ал киндер, ал буяу, сеңел.

«Ха, ишетәсеңме, диктатор Зөлфия, сиңа беркем дә теләктәш түгел!»

—Йә, шуннан ни, шагыйрь абый? Минем картиналарым кемгә кирәк? Син үзең дә безгә бу каты бәгырьле җәмгыятьтә яшәве чамасыз авыр дигән идең.

—Без барыбер яшик, сеңел. Кайчакта безне пәйгамбәрләргә тиңлиләр. Ә алар бөтен дәверләрдә дә кыен ашаган. Син Муса пәйгамбәрне кара. Кырык ел буе эссе чүлдән халкын Аллаһ тәгаенләгән җиргә табан әйдәгән ул. Аны тиргәгәннәр, гаепләгәннәр, сатканнар, ә Муса ниятеннән чигенмәгән: җәннәт почмагына китереп җиткергән кавемен. Әмма да ләкин үзенә генә шул җиргә аяк басарга насыйп итмәгән Аллаһ.

—Ник, шагыйрь?

—Үлгән чөнки. Менә без дә каләмне йөрәк канына мана-мана язабыз, янәсе милләтне рухи караңгылыктан, мәнсезлектән, динсезлектән яктылыкка табан сөйрибез һәм шунын әҗерен дә күрмичә җан тәслим кылабыз. Пәйгамбәрлек вазифасы Аллаһның иң зур әманәте. Ник ул миңа йөкләтелгән дип зарлану—гөнаһ, сеңел.

—Син сүздән матур такыя үрәсең, шагыйрь.

—Тукта, бер сурәт белән саташам дигән идең.

—Әллә инде шунда... Җүләрлек ахрысы инде. Мин ничәмә-ничә ел күргәзмә залының иң түрдәге диварына бер картина элдем. Хыялымда.—Зөлфия сусыл яфракларны сыдырып, учында изде. Шәфкатьсез! Бичара каеннарның чәчен йолкый! Учы ямь-яшел... Әнә юлдашы бу гамәлен ошатмыйча каш җыерды.—Әйе, нибарысы хыялымда...

—Өзмәсәнә, сеңел! Рәнҗетмә каенны!

—... хыялымда гына, әйе. Мөгаен, шушыдыр дип тотынам да алданам, тотынам да алданам. Анысы да түгел, монысы да түгел икән. Аңлыйсыңмы, шагыйрь?! Яфрак өчен гафу ит, яме ?

—Камиллекнең чиге юк диләр. Һәм син ул чикне эзләмә дә. Өч гомер яшәп, йөзәрләгән әсәр әмәлләсәк тә без аңа ирешмәячәкбез. Бер Аллаһны гына бөек иҗатчы дип таныйк без. Аның тарафыннан бар ителгәннәр генә—җанлымы ул, җансызмы, һич кимчелексез. Кодрәт иясеннән сирәк кешегә талант очкыны чәчридер. Бүләк инде ул. Язам дип кенә—язучы, ясыйм дип кенә рәссам булмыйсың.

—Миңа нишләргә соң шагыйрь?

—Бәй, бүләгеннән разый бул. Ник һаман минем белән гәпләшеп вакытны үтерәсен? Эшкә тотын! Сина бер зур үтенечем бар: күргәзмәнә чакыр! Хыялындагы сурәткә минем дә багасым килә. Бистәдә иң бәләкәй йорт—шагыйрь абыеңныкы, «Китап Мингалим» дисән, эте-бете белә.

Җанда укмашкан соры болытларны куып таратыр өчен кайчакта көчле җил дә кирәкми, «өф» итеп өргән бер җылы сулыш та җитә икән. Шагыйрь сулышы шундый иде. Күнел күге аязып, кояш елмайды. Үе белән хыял капкасына табан чапты Зөлфия. Ара ерак та, якын да иде. Кемгәдер бирелгән вәгъдәләр, кемгәдер тиеш бурычлар аякка урала. Диана белән араны матур гына өзәсе иде. Ул дөнья сасытырга бик оста, «миннән акча суырды» дип, саесканнарны көнләштереп колактан колакка хәбәр очыртыр. Аның салонында Зөлфиянен таныш-белешләре дә «яшәрә.»

...Күркә сыман кызылдан киенгән Диана күзен акайтып аңа ыргылды.

—Җир йотты бугай сине! Ни өендә, ни остаханәндә юк!

—Зинһар, кызма, Диана. Мин синен яшь сөяркәнне ясый алмыйм!

—И кыланчык! Бәянне күтәрәсен, чистый. Ясама-а,—диде «күркә.»—Бигайбә! Сина бер сюрприз әзерләдем. Ни ул дип сора!

—Сорамыйм,—диде салон ишеге төбеннән ары узмаган Зөлфия, әмма Диана аны беләгеннән тотып эчкә тартты.

—Аяк өсте генә саубуллаша, хәйләкәр! Утыр, ату шапылдап егыласын.

Кибән хәтле таза гәүдәле хатынның җиле дә аудара иде, ул ирексездән фойедагы йомшак кәнәфигә утырды.

—Парижднан Илдар кайтты.

—Нәрсә?!

—Илдарын Казанда, исәр. Сине таптыра.

«Ник аны таптыра, ник?!»

—Марс бәгыремнең чыраен мин аңардан ясаттырам. Кемнеке?—Париж рәссамыныкы дисеннәр! Илдар кире какмады. Тәмам изгән-баскан француз инде үзе! Килеш-килбәте белән дим. Чүпрәсе татарныкы, конечно, шулай булмаса сине сагынып кайтмас иде. Туры сүземә үпкәләмә, Зуля. Урманга утын ташымыйлар, анда анын муенына унлаган хатын асылыныр иде. Их, башсыз да бит безнең ирләр!

Илдар аны сагынып кайткан... Берәүсе шатлыгыннан уңлы-сыллы сикерер иде... Егет аны иң авыр көннәрдә ташлады. Әгәр ул «тотын» дип чәнти бармагын гына сузса да, Зөлфия хәсрәт күленә батмас иде. Онытылдымы Илдар? О, юк! Аның шунысы көйдерә—онытылмады...

Ә Илдар, чынлап та, чатыр чабып иске дустын эзли булып чыкты. Кәгазь кисәгенә язып остаханә ишегенә кыстырган. Озын сүзнен кыскасы, кичке сәгать биштә Бауман урамы башындагы сәгать янында түземсезләнеп көтә егет. Ә моңарчы ул нишләгән?! Ник минутларны саный-саный вакытны ашыктырмаган?! «Барма!» ди акыл, чөнки хуҗасы өчен рәнҗегән. «Бар!» ди йөрәк, чөнки һаман ярата. Мәхәббәт дигәндә хатын-кызның җүләрлеге чиктән аша икән.

Зөлфия акыл белән йөрәкне озак сугыштырды. Ахырдан йөрәк җинде. «Француз» чабышкы аты кебек пырдымсызланып сәгать төбендә таптана, әле уңга, әле сулга борылып карый иде.

Хатын кибет чатына посып аны күзәтте. Их, берни булмагандай кочагына атыласы иде! Тик менә монысында йөрәк көчсез, акыл йөгәнне нык урап тота. Чү, дөнья агара , урамнан кешеләр югала... Алар бөтен шәһәрдә икәүдән-икәү генә, имеш. Һай, гашыйк жан халәте лә бу! Ярату үлмәгән икән, үлмәгән. Зөлфия, качышлы уйнагандай, өч хатын артыннан ышыкланып килде дә, Илдарның каршысына чыгып басты. Элеккеге гадәт белән егет кочакламакчы иде, ләкин хатын ике арага кулын куеп өлгерде.

—Нихәл, Илдар?

«Хәл... әл... әл...» Колакта кайтаваз зеңләде. «Әл... әл...» Ник дулкынланасың инде, ташлаган яр?! Телен йоткан Илдар ишарә белән әллә кая гына күрсәтте. Чәйханәгә керәсе иттеме, яшьләр хихылдашкан тимер эскәмиягә төрттеме. Бу очрашу аларның икесен дә хәтәр генә каушаткан иде. Сыра чөмергән егетләр утыргычны бушаткан иде, Зөлфия сүзсез генә шунда елышты.

—Бәлки, кафеда чәйләрбез. Анда аулак.

—Һава сулыйк.

Бая югалган кешеләр кинәт кенә күбәйде, узган-барганның һәммәсе дә аларга чекерәя кебек иде. Аяк астында өч күгәрчен нәрсәдер чүпли, югыйсә таш асфальтта җим дә юк...

—Алайса, кичкырын икебез өчен генә мәҗлес оештырырбыз,—диде Илдар, гаебен югандай.

—Озаккамы?

—Карарбыз әле. Өч-дүрт көн тоткарланырмын, ахрысы.

—Диананың яшь сөяркәсен ясыйсың икән. Ана ике ай кирәк.

—Хи, ике ай! Күз йомып, бер сәгатьтә сызгалап атам мин аны. Кем сон ул хәчтерүш! Хатын-кыз кесәсен капшаган имгәк шунда.

—Халтура эшләдем дип ахырдан вөҗданың газапламас микән?

—Әйтәм бит, кешесе шуңа гына лаек. Минем башка нәрсәгә вөҗданым борчый. Сине уйлап.

—Мине уйлап?!—Зөлфия гаҗәпләнгән кыланды. Югыйсә ул бөтен әрнүләрен янгыр итеп шушы ирнең өстенә яудырырга тиеш иде.—Нишләгән әле син миңа?

—Хушлашмыйча да киттем. Качкан төсле.

«Ә син качмадыңмыни, Илдар? Зөлфия синең өчен укылган китап иде».

—Парижда кызыкмы, Илдар?

—Кызык. Иҗат өчен мөмкинлекләр зур. Анда талант хуҗа, блат дигәнең Рәсәй чигендә ботын сындырган.

—Хәзер бездә дә ирек...

—Ирек бар анысы, тик мәгънәсе юк.

Зөлфия юри үртәште:

—Кадеребезне дә беләләр.

—Шулайдыр. Мәрхүм рәссамнарның «алтын фонд»ка кирәклек картиналары берлекнең юеш подвалында чери. Кая инде үлгәннәргә ихтирам, без—терелләр дә бер-беребезне хөрмәт итмибез.

Сәләмә киемнәргә төренгән ир чүпрәк букчасыннан ипи алып күгәрченнәргә ваклап сипте. Сукбай халкы юмарт, ризык тапса—кош-корт, эт-мәче белән бүлешә.

—Рейсыңны әйттеләр дә... Самолетың артыннан карап калдым...

Йөрәккә рәнҗү-үпкә булып каткан ташны тамчы барыбер тишә!

—Кичер, җаным!—Илдар озын гәүдәсен урталай бөкләп, башын анын итәгенә куйды.—Синдә төшенкелек башлангач, мине дә үзең белән упкынга өстерәрсен дип курыктым. Көчсез инде без ирләр, ә!

—Тор, кешеләр сәерсенеп үтәләр.

—Ә син бездә ирек дисең.

Тезләрендә егетнең җылысы калды. Йә, гафу ит инде, Зөлфия. Әгәр син илаһи картина дөньясына ак килеш, пакь килеш керәм дисән, тотма күңелеңдә кара ачу шәүләсе!

—Без китәбез, җаным. Бу юлысы икәү. Билетлар алынган,—диде Илдар.

—Кая китәбез?

—Парижга, жаным. Мин сина кич белән барысын да тәфсилләп сөйләрмен. Хәзер мин тиз генә Лаештагы апанын хәлен белеп кайтам. Тугызлар тирәсендә синең фатирда очрашабыз. Кайсы ресторанда Казан белән саубуллашабыз, үзең сайла, яме!

Зөлфия тыны бетеп пышылдады:

—Ярар...

Жиргә табаны әллә орынды, әллә юк. Көтелмәгән тәкъдим анын йөрәген жилкеткән иде. Йа Аллам! Илдар белән Парижга оча! Моннан сон алар гел бергә яшәр, гел бергә... Чын бәхет шушы түгелмени?!

Тукталышта ана кемдер:

—Апа,—диде. Баш түбәсенә яшел кәләпүш чәпәгән теләнче малай икән. Ул үз итеп Зөлфиянен беләгенә сарылды.—Апа, мин сине ерактан ук таныдым. Әни терелде, апа. Синен исемен ничек, апа?

—Зөлфия. Ә синеке?

—Илһам. Мин, ант мәгәр, синен акчана дару алдым, апа.

—Ышанам, балакай. Бәлки, үскәч пирамидаларны үзебездә генә төзерсен, ә?

Малайнын вак-вак сипкелле көләч йөзе сүрәнләнде, ул борынын мыш-мыш тартып:

—Юу-ук, апа, бездә аларны җимерәләр шул,—диде.

Нәрсә дип әйтергә дә аптырап сүз эзләгәндә урам аркылы мәчет манарасыннан азан кычкырдылар.

—Селкенмә, тукта, апа! Мулла абый мондый чакта юлыгыздан киселеп торыгыз, дия.

Ул да Илһам кебек башын аска иде. Йөрәк чемер-чемер итә... Анын ихтыярыннан тыш янакларын чылатып күздән яшь ага... Зөлфия элек тә азан укыганнарын ишетә иде, ләкин ана битараф иде. Эчен-тышын бергә сыктаткан нинди кодрәтле моң соң бу?! Ул ерактан ук урап килә... Әйтерсен, вакыт елларны сыза-сыза кирегә чигенде дә, Камил бабасынын тавышын ишеттерде. Ә ул Парижга җыена... Дөньяда йөзәрләгән хыянәтләр бар. Аларның кайберләре онытыла, ә кайберләренә мәнге кичерү юк. Менә рәссам хатын да киндергә күчерәсе хыялына хыянәт итә. Мөәзин оныгынын баласына гафу булыр микән? Үзең сайлаган илләргә ялгызын гына ашык инде, Илдар!

## 5

Сары суккан каен яфраклары очып арган күбәләкләр төсле салмак кына тирбәлеп жиргә куна. Шагыйрь йөргән бормалы-бормалы кәжә сукмагы ерактан ук сагыш булып сузылып килә—килә дә, бөгәрләнеп жанга кереп ята. Әлләни аралашмадылар да... Ә бер-берсе белән гомер буе танышлар кебек. Кайда соң ул, шагыйрь? Өч тапкыр авылга барды Зөлфия. Хуҗанын капкасы ачык, ә өй ишеге бикле, карт эте генә һау-һау өреп тар ишегалдын саклый иде. Бу юлысы тамагы карлыктымы, ач идеме, ул өрүеннән тиз туктады һәм калтыраган аякларын бөкләп, такталар өстенә җәелде. Урамнан бала житәкләгән күрше хатыны узып бара иде, ул йорт тирәсендә еш күренә башлаган ят кешедән шикләнеп:

—Син кем?—диде.

—Беркем дә түгел.

—Сез барыгыз да беркем дә түгел дисез, ә үзегез һаман иснәнәсез. Ач этен ашатыгыз ичмасам. Мин ятим үстерәм, ипи валчыгы да исәптә. Аңа хуҗасы сөт кенә эчертә иде.

Зөлфия көн саен эткә сөт китерде. Акбай хатынны шул хәтле якын итте ки, хәле булмаса да, күрешү шатлыгын белгертеп, уңлы-суллы койрык болгады. Ә бергәләшеп шатланырга хуҗа гына юк иде. Калмады хастаханә, калмады

милиция бүлекчәләре—шагыйрь табылмады. Бер генә нәрсә тынычландыра: каядыр качып шигырь язадыр, бәлки күнелендә гаҗәеп поэма тугандыр, иҗатка чумсаң бөтенесе дә онытыла, хәтта үзеңнең исемең дә! Әнә бит, Зөлфия ике ай авылда хыялы белән яшәде. Һич кенә дә ычкына алмады, мең җепкә чолганды, аның каравы, җимерелгән мәчет кабат торгызылды. Әлегә киндердә, билгеле. Йөз яшьлек карчыкның хәтере тутыкмаган иде, ул: «Хәрәмләшмә, дөрес яса,»—дип җелекне суырды. Алтынсу рам белән каймаланган картина башка эшләре белән беррәттән күргәзмәгә куелыр. Нәкъ хыялдагыча! Анда хәтле «чакыр» дип инәлгән шагыйрьне ничек тә табасы иде. Иң гадел бәяне ул әйтәчәк, ялагайланмыйча, куштанланмыйча, ялган кушмыйча. Зөлфия өчен иң сөенгән кеше дә шагыйрь булачак, чөнки Ходай аңа матурлыкны күрерлек могҗизаи күнел күзләре биргән...

Соңгы килүендә күрше хатыны бик ачылып сөйләште.

—Әй интегәсең дә, чибәркәем. Кая олактың икән син, Мингалим?! Дачафәләндә микән әллә? Аның «Сандугач бакчасы»нда чиертергә яраткан дусты бар иде, ул бәндә эчә дә, икешәр атна махмырдан чирли, Мингалим инде аны тәрбияли, терелтә. Син шул тирәләрне караштыр әле, чибәркәем.

Җирдә казынуны өнәмәгәнгә күрә Зөлфия бакчалар белән мавыкмый иде. Бу исем, мөгаен, аның колагына чалынгандыр, әмма ул аңа илтифат итмәгәндер. Ә Васильич бакчадан хәбәрдар иде.

—«Сандугач бакчасы»мы? Совет заманында ул иҗат йорты сымаграк урын иде. Тиеннәр генә түләп алган кечкенә-кечкенә агач өйләр, чәчәкле аллеялар, мәһабәт наратлар, балыклы һәм бакалы күл... Барлык хыялыйларны—төрле жанрда язган әдипләрне берләштергән җәннәт, валлаһи! Аннары рухы бай, үзләре ярлы хыялыйларны куып, рухы хәерче, ә үзләре бай башкисәрләр анда ташпулатлар тергезде. Нәрсә, син дә шуннан бер кисәк җир умырырга исәпләдеңме? Ха-ха, картиналарыңны сатып кына баермын димә шул. Ну, кызкай, шәп күргәзмә оештырып йөрисең икән син! Көнләшәм, валлаһи!

—Бакчага юлны өйрәт!—диде Зөлфия. Ул инде күргәзмә турында уйламас дәрәҗәгә җиткән, шатлыгын шагыйрь хәсрәте кысрыклаган иде.

Васильич чакрымнарны билгеләп маршрут сызды.

Ләкин «Сандугач бакчасы»ның биек тимер рәшәткәләре аша узу сират күперен кичүгә охшап тора иде. Биленә кораллар аскан яшел киемле егет аңа:

—Рәиснең рөхсәтеннән башка чит кешеләр кертелми,—диде.

Рәис дигәнең сакчыдан да дорфарак иде. Зөлфиянең гозерен колак читенә дә элмәде.

—Безнең бакчада бомжлар яшәми, гражданка,—диде.

Ул инде өметен өзеп, машинасына утырганда гына каравыл өеннән бер хатын чыкты.

—Кем, син, наным, Мингалим югалды мәллә, Ходаем?

—Мәрхәбә апа, тыгылма, идәнеңне юууыңны бел!—дип, бугаз ертып, рәис китеп барды. Мәрхәбә дә усал иде, чаш иттереп капканың тимер келәсен шудырды.

—Юармын, өйрәтмәгез! Мингалимне эзлисеңме, наным? Без бит аның белән кавышып алты ай яшәдек. Әнә-ә, куаклык эчендәге иске йортта. Икенче катында. Яраттым, яраттым да соң мин аны, наным. Әйдә, куышыбызны кара. Әй, син, сакчы малай, эт кебек ырылдамасана, керт кешене! Әлсә идәнеңне юмыйм. Мин, наным, мондагы байбәтчәләрнең шакшысын чистартам. Биш былтыр шушы бакчада кизү идем. Бернәрсәгә дә тимиләр иде. Язучыларның кәгазь-каләмнән битәр урлатырлык малы юк иде. Боларныкы гына танк белән сакларлык.

Ярым ишелгән йортнын икенче каты чорманы хәтерләтә иде. Түбәсендә—буй-буй ярыклар, нуешләрдә—пәрәвез оялары...

—Мингалим абзан төннәрен тәрәзәдән карап шигырь яза иде, наным. Өстәл лампасы яктысында. И-и, гомер. Югалмагандыр ла ул, ә, наным? Юкмы? Һаман да гыйшык турында поэмалар сырлыймы? Үзенә тишмә берүк, яме? Болай гына соравым ла. Безнен яшьтә дә мәхәббәт янарталар, тик ул шигырьгә өйләнгән инде. Холкы кытыршырак иде анын. Жайсызрак кеше иде Мингалим. Исем-бүләкләргә хирыс, каләмдәшләренә, жый, жый, теге дөньяда, бәлкем, иманлымы син дип төпченмәсләр, югары исемлеме, дәрәжәлеме диярләр дип чеметтерә иде.

Зөлфия терсәге белән буявы кыршылган тузанлы тәрәзә төбенә таянып, янакларын учлады. Наратлар, ни буй үстереп тә, куып житәлмаган төпсез күк йөзендә тынлык. Менә карангылык инәр... Жиһан шәмдәлләрен кабызыр, и Алла...

> Эзләмәгез жирдән, сез тапмассыз аны,
> Йолдызларга табан очты шагыйрь жаны...

... Икенче көнне ул тагын Мингалимнәр авылына юнәлде. Нигәдер күнел шомлана иде. Тикмәгә түгел икән. Тәбәнәк өенен капкалары шар ачык, ишегалдында иске жиһазлар, кием-салым, китаплар, кәгазьләр ауный иде. Мондый ямьсез күренешкә тап булса да, башта Зөлфия сөенде: шагыйрь исән-имин! Тик нишләп ул әйберләренә үчеккән икән? Кытыршы холкына дуамаллык та өстәлә микәнни?

Баласын чаптыра-чаптыра күрше хатыны килде.

—Әй, чибәркәем, кичә монда мәхшәр купты! Мингалимнен ишеген каерып, барлык әйберләрен урамга ташладылар. Шикләнгән идем аны, элек тә... Алар күптән иснәнә иде.

—Кемнәр «алар?»

—Туганнары, имеш. Нинди туган ди?! Мингалим ятим иде. Жиренә ымсындылар, жиренә. Ялгызакларны йомдырып жир сата бүген бандитлар. «Нишлисез?» дип, койма аша гына кычкырган идем, берсе: «Авызынны яп, күзенне капла, ату атам,»—дип янады. Зинһар, аяк ал, чибәркәем моннан!

Зөлфиянен тамак төбенә таш бөялде.

—Ак... Акбай кайда, апа?

—Куркып оясына поскандыр.

Ул кулын оя авызына тыкты. Хайван, хәлсез генә чинап, анын учын ялады.

—Әйдә, Акбай, әниләргә китәбез. Шулай кирәк, акыллым. Мин абыеннын кульязмаларын жыеп машинага тутырам да... Кайчандыр ул минем картиналарымны уттан саклады, хәзер—минем чират. Кайсыбыз үкси сон безнен, Акбай? Синме? Минме? Икебез дә мени?..

Их, янадан диктатор Зөлфиягә әйләнәсе иде. Беркатлы хыялыйлар өчен түгел бу замана, түгел! Менә чынбарлык аны кабат унлы-суллы янаклый. Әй син, язмыш! Тупаслыкнын тантана итүен күрсәтер өчен бүтән мисалларын беткән идеме, ә? Монын өчен шагыйрь фажигасе белән дә очраштырырга кирәк идеме?! Йөрәк канына манып язылган шигырьләрне чүплеккә себереп түккән жәлладларнын чыраен күрсәтеп тормасан да була. Алар—күп, алар Әэжүс белән Мәэжүс кебек гүзәллек дөньясынын туфрагына хәтле ашап килә. Тиздән анда берни дә чәчелмәс. Шытмас анда ижат орлыклары...

Фатирында ябылып ул тәүлек буе шигырь укыды. Сүз көче, сүз кодрәте аны биһуш иткән иде. Ә төшендә хыялындагы мәчет манарасыннан, дога

булып, хәрефләр коелды. Монысын ни дип юрарга икән, и Алла?! Шагыйрь белән рәссам рухташ, берсе кәгазьгә язган, икенчесе киндергә төшергән илаһи иҗат бөртекләре уртак, димәк, куанычы да уртак. Әллә... Әллә... «Йолдызларга табан очты шагыйрь җаны...» Юк, юк, ул исән!

—Кызым, син алай бетеренмә әле.—Үги анасы һәр нәрсәдән хәбәрдар иде. Иярәште аңа Зөлфия, ниһаять йөрәге белән якынайды. Гүя бу карчык салкын шәһәрдә җылы учак иде.—Мингалим дигән шагыйрьнең туганнарыдыр теге явызлар. Мал дип үлә бит кеше. Кайтыр, боерса, Мингалим. Абыеңа барысын да сөйләдем мин, кызым. Эзләттерәм, диде, милисәдән дә, егетләреннән дә. Акбай, хуҗасын сагынса да, тамагына каба. Күзе эренләгән иде, дару сөрткәч уңайланды. Синең машина тавышын әллә каян ишетеп колагын шомрайта, хайванкай. Син үзеңне җайла, кызым. Күргәзмәң борын төбендә. Абыең кушканнарны ярдәмчеләре җиренә җиткереп эшләгәндер, иншалла.

—Эшләде, әни. Зал зур, якты. Картиналар эленгән. Абыйга рәхмәт, бөтен чыгымнар аның кесәсеннән. Уңайсыз да инде. Ана да күктән акча яумыйдыр.

—Акча ул, кызым, кулында да, кесәңдә генә булсын, йөрәгеңдә булмасын. Абыеңның ниятләре гел изгедән. Алла боерса, Суык Чишмәдә мәчет салдыртам, ди. Синең сурәтеңдәге күчермәсен, ди. И Алла, үзем дә шуны үтендем инде балакаемнан. Ни, кызым...—Үги ана, гадәттә, бик дулкынланганда йә яулык очын, йә алъяпкыч итәген бөтәрли иде.—Ни инде менә... Мөслимә абыстай минем хакта әйткәндер инде...

—Әйтмәде, әни...

—Шулаймы? Кая, Акбайның сөтен җылытыйм әле.

—Этнең савыты тум-тулы бит, әни.

—Шулаймы? Ахшамга иртәрәктер, әйеме? Кояш баемагандыр...

—Йә, әни, Мөслимә абыстай нәрсә әйтергә тиеш иде миңа?—диде түземлеге төкәнгән Зөлфия.

Карчыкның күзләре дымланды.

—Атаң мәгълүм иде инде болар, кызым. Рәхмәт, Исламгали ялгыш та битәрләмәде. Мин унбиш яшемдә Суык Чишмәдән кыяклаган бала, шуннан бирле оятымнан туган якка бер дә кайтмадым. Безнең нәсел—каргалган, кызым. Балаларда гел тилелек чире. Минем генә улым бәгырем камил акыл белән туды. Мөәзин бабагызны кырга атарга апчыккан Гыйздулланың төпчек сеңелесе лә мин.

—Елама, әни...

...Күргәзмәгә халык күп җыелды. Иҗат әһелләре өчен мондый очрашулар тансык иде. Кырыс заман күмәк аралашуларны шактый гына чикләде. Зөлфия әрле-бирле зал буйлап йөрде. Йөрмәде, томанда йөзде. Аны котлыйлар, аның кулын кысалар. Иң түрдә—хыялдагы мәчет сурәте. Әнә, чәчәк бәйләме тотып Илдар килә. Тагын ни кирәк аңа?! Бәхетеңнән тәгәрә, ауна, көл! Ләкин кемдер җитми, аңардан башка зал буш, ятим... Чү, шагыйрь моңаеп кына ишек төбендә аңа кул селти! Зөлфия, кешеләрне ерып, шул якка атылды. Тик... тик күз алдаган иде... Ә күңел алдамады. Бу—йолдызларга очкан шагыйрь җаны иде. Ул аның шатлыгын уртаклашыр өчен бер генә мизгелгә җиргә төшкән иде.

*Октябрь, 2009— февраль, 2010*

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШКАН ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ

## Гамир Насрый *(1916–1959)*



1916 елның 3 гыйнварында хәзерге Башкортстанның Кызыл Кама районы Иске Янжегет авылында туа. 1934-1937 елларда Казан театр техникумында укый, аны тәмамлагач, Кызыл Армия сафларында хезмәт итә (1937-1940), совет-фин сугышы кампаниясендә катнаша. Армиядән кайткач, берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында эшли.

1942 елны Гамир Насрый Ватан сугышы фронтына китә, Сталинград янындагы һәм бүтән фронтлардагы күп кенә канлы сугышларда катнаша, ике тапкыр яралана. Ватан сугышының соңгы чорында ул фронт газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә, совет сугышчыларының батырлыклары турында үзе эшләгән «Фронт хакыйкате» («Җину байрагы») газетасы битләрендә йөзләрчә хәбәрләр, очерклар, шигырьләр бастыра.

Сугыштан соң Гамир Насрый драматург буларак таныла.

## Мәгъсум Насыйбуллин *(1925–2009)*



1925 елның 15 октябрендә Татарстанның Кукмара районы Байлангар авылында туа. 1943 елның сентябрендә гаскәри хезмәткә алына, Пермь өлкәсенең Куеда дигән тимер юл станциясе бистәсендә оештырылган кыска мөддәтле хәрби мәктәпне тәмамлагач, кече командир сыйфатында хәрәкәттәге армиягә озатыла. Литва җирләрен азат итү, Көнчыгыш Пруссиядә Кенигсберг шәһәре өчен барган сугышларда катнаша. Яралангач, дәваланырга Уралга җибәрелә.

Сугыштан соң Мәгъсум Насыйбуллин детектив әсәрләр язучы буларак киң танылу ала.

## Әхәт Нигъмәтуллин



1921 елның 30 ноябрендә Оренбург өлкәсе Ивановка (хәзерге Красногвардейский) районының Үтәй авылында туа.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Брест крепостен, андагы совет яугирләрен немец фашистлары чолганышыннан азат итү өчен барган дәһшәтле атакаларда катнаша. Атакаларның берсендә ул катнашкан рота командиры каты яралангач, Әхәт ротаны җитәкли, яралана. Госпитальдә дәваланганнан соң, икенче группа инвалидлык алып, туган авылына кайта. Мәктәптә ел ярым татар теле һәм әдәбияты

укытканнан соң, 1944 елда Казан дәүләт университетының татар бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлагач, укуын СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы аспирантурасында дәвам итә.

Әхәт Нигъмәтуллин актив җәмагать эшлеклесе, әдәбият галиме буларак мәгълүм.

## Зәки Нури *(1921–1994)*



1921 елның 24 декабрендә хәзерге Татарстанның Чүпрәле районы Татар Төкесе авылында туа.

1941 елның маенда армиягә алынып, ул гитлерчылар һөҗүменең беренче көннәреннән үк сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1941 елның августында полкташлары белән бергә чолганышта калып, партизаннар отрядына кушыла һәм 1942 елның мартыннан 1944 елның августына кадәр мәшһүр Константин Заслонов җитәкчелек иткән белорус партизаннары берләшмәсендә башта дошман объектларын шартлатучы-диверсант, соныннан разведка отряды башлыгы булып хезмәт итә. Белорус җирләре фашистлардан азат ителгәннән сон, Зәки Нури ике елдан артык Орша шәһәр советының башкарма комитеты рәисе урынбасары булып эшли һәм шәһәрне төзекләндерү, аны сугыш хәрабәләреннән арындыру эшләрендә үзен оста оештыручы-җитәкче итеп таныта.

Зәки Нури 1964-1971 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире була, тора-бара шагыйрь буларак киң танылу ала.

## Атилла Расих *(1915–1996)*



Рәсми документлары һәм паспорты буенча 1916 елның 16 сентябрендә хәзерге Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә туган булып исәпләнә. Асылда, ул бер ел алдарак Төркиянең Истанбул шәһәрендә дөньяга килә.

1940 елның гыйнварында хәрби хезмәткә чакырыла, Германия белән сугыш башланып, 1941 елның көзендә фронтка озатыла, Ватан сугышы беткәнче хәрәкәттәге армиядә була: хәрби фельдшер сыйфатында Мәскәү яныннан алып Эльба ярларына кадәр сугышчан юл уза.

Сугыштан соң Атилла Расих күренекле әдипкә әверелә.

## Хәбра Рахман *(1914–1942)*



1914 елда хәзерге Татарстанның Балтач районы Янгул авылында туа. Сигез яшендә чагында әти-әнисез калып, ятим балалар йортында тәрбияләнә. 1930 елда Арча мәктәбенең җиде сыйныфын тәмамлап, авылда укытучы булып эшли башлый. Шушы елларда «Ялчы» газетасында аның беренче шигыре һәм хикәяләре басыла.

1931-1936 елларда Хәбра Рахман Казанда татрабфакта, аннары Казан дәүләт педагогия институтында белем ала. Институтны тәмамлаганнан соң, аны татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп Алабуга педагогия училищесына эшләргә җибәрәләр. 1937 елда аның «Чәчәк ява» исемле бердәнбер мөстәкыйль җыентыгы дөнья күрә. Газета-журналларда кечкенә-кечкенә хикәяләре һәм Халхин-Гол вакыйгаларына багышланган «Сугышта» («Совет әдәбияты», 1940) исемле зур гына очеркы басылып чыга. Сугыш алдыннан ул шулай ук «Шомырт чәчәкләре» исемле повесть язарга керешә, ләкин әсәр тәмамланмый кала. 1938-1940 елларда Хәбра Рахман гаскәри хезмәттә була, Халхин-Голдагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, яралана, шәхси каһарманлыгы өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, Хәбра Рахман, Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр әүвәл Алабуга педагогия училищесында һәм китапханә техникумында тел-әдәбият укытучысы, аннары Алабуга район газетасының мөхәррире булып эшли. Сугыш башлануга, ул фронтка китә һәм, Мәскәү янындагы канлы бәрелешләрнең берсендә авыр яраланып, шул ярадан савыга алмыйча, 1942 елның ноябрендә вафат була. Аның гәүдәсе хәзерге Тверь өлкәсенең Максатиха дигән тимер юл станциясе каберлегенә җирләнә.

## Мәҗит Рәфыйков *(1925–1986)*



1925 елның 17 апрелендә Башкортстанның Күгәрчен районы Күгәрчен (Җидеболак Күгәрчене) авылында туа. 1943 елның мартында ул армиягә алынып, Эстәрлетамак шәһәрендә урнашкан Рига хәрби-пехота училищесына укырга җибәрелә. Анда дүрт айлык әзерлек курсы үткәннән соң, ул шул ук елның августында фронтка китә һәм рота санинструкторы сыйфатында Украина җирләрен азат итү сугышларында катнаша. Ләкин фронтта аңа озак булырга туры килми: 1943 елның сентябрендә Запорожье шәһәре өчен барган сугышларның берсендә каты яраланып, ул госпитальгә эләгә һәм соңыннан, хәрби хезмәткә яраксыз табылып, инвалидлыкка чыга.

Сугыштан соң Мәҗит Рәфыйков прозаик һәм тәрҗемәче буларак таныла.

## Бари Рәхмәт *(1897–1957)*



1897 елның 29 маенда хәзерге Казакъстан Республикасының Жилая Коса авылында туа.

1918 елда исеме танылa башлаган яшь шагыйрь гаскәри хезмәткә алынып, әүвәл Казандагы аерым татар батальонында укчы солдат, аннары мәркәз мөселман хәрби басмасы «Кызыл Армия» газетасында әдәби бүлек мөдире булып хезмәт итә. Шул газета битләрендә һәм Казанда чыккан башка көндәлек матбугат басмаларында («Эш», «Эшче», «Кызыл Шәрекъ») солдат шагыйрьнең лирик, публицистик һәм сатирик шигырьләре дөнья күрә.

1942-1945 елларда Бари Рәхмәт фронтта була, Украина, Молдова, Болгария, Венгрия җирләрен азат итү өчен барган сугышларда катнаша, яралана. Фронт шартларында да ул шигырьләр язуын дәвам иттерә.

Сугыштан соң Бари Рәхмәт күренекле балалар шагыйренә әверелә.

## Халикъ Садри *(1890–1955)*



Халикъ Садри (Габделхаликъ Садретдинов) 1890 елның 4 августында хәзерге Самара өлкәсенең Кляүлин районы Иске Ярмәк авылында туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1918 елның маенда Самарада татар телендә чыга башлаган «Кинәш» исемле газетада эшли, аннан соң, 1919-1922 елларда—партиянең Самара губерна комитетында татар-башкорт секциясе рәисе хезмәтендә. 1920 елда ул, татар халкы вәкилләренең берсе буларак, Мәскәүдә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү турындагы тарихи Закон проектына кул кую тантанасында катнаша.

Ватан сугышы елларында Халикъ Садри, полк хәрби комиссары буларак, фронтның алгы сызыгында сугыша, яралана, сугыштагы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Халикъ Садри прозаик буларак таныла.

## Мөхәммәт Садри *(1913–1999)*



1913 елның 31 маенда Казанның Яңа бистәсендә туа.

Мөхәммәт Садри үзенең беренче шигырьләрен «Кызыл яшьләр» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы һәм татар пролетар язучыларының «Атака» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә бастыра. 1932 елның язында унтугыз яшьлек шагыйрьнең «Җыр башлана» исемле беренче китабы дөнья күрә.

1941 елның июлендә Мөхәммәт Садри Ватан сугышына китә. Алгы сызыкта тупчы-артиллерист, аннары кыр складында сугыш кораллары бүлеге башлыгы, транспорт башлыгы, гвардия минометлары («катюшалар») дивизионында корал тәэминаты башлыгы була. Смоленск өлкәсендәге Мәскәүне саклау сугышларында катнаша, каты контузия ала. 1943 елның көзендә алты ай госпитальдә дәваланып чыккач, Александр Фадеев юлламасы белән, М. Садрины Беренче Украина фронтында татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасы редакциясенә оештыручы итеп җибәрәләр. Ул шушы фронт газетасы коллективы, анда эшләүче Риза Ишморат, Гали Хуҗи, Госман Бакировлар белән берлектә Украина җирләрен, Польшаны азат итүдә, Германиядәге сугышларда, Берлинны алуда, Праганы азат итүдә катнаша.

Сугыштан соң Мөхәммәт Садри күренекле шагыйрьгә әверелә.

## Рәхим Саттар *(1912–1943)*



1912 елның 15 августында Башкортстанның Чишмә районы Түбән Хаҗәт авылында туа. Ул балачактан ук әдәбиятка гашыйк булып үсә, дүртенче сыйныфта укыганда шигырьләр яза башлый. Урта мәктәпне Р. Саттар Уфа шәһәрендә тәмамлый. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен аңа Нәкый Исәнбәт укыта.

1941 елның җәендә Рәхим Саттар үзе теләп фронтка китә. Десантчы сыйфатында ул фашистлар тылында үткәрелгән күп кенә сугышчан операцияләрдә катнаша. 1942 елның маенда булган шундый операцияләрнең берсендә чолганышта калып, фашистлар кулына эләгә һәм, берничә ай Смоленск, Борисов шәһәрләрендәге хәрби әсирләр лагеренда газап чиккәннән соң, Берлин янындагы Вустрау лагерена озатыла. Шунда ул Абдулла Алиш белән очраша һәм озакламый Муса Җәлил һәм аның иптәшләре тарафыннан оештырылган антифашистик оешманың иң ышанычлы әгъзаларыннан берсе булып китә. Ул әсирләр лагеренда һәм мәгълүм «Идел-Урал» легионында антифашистик листовкалар язып таратуда актив катнаша. 1943 елның август аенда яшерен оешма фаш ителеп, җәлилчеләрне кулга алганда, Р. Саттар да шул исемлектә була, әмма ул 1943 елның июнь аенда ук лагерьдан качып китә. Аның шуннан соңгы язмышы әлегәчә билгесез.

Рәхим Саттар 1942-1943 елларда Смоленск, Борисов, Вустрау, Радом һәм Берлиндагы хәрби әсирләр лагеренда чагында да шигырьләр яза. Алар кульязма җыентык рәвешендә туган илгә кайтып ирешә һәм берничә тапкыр матбугатта басылып чыга.

## Үзбәк Саттаров *(1922–1982)*



1922 елның 8 мартында Татарстанның Әлмәт авылында (хәзерге Әлмәт шәһәре) туа. 1939 елда Әлмәт урта мәктәбен тәмамлый.

1941 елның августында аны армия хезмәтенә чакыралар. Бер ел хәрби училищеда укып, техник-инженер белгечлеге алганнан соң, ул сугыш беткәнче фронтның алгы сызыгында була, Курск, Воронеж, Белгород өлкәләрен, Украинаны азат итү сугышларында катнаша.

Сугыштан соң Үзбәк Саттаров балалар язучысы буларак таныла.

## Сирин *(1896–1969)*



Сирин Хәниф улы Батыршин 1896 елның 14 декабрендә Татарстанның Ютазы районы Кәрәкәшле авылында туа. 1918 елда Бөгелмәдә чыга торган «Юксыл» газетасында ул беренче шигырьләрен бастыра. 1929 елда шагыйрьнең балаларга атап язган «Яз», «Җәй», «Көз», «Кыш» дигән шигырьләре, рәсемнәр белән бизәлеп, һәрберсе биш-алты битле аерым китап булып басылып чыга, ә 1931 елда «Тамчылар» исемле күләмле генә җыентыгы дөнья күрә.

Ләкин Сирингә шигъriяттәге уңышлары һәм яңа иҗади хыяллары белән озак юанырга туры килми: 1935 елның 22 августында ул кулга алына. Биш елга ирегеннән мәхрүм ителә.

Лагерьдан Сирин 1941 елда, сугыш башланыр алдыннан гына азат ителә. Төрмәдән ул рухи яктан сындырылып, иҗади яктан тәмам сүнеп чыга. Озакламый аны Ватан сугышы фронтына җибәрәләр. Ул алгы сызыкта сугыша, яралана. Сугыштан соң туган авылына кайткач, әдәбият дөньясыннан бөтенләй читләшеп, колхозда гади умартачы булып эшли башлый.

## Максуд Сөндекле *(1904–1981)*



1904 елның 16 сентябрендә Татарстанның Тәтеш районы Сөндек (Сөендек) авылында туа.

1931-1935 елларда Донбасстагы татар телендә чыга торган «Пролетар» исемле газета редакциясендә әдәби хезмәткәр була. 1935 елдан алып, Ватан сугышы башланганчы, Башкортстан радиокомитетында эшли, 1941-1943 елларда фронтта була.

Сугыштан соң Максуд Сөндекле шагыйрь һәм прозаик буларак таныла.

## Гурий Тавлин *(1925–1998)*



1925 елның 25 декабрендә Татарстанның Зәй районы Урта Баграж авылында туа. 1942 елда Югары Баграж урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Түбән Бәеш җидееллык мәктәбендә балалар укыта. 1943 елның февралендә Гурий Тавлин армиягә алына, училищеда кыска вакытлы әзерлек үткәч, фронтка китә. Днепрны кичүдә, Украинаны, Белоруссияне, Польшаны фашистлардан азат итүдә катнаша.

Сугыштан соң Гурий Тавлин прозаик буларак таныла.

## Рафаил Төхфәтуллин *(1924–1994)*



1924 елның 1 гыйнварында Татарстанның Арча районы Яңа Иябаш авылында туа. 1942 елның августында Рафаил Төхфәтуллин армиягә алына һәм, алты ай чамасы хәрби училищеда әзерлек курсы үткәннән соң, фронтка җибәрелә. Башта—пулеметчылар, соңыннан элемтәчеләр отделениесе командиры сыйфатында ул Брянск, Орша һәм Рига шәһәрләре янындагы каты сугышларда катнаша, ике тапкыр авыр яралана һәм бер тапкыр контузия ала.

Сугыштан соң Рафаил Төхфәтуллин танылган прозаикка әверелә.

*Ахыры киләсе санда*



Лена
Шагыйрьҗан

# «ШИГЪРИ ТАМЧЫЛАР» ЦИКЛЫННАН

## АФОРИЗМНАР ҺӘМ ХИКМӘТЛЕ ФӘЛСӘФИ СҮЗЛӘР

***

**Сиңа, Адәм—ике дөнья:**
**бакые вә фаные...**
**Икесен дә төзеп куйган**
**Аллаһ—Галәм баные**[1]

***

**Яшәү масштабым тар булса да,**
**Шигырь масштабым киң булды!**
**Киң карашлы, киң күңелле кем бар—**
**Йөрәгемә тик шул тиң булды...**

***

**Салмак кына тартып барам арбамны,**
**утырып барган белми безнең арганны...**
**Арбам гади—ишме асыл йөгемә?—**
**Тәгәрәтсәң, җитәр җирнең чигенә...**

### Картайгач дөнья әйттерә...

**Дүрт кыйбла—бер җилгә,**
**дүрт хатын—бер иргә...**
**Җиде булса да ризамын,**
**ялгыз калмасам җирдә...**

[1] баный—архитектор.

Лена ШАГЫЙРЬҖАН—*шагыйрә; «Ышанам күңелемә», «Божра һәм хөҗрә», «Сагынмаклык» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгының һәм Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Элек һәм хәзер...

Бик күпләр бар дип тә белми
астрономия фәнен.
Аның каруы шәп белә
«гастрономия фәнен...»

***

Һәрбер йөрәк эзли үз ритмын
Сикәлтәле чуар заманда.
Һәр заманның уртак йөрәк тибешен
Шагыйрь теркәп бара һаман да...

***

Кесәңне сакла—базар юлында:
кошелёгың төшеп калмасын.
Намусың сакла—гомер юлында:
кешелегең төшеп калмасын...

***

Йөрәгемнең түрендәге «гадел сәгать»
гомер мизгелләрен санап, көн-төн йөри...
Шигырең түгел, дус йә дошман сүзе мәллә
иҗатыңа бәя биргеч «критерий»?..

## Үзеңне сакла диючеләргә

Җир үзен ничек саклый!—дип,
аңа рәхмәт яудырам:
бер ягы йоклаганда да,
бер ягы уяу тора...

## Ярымшарлар картасына карап

Җир шары ул «тоташ савытлар» кук—
тигезләнеш сорап, «тулып тора»:
Бер ягына нәрсә койсаң, шуны
икенче ягына «куып» тора...

***

Диннәр бар да Хода бәндәләрен
татулыкка өнди үзара.
Диннәр арасында татулыкны
кемнәр икән менә бозалар?..

***

Каһәрләнде каһарманнар
каһкаһә белән һаман...
Инде килеп хуҗа булды
каһарманнарсыз заман...

***

Бик тиз оныталар икән
кул чапканнар кичә гөрләп,—

«Онытмагыз аны!»—ди-ди,
кемедер чапмаса тирләп...

***

«Каян гына сүзен таба!»—
дип соклана шигыремә...
Сүз ул балык кебек каба
хисең белән фикереңә...

***

Шигырьнең аның «андые» да кирәк,
«мондые» да кирәк:
кайберәүләр өчен ярып әйтү зарур—
маңгаена терәп...

***

Онытма һич, сине Кеше итте
Шигырь дигән дан-рух дирбиясе...
Барлык сабаклардан өстенрәк
Шигырь биргән тормыш тәрбиясе...

## Бер филолог зары

Кучемле-кучемсез фигыльне
кучемле-кучемсез милектән
аера белмәдек нилектән?..

***

Яшәп яталар ялгыз-йолгыз
Ничәмә-ничә шәхес-йолдыз.
Көнозын—күренми беркемгә,
төнозын—бер Ходай иркендә...

***

Кая очып китте дәртле Кошым
Әллә инде куймый калдым җимен?
Җавап килә Коштан: «Хафаланма,
Заманында куймадың һич кимен...»

***

Базарында артык күптер тормыш,
мазарында гүя чүптер үлем...
Бер карыйсың бу дөньяга җылап,
бер карыйсың—бар нәрсәдән көлеп...

***

Май язып карады берәү,
чыкмады май—«сөте» сыек...
«Зур эшләр» майтарды үзе,
әзер май-каймакны җыеп.

***

Уең күбәйсә, уеның азая,
Эшең күбәйсә, дус-ишең азая...

***

Мәхәббәт ул җәннәт икән, оҗмах икән,
бу дөньяда иң бәхетле почмак икән.
Мәхәббәтсез көн итүдә бер дә тәм юк,
ләззәтле газапсыз яшәү—тәмам тәмуг...

***

Гайбәтләрнең чыгаралар төрлесен,
ялган кушып—серлесен вә керлесен.
Аямыйлар ялгызын да, парын да,
пыр туздырып—хатынлысын, ирлесен...

***

*М. Исәнбаевның «Кояш чыгуы» дигән биюен карагач...*

Чәчәк тажы ачылган «тизлектә»
Кояш күтәрелде офыктан...
Мәхмүт Исәнбаев «таңына»
тамашачы утыра калып таң...

***

Һаваларда озак очтың,
Җитәр, җиргә төш, диләр...
Җиргә төшсәң дә ярамый,
Йөрмә монда, «көш!» диләр...

***

Һавалы мин, тик тәкәббер түгел,
«Һавалана» алмый таш кына.
Тәкәбберләр—канатсыз бәндәләр,
Ә мин һаваларга ашкынам...

***

Хискә бирелүләр күпкә китсә,
эшкә бирелүдән бизәсең...
Эшли-эшли өшәнепләр бетсәң,
җаның корыганын сизәсең...

***

Вампирларга донор булып,
бушап беткәч, тагын тулып,
Яши шагыйрь, рыясыз җан,
чәчәк аткан саен, сулып...

***

Хаста адәм, хәл белергә
килгән һәрбер кешедән
дәва көткән күк, җылы сүз
көтә җаны өшегән...

***

Сүзләрне без ефәк җеп шикелле,
үткәрәбез «энә күзеннән»:
Бүләкне дә гадел бүлә бел син,
яралган ул «бүлү» сүзеннән...

***

Тыныч яшәү—йолаларга,
кагыйдәгә сыюлык...
Һәрбер кыюлык артында—
җимерелгән «тыюлык»...

## Тукай белән бәхәсме?..

Бу дөньяда юкка гына
тумагандыр ул шөгыль:
Тәнгә мунча булган кебек,
жанга мунча—ул шигырь...

***

Тормыймын алдан юратып
язмышның киләчәкнең;
Еладым—елаячакмын,
көлдем һәм көләчәкмен!

***

Тарихың да артта кала
хурлык-оялы белән.
Мәгәр Татар артта калмас
әдәбияты белән!..

***

Бу дөньяда яшәр өчен
көрәшергә көн дә кирәк.
Яшерен генә ярышырлык
көчле көндәше дә кирәк...

***

Без яшәгән заман искерде,
үзе бездән алда картайды...
Өлге итеп алу кирәк җанга
гел яңарып торган карт Айны...

***—

Хисләреңне йотып барсаң гел эчеңә,
Җан чишмәсе акмый башлый—гаҗәп икән.
«Берәүгә дә кирәкми» дип хафаланма,
үз-үзеңне сугару да хаҗәт икән...

***

Язмышыңны эч төбенә хәтле,
калдырмыйча бөртек-тамчысын.
Татыр өчен килгән адәм Җиргә
пәрәннеге белән камчысын...

Мәдинә
Маликова

# ЮКӘ ЧӘЧӘК АТКАН ЧАК ИДЕ

**(НУРЗИФА)**

РОМАН

## Күңел сандугачы сатылмый

Хәнәфи табынның шәбен әзерләгән иде. Аракының «Смирновски»е, шампанскийның Франциядә эшләнгәне, коньякның «Һеннеси» дигәне. Соңгысы үзе өчен, билгеле, тегеләрнең авызы аракыга күнеккән. Ә шешәләр табынны ямьләп торсын. Торсыннар! Бик затлы рестораннарда да андыйлар өстәлгә сирәк куела. Кабымлыклар да «Бәхетле» кибетенен махсус кишттәләреннән яисә алдан заказ биреп пешертеп алынган: казылык, бастурма, рулетлар. Сырларның Австриядән, Алманиядән китерелгәннәре. Авокадо, манго, ананас.

Мондый табыннарның тәмен белә иде Хәнәфи. Һәм рәхәтләнеп тезде дә. «Мальчишник»ка, ягъни егетләр генә җыелганда менә дигән инде.

Әмма күңелне иң нык очындырганы табында түгел, идән астында иде: Мозаффарның баш өстендә аның дуслары белән кәеф-сафа корып утыру үзе генә дә ни тора! Кайсыдыр җаһилләр җинелгән дошманнарын тезеп яткырып, алар өстенә такта җәеп, мәҗлес уткәрә торган булганнар. Дошманнарын изә-изә биегәндә алар нинди ләззәт кичергән булсалар, бу минутларда Хәнәфинең күңелен шундыйрак хисләр кытыклый иде. Дөрес, Ансар җырларга теләк белдермәгән иде белдерүен, әмма мондый табын янында, мондый эчемлекләрне авыз иткәннән соң чын җырчы тыела аламыни?

...Егетләр бүлмәнең бусагасын ничектер сагайган кебегрәк атлап керделәр. Көн яктысыннан соң биредәге аксыл лампалардан, ясалма тәрәзәдән төшкән яктылык никтер җансыз кебек тоелды, ялтырап торган паркет, биек түшәм салкын сыман—кыскасы, бу торакка җан җылысы иңмәгән , кот кермәгән иде әле.

—Ә моны ник каплап тотасың?—дип сорады Зөфәр дивардагы каплаулы

*Ахыры. Башы 3 санда.*

рамга ишарәләп. Һәм өстәл янында мәрәләнгән Хәнәфи аны-моны аңышып өлгергәнче, киндерне тартып та алды. Картинадагы чалкан яткан ефәк күлмәкле кыз, башын борып, бүлмәдәгеләргә сынап карагандай булды.

—Бәй, Мозаффарныкы бит бу!

—Әйе, аныкы,—диде Хәнәфи.—Иде,—дип өстәде аннары.

—Ә хәзер кемнеке?

—Безнең хуҗага сатты ул аны,—диде Хәнәфи.

—Ну бу байлар! Һәммәсенә куллары житә! Монысын сатмыйм, дигән иде бит Мозаффар, ник алай итте икән?

—Анысын үзеннән сорарга кирәк инде,—диде Хәнәфи.

—Сорар идем дә, юк бит әле ул. Иллә дә әйбәт булыр иде, шушында булса. Һич башыма сыймый: кайда йөри икән соң ул?

—Илһамы килгәндер дә бездән качып кына чираттагы шедеврын язып ята торгандыр әле,—диде Ансар.

—Озак тормас, шәт. Ул Прагага киткәнче бер очрашасы иде.

—Әйе шул, бусы очрашуның соңгысы булмас, —диде Хәнәфи.—Ягез әле, утырышыйк. Юкса «Смирновский» белән шампанский жылына монда! Кайсын салыйм сезгә?

—Ин шәбе агы инде...

Хәнәфи, кыйбатлы ресторандагы официант кебек кыланып, биек, сырлы, үтә күренмәле шешәне ак тастымалга урап тотты да, озын торыклы рюмкаларга аракы койды. Үзенә коньяк салды.

Табын янына утырышып, очрашу хөрмәтенә дип берәрне йотып куйгач, тамаклар жылынып киткәндәй булды, әмма нилектәндер күңелләр салкын калды кебек. Жан дуслар арасында була торган якынлык уянмады, телләр чишелеп, авызлар ерылмады. Чәйнәштергән арада ихатаның хуҗасы Самаркин хакында сорашып алдылар, аның Италиядә Берлусконининың бер вилласын сатып алырга йөрүе турында ишеткәч, тел шартлатып, башларын чайкап куйдылар.

—Нинди-нинди хезмәтләре аркасында шулкадәр байлыкка ирешә икән бу адәм баласы?—диде хәйран калып Зөфәр.

—Эшләп кеше байый димени!—диде аңа Ансар.

—Шулхәтле малны талап жыймагандыр бит инде! Тотып ябарлар иде!

—Андыйларны бик тота алмыйлар!—дип шагыйрьне баласыткандай әйтеп куйды Ансар.

—Мал туплый белү би-ик күп хезмәт сорый ул, егетләр,—диде Хәнәфи гадәтенчә серле елмаеп.—Асылда без барыбыз да бай-мул яшәргә омтылабыз. Тик моңа ирешү өчен төрлебез төрле чара куллана. Фәкать шул гына. Кайсыбыз сайлаган чара үтемле була, ә кайсыбызныкы юк.

—Иң үтмәсе каләмдер инде аның,—дип куйды Зөфәр.—Жырчыларга түлиләр әле, ә минә безнең кебек каләм ияләренең хәле мөшкел. Китап чыгарыр өчен житмеш мең сорыйлар. Шуны да табып булмый.

—Болай гына чыгармыйлармыни? Хөкүмәт хисабына,—диде Хәнәфи.—Өстәгеләр, милләтне кайгыртабыз, дип күкрәк сугып мактана лабаса.

—Нәшриятта чират бит. Шигырь китабы әкрен сатыла, элек чыкканы да складта ята, диләр дә бетте китте.

Ансар Хәнәфигә төбәлде:

—Хуҗаңа сүз кушып карамыйсыңмы соң?—диде.—Назиров ул татарның күз өстендә каш кебек шагыйре, тере классик, диген. Аның яңа әсәрләрен халыкка житкерергә ярдәм итсә, савап булыр үзенә, бераз булса да гөнаһлары ярлыканыр. Житмеш мең аңа «фу» бит ул...

Хәнәфи башын иеп, уйланыбрак торгандай итте дә:

—Анысы шулай... Ләкин тик торганда акчасын уңга-сулга сибеп йөргән

кеше баемый шул ул,—дип, Ансарның тәкъдименә читтән суктырып җавап бирде.

—Шул-шул, үзләренә файдасы тимәсә, тиен дә бирмиләр!

—Мин нинди файда китерим инде аларга,—диде Зөфәр монсу гына,—Бар байлыгым —күнелдәге былбыл да куллдагы каләм... Берсе дә кибет киштәсенә куя торган түгел.

—Алай димә! Бу заманда матбугатның көче бәяләп бетергесез!—дип каршы төште аңа Ансар.—Каләм ияләре, әнә, әле кичә генә халыкка исеме дә билгеле булмаган адәмнәрне ике-өч ай эчендә президент ясап куя. Башкаларга да яхшылык эшли, үзе дә рәхәт яши. Каләмне аны сата белергә генә кирәк.

—Каләмне сату дип әйтү генә ансат,—диде Зөфәр.—Үз-үзенне, кешелегенне сату дигән сүз бит ул. Исемле каләм ияләренең бәгъзесе, селәгәен агызып, берәр байны күккә күтәреп мактап язып чыкса, бөтенесе беләләр: бу автор шул бай исәбенә китабын нәшер иткән... Яки аннан башка төрле файда күргән. Хәзер шунын әҗерен түли... Һәммәсе ап-ачык, кулыннан тотучы гына юк.

—Әйе шул, аның өчен берәүне дә судка бирмиләр. Штраф та салмыйлар хәтта. Куркып-нитеп торасы юк,—диде Ансар үчекләп.—Самаркиннан акча аласың икән, шигъри тулпарынны аның арбасына җигәргә тиеш булачаксың инде. Аны мактап бер шигырь генә булса да чыгармый котыла алмассың. Ә бәлки, аңа мәдхия җырлап поэма язарга туры килмәгәе әле!—диде Ансар.

—Бу очракта шигырь-поэма ише генә батмас шул,—диде Хәнәфи.— «Ватаным Татарстан»да... иң яхшысы, «Вечерняя Казань» гәзитендә, Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре дигән титулларынны куеп, зур мәкалә бастырып чыгарырга алынсаң, ул чакта сүз алып барып булыр иде. Егор Викторович андыйны ярата. Сайлаулар якынлашып килә. Яхшы булыр иде ул.

—Татар кешесе өчен шагыйрь Назировның сүзе изге! Ул мактаган кешегә халык сайлауларда тавыш бирә дә бирә инде...—диде Ансар тагын да мавыккандай кыланып.—Чынлап торып тотынсамы! Самаркинны Татарстаннан Рәсәй думасына, билләһи, сайлаттыра... Ә син аннан кыйбат сора,—диде Ансар.—Сатылгач сатылгач, баеп калырга кирәк. Җиде томлыгыңны бастырып чыгарырлык итеп бирсен.

—Сатылырга кинәш итәсез инде алайса... Ә бит без сатылмаска, шигърияткә, сәнгатькә риясыз хезмәт итәргә, дип ант бирешкән иҗат әһелләре.

Беркемгә дә баш имәде шагыйрь,
Бөгелмәде сыны шагыйрьнен,
Көчлеләрнең йөзләренә бәреп,
Чын дөресен әйтте шигыре...

—Озакламый очрашырбыз,—дип дәвам итте ул.—Мине каршыгызга бастырып, йөземне кызартмакчы инде әллә сез?

—Нинди хыянәт булсын ул? Шигырьне ташлап, базарга сәүдә итәргә чыгып басмадың ла син! Иҗат җимешен саткан һәр сәнгать кешесен талантына хилафлыкта гаепләп буламыни? Әгәр алайга китсә, җырлаган өчен акча алган артистларны да гаепләргә була... Әйдә, бер тост әйт әле, Ансар!—дип сүзне икенчегә борды Хәнәфи.—Әллә соң җырлап бирәсеңме?

—Чыннан да, җырлап җибәр әле, малай!—дип аңа кушылды Зөфәр.

—Гонорарын күп түлисезме соң?

—Шигырь белән түләрмен! Самаркинга сатылып булмас, ә сина—рәхәтләнеп!

Ансар тамагын кыргалады да «Баламишкин»ны такмаклап җибәрде:

—Мишкиннарның өе зәңгәр,
Без дә шулай буятыйк;
Ашыйк-эчик, уйныйк-көлик,
Күңелләрне юатыйк.

—И-их, шәп тә әйттерәсең инде!—диде Зөфәр. Һәм үз такмагын әйтергә керешге:

—Гыймадинең тавышы шәп,
Чи күкәй эчә микән?
Мин дә шулай җырлар идем—
Мин дә күкәй эчәр идем—
Ничәнә эчим икән?

Сүз шунда өзелде—ишек каерылып ачылды һәм бусагада Самаркинның мәһабәт гәүдәсе пәйда булды. Бүлмәдәгеләр ихтыярсыздан урыннарыннан торып басты.

## Котелмәгән хуҗа

—Ну, орлы, как вы тут устроились без меня, а? Привет, привет!

—Сез... кайчан кайттыгыз! Нигә хәбәр итмәдегез? Машина белән каршы алган булыр идек...—дип аңа каршы атлады Хәнәфи. Бер мизгелдә ул ничектер кечерәеп, шинеп калгандай иде.

—Синннән башка каршы алучы юк, дип уйлыйсыңмы әллә мине? Монда әйбәтләп каршыла! Ә син, күрәм, хуҗага дип прибор да куймагансың.

—Хәзер! Хәзер!

Хәнәфи, кая басканын белмичә, шкафка таба атлады, тартмаларны каударланып ачкалап, савыт-саба шылтыратырга керешге. Кунак егетләрнең карашы исә хуҗага төбәлгән иде.

Самаркин кая гына барып, нинди генә төркемгә эләксә дә, барча карашларны үзенә җәлеп итә торган кеше иде. Бүтәннәрдән бер башка калку, карап торышка ук гайрәтле, шул ук вакытта ыспай гәүдәле. Кыска киселгән салам чәчле йомры башы текә муенга утыртылган, кояшта янмый торган ак бите уртасында зур гына туры борын, үткен карашлы күксел күзләр. Кызыл иреннәре арасыннан тигез, таза, саргылтрак эре тешләре күренеп тора. Ияге нык ихтыярлы, үзсүзле кешеләргә хас булганча, шакмаклы, чыгынкы.

Әмма яше кырык тирәсендәге бу ирне башкалардан аерып торган төп сыйфат килеш-килбәтендә генә түгел, ә бәлки кискен, төгәл хәрәкәтләрендә, һәркемгә өстән карап күнеккәнгә, бераз кысылган күз карашының үткенлегендә, бөтен рәвешеннән бөркелеп торган буйсындыру көчендә иде. Ир солтаны, дөньяның тоткасы, алтын багана дип нәкъ шундыйларга әйтәләрдер. Кара сызыклы ачык коңгырт костюмы, керсез ак күлмәге, алсу галстугындагы каптыргычта җемелдәгән асылташ, пинжәгенең ачык изүен рәтләштергәндә сул беләгендә ялтырап алган кыйбатлы сәгать (мөгаен «Ролекс»тыр), уң кулының атсыз бармагындагы киң алтын балдак, ялт итеп торган көрән штиблетлар—болар барысы да затлы картинаның бик тә кыйммәтле кысасы шикелле иде.

Кая басса шунда киң мәйданны биләргә күнеккән, күзе төшкән һәрнәрсәгә хуҗа булырга омтыла торган зат иде бу. «Киң урамнар безгә

тар»,—дигән җырны нәкъ менә шундыйлар уйлап чыгаргандыр да.

Ул кин елмаеп, җинел адымнар белән туп-туры Ансарга таба юнәлде:

—Вот так встреча! Здравствуй, дорогой!

Анын кыяфәтеннән, көр тавышыннан бүлмә ничектер кечерәеп, җылынып киткәндәй булды.

—Гәзитләрдә сезне Голландиядә дип язганнар иде бит әле! Кайтыгызмыни?—дип аптырап калган җырчыны кочаклап, аркасыннан каккалады ул.

—Исәнмесез,—диде анын кочагында бераз кечерәебрәк калган Ансар.—Кайтканыбызга өч көн генә әле.

—Молодцы! Хәнәфи, син нәрсә мыштырдыйсын анда?! Мин кайтуга шундый бөек җырчыны чакыргансың икән, сыйлый да бел!

Хәнәфи өстәлгә чиста тәлинкә-чәнечке, бокаллар куйган арада:

—Ә бусы безнең бик атаклы шагыйребез Зөфәр Назиров,—диде.—Тукай премиясе лауреаты, халык шагыйре.

—Бик шатмын!—дип Зөфәрнен кулын кысты Самаркин. Анын йөзе сүрелгән, карашы читкә төбәлгән иде. Күренеп тора: ул шигърият белән кызыксынмый, җырчылар белән исә бай мәҗлесләрдә, кичәләрдә күп аралаша иде, күрәсең.

Хәнәфи кунакларга—аракы, хуҗа белән үзенә коньяк салды да, рюмкасын күтәреп:

—Юлларыгыз уң булган өчен!—диде.

—Ә син минем юлым уңганны каян беләсең ?

—Күренеп тора.

Рюмкасын бушаткач, Самаркин кызыл балык калҗасын кабып чәйнәштерде дә:

—Семганың тозы аз,—дип тоз савытын тәлинкә өстендә селкештерде.

—Нәрсә шым булдыгыз,—диде.—Мин кергәндә әңгәмәгез бик шәп куерган иде бит. Нәрсә турында иде ул?

—Матурлык турында.

—О-о, матурлык турында бәхәс купса, акча ызгышыннан яманрак инде ул. Уртак матурыгыз бармы әллә?

—Юк, без сәнгать турында. Сәнгатькә тугрылыклы хезмәт итәргә, байлык артыннан кумаска дип ант итешкән идек,—диде Зөфәр.

Самаркин чәйнәвеннән туктап, аңа текәлде:

—Сез аңа ничек хезмәт итмәкче идегез сон?

—Һәркем үз өлкәсендә. Мин шигъриятта, Ансар сәхнәдә, Хәнәфи белән Мозаффар рәсем сәнгатенә... Ничек дигән әле Пушкин: «Веленью божьему, о муза, будь послушна!»

Самаркин борылып Хәнәфигә текәлде.

—Шулаймыни? Син дә сурәт ясап кына тамак туйдырмакчы идеңмени?

—Ну, яшь идек бит... Идеалист чак...—диде Хәнәфи.

—Нәкъ менә яшьлектә антлар ихлас күңелдән, чын йөрәктән бирелә дә инде! Кызганыч, арагызда мин булмаганмын.

Зөфәр гаҗәпләнеп аңа төбәлде.

—Сез дә кушылган булыр идегезме әллә? Сәнгатькә хезмәт итәргә ант эчәр идегезме?

—Ә сез бездән башка гына яшәп бетермәкче идегезме әллә?—дип үткен карашын Зөфәрнең йөзенә төбәде Самаркин.—Шалишь, брат! Без булмасак, сез дә юк. Ә менә бергәләшеп тотынсакмы? Сәнгать гөрләп үсәчәк. Мин үзебезнең опера театрын Франциягә алып барырга уйлап йөрим әле. Ә нәрсә, заманында Дягилев эшләгән безнең кулдан килмәсме

әллә! Парижда аның «Дягилев сезоннары» булган бит. Ә менә мин меценат булып, Самаркин сезоннары уздырсам? Меценат Самаркин! Шәп янгырый бит, черт побери! Ансарны Франс-опера сәхнәсенә менгереп җырлатсак, беләсезме, ничек гөрләр иде аның даны!

Ансарның йөзе алланып чыкты.

—Белмим шул...—диде ул бик нык шикләнеп.—Алдан әйтүе кыен.

—Әллә булмас дисеңме?

—Зур акчалар белән әллә ниләр эшләп булыр анысы. Театр директорына әйтегез генә, җир читенә алып бара. Тик мине анда ничек кабул итәрләр бит әле...

—Ә син булдырам, диген. Мин сине иң талантлы җырчы дип беләм, син дә шуңа ышан. Талантка тыйнаклык килешми, брат! Мин Миланда «Ла Скала» да булдым. «Травиата»ны тыңладым. Андагы Альфред синең кисеп ташлаган тырнагыңа да тормый! Ни тавышы, ни кыяфәте. Театр бинасының да безнең Казанныкыннан артык җире юк! Булган байлыкны күрсәтә генә белмибез. Менә Мәскәүдәге картиналар галереясын ачып җибәрик әле. Аннары мин театрга ныклап тотыначакмын. Кстати,—дип Хәнәфигә борылды ул.—Казаннан кемнәрнең картиналарын алып барасын кайчан хәл итеп бетерәбез инде?

—Иң беренче чиратта Юлдашевның әсәрләрен алырсыз инде,—диде Зөфәр.

—Ә ул кем?

—Хәнәфинең сабакташы.

—Шулхәтле талантлымыни? Ә ник син мине аның белән таныштырмыйсың?

—Юкка чыккан әле ул,—диде Зөфәр.

—Ничек юкка чыккан? Кая?

—Хатыныннан качкан булса кирәк.—диде битараф тавыш белән Хәнәфи.—Бозылышып йөргән чаклары.

—Хатыннан качса, дусларыннан качмагандыр бит?

—Безнең шалтыратканга да җавап бирми шул,—диде Ансар.

—Сәер халык шул ул рәссамнар. Акылы тулы булган кеше иҗат итә алмый, диләр бит.

Зөфәр чәйнәп утырган хуҗаны күзәтте. Болгавыр заманда кинәт баеп китүчеләр арасында иң нык күзгә ташланганы, мөгаен, Егор Самаркин иде. Моннан ун еллар элек, заводлар туктап, фабрикалар ябылып, эш кешесе ике кулын салындырып өенә кайтып утыргач, ил җитәкчеләре һәркем үз ягын үзе карарга тиеш, дигән күрсәтмә биргәч, бар халык, нәрсәгә тотыныйм да, ниләр майтарыйм икән, дип аптырап йөргән арада, болганчык суда коры кул белән чуртан эләктерә белүчеләр табылды. Ике-өч ел эчендә нindидер могҗиза белән зур заводлар, рудник-шахталар аерым шәхесләрнең кулына кергән булып чыкты. Ничек алай булган? Илнең бөтен байлыгын бар халыкка тигез итеп бүлеп бирергә ниятләгәннәр иде бит югыйсә. Шул ниятне тормышка ашыру максатыннан һәр гражданинның кулына «ваучер» дигән кәгазь дә өләштеләр. «Һәр ваучерның бәясе бер «Волга»га тиң!»—дип кат-кат гәзитләрдә басып чыгардылар, телевизор экраннарыннан сөйләделәр.

Тик халыкның күпчелеге ул кәгазьне машинага алыштыру җаен тапмады. Менә шуның рәтен-җаен белгән, юлын тапкан үткен адәмнәр баеп калды да инде. Самаркин шундыйлардан иде. Ул, мәсәлән, авылларга барып, анда кооперативлар оештырып җибәрде. Һәм шул авылларда яшәүчеләрдән ваучерларын җыеп алды да, алар урынына «акция» дигәннәрен тоттырды. Ваучерларын базарда яртыга алыштырган сәрхүшләр бер тапкыр булса да эчеп кинәнделәр ичмаса, Самаркинның кооперативына кергән җир

кешеләренә анысы да тәтемәде. Чөнки алар аны-моны аңлап, унга-сулга карарга өйрәнгәнче, еллар узып китте, ул арада теге «акция»ләрне өләшкән кешеләрнең кайсы эшен алыштырган, кайсы пенсиягә чыккан, кайсы гүр иясе булган иде инде. Нәкъ Хужа Насретдин әйткәнчә: биш ел узганчы йә ишәк, йә бай үлә.

Ә менә Самаркин канатны кин җәйгән, бөтен Рәсәйне иңли, хәтта Себергә, Ерак Көнчыгышка барып житкән иде. Анда исә үзләренең башлы, тешле, мут егетләре житәрлек, читтән килгәннәрне кочак җәеп көтеп тормыйлар. Самаркин баргач, анда зур ыгы—зыгы купкан. Бу инде сиңа Идел чуртаннарының тешләшүе генә түгел, Тын океанда акулаларның чәйнәшүенә тиң булган, күрәсең. Һәрхәлдә гәзитләрнең «Криминал» дигән бүлегендә аның исеме еш телгә алына. Тумышы белән Казаннан булгангадыр инде, аңа «Татар» кушаматы тагып куйганнар, ә бу андагы күпләрнең күңелендәге нәфрәт хисен тагын да ныграк күпертә иде.

Хәлбуки, бу кушамат аңа бөтенләй гаделсез тагылган иде. Паспортына милләте «русский» дип язылган иде аның. Дөрес, нәсел тамырына төшеп казынсаң, мөгаен, татар каны да табылыр иде. Әмма кыяфәтенә караганда бу сизелми, аның чуваш йә мари булуы бик ихтимал. Безнеңчә яхшы гына пупалавы да шуны дәлилли. Кушаматына исә ул тамчы да гарьләнми, киресенчә, авызын ерып, күзләрен корычтай елтыратып: «Татар барда хәтәр бар!»—дип кенә җибәрә.

Андыйга исе китми егетнең, кушаматлары аннан башка да житәрлек. Эшем кешеләре тирәсендә ул «Инвестор», туксанынчы елларда «Самаринвест» дигән бер оешмасы бик шаулап алган иде. Телевизордан бу сүзнең алтын кирпечтән тезелгәнен көненә әллә ничәшәр тапкыр күрсәтеп тордылар. Шуңа ышанып, бик күпләр соңгы акчасын Инвестор Самаркинга илтеп бирде. Бу табынга алданрак өлгергәннәр майлы калҗа эләктерде эләктерүен, әмма күпчелек кәкре каенга терәлеп калды. Бәгъзеләр: «Әйдәгез, бергә оешыйк та, судка бирик!»—дип кычкырынганнар иде дә, халыкның күпчелеге еллар буе суд юлын таптасын күз алдына китерде дә тынды...

Мәдәният тирәсендәгеләр Самаркинны яратып «Безнең Спонсор» диләр. Ә кайберәүләр өчен ул «Братан Егор»... Инде менә «Меценат Самаркин» да булмакчы!

Халык арасында аның исеме президентныкыннан ешрак телгә алына. Кайберәүләр гаепләсә дә, күпләр соклана. Менә ичмаса яши белә кеше! Бөтен Казан халкының күзен кыздырган, алты метрлы ак лимузины гына да ни тора! Игелекле гамәлләрне дә күп кыла: теге чакта үзенең кооперативына кереп торган авылларның берничәсендә чиркәү, мәчет төзетте, күпер салдырды. Ятимнәргә, сукбайларга, ристаннарга күрсәткән ярдәме хакында да язгалап торалар.

Рәсәй думасына элекке сайлауларда, Самаркинга халыкның туксан тугыз проценты тавыш биргән диделәр. Телевидение дума утырышларын күрсәтә башласа, экранда аның чырае чалынмый калмый, чөнки тирәсендә һаман ыгы-зыгы кубып кына тора, бервакыт хәтта Жириновскийның үзе белән якалашканы күзгә чалынды.

Боларны яшен тизлеге белән күз алдыннан үткәргән Зөфәр икеләнебрәк утыра иде: Ничегрәк сөйләшергә моның белән: Спонсор итепме, Инвестор итепме? Ваучерлар турында сорасаң ни әйтер икән? Эш шунда ки, аның Мөслим районында яшәп ятучы әти-әнисенең, туганнарының әлеге хикмәтле кәгазьләре дә шушы адәмнең кулына кереп юкка чыккан иде.

...Егор исә алдындагы тәлинкәсенә текәлгән дә, тоз сибелгән семга балыгын чәйни, берни дә сизми кебек. Ләкин ул ерткыч җанвар сизгерлеге белән шагыйрьнең өнәмәгәндәй, хәтта гаепләгәндәй карашын тоеп алды.

Аның белән сүз көрәштерәсе килми иде, шуңа күрә авыз ачарга ирек бирмәде, Хәнәфигә борылды да:

—Ә син монданиләр майтардың?—дип сорады.

—Күп эшләр башкарылды инде. Аскы катларны да рәтләп бетердек...

—Карап карарбыз...

Бу сүзләрне ишеткәч, Хәнәфинең чырае тартышып куйды.

—Тик бүген булмас инде, арылды, —диде Самаркин.—Иртәгә иртән астын-өстен тикшереп чыгарбыз...

—Монда гына ял итәсезме?

—Хатын янына кайтыйм әле мин. Иртәнгә әзер бул!—диде ул бармак янап Хәнәфигә.—Кара аны!

Һәм кулын салфетка белән сөртеп балык өстенә ташлады да, урыныннан кузгалып, ишеккә юнәлде.

—Янадан очрашканга кадәр сау булып торыгыз!

Хәнәфи аның артыннан җиңел сулап карап калды. Ул тизрәк дусларын илтеп куярга ашыга иде. Чөнки бүген караңгы төшүгә бик мөһим мәсьәләне хәл итәсе бар: Мозаффарны кая да булса яшерергә кирәк иде.

## Тоткынны кая куярга?

«Дэу-Нексия» яртылаш балчыкка каткан, түбәсеннән күксел икәне беленсә дә, аскы өлешенең төсен чамалау авыр иде. Әле генә кунакларын «Джип-Чероки» белән озатып кайткан Хәнәфинең моны күреп, болай да сытык чырае тәмам бозылды: явар-яумас яңгырдан шушы кадәр пычранырга каян җай табалардыр! Машинадан аның каршына чыгып баскан Кырысның үзен күр тагын: өстендә һаман шул бер ала-кола ярым хәрби форма. «Ташла шул чабарыңны, Чечняда түгелсең!»—дип әйтеп тә карады инде аңа Хәнәфи. «Ыштансыз йөрергәме әллә?»—дип дорфа җавап бирә Кырыс. «Башка ыштан бетмәгәндер ләбаса!»—«Сиңа барыбер түгелмени? Эш эшләнә бит».

Кыяфәтенә карарлык түгел, сагыз чәйни үзе житмәсә. Таптылар гадәт! Телевизорлардан күренгәне бар: кайбер президентларның тән сакчыларына кадәр лач-лач сагыз чәйнәп йөри!

Киң таралган бу яман гадәтне дә Хәнәфинең жене сөйми иде. Ләкин сакаллы сабыйны әдәп-тәртипкә өйрәтер чак түгел иде.

Ул, машина янында баскан килеш кенә ике авыз сүз белән хәлнең мөшкеллеген аңлатты: иртәгә иртән хуҗа бөтен ихатаны тикшереп чыгачак. Һәммә нәрсәне тәртипкә салырга кирәк булыр. Барыннан да бигрәк, Мозаффарны аның күзенә чалындырырга ярамый. Димәк, аны башка берәр жиргә күчереп торырга туры килер. Вакытлыча, бер-ике көнгә генә. Хуҗа Казанда, мөгаен шуннан артык юанмас.

Моны ишеткәч, Кырысның чыраенда астыртын, кинәнүле көлемсерәү чагылып узды. «Әһә, миннән башка бер эшең дә бармыймы?»—дигәнне аңлата иде бу.

—Эшлибез аны, элементарно,—диде аннары.—Безнең Левченко поселогында бик аулак куышлар бар. Яки Жилплощадкада. Эт белән эзләсәләр дә таба алмаячаклар. Егетләр бик ышанычлы.

Хәнәфи һаман әле сагыз чәйнәп торган Кырысның чыраена нәфрәт белән текәлде.

—Бу эшкә син ничә кешене катнаштырмакчы буласың тагын?

—Кешесез булмый бит инде.

—Тап бер жаен! Синнән, миннән гайре беркем дә белмәсен! Еракка олактырма! Күз алдыңдарак булсын! Хакыңнан тормам!

Кырыс башын кырын салып соры болыт каплаган күккә карады, гүяки аннан вак янгыр аша ниндидер кинәш көтте. Менә аның чырае яктырып китте:

—Бар андый бер аулак урын.

—Нинди аулак урын?!

—Анда кергән-чыкканны санап бетергесез! Ишегалдында кафе, ишек төбендә каравылчы утыра.

Кырыс үзеннән шактый тәбәнәк Хәнәфигә баласытып карап куйды.

—Нәкъ менә шуңа күрә югалганны аннан эзләргә берәүнең дә башына килмәячәк тә инде,—дип дәвам итте Кырыс, шәкертенә сабак аңлаткан мөгаллим тавышы белән.—Аның бакчасында шәп кенә куыш бар. Шушындый очрак өчен махсус ясап куйган шикелле. Бер кешегә менә дигән. Ишек-тәрәзәсе юк, тирә-ягын кычыткан баскан. Төнлә илтәбез дә тыгабыз шунда.

—Ишексез булгач, ничек тыгарсың соң син аны?

—Түбәдән төшерербез. Түбәсе чәрексез `күренә, калайлары купкалаган.

—Кычкыра башласа?

—Ә нәрсәгә аны кычкыртып торырга?

—Ә ничек кычкыртмассыз?

Кырыс, чәйнәвеннән туктап, Хәнәфигә аңгырага карагандай текәлде. Аннары җилкәсен сикертеп:

—Аның чарасы бик гади инде: авызын томалыйсың,—диде.

—Син киткәч кычкырса, дим!

—Аны кем ишетсен! Кеше-кара йөри торган җир түгел лә.

—Шул куышта адәм баласы күпме җан асрар дип беләсең?

—Бер атнага берни булмый. Әнә, телевизордан күрсәтәләр бит, җир тетрәп, хәрәбәләр астында исән калган кешеләрне икешәр атнадан соң тапкан очраклар бар.

Хәнәфи пошаманлы уйга калды: әлбәттә инде, сабакташынны ташландык будкага тыгып кую акылга сыя торган гамәл түгел иде. Андыйларны шул борынгы заманнарда кансыз байлар, үзләренең кальга-крепостьларында гына эшли торган булганнар... Әмма бүген шуннан башка чара да юк иде.

Икенче яктан уйлап карасаң, нәрсәсе бар аның ул хәтле? Жылы матрас, юрган, мендәр төшерергә кирәк булыр. Каплы су, печенье-мазар. Бер кечкә кер мичкә, дигәннәр. Иртәгесен, бәлки, һәммәсен бүтәнчә хәл кылып булыр.

—Тик сак булыгыз, пырдымсыз кыланмагыз!—диде ул ризалыгын белдереп.

—Обижаете, шеф!

—Мин монда булмыйм, үзегезгә кала. Кайчан алып китәсез?

—Иң җайлы чак төнге сәгать өчләр тирәсе инде.

—Патрульгә юлыга күрмәгез тагын.

—Ул сәгатьтә ментларны дә йокы баса.

Сүз дә юк: хәтәр ният иде бу. Әмма Хәнәфи башка чара тапмады, шунлыктан ризалашмый булдыра алмады.

## Таш капчыкта

Ике култык астыннан аркан белән бәйләнгән хәлдә таш капчыкка убылгач, Мозаффар үзен яман төш күргән кебек хис итте. Ни өчен аны бирегә китереп тыкканнарын аңлаудан тәмам гаҗиз иде ул. Нәрсә

кирәк Хәнәфигә? Куркытырга гына маташуымы, әллә бөтенләй юк итеп, котылырга ниятләгәнме?..

Бу инде сиңа яшерен остаханә түгел—анда урының корыда, жылыда, яктыда иде. Бирелә исә озак чыдап булмаячак. Моннан аны чыннан да тиз генә таба алмаячаклар... Кай төш икән соң бу? Җайсыз, сасы багажникта килгәндә, ул әлләни ерак китмәгәнннәрен чамалады чамалавын. Ләкин каян кая барганнардыр бит...

Багажниктан сөйрәп чыгарганда, аның күзләрендәге бәйне тагын бер тапкыр тикшереп, тыгызладылар. Аннары култык астыннан бау белән бәйләп, каядыр өскә өстерәп алып менделәр дә, аска томырдылар, тәнне яман авырттырып, бауны кире суырып алдылар. Артыннан нииндидер йомшак әйбер ишелде. Әллә соң терелэй күмеп куяларmы? Бу уйдан Мозаффар тирләп чыкты. Кабаланып капшанды—йомшак нәрсә сырма булып чыкты. Аннары өстән сузылып юрган төште, нииндидер вак-төяк коелды. Алары пластик шешәләр, кәгазь каплар—җан асрарлык азык-төлек иде булса кирәк.

Димәк, аны биредә юк итәргә теләмиләр. Бусы бераз хәл керткәндәй итте. Ул сырманы астына салып, юрганга төренеп утырды. Өстә, кайдадыр югарыда калай шалтырады. Караңгылыкка күнеккән күзләр анда яктылыкны шәйләде. Башта киңрәк тоелган яктылык чыганагы шундук тараеп, сызык кына булып калды—куышны өстән томаладылар булса кирәк.

Бу ни дигән сүз? Мондый хәлләр элекке заманнардан калган мажаралы романнарда гына тасвирлана лабаса! Әллә аны еллар буена шушында ябып тотарга җыеналармы?

Үче шулхәтле көчле микәнни соң бу Хәнәфинең? Көнләшүеннән тәмам шашканмы әллә? Кешене тотып алып ябып куеп, ирегеннән мәхрүм иткән өчен уголовный кодекста бик каты маддә бар. Ул үтерү, көчләү кебек үк бик авыр җинаять санала һәм аның өчен җәзаның да катысы бирелә. Ничектер шулай колакка чалынган. Ничә ел бирәләр икән?!

Мозаффар үзенең законнарны белмәвенә, алар белән бөтенләй кызыксынмавына инде менә ничәнче тапкыр үкенеп куйды. Ничек диләр әле? «Теләнеп йөрмәм, төрмәгә кермәм, дип ышанма!»—дигән мәкаль дә бар бит. Әйе, алга килми белеп булмый башның ни күрәчәген. Мозаффарның хәзерге хәле төрмәдәгедән яман. Адвокат чакырып була торган түгел...

Шулай да кул кушырып утырырга ярамас. Нәрсә дә булса булса эшләргә, кыймылдарга кирәк! Мозаффар үсмер чагында укыган китапларны, граф Монте-Кристоны исенә төшерде. Ул, әнә, зинданнан җир асты юлы казып котылган.

Үзең тырышмасаң, тырмашмасаң булмый. Казып карарга кирәк.

Мозаффар тирә-ягын капшарга керешә. Өстән ташлаганнары барсы да йомшак әйбер—пластик шешәләр белән печенье каплары гына икән. Алай да кармалана торгач, почмакта кирпеч сыныгы табылды. Туфрак йомшак иде. Бу аның күңелен җылытып җибәрде. Ул, тырнакларын авырттырып, сыдырырга тотынды...

...Кырыс белән Кармак кычытканнар арасында беразга тоткарландылар.

—Мин бер җиргә барып килим әле, чак кына сабыр ит,—диде Кармак. Һәм Кырыс авызын ачканчы бакча караңгылыгында эрегәндәй кинәт юкка да чыкты. Берәр нәрсәгә кулы кычытса, туктатам димә инде син аны! Тавыш куптарып булмый, көтеп тормый хәлең юк.

Күпмедер вакыттан соң куак арасыннан уфылдап килеп чыкты бу.

—Булды,—диде бик канәгать пышылдап һәм кочагындагы авыр әйберне юлдашының каршысына китереп куйды. Баксаң ул—сын икән! Язучылар

йортының эчке баскычы култыксасына куелган шәмдәлле хатын!

—Нәрсә син моны сөйрәп йөрисен әле?—диде Кырыс ачуланып.—Бүсерең чыкмасын!

—Яхшы малдан бүсер чыкмый!

—Җәтрәк кылан! Тизрәк ычкынырга кирәк моннан!

Бәхәсләшеп торыр чак түгел, алар икәүләшеп сынны бакчаның аулак ягына алып чыктылар. Машинаны шунда калдырганнар иде—йөкне арткы утыргычка урнаштырдылар да, тизрәк китеп бару ягын карадылар. Рульгә утырган Кырыс олы урамга чыккач мырламый чыдый алмады:

—Шундый чакта да нәфесеңне тыя белмисең,—диде.—Моннан күпме генә металлом чыга инде!

—Аны кем металломга тапшыра? Эретергә дә беләзек ясаучыга сатарга. Мин андыйны беләм.

Чыннан да бакыр беләзек мең сырхаудан шифа бирә, дигән хорафатның бик киң таралган чагы, аны күпләр сатып ала иде.

Мондый табышны шефның, ягъни Хәнәфинең күзенә чалындырырга ярамый иде. Шуңа күрә , Самаркин ихатасына кайткач, алар сынны ихата түрендәге кечкенә генә сарайга, себерке, көрәк-сәнәк, тырма ише кирәк—ярак арасына яшереп куйдылар. Чөнки Хәнәфинең ак, чиста, тырнаклары ялтыратылган кулларын пычратып, вак-төяк арасында актарынмаячагын яхшы беләләр иде.

... Бу вакытта Мозаффар манма тиргә батып тырмана да тырмана иде. Менә кинәт чинаган тавыш колакны ярып, тешкә тиде—ташка таш ышкыла башлады. Куыш идәнендәге туфрак юка катлам гына булып, астына тоташ бетон идән җәелгән иде.

Мозаффар хәлдән таеп сырма өстенә ауды. Нык арганын, тәмам талчыкканын тойды. Зиһене томаланган кебек булды, күзләре йомылып, тәне оеп китте. Аның күз алдына Нурзифа килеп басты. Ап-ачык булып, кояш яктысы төшкән остаханәсендәге кебек. Бер чакны «Казан гүзәле» дигән картинасын язганда, Мозаффар аның нык үзгәргәнен тоеп алган иде. Әйе, кинәт күзләре ачылгандай булды да, дөньясын онытып, кызның юка кофта аша томрап торган йомры күкрәкләренә, тыгыз, ипле сынына, төз аякларына текәлеп, шактый озак сүзсез-хәрәкәтсез басып торды. Күңелен соклану катыш үкенү ачысы сызландырды аның. «Кыюрак буласым калган,—дип уйлады ул.—Ничек кенә булса да бераә чарасын табарга, киемен салдырып, бөтен гәүдәсен, тәненең барча чалымнарын киндергә төшерергә иде. Моны ешрак эшләргә кирәк иде. Һәр елны бер тапкыр... Табигатьнең иң камил җимешенә, алиһәгә тиң кыз баланың тәне ничек үзгәргәнен, өлгергәнен, житлеккәнен тасвирлап барырга иде. Гомеренең иртә язында—умырзая кебек чагында... Аннары ак күбеккә күмелгән алмагачка тиң чорында... Әйе, аны күңел бөреләре ачылган елында нәкъ менә алма бакчасында тасвирларга кирәк иде. Мозаффар кояшлы иртәне, алмагачларны ап-ачык итеп, бик еш күз алдына китерә иде. Тик менә алар арасында үсмерлектән яшьлеккә күчеп килгән кыз баланың буй-сынын гына иртәнге томан урап, күзне адаштыргандай итә иде. Аны ап-ачык күрү-тасвирлау өчен Нурзифаның киемен салдырып, каршыңа бастырырга, шул кыйфәтендә шактый озак тотарга кирәк иде шул....

Әмма аны бу гамәлгә ризалату мөмкин эш булып тоелмады. Балалыктан чыгып кына килгән елларында бигрәк тә.

Дөрес, бервакыт Мозаффар бөтен кыюлыгын җыеп, әйтеп тә караган иде:

—Син бер вакыт тап әле,—дигән иде.

—Нәрсәгә?

—Миңа позировать итәргә.

—Мин сиңа гел позировать итәм бит инде, Мозаффар абый...

—Ә син... натурщицалар кебек...

Нурзифаның бит очлары кызарынып чыкты, иреннәре тетрәнде, күз керфекләренә яшь тамчылары эленгәндәй булды... Чәчрәп каршы әйтмәде, әмма ризалашмаячагы көн кебек ачык иде.

Шул рәвешле бу матур хыял тормышка ашмый калды. Ә бит нинди яхшы булачак иде! Кайсы да булса берәр рәссамның андыйны эшләгәнен Мозаффар белми дә!

Дөрес, ахыр чиктә Нурзифа аның хәлен аңлады. Мен рәхмәт ана: иң затлы, иң татлы, юкәдәй чәчәккә төренгән чорын тасвирларга мөмкинлек бирде. Аның ничек остаханәгә килеп кергәнен, ничек итеп киемнәрен салганын, ничек ятакка урнашканын күз алдына китергәч, салкын таш куышның диварларыннан җылы дулкын китереп бәргәндәй булды, Мозаффарның бөтен тәне тетрәнеп куйды. Әйе, илһам килгән чакларда иҗат кешесенең мәгъшукасын сөеп-назлап ләззәтләнүгә тиң тойгылар кичерүе хак шул. Нурзифаның соңгы портретын язганда, Мозаффар нәкъ шундый халәттә иде.

Тик сизә күңеле: мондый хәл бүтән кабатланмаячак. Сүзләрнең кирәге юк, Нурзифаның йөзеннән, күз карашыннан, тәвәккәл хәрәкәтләреннән, хәтта сулышыннан да ап-ачык аңлашылды: бу очрашу—аның хушлашу бүләге иде. Ул, мөгаен инде, башка беркайчан да, киемле хәлендә генә булса да, Мозаффар каршында өлге булып тормаячак.

Ләкин аны бөтенләй үк башыннан чыгарып ташлый алмас бит инде! Бигрәк тә мондый чакта, Мозаффарның югалганын белгәч, борчылыр, эзләр, бөтен шәһәрне кузгатыр! Ул шундый: тәвәккәл, көчле, ышанычлы. Чарасын табар, коткарыр!

Буй уй юаныч бирде, тынычландырып җибәрде. Мозаффар тирән йокыга талды.

## Хуҗаның күзе күпне күрә

Самаркинның күзе без иде. Шулай булмаса, бу хәтле байый алыр идемени ул?

Иртәнге сәгать җидедә капка төбендә, давыл хәбәрчесе булып, ак «Мерседес»ның клаксоны кат-кат чинады, капка ачылуга ихатага өермә бәреп кергәндәй булды. Хуҗа барда холуйлар йоклап ятарга тиеш түгел! Ике каравылчы йөгереп чыгып капканы ачтылар һәм тавышсыз шуышып кергән машина каршында ихтыярсыздан бил бөктеләр.

—Я, күрсәт ниләр майтарганыңны!—дип кычкырды ул машинадан төшкәндә, күзен тырнап ишектән чыккан Хәнәфигә.—Каян башлыйбыз?

—Өстән башларга була,—диде Хәнәфи.—Анда без бик яхшы кышкы бакча ясап куйдык.

—Син нәрсә? Һәр эшне нигезеннән башларга кирәкне белмисеңме әллә? Кая, подвал ачкычларың янындамы?

Хәнәфи Мозаффардан котылганына эченнән мең шөкер укып, аскы катның тимер ишеген шалтыратып ачты. Алгы бүлмә аша узып, остаханәгә күз салгач:

—Сәер халык сез, рәссамнар,—дип куйды Самаркин.—Тәрәзәсез җирдә рәсем ясау рәхәтмени?

—Үзенә күрә бер производство ачып булмасмы, диган идек.

—Ниткән производство ул?

—Мин сезгә байтактан әйтергә йөри идем...

—Әйт сон!

—Менә монда бик кызыклы альбомнар бар...

Шулай дип, Хәнәфи өстәлдә яткан зур, калын, авыр китапны алды да, битләрен ачкалап, төсле сурәтләргә бармагы белән төрткәләде.

—Атаклы рәссамнарның картиналары болар. Шактые эзсез югалган...

—Ну, югалган. Шуннан?—дип ашыктырды хужа каушап төшкән Хәнәфине.

—Моннан карап аларның күчермәләрен ясарга була...

—Синең андыйга да осталыгын бармы әллә?

—Минем вакыт юк. Үзегез беләсез... Ниятләсәк, оста кешене табарга була...

—Син нәрсә, минем галереягә җыен чүп-чар тутырмакчымы әллә? Анда чын картиналар гына булырга тиеш! Кара аны!

—Сезнең өчен димим... Андыйга кызыгучылар да күп бит... Алалар да өйләренә элеп куялар. Күргән кешегә чынмы-түгелме икәнен әйтеп тормасаң да була...

—Кая, бир әле!—Самаркин Хәнәфи кулыннан китапны тартып алды да, актаргалый башлады.

—Кайсылары бик кыйммәт инде боларның...—диде уйланып.

—Әллә ничәшәр миллион тора!

—Уйлап карарга кирәк... Минем анда әлегә урын житәрлек. Күчермә икәнлеге күзне ертып тормаса...

—Жиренә житкереп эшлибез инде аны! Экспертлар аера алмаслык итеп!—диде Хәнәфи жанланып.

Самаркин исә бу хакта озак уйларга теләк белдермәде.

—Бакчаны, пляжны яхшы эшләячәкбез, дип мактанган идең,—диде.— Әйдәле, карап карыйк!

Көн сүрән булуга карамастан, бакча чыннан да бик ямьле иде. Яр буеның өске киртләрендә тыгыз келәм булып сусыл чирәм үскән—арасында ник бер тузганак күзне ертып торсын! Футбол мәйданнарына чәчә торган үлән иде бу, орлыгын америкадан кайтарталар икән. Шул тере келәмгә затлы бизәк ясап ачык-кызыл бегония, зәңгәр, шәмәхә, алсу миләүшәләр, ак ромашкалар, тагын исемнәрен атап бетермәслек гөлләр күкрәп чәчәк аткан. Уртада, кечерәк фонтан тирәсендә, аркалы эскәмияләр өстенә шау чәчәккә күмелгән үрмәле розалардан куышлар ясалган.

Ялтырап торган чуерташ җәелгән кин сукмак кырыйларында—зәңгәр чыршылар, Ихатаны әйләндереп алган, өсте киртле кирпеч стена буйларында алмагач, камыр агачы, миләш, каен үсә. Бер-ике урында хәтта куе ябалдашлы куштан каштаннар да бар, аларның эре чәчәк тәлгәшләре шәмдәл кебек өскә караган.

Казанда мондый бакчалар күп түгел, яна байлар андыйларны берничә ел элек кенә ясый башлады. Аның осталары—ландшафт дизайнеры дигән белгечләр дә соңгы вакытта гына пәйда булдылар.

Хәнәфи бар булган мөмкинлекне файдаланды, шәһәрдәге яшеллек һәм су хуҗалыгындагы кайбер белгечләрне дә эшкә җикте. Алар белән килешү төзелгән, атнага ике тапкыр аннан машина белән биш-алты кеше килеп, һәммәсен карап, утап, йомшартып, утыртасын утыртып китәләр иде.

—Ярыйсы,—диде хужа.—Кеше алдында йөз кызарырлык түгел.

Яр буендагы көймәләр, ясалма комлык, киенү-чишенү урыннары, мунча да анда яхшы тәэсир калдырды булса кирәк. Һәрхәлдә, күтәреп мактамаса да, салып таптамады. Соңгы көннәрдә Хәнәфинең күңелен туктаусыз изеп торган авыр таш кечерәеп киткәндәй булган иде инде...

Бәла аяк астыннан, дөресрәге себерке, көрәк-сәнәк, тырма ише кирәк-

яракны саклый торган кечкенә сарайдан килеп чыкты. Самаркин аның ишегә борынын тыгар, дип кем уйлаган! Хәнәфинең ул ишекне ачканы да юк иде. Ә бу каерып ачты, шундук себерке артыннан бронза сын тартып чыгарды.

—Ах черт! Бигрәк авыр! Бу нәрсә?

Хәнәфи өнсез калды. Кем китереп тыккан моны? Бу бит... Язучылар йортыннан түгелме? Әллә шуның парымы?

Ярый әле Самаркин сын белән мавыккан, аны әйләндереп-тулгандырып карый иде, юлдашының хәлен сизмәде.

—Синекеме соң бу?

Ихатада ни барын белмәгәненңне әйтеп булмый, Хәнәфи үзен көчләп диярлек:

—Минеке...—диярга мәҗбүр булды.

—Ник чыгарып ташладың аны монда?

—Кая куясын хәл итмәгән идем әле... Баскыч борылышына куяр өчен ясалган ул. Мондагыга туры килеп бетми. Интерьерга ятышмый,—дип мыгырданды Хәнәфи.

—Баскычка ярамый, дисең инде... Бездә баскыч бер генә түгел лә! Ә беләсенме, кайсы интерьерга шәп булачак ул? Минем галереяга! Кулына борынгы шәмдәл тоттырабыз да бастырып куябыз. Күргәннәрнең күзе тоз булсын. Мәле, тот. Юсыннар, тазартсыннар да, яхшылап төреп минем машинага салсыннар. Мәскәүгә алып китәм мин аны.

Хәнәфи утлы күмер тоткандай калтыранган куллары белән сынның муеныннан эләктерде дә, бер якка янтаеп, эре-эре адымнар белән атлап барган Самаркин артыннан олы йортка таба китте.

Көтелмәгән хәлләр моның белән генә дә бетмәгән икән әле. әле. Аш бүлмәсенә керүгә, Самаркин туп-туры дивардагы каплаулы рамга таба юнәлде.

—Ә моны ник яшерәсең?

—Эшләнеп бетмәгән әле ул.

Самаркин киндерне йолкып алды да, бер-ике адым чигенеп, рәсем иң яхшы күренә торган ноктаны эзләп, унга-сулга чайкалды.

—Нәрсәсе эшләнеп бетмәгән? Артыгын тырышсаң, әйберне бозып ташлавың да бар. Син ясадыңмы соң моны?

—Мин...

—Син шундыйны яза аласыңмыни?

—Рәссам ла мин,—диде Хәнәфи каш астыннан

—Мин сине мондыйга ук сәләтле дип белми идем.

Самаркин кыска сары керфекләрен дә какмыйча, озак карап торды.

—Ник чишендереп ясамадың?

—Болай матур түгелмени?

—Гойяның картинасындагы рәвештә ята бит бу. Рамы ике катлы булырга тиеш!

Шулай дип ул, рамны дивардан алды да, аскы катын каерып чыгарды.

—Ах син шайтан!—диде. —Кем бу?

Моны һич көтмәгән Хәнәфи бөтенләй югалып калган иде.

—Ну... Бер кыз... Натурщица диярга була...

—Шә-әп!.. Син безне таныштырырга тиеш!

—Белмим шул... Ничек булыр икән?

—Аны каян табып була?

—Каян дип... Эшендә утырадыр.

—Ах, ул эшли дәмени әле? Ресторанда-фәлән түгелдер бит? Андыйга охшамаган.

—Фирмада эшли. Мебель сата.

—Мебель сата? Бу кызмы? Нишләп сез аны андый җирдә тотасыз? Яле, шалтырат үзенә! Урынында микән? Хәзер барып киләбез!

Шылтыратмыйча калып булмый иде. Кызганычка каршы, Нурзифа трубканы тиз алды. Эш урынында утыра икән...

Берничә минуттан ак «Мерседес» Казансу күпере аша выжлап чыгып бара иде инде.

Хуҗаның кәефе шәп кенә түгел, ничектер уйнак та иде. Бераз тынып барганнан соң ул, авызын ерып, үзе белән янәшә артта утырган Хәнәфигә борылды:

—Беләсеңме, минем башка бик шәп идея килде әле. Синең бу картинаңны галереяда башкалар белән беррәттән элмәскә кирәк. Аерым урнаштырырбыз без аны. Минемчә, бильярд бүлмәсендә аның урыны.

Озакламый Мәскәүдә ачылачак галереядә зур залдан тыш хатын-кызлар өчен аерым, ир-ат өчен аерым кунак бүлмәләре җиһазландырылган иде. Соңгысында сигара тарту, кальян суыру, карта уйнау өчен бөтен уңайлыклар булдырылган, кыйммәтле бильярд өстәле дә бар иде.

—Шунда эләргә кирәк аны,—дип кабатлады Самаркин очынып.—Икесен янәшә. Ачылышына бер кызык та ясап була. Беләсеңме нинди не?

—Их, сездәге акыл миндә булса икән...—диде башын томан сарган Хәнәфи авыз эчендә ботка пешергәндәй.

—Шул-шул менә! Берәүнең дә андыйга башы житкәне юк әле. Болай итәргә кирәк: киенгән гүзәлкәй белән чишенгән гүзәлкәйне түргә янәшә элеп куябыз. Алар янында... Беләсеңме нәрсә?

Хәнәфи аптырап аңа текәлде. Нәрсә тагын?

—Картиналар янында гүзәлкәйнең теп-тересе нәкъ шул позада ятып торсын! Чишенгәне рәвешендә!

Самаркин, юлдашының йөзе нинди галәмәткә кергәнне күреп, шаркылдап көлеп җибәрде.

—Ну кызык булачак! Селәгәйләре агачак мәскәүләрнең. Минем галереяга капчыклап акча агылачагын күз алдына китерәсеңме? Дерипаскасы да, Прохоровы да, Жириновские—берсе дә читтә калмаячак!

Аның алагаем эре бәдәненнән, куе тавышыннан, шаркылдап көлүеннән, ташып чыккан дәртеннән машина эче эсселәнеп, кысанланып калган иде. Менә ул бөтен гәүдәсе белән Хәнәфигә борылды да , аның салынкы иңенә каты кулы белән суккалады.

—Нәрсә жебеп калдың? Эшләргә кирәк моны! Ята торган кушеткасының дә нәкъ шунысын моннан алып китәрбез. Тәненә ураган ефәген дә! Иртәгә үк төяп озатырсың. Ә син,—дип рульдә утырган ак якалы, кырган башлы егетнең иңенә каккалады ул, —йөк машинасын кайгырт!

—Так точно, эшлибез аны,—дип башын бормый гына солдатларча төгәл җавап бирде тегесе.

Алар барып кергәндә, Нурзифа өстәл артында утыра иде. Самаркинны күргәч, ихтыярсыздан аягөсте торып басты, чөнки бу кешенең гади сатып алучы гына түгеллеген, ниндидер гадәттән тыш йомыш белән йөргәнлеген бер күз салуда чамалап алды.

—Исәнмесез! Хуш киләсез!—диде ул. Мондый кешене сатучы нәкъ шундый сүзләр белән каршы алырга тиеш иде.

Самаркин мәгънәле елмаеп аның каршына барып басты да:

—Так вот ты какая! Привет, привет! Менә син нинди икәнсең, ә! —дип калын, зур кулы белән кызның яңагын сыйпады. Нурзифаның йөзе үзгәреп китте, әле генә елмаюлы күзләрендә чиркану белән ачу катыш очкын кабынды, ул үзе дә сизмәстән шалт итеп Самаркинның кулына сукты.

—Кулыгызны озайтмагыз!

—Ты смотри, какая строгая! Недотрога! Яратам шундыйларны! Болай булгач, борчак пешәчәк безнең!

—Сезнең белән борчак боткасы пешерергә җыенган кеше юк әле монда,—диде Нурзифа һәм Хәнәфигә таба борылды:—Мин сезне Мозаффар абый турында берәр яхшы хәбәр китерерсез дип уйлаган идем!

—Ниткән Мозаффар ул тагын?

—Безнең бер рәссамыбыз юкка чыккан иде, шуны әйтә,—диде Хәнәфи.

—А-а, әйе, кичә әйткән идегез шул. Сезнең абыегызмы әллә ул?—дип Нурзифага борылды Самаркин.

—Абыем урынындагы кешем.

—Слушай, красавица, әйдә әле без синең белән болай сөйләшик. Мин сиңа ул юлдан язган рәссамны табып бирәм.

Нурзифаның йөзе өметтән яктырып китте.

—Ә сез чыннан да аны таба аласызмы?

—Самаркин бит бу, Самаркин! Булдырмаган эше юк!—дип ничектер уфтанган тавыш белән әйтеп куйды Хәнәфи.—Әгәр теләсә, шәһәрне генә түгел, дөньяны актарта...

—Кирәк икән чит илләргә дә барып җитәрбез.—дип өстәде Самаркин.— Тик шунысы: мин сиңа ярдәм итәм, син миңа. Баш на баш

—Ничек ярдәм итә алыйм мин сезгә?

—Мәскәүдә бик мөһим эшләрем бар. Җитди мәсьәләләрне хәл итәсе. Миңа ышанычлы секретарь кирәк.

—Мин секретарь эшен белмим!

—Аның әлләни авырлыгы юк. Приемнарга барганда мине озатып йөрерсең.

Кызның йөзе алланып чыкты. Ул байларны озатып йөргән кызларның хуҗаларына нинди төр «хезмәтләр» күрсәткәнен гәзит-журналлардан укып, телевизордан карап белә иде, билгеле. Мондыйга бармагыңны тоттырсаң, кулыңны гына түгел, үзеңне суырып алачак та кабып йотачак. Эһ тә дия алмассың. Сүзен кире кагу да да куркыныч, мондыйлар көчле, үчле... Нишләргә? Аннан ничек котылырга, шул ук вакытта Мозаффарны эзләтү эшенә ничек дәртләндерергә?

Нурзифа бер тын булса да уйланырга мөмкинлек эзләп, салмак хәрәкәт белән өстәлә артына узды. Карашын аска төбәп:

—Ышанычыгыз өчен рәхмәт сезгә,—диде.—Тәкъдимегез бик кызыклы. Мин уйлармын...

—Нәрсәсен уйлыйсың аның? Синдәй кыз гомере буе мондый тишектә сөрсеп ятмас бит инде! Хәзер үк минем машинага чыгып утырасың да шуның белән һәммәсе хәл ителә.

—Хәзер үк булмас шул. Башланган эшләрне тәмамлыйсы бар. Хуҗадан сорарга...

—Телисеңме, шушы минутта мин бу фирманы сатып алам? Хуҗасы-ние белән. Кая чакыр әле үзен!

—Эш анда гына түгел...

—Ә нәрсәдә? Нәрсә син авыз эчендә ботка болгатасың? Миңа ышанмыйсыңмы әллә?

Шулай дип Самаркин пинжәк кесәсеннән телефонын алды да колагына куйды.

—Слушай,—диде кемгәдер.—Язып ал яисә исеңдә калдыр. Рәссам... Кем дидегез әле?—дип Хәнәфигә борылды ул.—Юлдашев? Әйе, Мозаффар Юлдашев. Юкка чыккан... Шуны табарга кирәк. Живого или мертвого!

Моны ишеткәч Нурзифаның йөзе тартышып куйганны күреп:

—Лучше живого,—дип өстәде.—Достань из-под земли, слышишь? Монда сиңа Хәнәфи ярдәм итәр, ул теге типны яхшы белә. Озакка сузма, хәзер үк һәммәсен эшкә җик. Нәтиҗәсен миңа хәбәр итеп торырсыз.

—Булды, синең теләк үтәлә, —дип Нурзифага борылды ул аннары.— Хуҗаңның номеры ничек? Хәзер аның белән саубуллаш та, киттек!

—Мин сезгә әйттем бит инде: эш анда гына түгел!

—Ә нәрсәдә тагын?

—Минем егетем бар!

—Аңа да әйт, хуш, сау бул, диген!

Нурзифа тирән итеп сулыш алды да, тавышын күтәрә төшеп:

—Ул минем ярәшкән кешем, без туйга әзерләнәбез!—дип ярып салды.

Монысы Самаркиннан бигрәк Хәнәфине аяктан ега язды.

—Юк сүз, —диде ул үзе дә сизмәстән.—Мин белер идем инде...

Бер аңа карады Самаркин, бер Нурзифага. Аннары өстәл янына ук килде дә, иелеп, кызның бәбәкләренә текәлде, таза тешләрен күрсәтеп:

—Ну, девка, смотри!—диде.—Самаркинны алдарга маташу бик кыйбатка төшә! Шуны белеп тор.

—Мин дөресен сөйлим. Туй көнебез билгеләнгән инде. Тик әлегә читләрдән...—Нурзифа ялт итеп Хәнәфигә күз сирпеп алды...—Кешекарадан сер итеп тота идек.

—Шулаймыни? Бу егет сиңа читмени? Алай микән? Что-то темните вы тут. Болайга киткәч, син миңе кияүең белән таныштырмый кала алмыйсың инде. Мин аны күрергә телим. Бүген вакыт юк, иртәгәгә дип килешик. Очрашуны син оештырырсың!—дип, Хәнәфигә әмер бирде Самаркин.

## Җирән чәч, чуар йөрәк

Мозаффарның күздән ычкынып торуына дуслары, бераз сәерсенсәләр дә, гайре табигый хәл дип кабул итмәгәннәр иде. Бигрәк тә беренче көннәрдә. Талантлы егетнең башкаен ярсу йөрәге кая алып китмәс? «Кая бармый,ниләр күрми ир-егеткәй белән лә ат башы»...—дип юкка гына җырламыйлардыр.

Зөфәр Назиров белән дә андый хәлләр булгалап тора. Шагыйрьләрнең йөрәге чуар икәнлеге һәркемгә мәгълүм бит. Әгәр дә шулай булмаса, шигърияттнең бакчасында аллы-гөлле гөлләр ничек үсәр иде? Гүзәл затларның төрлесенә кабынган йөрәк хисләре белән сугарылган алар, шуңа шундый матурлар.

Зөфәрнең шигъри бакчасы исә күзләрне камаштырырлык иде. Андагы чәчкәләр шундый якты, чиста төсләр белән балкый, шагыйрьнең ихласлыгына, хисләре кайнарлыгына бернинди шик тууы мөмкин түгел. Әйе, ул һәрвакыт ихлас булды, кемгә генә гашыйк булмасын, бу мәхәббәтем иң чыны, иң соңгысы, мәңгелеге дип ышанды. Үзе белән бергә укыган хыялый карашлы яшь шагыйрә Розага дисеңме, редакциядә бер күрүдә аңа тилереп гашыйк булган кыйгач кара кашлы, миһырбанлылыгы бөтен кыяфәтендә чагылып торган беркатлы Фәрдиягә дисеңме... Хәер, анысы гомерлек булып чыкты—алар өйләнештеләр.

Бирелә Зөфәрнең башын әйләндергән кызларның һәммәсен дә санап китеп булмый, исәбен алырга теләгән кеше аның шигырь китабын алып укысын. Андагы мәхәббәт шигырьләрен аерып алып санайсың да, икегә-өчкә бүләсең. Чөнки бер мәгъшукага багышлап өчтән артык шигырь язып булмый. Бу нисбәттән караганда, ул рәссам Мозаффардан бик нык аерылып тора иде шул. Рәссамнар алар вакыт узган саен кешенең тышкы

кыяфәтендә һәм рухында булган үзгәрешләрне бик сизгер тотып алалар һәм тасвирлыйлар. Шунлыктан бер кешенең гомер агышында, язмыш борылышларында үзгәрешен генә түгел, яшәешнең асыл мәгънәсен чагылдырырга омтылалар. Ә шагыйрь ул асылда мәгъшукасы хакында түгел, үз кичерешләре турында яза...

Алай да өйләнеп алганнан соң беренче баласы туганчы Зөфәр, үз тормышындагы үзгәрешләрдән башы әйләнеп, янынннан үтеп-сүтеп торган кыз-кыркынга күз салмыйрак йөргән иде. Шигырьләре дә башлыча Фәрдиягә, дөньяга яңа кешенең килгәнен көтүнең рәхәтлегенә багышланган иде. Әмма бала төннәр буе елап тенкәгә тиеп беткәч, аңа инде күз дә күнеккәч, гаилә тормышы чәчәкле болында истирәхәт кылып йөрүдән бигрәк тир агызып җир сөрүгә охшап калгач, шагыйрь күңеле янадан уйнаклый башлады. Әйе, Зөфәр кебекләрне никах язуы белән зынҗырлап булмый шул! Аларны гаепләргә дә ярамый: әгәр ул берне генә яратып, берәү белән генә гомер итсә, шигырьләрендә ни кызык калыр иде?

Фәрдия—сизгер күңелле, зирәк хатын, бу хакыйкатьне яхшы аңлый иде. Ул гынамыни! Күпме башка шагыйрьләрнең, әдипләрнең гомер юлдашлары шулай аңлап, түзеп, ирләренең вакыт-вакыт «уҗымга кереп алу»ларына күз йомып яши! Мондый чакта икенең берсе бит инде: йә түзәсең, яисә ташлап китәсең. Зөфәр кебек талант иясе белән аерылу исә үзе зур ахмаклык булыр иде. Андый танылган кешене, халыкның сөекле улын тагын каян табасың?

Зөфәр үзе дә балаларын әтисез калдыра торган намуссыз адәм түгел, берничә аймы, берәр елмы башы әйләнеп йөргәннән соң һәм шигырь сөючеләрнең күңелен дәртле җырлары белән янә бер тапкыр ургытып алганнан соң, бераз басынкылана һәм кичләрен редакциядән туп-туры өенә кайтып, якты зәңгәр күзләре белән хәләл җефетенә мөлдерәп караштырып, улын тезендә биетеп утыра торган иде. Шәүкәт Галиевнең барыбызга да таныш җыры:

> Ничә тапкыр гүзәлләрне күреп,
> Минутлык хискә исердем,
> Айнудым да, сөенеп туялмыйча,
> Тагын сине искә төшердем,—

аның холкына да бик тә туры килә иде.

Хәер, күпчелек очракта аның очынып мавыгулары яңа матур шигырьләр тууга этәргеч булып кына кала, гөнаһсы исә күз зинасыннан түбән төшми иде. Шагыйрьләргә сөюнең «платонический» дигәне аеруча хас бит ул.

Бу көннәрдә Зөфәрнең чираттагы сулга каерган чагы иде. Университетта укучы бер яшь кыз аның шигырьләрен урысчага тәрҗемә итеп, телевидениедән бик матур тапшыру оештырган иде. Казан кызы Елена Борисова яшьли татарлар белән аралашып үскән, безнеңчә чатлатып сөйләшә белмәсә дә, аз-маз аңлый, халыкча әйткәндә «түбәсе тишек», ягъни безнең сүзләр аның миенә саркып керә, әмма иң мөһиме, аның дуслары арасында татарлар күп һәм шунлыктан ул халыкның рухын аңлый, шагыйрьләргә ихтирам белән карый иде. Бишенче курста укып, шул ук вакытта телевидениедә дә эшләп йөрүче бу кыз яшьтән үзе дә шигырьләр яза, хисле, мавыгучан зат иде. Шуның өстенә табигать матурлыкны да җәлләми биргән иде үзенә чукынмышның! Озын буйлы, сылу гәүдәле, ак йөзле, алтынсу чәчле—бер кашык бал белән йотарлык инде менә! Шигырь укыганда күксел күзләреннән сирпелгән, иреннәреннән бөркелгән яктылыкны, бит очларының алланып чыгуын күрсәң! Түн күңелләр дә эрер,

шагыйрь йөрәгенә ничек түзсен. Өстәвенә бергәләп иҗат итү дә аларны бер-берсенә магнит белән тарттыргандай итте. Уртак иҗат ике чакма ташны бер-берсенә бәрү кебек бит ул—очкыннар чәчрәп кенә тора. Һәм илһамнан җилкенгән йөрәкләргә ялкын үрләтми калмый да калмый инде.

Әйе, икәүдән-икәү очрашканда шигырьләр күп сөйләнде, күңел түреннән яңалары ургылып чыкты, аларны бер телдән икенче телгә күчергәндә бик күп көтелмәгән ачышлар ясалды. Шигърият бакчасында яңа гөлләр чәчәк атып, күзләрне камаштырды, семьяны гына түгел, бөтен дөньяны янә оныттырды.

Бәлигъ булган һәркем белә: андый чакта син инде үзеңә-үзең хуҗа түгел. Дөресрәге, акылың синә хуҗа түгел. Кичен эш вакыты бетәргә берәр сәгать кала, аяклары Зөфәрне редакция бинасыннан алып чыгып китә дә, трамвайга утыртып, «Мәскәү базары» дигән тукталышка илтеп куя. Ә аннан телевидение бинасы ерак түгел. Зөфәр базар белән шул бина арасында киләп сарып йөри башлый. Бер очта аның сукмагы чәчәкләр сата торган рәткә килеп терәлә. Һәм ул көрсенеп кесәсен капшый. Анда исә гадәттә трамвайлык кына акча калган була.

Бүген исә ана узган айны яшьләр журналында басылып чыккан шигырьләр бәйләме өчен гонорар биргәннәр иде. Ул, трамвайдан төшүгә, зур-зур өч роза сатып алды.

Леночканы очратмаса, чәчкә күтәреп өйгә кайтырга туры киләчәк иде, әмма ул кыз белән очрашачакларына тәгаен ышана иде. Чөнки яшь шагыйрәнең дә йөрәге тын түгел, аның да аяклары кич җитүгә шул тарафка тарта иде. Алар, әлбәттә, күрештеләр. Болай гына, очраклы кебек кенә. Икесенең дә башын томан сарган иде, ниләрдер сөйләшеп, көлешеп трамвайга утырдылар. Хәер, монысы гадәт буенча эшләнде: икесенең дә өйләренә юл шәһәр үзәге аша үтә, трамвайга утырып, башта озын урам буйлап, аннары чакрымга сузылган дамба һәм күпер аша киттеләр.

Көн саен күрешеп торсалар да, сөйләшәсе сүзләре бетәсе түгел иде. Чөнки Зөфәр яңа шигырьләр язган, Лена исә элеккеләрен тәрҗемә иткән икән. Үзе дә язган. Кыенсынып, Зөфәрнең күзләренә мөлдерәп карап, аларны укыды.

Вокзал янында трамвайларны алыштырырга кирәк иде. Менә шунда алар ялгыш трамвайга утырган булып чыктылар, Елга портына барып эләктеләр. Андагы кафега кереп тамак ялгап алдылар. Гонорар алган чак бит, өстәлгә бер шешә шампанский да килеп кунаклады... Сый-хөрмәттән күңелләре бихуш булып, соныннан алар чәчкәләрне көләч официанткага бүләк иттеләр.

Һәммәсен тасвирлап торуның кирәге юк, эчендә җаны булган һәркем үз гомерендә андый бәхетле сәгатьләрне кичерми калмый.

Шигырь балы белән шампан күбеге бергә буталса, эшләр була инде ул! Бигрәк тә Зөфәр белән Лена кебекләр арасында.

Алар кафедан чыкканда, караңгы төшкән иде инде. Вакыт соң, трамвайлар сирәк йөри. Шактый озак җәяү барганнан соң, көттереп килгәне икенче трамвай булып чыкты. Кольцога хәтле генә булса да барыйк, дип утырдылар. Әмма сүзгә мавыгып, төшә алмый калдылар.

Мөштәри тукталышында төшкәч, Язучылар йорты янына килеп чыктылар. Трамвай, тәгәрмәчләрен чыелдатып, финанс институтының ерактан балкып торган бинасы яныннан үргә үрмәли башлагач кына аңнарына килделәр. Таныш бизәкле рәшәткә, аның янында биегәеп утырган юкәләрнең ышыгы шагыйрь күңелен ымсындырмый калмады, әлбәттә. Бакчасы нинди бит аның! Мондый затлы рәшәткәләр белән әйләндереп алынган паркларда Пушкин, Лермонтов кебек шагыйрьләр үзләренең мәгъшукаларын кочып үпкәннәрдер. Татар шагыйренең кай җире алардан ким?

—Әйдәле, безнең бакчага кереп чыгыйк!—диде ул Лenaның ничектер салкынаеп киткән бармакларын каты кысып. Кыз риза булмас, дип уйлаган иде. Әмма Лена куркып та, икеләнеп тә кала торганнардан түгел, гадәти булмаган һәр урын, һәр кеше, һәр вакыйга аның иҗади күнелен рухландыра, кызыксыну уята иде.

—Әйдә!—диде ул.

Кече капка төнгә дә бикләнми, ябып кына куела. Аны ачып ишегалдына аяк басу белән уң якта тагын бер кече капка бар—анысы бакчага алып керә. Өлгер завхоз Хәлим аны төнгә бикләп китә. Мондый бикләр, кайбер бомжлардан саклый да торгандыр, бәлки, ләкин гашыйкларга ул гына киртә була аламы!

Чуен капканың аякка терәк булырлык бизәкләре житәрлек.

—Әйдә, өстеннән керәбез!—диде Зөфәр. Һәм гашыйкларда гына була торган гайрәт белән, Лenaның яшьлек һәм сәламәтлек белән тулы сыгылмалы, тыгыз гәүдәсенең авырлыгын да тоймыйча биленнән тотып өскә күтәрде. Кыз җинел хәрәкәт белән аргы якка төште. Аның артыннан бер җилпенүдә Зөфәр дә сикерде.

Алар житәкләшеп, тыннарын кысып, аяк астында берәр чыбык шыртлап сынмасын өчен, тычкан тотарга барган мәчедәй сак кына атлап, бакчаның аргы башына таба уздылар. Шәһәр уртасы булса да, бирегә утларның яктысы төшми, бинаның тәрәзәләре караңгы, шунлыктан урмандагы кебек аулак һәм хәтта бераз шомлы да иде. Бу шомны урамнан сирәк-мирәк узган машиналарның гүләве дә, трамвайның зыңгылдавы да, аяз күктәге уракайның яктысы да тарата алмый, чөнки бакчаның аргы башы кыргыйланып үскән куаклар, кычыткан белән ышыкланган,тирә-юнь юкә балы исенә туенган иде.

Менә алар уртада агач гөмбәзе һәм баганалары белән чак кына яктырып торган фонтан яныннан, тимер рәшәткәләре каралып торган терраса турыннан уздылар һәм аның артындагы кинобудка турына житкәч, тәмам караңгылыкка чумдылар. Гашыйклар өчен менә дигән урын... Тәкате тәмам төкәнгән Зөфәр Ленаны әләктереп алып, таш диварга китереп терәде һәм дөньясын онытып, шашып үбәргә кереште. Кызның да карышырлык хәле калмаган иде...

Ләкин иң кызган минутта, һич көтмәгәндә, ул кинәт сискәнеп, сынын катырып турайды. Учларын Зөфәрнең күкрәгенә терәп, көч белән читкә итте.

—Кемдер бар...—диде шомлы пышылдап.

—Син нәрсә! Кем булсын монда! Берәр кош очкандыр...

—Юк... Кош түгел... Шакыйлар...

—Кайда?

Кыз аңа яны белән борылып, учын кирпечкә куйды.

—Менә монда...

—Теге яктамы әллә?

Зөфәр кызны ычкындырып, почмакның теге ягына барып карады. Кыз исә кирпечкә колагын терәгән иде.

—Эчтән шакыйлар...—диде ул.

—Юкны сөйләмә... Кем булсын анда... Безнең Хәлим аны бер ай элек кирпеч белән томалап куйды бит инде.

—Ә син тыңлап кара...

Зөфәр колагын каты, салкын кирпечкә терәде.

—Менә монда, биредә яхшы ишетелә,—диде Лена.

Чыннан да колакка ниндидер тавыш килеп ирешә. Әйе шул, шакыйлар түгелме?

Тик кем керсен анда? Клуб май аеннан бирле бикле тора лабаса.

Озакламый ремонт башланачак, шуна күрә ул тирәдәге бөтен ишекләр йозаклы.

—Кем бар анда?—дип кычкырды Зөфәр..

—Тише!—диде Лена.—Каравылчыны уятырсың...

—Менә хикмә-әт!—дип сузды Зөфәр.—Хәлим мәтәлеп төште микән әллә?

—Ничек мәтәлсен ул анда?

Шагыйрьнең хыялга маһир башы поэма яисә баллада язганда була торган мавыгу, хәтта илһамлану белән тулды.

—Каминның тышка чыга торган торбасын төзәтергә кушкан идек без аңа.

—Кесә телефоны үзе беләндер лә!

—Ә бәлки өстәлендә калдыргандыр! Түбә ямаганда телефон нәрсәгә?

Гайре табигый хәлләр иҗат әһелен гомумән җәлеп итә, Зөфәргә бу сыйфат аеруча хас иде. Аңа шул беркем башына килмәс нәрсәләрне бир!

—Менә күрерсен, Хәлим утыра анда!—диде ул.—Хәзер чыгарабыз без аны. Ну бушка түгел! Бер шампанский алып бирсен!

Һәм ул, авыл малаеның гадәтен исенә төшереп, стенага терәлеп торган тупылга үрмәләде. Ай яктысында түбә төзек күренде. Ә менә шакыган тавыш ачыграк ишетелә башлады, аңа кычкырганы да килеп өстәлде. Зөфәр бер калайны кырыннан эләктереп тартып карады—купмады. Икенчесен каерган иде—тегe кайтарылды да чыкты. Астан, караңгылыктан сыкрану авазы килеп иреште.

—Хәлим, синме?!

—Ми-ин!...

—Нишләп ятасың анда?

—Чыгарыгыз мине моннан!

—Тукта, хәзер төшәм... Төшимме?

—Тө-өш!

Өч метр биеклек шагыйрь өчен әллә ни ара түгел, ул бик җиңел барып төште. Һәм сыгылган тезләрен турайтып, аягүрә баскач, дөм-караңгыда:

—Хәлим, син ничек монда килеп эләктең?—дип сорады.

—Хәлим түгел... Мозаффар мин...—дигән җавапны ишеткәч, аның мие түнеп китте.

Алар арасында булган болганчык сүзләрне биредә тәфсилләп сөйләп торуның кирәге юктыр. Тиз арада аңлаштылар, биредән чыгу юлын эзли башладылар. Зөфәр диварга терәлеп басты, Мозаффарны үз җилкәсенә күтәрде, тегесе бар булган көчен җыеп, түбәгә үрмәләде. Бөтен күкрәгән тутырып сулыш алды...

Ул арада түбәгә Лена да менеп баскан иде.

Бил каешларын урап, тырыша-тырмаша Зөфәрне таш капчыктан көч-хәл сөйрәп чыгардылар. Бу мәшәкатьләр белән азапланган арада Зөфәрдән Лена кайгысы киткән иде инде. Түбәдән сикереп төшкәч, ул кызның очкындай янган күзләрен күреп, уңайсызланып китте.

—Кичер,—диде.—Мин сине озата алмыйм. Дусны илтеп куярга кирәк.

## Дус–иш кирәк гомер итәргә

—Әйдә, сезгә кайтыйк әле,—диде Мозаффар урамга чыккач.

—Бик дөрес! Безгә кайтыйк!

Кольцо ягыннан, маңгаендагы утларны җемелдәтеп, трамвай килгәне күренде. Ярый, халыкның күпчелеге тукталышта төште, вагон бушап диярлек калды. Алар арткы ишектән кереп, шым гына почмакка елыштылар. Күпне күргән таза гәүдәле кондуктор хатын, Зөфәргә ике билет биргәндә,

Мозаффарның сәер кыяфәтенә күз салып, чыраен сытып куйды.

Фатир ишеге ачылган тавышка бүлмәдән берсе биш, икенчесе өч яшь чамасы ике малай йөгереп чыктылар да Зөфәрнең ике ботыннан кочаклап алдылар.

—Әнисе! Чык әле, кунак бар!

Аш бүлмәсе ягыннан башындагы чәчкәле яулыгын рәтләштерә-рәтләштерә килеп чыккан Фәрдия, бусагасын атлап кергән бер кешегә елмая торган гадәтен онытып, шаккатып Мозаффарны баштанаяк күздән кичерде, ят истән борынын мышкылдатып куйды. Кунакның сәламенә җавап бирмичә:

—Ай алла, ни булды?..—дип сорады.

—Егылдым, Фәрдия ханым... Җайсызрак барып төштем...

—Машина бәрдеме әллә? Кай җирең авырта?

—Булды инде бераз...

Фәрдия кабаланып юыну бүлмәсенең ишеген ачты да шаулатып су агыза башлады.

—Кил монда, юынып чык! Киемнәреңне салып, машинага тыгып куй. Әйләндереп чыгарырмын. Ә син Зөфәрнекен киеп торырсың. Чиста тастымал элгечтә.

Мозаффар артыннан ишекне япкач, пышылдап иреннән:

—Ни булган моңа?—дип сорады ул.

—Түбәгә менгән дә тишегеннән мәтәлеп төшкән.

—Нинди түбәгә? Дачаларындамы әллә?

—Рәссамның кайчан нишләгәнен кем белә? Матуррак ракурс эзләгәндер. Алар безнең йортның үзен, бакчасын, рәшәткәләрен, агачларын ясап бетерделәр бит инде. Түбәсен ясыйсы килгәндер. Андый чакта аларның күзенә ак-кара күренми, үзең беләсең.

—Беләм инде, белмәгән кая!—диде Фәрдия мәгънәле итеп.—Барыгыз бер иш. Күпме яткан инде ул анда?

—Әйтми бит. Ник төшкәнен дә, кайчан төшкәнен дә. Аны югалтып эзли башлаганнарына атна узды бугай инде.

—Тузга язмаганны шагыйрьләр генә кыла дисәм, рәссамнар да сезнең белән бер чыбыктан куылган икән! Мондый кыяфәт белән өенә кайтса, Азалия һушыннан язар. Ярый әле, монда алып кайткансың. Бераз хәл алсын да озатып куярсың.

—Нәрсәгә аны озатырга? Гарип түгел лә...

—Бигрәк хәлсез күренә бит! Син иренсәң, үзем озатырмын.

—Озаттырса...

Фәрдия телефон трубкасына тотынды.

—Азалиягә әйтим әле, борчылып тормасын.

—Ир белән хатын арасына кысылмасаң да ярар. Кулы бар ич аның, шылтыратыр үзе! Кирәк булса...

—Ничек инде кирәк булмасын? Анда ут йотып торалардыр...

—Ә бәлки аның сюрприз ясыйсы киләдер?!

...Мозаффар, чистарынып-кызарынып, Зөфәрнең кара төстәге «Адидас» костюмын киеп чыккач, башын сөлге белән сөртә-сөртә диванга килеп утырды да:

—Әгәр рөхсәт итсәгез, берәр урын тапсагыз, мин шушында гына йоклар идем,—диде.

Фәрдия сәерсенгәнен сиздермәскә тырышты:

—Була, була! Ашап-эчеп алыйк та, ятарсың да йокларсың. Бик җайлы диван бу безнең. Бәхетең бар икән, бүтән кунагыбыз юк чакка туры килдең. Югыйсә гел буш тормый.

—Туган-тумача, дус-иш күп бит безнең, бар да якын итәләр,—дип куйды Зөфәр канәгать елмаеп.

—Тор әле,—диде Фәрдия Мозаффарга.—Табын әзер анда. Сез балалар белән бергә ашый торыгыз, мин урын җәеп куйыйм.

Һәм кунагы кузгалуга диванны шатырдатып кинәйтеп тә җибәрде, эчке бүлмәдән чиста җәймәләр алып чыгып җәйде.

Аннары өстәлдә яткан тар кенәгәне актаргалады, кесә телефонын алды да, эчтәгеләр ишетмәсен өчен ишекне сак кына ачып, баскыч мәйданчыгына чыкты.

—Исәнмесез. Юлдашев фатирымы бу?—диде телефонга.—Азалия синме? Фәрдия әле бу, шагыйрь Назировның тормыш иптәше.

—Исәнмесез, Фәрдия. Сез икәнсез әле...—Азалия кем дә булса башка берәүнең шылтыратканын көтә иде булса кирәк, тавышы бик төшенке иде.

—Борчылып тормагыз, дип шылтыратуым иде. Мозаффар бездә.

Телефон тынып калды. Әллә өзелде инде?

—Алло, алло! Ишетәсезме?.. Мозаффар, дим, бездә әле. Кайтып тормас, бәлки, монда гына кунар. Шуны гына әйтмәкче идем.

—Кайчаннан бирле сездә ул?—дип сорады Азалия ышанып җитмәгәндәй.

—Зөфәр белән кайтканнарына бер сәгать бардыр инде.

—Бер сәгать! Аңарчы кайда булган?

—Анысын сорарга өлгермәдем әле. Тизрәк сине сөендермәкче идем. Зөфәр аны югалган дибрәк әйткән иде.

—Кайтсын! Хәзер үк!—диде Азалия сөенеч тә, ачу да, гаҗизлек тә катыш тавыш белән.

Фәрдия аны йомшартырга теләп, җинелчә генә кеткелдәп куйды.

—Ир солдат түгел бит ул, Азалия, ә хатын ефрейтор түгел. Әмер биреп булмый. Тик шуны бел: гөнаһлы юлда йөрмәгән ул, газаплы җирдә булган.

—Ничек? Нишләп?

—Ниндидер бәлагә тарыган, ахры. Кыяфәте шундый.

—Нинди бәла? Нигә ачык кына әйтмисең?

—Нинди икәнен үзенә сөйләр. Мина әйтмәде, сорамадым да. Башы исән, дүрт саны төгәл, шунысына сөенергә кирәк.

—Ә ник кайтмый соң ул?

—Сәбәбе бардыр, —диде Фәрдия уйланып.—Кайтырга ярамыйдыр. Ә бәлки аны ишек төбегездә сагалап торалардыр!

—Кемнәр?

—Кемнәр аны шундый кыяфәткә керткән, шулар. Телефонны тыңлаулары да бар. Үзе шуңа шылтыратмыйдыр. Син сабыр ит. Кайткач һәммәсен аңлатыр.—Аннары көрсенеп өстәп куйды:—Чын талант иясе белән гомер итү җиңел түгел ул! Укып та беләбез, үзебезнең сыртта да татыйбыз! Минем шылтыратканны аңа әйтә күрмә тагын! Үпкәләр! Тыныч йокы!

...Нинди тынычлык! Ниткән йокы! Телефонын куярга оныткан Азалия шактый вакыт нишләргә белми бүлмә уртасында басып торды: әллә куанычыннан үрле-кырлы сикереп биергә, әллә борчуыннан утырып еларга. Бөтен үпкә-рәнҗүләрен оныткан иде ул, тик ире исән-сау гына булсын!

## Кияү-кәләш уены

Самаркинга: «Ярәшкән егетем бар»,—дип, хәйләләде Нурзифа. Күзенә карап ялганлады. Алай да кискен минутта аның теленә бу сүзнең килүе бер дә юкка түгел иде. Хәтәр кешенен үткен карашы астында, үзен микроскопка

куелгандай хис итеп, тәмам чарасыз басып торганда, аның күнел түреннән Рашатның елмаюлы йөзе калыкты, ул шукланып күз кыскандай: «Тәвәккәллә! Хәйләлә!»—дигәндәй булды. Аннан көч алып әйтелде бу сүзләр.

Әйе, сүзләр әйтелде, инде менә гамәлгә керешергә, егетенне Самаркин каршына илтеп бастырырга кирәк иде. Моны Рашатка ничек әйтергә? Ни дип анлатырга? «Син минем киявем бул әле»,—дияргәме? Әллә бүтәнчәме? Ничек кенә әйтсәң дә, бик сәер булачак бит бу! Бернинди әзерлексез, нигезсез шундый тәкъдим ясаган кыз хакында егет ни уйламас?

Көн буе тынгы белмәде, төн буе йокы күрмәде Нурзифа. Бәгыренә утлы кисәү тыкканнармыни: көйдерә дә көйдерә генә!

Иртән эшкә килеп утыруы булды, Хәнәфи шылтыратты:

—Сәлам, Зифуш! Сәгать бердә машинаны кая җибәрим?

Тавышында боз салкыны, сүзләрендә таш катылыгы—элекке төчелеге кая киткән, диярсен!

—Нишләп сәгать бергә?

—Самаркин белән бездә очрашачаксыз. Киявенне алып килергә онытма! Егор Викторович сезне алырга үзенен «Мерседес»ын җибәрергә кушты.

Нурзифаның хәтерендә янә Рашатның шук йөзе җанланып: «Үртә! Шаярт!»—дип күз кыскандый булды.

—Самаркин машинасына утырырга сез минем егетемне кем дип белдегез? Аның ак «Лада»сы бар!

—Ах, аның да ак «Лада»мыни? Әле минеке дигән иден.

—Икебезнеке бергә!

—Юлны онытмадыңмы? Кара аны, сонга кала күрмәгез! Егор Викторович андыйны яратмый, санга сукмау дип кабул итә. Аның мин-минлегенә тиюдән Алла сакласын!

—Сез куркыгыз Самаркиннан, без куркаклардан түгел!

—Әй син сүзендә тор. Очраштырам диден, очраштыр. Онытма: нәкъ сәгать бердә.

Нурзифа телефон экранына карады: ун тулып килә икән. Әгәр Рашатның эше бик тыгыз булса? Яисә хәлгә керергә теләмәсә?..

Тик көймә комга килеп терәлгән, башка чара юк иде—Нурзифа дулкынлануын басарга тырышып, телефон төймәләренә төрткәләде. Ярабби, җавап кына бирә күрсен иде!

Озак көтәргә туры килмәде бугай, әмма бу мизгелләр бик озын тоелды, йөрәк дөп-дөп бәргәләнде, колак кат-кат чыңлады. Менә ниһаять—нинди зур бәхет!—Таныш тавыш ишетелде.

—Алло! Алло-о!

—Бу Нурзифа әле.

—Хәерле көн, Нурзифа!

—Исәнмесез. Сез ник әле шкафларыгызны һаман алып китмисез? Ачуланалар монда!

—Иртәгә-берсекөнгә керep, китергән өчен акчасын түләп чыгармын.

—Бүген кирәк иде.

—Бер көн торганга берни булмас. Шкаф сөт түгел, ачымас.

—Минем сездән бер киңәш тә сорыйсым килгән иде.

—Эш бетүгә килеп житәрмен. О-кей?

—Миңа хәзер кирәк!

—Ашыгычмыни?

—Бик!—диде Нурзифа басым ясап.—Би-ик ашыгыч!

—Ярый алайса,—диде бераз гаҗәпләнгән Рашат.—Бер-ике сәгатьтән сугылып чыгармын. Мин рульдә әле.

Ике сәгать дигәне артыгы белән узып китте, бу вакыт эчендә Нурзифа

ничәдер тапкыр телефоннан шылтыратканнарга жавап бирде, ишектән кергәннәр белән сөйләште, тик боларнын барысын да робот кебек башкарды, кылганнары-әйткәннәре зиһененә барып ирешмәде. Ниһаять, таныш машина тротуар эргәсенә килеп туктады. Менә ул гадәттәгечә жинел атлап, бит очларын чокырайтып, шаян елмаеп, бусагадан атлады. Ул керүгә гадәттәгечә бүлмә яктырып, һава сафланып киткәндәй булды.

—Саумысез,—ди.—Кем тия?

—Самаркин!—диде Нурзифа.

—Кит аннан? Сина да кулы життемени инде? Кайда таныштыгыз сез анын белән?

—Портретны күргән. Ул мине үзе белән Мәскәүгә алып китмәкче.

—Әйе-е,—диде Рашат көлеп, —шаккатарсын сәнгатьнең көченә һәм Юлдашевнын осталыгына... Эшләрең хөрти икән болай булгач. Самаркин ишеләр күзе төшкәнне кулына эләктерми калмый. Бар икән күрәселәрең! Мәскәүләрне дим.

—Мин анда бармыйм!

—Самаркинга каршы тормакчымы әллә син? Ай-һай көчле икәнсен!

—Көчле. Янымда терәгем булса.

—Нинди терәк ул?

—Мин ана, шушы арада кияүгә чыгам, дидем. Ир хатынын беркем беркая алып китә алмый... Мина кияү кирәк!—дип егетнең күзләренә туп-туры төбәлде Нурзифа. Рашат гажәпләнүеннән сызгырып куйды:

—Прокаткамы әллә?

—Әйе. Бер сәгатькә.—Нурзифа өстәлдә яткан телефонынын экранына күз салып алды.—Егерме минуттан мин анын каршында булырга тиеш. Киявем белән парлап.

Рашат карашын түбән төшереп, башын чайкап куйды.

—Ишетмәсән ишет,—диде үзалдына. Аннары башын күтәрде дә:—Безнең мәдәният сараенда спектакльләрнен төрлесе куела, мондыен уйнаганнары юк бугай әле,—диде.

—Сез артисттамыни әле?

—Һәвәскәр. Ә нигә, уйнап карарга була! Самаркиннын сүзен сүз итмәс өчен генә булса да. Киттек алайса!

...Алар килеп житәр-житмәс тимер капка ачылды, машина туп-туры ишек алдына барып керде. Хәнәфи аларны болдырда көтеп тора иде инде.

Ул бик тә житди һәм эшлекле кыяфәт белән кунакларны мәрмәр баскычтан өске катка алып менеп китте.

Самаркин түгәрәк өстәл янында жәелеп утырган иде, аларнын сәламен дә алып тормыйча:

—Ну!—диде.—Что скажете, молодые?

Шунда сүз һич көтмәгән борылыш алды. Рашат хужаны күрдеме-күрмәдеме, карашы сул як диварга, анда эленеп торган ике картинага төбәлде. Йөзе агарынып чыкты. Моны күреп, Нурзифанын йөрәге жу итте: картиналарнын берсендә ефәккә төренеп, икенчесендә бөтенләй ялангач хәлдә ул ята иде. «Бетте... Бөтенесе жимерелде...» Анын бу уйларын раслагандай, Рашат, кашларын жыерып, ачу белән ана борылды:

—Бу ни дигән сүз!—диде.—Нишләп син боларны монда элеп куйдырдын?

—Мин түгел,—дип бызырдады Нурзифа.—Беренче күрүем... Белмим, ничек алар монда килеп кергәндер...

—Синең рөхсәттән башка беркем мондый картинаны кеше күз алдына элеп куя алмый!

Рашат картиналарга якын ук килде дә:

—Һәм минем рөхсәттән башка!—дип өстәде.—Юлдашев картиналары бит болар!

—Ничек Юлдашевныкы?—дип сикереп аягына басты Самаркин.—Ә син миңа ни дигән идең?—дип Хәнәфигә төбәлде ул.

Агарынып каткан Хәнәфи, иреннәрен көчкә кыймылдатып:

—Белеп сөйләмиләр...—диде.

—Мин ялгышаммы?—дип аңа таба атлады Рашат.—Юлдашевның кылкаләмен бер күрүдә таныйм мин, беләсең килсә. Ә бу картинаны мин... без...—дип, оятыннан кая керергә тишек тапмый басып торган Нурзифага күз салып алды да, батыраеп китте ул.—Без моны үзебез заказ биреп яздырган идек! Туйдан соң йокы бүлмәбезгә элеп куяр өчен!

Һәм рамнарны элгечтән алырга үрелде.

—Тукта! Нишлисең! Хакың юк!—дип аның беләгенә килеп ябышты Хәнәфи.

—Минем хакым юкмы? Монда, һичшиксез, криминал катышкан. Мин юрист, беләсегез килсә! Әгәр Юлдашев боларны бездән рөхсәтсез кемгәдер саткан булса, без аны судка бирәбез! Яле, ярдәм ит!—дип картинаның берсен алып Нурзифага сузды ул.—Алып китәбез без аларны! Вещдок итеп!

Шулай дип, рамның икенчесен үз кулына тотты. Аның кыланмышлары Самаркинга мәзәк тоелды булса кирәк:

—Юрист түгел, артист син, мөгаен,—диде.—Кияү дисең инде үзенне. Әгәр мин тикшерсәм?

—Тикшер, бүтән эшең булмаса.

—Мондый афераны күргән юк иде әле. Кызык бит. Туегыз кайчан була инде?

—Өч көннән.

—Шулай тизмени? Кайда уздырасыз?

—Әлмәттә.

—Мине чакырасызмы соң?

—Туган-тумача күп безнең. Чакырасы кунакларга күптән хәбәр ителгән.

—Әлмәттә, дисең алайса. Тикшерә алмас, дип уйлыйсыңдыр ... Телисеңме, сезне минем ак лимузин белән илтеп куярлар? Бер унайдан шофер туйны да күреп килер...

Тәмам әвәрә килгән Нурзифа:

—Кирәкми, безгә ак «Лада» җиткән...—дип башлаган иде, Рашат каты гына:

—Сиңа, сөеклем, бу ямьсез гадәтеңнән бизәргә туры килер,—диде.—Хатын кешегә иреннән узып авыз ачу килешми!

Аннары Самаркинга борылды:

—Бу тәкъдимегезне ничек кабул итәргә? Спонсор Самаркиннан дипме, әллә Инвесторданмы?

—Меценат Самаркин тәкъдиме бу! Дөресен сөйләсәгез. Әгәр сүзегез ялганга чыкса, Кредитор Самаркин булырмын мин сезгә! Бензин хакын гына түгел, лимузин бәясен түләргә туры килер!

—Меценат тәкъдименнән баш тарталар димени! Лимузин икән лимузин. Утырабыз да кайтабыз. Күрсеннәр безнең кемлекне!.. Рәхмәт!—дип чак кына башын иде Рашат Самаркин тарафына.—Сүзегездә торсагыз, машинагызны шимбә көн иртән җибәрерсез. Ә безне, сөеклем, ательеда көтәләр. Туй күлмәген үлчәргә кирәк.

Хуҗалар белән саубуллашып, өйдән чыгып машинага утырганда, Нурзифа, юка кофтадан булуына карамастан, тирләп беткән иде.

## Туй күлмәге—сафлык билгесе

Капкадан чыгып, каравылчылар күзеннән югалуга, Рашат машинасын туктатты да, телефонын кулына алды.

—Азалия ханымга шалтыратып алыйк әле,—диде.—Урынында микән?

—Кайсы Азалиягә?

—Ә-ә, син белмисеңдер әле. Казанда туй күлмәкләренең иң шәпләрен «Азалия» ательесында тегәләр.

—Каян беләсең?

—Мин анда тукыманы илтеп биргән идем инде.

—Нинди ателье? Нинди туй күлмәге? Мин сине бер сәгатькә прокатка гына алдым ла! Уйнадык, ышандырдык та бугай. Житте-бетте. Финита!

Рашат ана күзләрен кысып, кистереп карады.

—Син нәрсә, бөтен егетләрне үз кубызына биетмәкчеме әллә? Самаркинны, аның ялчыларын, мине...—Ул гажәпләнгәндәй башын чайкап куйды.—Каян килгән режиссер! Гел үзенекен генә итмәкче. Минем сүзне аяк астына салмакчы.

—Нинди сүзне?

—Әле генә Самаркинга ни дидем мин? Туй күлмәге үлчәргә барабыз, дидем. Син ризамы, юкмы?

Бераз тынып торды да, җавап булмагач:

—Дәшмәү—ризалык билгесе,—диде.—Тик алдан минем бер шартым бар: хәзер үк никах килешүе төзибез.

—Нәрсәгә?

—Мин болар өчен...—ул арткы утыргычта яткан ике рамга ишарәләде,—сиңа беркайчан да үпкә сүзе әйтмәячәкмен. Ә син минем үткәннәремдә казынмыйсың. Тормышны чистадан, актан башлыйбыз. Син шуңа риза булыр иденме?

—Әйе,—дип пышылдады Нурзифа.

—Эш күп безнең. «Алмаз» кибетенә керәсе бар.

—Анысы нәрсәгә?

—Туй балдагын шуннан алырбыз. Нindirәге килешер икән? Бир әле кулыңны!

Аның учына кайнар кулын салгач, Нурзифа дулкынлануыннан нишләргә белмичә, көлеп җибәрде: ул әле һаман аңлап бетерми иде: уенмы бу, әллә соң... житди сүзме? Ышаныргамы, ышанмаскамы? Уен булса, катнашыргамы? Чын булса, ризалашыргамы? Ләкин төптән уйланмаган бит әле! Әзерләнелмәгән, эчтән хәл кылынмаган!

Әмма Рашат уйларга, хәтта аңга килергә дә ирек бирмәде. Шылтыратып, Азалиянең эшендә икәнен белде дә рульгә ябышты:

—Төшке тәнәфесен беткәнче барып килик,—диде.—Ашап аласын да бар. Болар бигрәк сансыз икән, кунакларын сыйламыйлар да.

«Азалия» ательесы ерак түгел, шәһәрнең иске ягындагы яңа төзелгән йортның аскы катында икән. Бөтен нәрсә өр-яңа, ялтырап тора. Алар бусагадан атлауга, эчке яктан каршыга Азалия килеп чыкты. Ул озын кара чәчен күпертеп, баш артына җыеп куйган, йөзе сулып киткән кебек иде.

Рашат белән янәшә Нурзифаны күргәч, гажәпләнгәне сизелде, салкын гына исәнләште дә, Рашатка карап:

—Ә кәләш?..—дип сорады.

—Кәләш менә шушы инде.

—Ничек алай? Ә теге...

—Теге чакта килгәнемме?.. Анысы өлге өчен генә иде.

—Бусы... чынымыни?

—Чып-чыны.—Рашат, Нурзифаның үзенә бик якын икәнен исбатларга теләгәндәй, иңennән кочып алды. Азалиянең түгәрәк йөзендә хисләрнең әллә ничә төрлегә үзгәреше чагылды. Кырыслыгы кимегәннән кимеп, күзләре яктырганнан яктыра барды. Ниһаять, ул елмаеп җибәрде:

—Котлыйм!—дип кыз кулын сузды.—Мин бик шат! Сез бик матур пар! Бәхет-шатлыклар телим!

Ул мондый очракта гадәттә әйтелә торган сүзләр сөйли, әмма эчендә үзенә генә хас, ул гына кичерә алган хисләр кайный иде. Нурзифа аның очкынланган күзләренә йотылып карады, һәм әйтелмәгәнен сүзсез аңлады: димәк, Мозаффар табылган... Шулай булмаса, бу хатын болай шат күренмәс иде. Өстәвенә, Нурзифаның кияүгә чыгуы да аның өчен яхшы хәбәр иде, күрәсең.

Менә ул аны калтыранган кулыннан тотып эчкә, ике ягы тоташ көзгедән торган кечкенә кием үлчәү бүлмәсенә алып кереп китте.

—Ярый әле кисәргә өлгермәгән идем,—диде.—Теге артистканың гәүдәсе бөтенләй башка бит аның. Синекенә житәмени!—дип күзләре белән яктыртып алгандай карап куйды ул Нурзифага.—Мин сиңа күлмәкне дөньяда булмаганча итеп тегәчәкмен. Менә күрерсең. Сокланып туймаслар! Ай-яй, егетнең шәбен эләктергәнсең!

—Мин түгел, ул эләктерде мине!

—Алай булса, бигрәк шәп! Фасонын нинди итәбез?

—Түше нык ачык булмасын иде. Әтиләре янына кайтабыз.

—Ачык ярамый. Бер күз салуга, бик тә инсафлы, садә, саф бала икән бу, дип уйласыннар. Жинле, ябык изүле, мул күлмәк килешәчәк сиңа. Баш бөркәнчегең чәчләреңне каплап торсын. Әти-әниләрегезгә ихтирам билгесе булачак ул. Яле, үлчәмнәреңне алыйк!

Азалия кешенең гәүдәсен кулындагы тасма белән генә түгел, хәрәкәтчән сизгер куллары, бармаклары белән дә үлчи белә иде. Шуңа да ипле, килешле була иде ул теккән киемнәр. Бу юлы ул Нурзифаның тәненә аеруча назлап, иркәләп орынды.

«Ә мин теге чакта аны кара итеп ясаган идем...—дип уйлады Нурзифа күп еллар элек ясаган сурәтен исенә төшереп.—Икебезне бер зынҗыр белән урап куйган идем. Күрә белмәгәнмен: кара чәч, кара күзләр артында ак күңел икән. Ә зынҗыр дигәнем тимердән түгел, гөл сабакларыннан үрелгән булган икән...»

Бу минутларда аңа бик рәхәт тә, жиңел дә иде. Уен булса булсын, матур уен иде бу!

## Хәерле юл!

Аяз, тыныч, жылы иртә иде. Вокзал каршына тезелеп баскан, янякларына ак хәрефләр белән «Татарстан» дип язылган яшел вагоннар тирәсендә гадәттәгечә ыгы-зыгы хөкем сөрә. Берсе тирәсендә төркем аеруча куе булып, анда республиканың мәгълүм шәхесләре күренә иде: чал кергән күперенке чәчле, какча чырайлы мәдәният министры Илгизәр Кәримов, ак түгәрәк йөзле, тулы гәүдәле Тимур Акулов, кыяфәте белән башкортка охшаган Айдар Хангилдин, танылган рәссам Әгъләм Талипов. Көлешеп сөйләшкән, бертуктаусыз үзгәреп торган бу төркем тирәсендә башка мәгълүм рәссамнарның йөзләре дә чалынып китә, аларның танышбелешләре, хатыннары чуала. Шунда ук телевидение камерасын китереп куйганнар, яшь кенә бер кыз әле берсенең, әле икенчесенең авызына микрофонын китереп тери—интервью ала иде.

Менә вокзал бинасыннан Ансар Гыймадиев белән Зөфәр Назиров килеп

чыкты. Алар төркемдәге халыкны күздән кичерделәр дә, читтәрәк туктап калдылар.

—Безнең дус күренми бит әле монда,—диде Зөфәр.

—Хәнәфине күр син, Хәнәфине! Нинди нәчәлник!—диде Ансар.

Чыннан да, министрның жилкәсе янында Рәҗәповның керпе башлы болгана иде.

—Юл өчен дип Самаркиннан ярдәм сорадылар микән әллә? Бусы хуҗасының акчасын китергәндер, бәлки?—диде Зөфәр.—Әллә Прагага үзе барамы?

—Кем алып барсын аны? Кулга тотарлык берәр сурәте булса икән!

—Самаркин шундый шарт куйса, алып бармый хәлләре юк. Малевичның «Кара квадрат»ы кебек берәр нәмәрсә әмәлләгәндер. Шуны күтәрер дә барыр.

—Синең шул булыр инде, әллә ниләр уйлап чыгарасың,—диде Ансар көрсенеп. —Күкләрдә йөзәсең. Жиргә төшеп караганда, бер дә яхшы фал түгел бит әле бу. Хәнәфи монда, Мозаффар—юк. Әллә тагын берәр этлек эшләде микән бу җаһил?

—Ул-бу булырга тиеш түгел иде,—диде Зөфәр.—Бик сак кыландык бит. Мозаффар хатыны белән дә бездә генә күреште. Министрга да бездән шылтыратты. Өенә бүген иртән генә кайтып китте. Киенеп, әзерләнеп килергә кирәк булганга гына.

Төркем уртасындагы Кәримов, Хәнәфине кулы белән читләштереп, үрелеп вокзал артына карады: ул да кемнедер көтә иде булса кирәк. Мөгаен, Мозаффарныдыр. Менә аның йөзе яктырып китте, ул, халыкны аралап, перрон аша атлады. Аның каршысына зур сумка тоткан Мозаффар белән Азалия киләләр иде.

—Ниһаять, сине күрер көн дә бар икән!—дип рәссамга кулын сузды министр.—Әгәр чехлар якламаса, билләһи, бер-бер чара күрә идем мин сиңа. Ну син барыбер моның сәбәбен аңлатырга тиеш. Болай булмый.

—Әйләнеп кайтканчы түзегез инде, аннары теләсә нишләтерсез,—диде Мозаффар. Аның йөзе шактый суырылган, кояш күрмәгәннән агарынган иде.

Зөфәр белән Ансар да шул якка таба атлый башлаганнар иде, вагон кырые буйлап йөгергән Хәнәфине күреп алдылар. Тагын да кечерәергә, күзгә күренмәстәй булырга теләгәндәй, урталай диярлек бөгелгән, муенындагы калын сары чылбыры, бушаган муенчак кебек, әрле-бирле болгана.

—Әй! Кая ашыгасың әле син болай?—дип аның каршысына китте Зөфәр.—Сабакташыңны кул болгап озатып каласың килмимени? Бер бүлмәдә буяу изгән иҗатташың бит ул синең!

Хәнәфи абынып егыла язды, тукталды да, телефон йомарлаган кулының аркасы белән маңгаен сыпырып алды.

—Хуҗа чакыра,—диде сулышына кабып.

—Эшем бар, бушагач килермен, дияргә иде.

—Ашыгыч, ди. Аварияга юлыккан бугай.

—Син ашыгыч ярдәм түгел лә!

—Хәнәфинең үзенә ашыгыч ярдәм кирәк булмагае әле монда,—диде Ансар мәгънәле итеп.—Син болай арттан шылуны гадәт итеп алма тагын!—дип өстәде аннары.—Мозаффар әйләнеп кайтуга, җыелышырга дип ниятләдек әле без. Үткән ун ел эчендә эшләгән эшләребезгә нәтиҗә ясар чак житте. Хәтерлисеңме? «Матурлык яки үлем! Сәнгатькә хыянәт иткән кешегә бу жирдә урын юк!»

Хәнәфи, авызын кыйшайтып ачы көлемсерәде:

—Сез җәзага тартмакчымы әллә?

—Безнең җәза нәрсә ул! Вөҗдан газабыннан Алла сакласын, диген!

Хәнәфи тагын бер тапкыр артына күз сирпеп алды да:

—Хәзергә хушыгыз,—дип китү ягын арады.

—Сак бул, абына күрмә, егылып башыңны ярырсың!—дип калды Ансар аның артыннан.

Перронда игълан тавышы яңгырады: поезд кузгалырга биш кенә минут калган икән.

Ике дус өченче дустын хәерле юл теләп озатырга ашыкты.

... Поезд кузгалып киткәч, трамвайга таба барганда, Ансар эчтән уфтанып:

—Нишләптер Нурзифа күренмәде,—диде.—Ник килмәде икән? Мозаффар аны көткәндер.

—Син белмисеңмени, Нурзифа китте бит ул,—диде Зөфәр барган жиреннән тукталып.

—Кая китте?

—Кияве белән Әлмәткә киттеләр алар бүген.

—Кияүгә чыктымыни ул?

—Чыккан шул. Азалия минем хатынга әйткән, төн йокламый Нурзифага туй күлмәге тектем, дигән.

—Кияве кем икән?

—Минем күргән юк. Чибәр егет, йөзендә иман нуры бар, дип мактаган Азалия.

—Кызык бу дөнья,—дип куйды Ансар.—Еллар буе яшисең, көннәр һаман бертөсле үтеп тора, кинәт кенә һәммәсе үзгәрә. Мизгелләр бөтен язмышны бора да куя. Йә бәхеткә, йә афәткә.

—Бу юлы һәммәсе яхшыга булды сыман... Бирсен ходай. Нурзифа кебек кызларның бу жирдә яшәргә тулы хакы бар.

...Ә бу вакытта ак лимузин, каршы килгән машиналарның шоферларын хәйран калдырып, Әлмәткә таба бара, Самаркинның ак «Мерседес»ы исә Мәскәүгә чаба иде. Братан Егорның юл уңаеннан Нижгарга кереп чыгасы бар иде, шуңа күрә ул поездга утырмады. Машинаның багажнигында, биләүдәге бала кебек төрелгән бронза кыз ята, озакламый ул Самаркин менеп йөри торган баскычның бизәге булып басачак иде. «Парын ясатып алырга кирәк булыр,—дип уйлады Егор Викторович.—Чишенгән булсын. Ике якка икесен бастырып куярмын: бер якка бусын—күлмәклесен, икенче якка ялангачын. Күргәннәрнең күзе тоз булсын!» Шуларны күз алдына китергәч, ул үзалдына хихылдап куйды.

### Туйда бии тукмак та

Тимержан иртәдән бирле тәрәзә тирәсендә болганды. Килә дә карый урам якка, килә дә карый.

—Нәрсә киләп салып йөрисең син һаман?—диде аңа Суфия.—Барыбер өйләсез кайтып житә алмаслар.

—Ә син аларның кайтырына ышанасыңмы соң?

—Шылтыратып әйтте бит инде кичә!

—Аның сүзенә ышансаң! Йә тегеләй сөйли, әле болай. Бер атна элек, туйны кичерергә туры килмәгәе, дип мыгырдаган иде. Ничә көн инде кодалар белән сөйләшә алган юк. Әллә чирлиләр, әллә кире уйларга маташалар. Ни диярга белмәссең. Синең генә ул берсенә дә исең китми!

—Ничек инде исем китмәсен... Ут йотам...Тик нишлим соң... Көтәргә генә кала. Иншалла, кодалар белән бергәләп кайтып та житәрләр...

Тимержан ачык тәрәзәдән биленә кадәр тышка үрелде.

—Бу нинди әкәмәт?

Урамда вагон озынлыгында диярлек ак машина күренде. Аның капотына кәрзине белән чәчкә беркетелгән, түбәсе аша кызыллы-зәңгәрле ефәк тасмалар сузылган иде.

—Кил әле, кара, мондый машина күргәнең бармы синең?—диде Тимерҗан Суфиягә.—Туй машинасы бит бу. «Татнефть»нең берәр түрәсе малаен өйләндерә микән әллә? И-и, кыланып та куялар инде.

Ул арада, лимузин әкрен генә шуышып, тротуар кырыенда туктап калды. Кияү белән кәләшне каршы алырга дип килгән яшь-җилкенчәк, бала-чага аны сырып алды. Машинадан кул сузылып, малайларга конфет сипте, аннары Рашатның башы күренде.

—Бәлеш, Рашат бит бу! Безнең малай! Хатын, кая кәләшнең аяк астына салырга дигән мендәрең? Кая бал-маең?

—Хәзер-хәзер,—диде Суфия каударланып.—Мин мендәрне алам, ә син бал-май савытын тот!

Алар чыгып җиткәндә, өр-яңа аксыл костюм, ак күлмәк кигән Рашат машина янында басып тора иде.

Ишектән чыгып килгән әти-әнисен күргәч, ул, иелә төшеп, машинаның урта ишеген ачты һәм акка төренгән, йөзен бөркәнчек белән каплаган кәләшкә чыгарга ярдәм итте. Суфия иелеп аның аяк очына мендәр салды.

—Төкле аягың белән, балам! Уртасына, ныгытып бас!

—Аллага шөкер, кайтып җиттегез!—диде Тимерҗан.—Исәнме, улым, саумы, кызым! Ягез әле, бал-май кабыгыз! Бер-берегезгә балдай татлы, май кебек йомшак булып гомер итәргә язсын. Кап, килен!

Ул кашык белән бал сузды, Рашат кәләшнең йөзен каплаган бөркәнчекне күтәрде... Шунда Тимерҗанның кулы һавада эленеп калгандай булды. Бер кәләшкә карады ул, бер улына. Ә тирә-юньдә төркем зурайганнан зурая, конфет капкан малай-шалай, Рашатның дус-ишләре генә түгел, узгынчылар да туктап калып, бу тамашаны күзәтә иде.

Көтелмәгән хәлдән гадәттәгечә Суфия коткарды. Тимерҗанның беләгеннән тотып, кашыкны кәләшнең иренենә терәде:

—Икәүләп каптырыйк әле! Киленебез бигрәк чибәр, күз тия күрмәсен! Рашатның әти-әнисе менә без инде... Тимерҗан белән Суфия...

—Ә мин Нурзифа...

—Сөбханалла, исемең бигрәк матур! Без сиңа Нурзифа кызым диярбез, ә син безгә әти, әни, дип эндәшерсең инде...

Каенана белән килен шул рәвешле сүз алышкан арада Тимерҗан аңын җыярга тырышты. Алай да бәхетле ата рәвешенә керер өчен аңа бераз булса да вакыт кирәк иде.

—Барыгыз әле, кайткан машинагызда шәһәрне әйләнеп килегез! —диде ул улына.—Дусларыңны да утырт! Күрсеннәр безнең кемлекне!

Чәчәккә төренгән, тасмаларга уралган ак лимузинның Әлмәт урамнарын ураганын ул көнне күпләр күреп калгандыр.

Ә иртәгесен мәдәният йортында шаулап-гөрләп туй узды.

...Бу парның очрашу-кавышу тарихы исемә төшкән саен хәйран калып куям мин. Уеннан уймак кына түгел, балдак та чыга икән... Әйе, пар балдак чыкты бу матур уеннан.



Сирень
Якупова

# СҮЗГӘ ТӨРЕП, ҖЫР-СЕР ИТТЕМ...

***

**Һәркем белгән, аңлаганны,**
**Укыганны, ятлаганны,**
**Һәр көн күргән, ишеткәнне,**
**Инде күрми дә үткәнне,**
**Сүзгә төреп җыр-сер итү—**
**Азмы, күпме бер шагыйрьгә?**

**Ел-гасырлар аша үтеп,**
**Сүзен сүзгә аннан сүтеп,**
**Серне ачу бар дөньяга,**
**Таң калдырып өр-яңадан—**
**Азмы, күпме бер шагыйрьгә,**
**Бер йөрәккә, бер бәгырьгә?**

***

**И түбәннән агылалар бу болытлар,**
**Уй-түбәмә кагылалар бу болытлар.**
**Туган йортым...**
**Менсәм аның түбәсенә,**
**Бер шигем юк түбәм күккә тиясенә.**

**Тик күптәннән минем анда менгәнем юк,**
**Күк күгәрчен балаларын күргәнем юк.**
**Җил малаен көнләштереп, көлә-көлә,**
**Кыек буйлап яланаяк йөргәнем юк.**

**Морҗаларның корымнарын борынымнан**
**Ничә җәйләр соңгы тапкыр сөрткәнемә?**
**Ничә көзләр, ничә кышлар, ничә язлар**
**Туган җирдән еракларга киткәнемә...**

---

Сирень ЯКУПОВА—*шагыйрә; «Яшәү сере» һ. б. Казанда һәм Чаллыда дөнья күргән берничә китап авторы. Чаллыда яши.*

И түбәннән агылалар бу болытлар,
Йөрәгемә кагылалар бу болытлар.
...Менсәм дә мин Каф тавының түбәсенә,
Бер шигем юк түбәм күккә тимәсенә.

***

Бүген
Минем күңел керпе инде.
Йомшагым, дип, әйтер иде
Тик әнием, исән булса...

Тырпаешкан энәләрдән
Сыйпар иде тыны белән.
Назлы, җылы кулы белән
Балачагым тәме килгән,
Балачагым исе килгән
Алсу алма бирер иде,
Керпе күңел эрер иде,
Их, әнием исән булса...

***

Соң булса да танысыннар дисәң,
Ялкыныңнан кабынсыннар дисәң,
Керә белү кирәк
Миләш булып янып күзләргә.
Йә, һичьюгы,
Төрә белү кирәк
Януыңны тәлгәш-сүзләргә.
Төкрек йота-йота өзсен кемдер
Иреннәре, юк, күңеле белән!
«Тфү, әче!»—дип сүксен дәме кемдер?
Исең киткән,
Балланулар алда—кышка керәм...

***

Егылсаң да, югарыга егыл!
Көлсә көлсен дөнья, башын чөеп:
Күрәсезме, йолдыз тузанына
Батып ята берәү өстә (!) диеп.

Егылсаң да, югарыга егыл,
Күз яшьләрең тамсын—гүя яңгыр.
Корымасын дисәң нәсел гөлең,
Йөрәк дымың җиргә биреп калдыр.

Егылсаң да, югарыга егыл,
Беркем килеп сиңа абынмасын.
Каргый-каргый тибәр түмгәк булу
Язмышыңа берүк язылмасын.

Егылсаң да, югарыга егыл!
Ай яктырак анда, кояш җылы.
Һич сер түгел, күкләр аша кыска
Ак җаннарның мәңгелеккә юлы.
Егылсаң да, югарыга егыл...

***

Агачларның әле телсез мәле,
Иреннәре—ачылмаган бөре.
Мине генә шулай тилертәме
Һәр яз саен яшәрүләр сере?

Мине генә шулай тилмертәме
Бу каеннар, серне җилгә чишеп?
Төннәр буе җаным сакта тора—
Бер ачылыр мәңгелеккә ишек.

Йолдыз булып атылыр да биге,
Күкрәү булып күгәннәре иңрәр...
Соңгы тапкыр шулчак әче сүгенеп
Тибәр йөрәк: «Ашыгасың, җүләр!»

***

Җиде кат үлчәдем, җиде кат,
Ә кискәч, аңладым—ялгыштым.
Үлчәмен алдым дип дөньяның,
Ачуын китердем язмышның.

Тегүче кызымын, югыйсә.
Өлгенең ниндиен күрмәдем.
Таррак, кыскарак иткәнмен
Ал ефәк бәхетем кулмәген.

Кемгәдер тап-таман булачак,
Сөенеп киячәк бер ханым...
Ачуын китердем язмышның,
Үлчәмен алдым дип дөньяның.

***

Дөя дә бүләк, төймә дә,
Диеп ялгышкан
Чаклар узды. Дөя көтәм
Бүген язмыштан.

Гел төймә генә дигәнме
Миңа тигәне?
Сорамыйм, юк, таләп итәм
Бүләк-дөяне!

Чу, нишләвем?
Гел өлешсез
Калганнар күпме!
...Бәйрәм күлмәгемә тактым
Төймә-бәхетне!

***

Җилләр иркендә күңелем,
Ай-йолдызлар иркендә.
Күкләр кочып күтәрә дә,
Җирләр тартып төшерә.

Галәм таганында шулай
Атынамын тумыштан.
Елларыма исем китми—
Вакыт белән узышам.

***

Садәлекне сөрмә итеп тарттым,
Кершән итеп яктым тыйнаклыкны.
Керфекләрдән тамган оялчанлык
Күңелемнән юды уйнаклыкны.

Сөйләгәнем, аһ, пышылдау булды,
Җырлаганым? Мин тик тыңлый белдем.
Чишмә чагын хәтерләмим җанның—
Тумыштан ук салмак, уйлы идем.

Ялгармын дип хистән җепләр үрдем—
Йөрәк кылым калды өзелми дә.
Сизелми дә үтте яшьлек, димим,
Мин яшьлектән үттем сизелми дә...

Рәмзия
Габделхакова

# ТАУ АРТЫНДА КОЯШ БАР

РОМАН

Иркәм, мин сиңа үзебезнең шахта турында да бераз сөйлим әле. Гомер шунда үтте бит. Сугышка кадәр үк Америка геологлары Тянь-Шань тауларында уран ятмасы табалар. Шунда шахта сыман нәрсә ачыла. Башта анда Америка белгечләре эшли, авыр эшкә җирле халыкны җигәләр. Үзбәк, кыргызлар руданы агач әрҗәләргә тутырып, ишәкләргә төяп, американнарның аэродромына ташый, самолетка төйи. Имеш, ул уран Америкага озатылып торган. Шулай итеп, өстәге иң яхшы ятмалар океан артына китә. Шахтада эшләүчеләргә ул чакта акча түләнмәгән,—доллар белән нишләсен үзбәк?—азык-төлек белән генә исәп-хисап ясаганнар.

Сугыш елларында рәсми рәвештә уран руднигы ачыла, монда үзебезнең белгечләр эшли башлый. Тау итәгенә поселок та төзелә. Төрле халык җыела. Безнекеләр дә монда күчеп килә. Шахтада эшләүчеләр солдат хезмәтеннән генә түгел, хәтта фронтка китүдән дә азат ителә иде. Менә шундый кадерле, кыйммәтле була ул уран рудасы. Мине дә армиягә алмадылар, син монда кирәк, диделәр. Шулай итеп, ярты гомер җир астында үтте. Менә, иркәм, кара син бу кулларга, күпме юсаң да кап-кара алар, мәңге агарасы юк. Җитмәсә, тавык тәпие сыман кытыршы да. Бу куллар белән хәзер кызлар иркәләп булмый шул инде. Яшь чакта бер дигән егет идек. Юкәлегә кайтып, авылның иң матур кызына өйләнеп килдем. Апаң фермада сыер савучы булып эшли иде. Монда килгәч кенә укыды ул, минем әби юлыннан китте. Өч көн артыннан калмый ялынып йөрдем, тәки ризалаттым. Бик чибәр иде апаң, авыл егетләре көнләшүдән күлмәк якаларын чәйнәп калды. Ана кызыгып, өметләнеп йөрүчеләр күп булган. 1959 елда өйләнештек. Ул чакта зурлап туйлар үткәрү юк, ияртте дә алып киттем. Башта алачыкта яшәдек. Аннары менә бу йортны төзеп кердек. Материал эзләп ерак барасы юк, балчыгы-комы үзебездә. Шуларны салам белән бутыйсың да, менә дигән кирпеч-саман килеп чыга. Мондагы балчык бик яхшы, үзле бит, шуңа безнең йортлар җир тетрәүгә дә бирешми. Тагы нәрсә дим инде. Балаларны—Әнәс белән Рамиләне беләсең. Аларга тау эчендә эшләргә туры килмәде. Уран беткәч, шахталар ябылды бит. Халыкка эш булсын дип, лампа заводы төзеп куйдылар. Директоры Николай Мелькер дигән, иллә дә шәп, булдыклы бер нимес. Заводны бөтен дөньяга танытты тәки.

*Дәвамы. Башы 4 санда.*

Яшьләр шунда агыла хәзер. Ник бармасыннар, зарплат яхшы, рабучийны кайгырту бар. Кешегә күп кирәкмени, дөньялар гына имин булсын. Шуны онытма, иркәм: тынычлык белән саулык иң зур байлык ул... »

Жизнәм тынып калды. Ә мин, сораулы карашымны аңа төбәп, сүзенең дәвамын көттем. Ләбиб абый, тагы ни сөйлим икән дигән сыман бераз уйланып торды да: «Житкәндер, шәт...»—диде. Аннары тәмәке тартырга чыгып китте. Ул әйләнеп кергәч, язганнарымны ана кычкырып укыйсы иттем. Тикшерми булмый, хата-фәлән китүе бар. Жизнәм бик игътибарлап тыңлады, күңеле булып, гөрелдәп көлеп тә куйды. Көлгәндә йөзендәге җыерчыклары язылып, яшәреп киткәндәй тоелды. Кеше үзенең үткәннәренә оялмыйча, горурланып карый алса, рәхәттер инде ул.

—Язылганнар дөрес дип расла әле, җизнәй, истәлеккә калыр,—дидем мин.

—Раслыйбыз аны!

Жизнәй борынына күзлек элеп, тырыша-тырыша нидер сырлап куйды.

—Менә шулай... Моны әлегә беркемгә күрсәтмә, иркәм, үзеңдә генә сакла, яме.

Анын язган сүзләрен укыдым да, әллә нишләп киттем.

—Дөнья хәлен белеп булмый,—дип куйды жизнәй моңсу гына көрсенеп.

Күзләре коры булса да, карашы яшьле иде...

«Үз әтием турында да язарга кирәк»,—дип уйладым мин шул чакта. Болай остарып киткәч, нигә язмаска?! Шулчак өзелеп әтине сагынып куйдым, шул хәтле күрәсе килеп китте. Жизнәм кебек менә шулай каршымда утырсын иде, кечкенә баладай күкрәгенә килеп сыенып идем. Сыенып-иркәләнер идем, бәлки күңелем нечкәреп елап та алыр идем... Нишлиләр икән алар хәзер?

Әй лә, Кифаясы белән төпчек малайлары янында үчти-үчти киләләрдер әле. Илнарга сан да юктыр. Шулай уйлагач, сагыну хисе басылгандай булды.

***

Уйга килгән алга килә дип әйтәләр бит.

Килде әти... Юк, үзе түгел, хаты килде. Ләкин анын кулы белән язылган хатны алу да минем өчен әти белән күрешүгә тиң иде. Ярый әле, үз кулыма килеп эләкте ул! Югыйсә ул көнне жизнәм өйдә иде. Мин ашарга пешердем дә, кибеткә ипи алырга чыгып киттем. Эшкә икенче сменага барасы иде. Шуннан кайтышлый, почта әрҗәсе ярыгыннан күренеп торган ак кәгазьгә күзем төште. Газетларга ияреп, хат та килеп төште.

Аны тиз генә ача алмый җәфаландым, ашыгу-дулкынланудан кулым карчыкларныкы кебек калтырый башлады. Сабырсызланып хатны укырга керештем:

«Исәнмесез, кадерле туганнар! Ләбиб, Фатыйма, балалар! Сәлам сезгә туган яклардан, безнең гаиләдән. Гөлзадә вафатыннан соң сезнең белән хәбәрләшкән дә булмады. Бәлки сезгә дә килеп ирешкәндер, мин өйләндем бит, улыбыз бар. Ир-ат ялгыз яши алмый. Хатыным Кифая үзебезнең авыл кызы, бер-беребезне яшьтән беләбез. Балаларны якын итте. Илнар аңа ияләште инде. Тик Наргизә генә өйләнүемне өнәп бетермәде...»

Шул урынга җиткәч, хатны ертып атасым, җиргә салып таптыйсым килде. Ну әти! Кем инде үлгән хатынының апасына шундый сүзләр яза?! Бик кирәк инде Фатыйма апага синең Кифаяң! Житмәсә, мине хурламакчы. Өнәмәде, имеш! Шатлыктан кул чаба-чаба биисе булды микәнни?

Хатны ертып ташлаудан кызыксынуым гына туктатып калды, сабырлыгым

житеп укып бетердем: «Фатыйма, безнең Наргизә югалды бит әле. Ул Әлмәттә эшләп йөри иде, алтынчы август көнне ялга чыккан булган. Бергә торган дустына, авылга кайтам, дигән. Тик кайтмады. Шуннан бирле ни тере, ни үле хәбәре юк. Бу хәлгә бик борчылабыз. Алай-болай сезгә берәр нинди хәбәре килмәдеме? Башка якын туганы юк бит. Үпкәләп кайтмый йөрүе генә булса бер хәл, харап була күрмәсен дип куркам. Фатыйма, әгәр Наргизә турында ни дә булса ишетсәгез, зинһар, хәбәр итегез. Ни уйларга белмибез, бөтен тынычлык югалды...»

Менә монысы яхшы, бик хуп! Кайгырыгыз, ут йотыгыз, җәфаланыгыз, төннәр буе йокламагыз! Шул кирәк сезгә!

Мунчага алып кердем дә, хатны «бик тәмләп» яндырдым. Кеше уттан, судан, җирдән көч ала, имеш. Әгәр шулай икән, бу хат янганда чыккан ялкын бөтен җан-тәнемне иркәләп-сыйпап узды, шундый рәхәт булды миңа. Үч алуның никадәрле татлы хис икәнен аңласагыз-белсәгез икән! Ул көнне бәхет кошы тоткандай очып-биеп йөрдем.

Ләкин хат җавапсыз калырга тиеш түгел иде. Шуңа күрә почтага кереп авылга телеграмм суктым: «Ее у нас нет. О ней ничего не знаем.» Моннан соң башка борчымаска тиешләр. Тик елашып ятсыннар шунда, шул кирәк аларга! Ә Илнар... Нишлим соң инде, нишлим?! Сагынам бит мин аны! Яшереп кенә хат язасы иде, сөйләшәсе иде үзе белән. Тик ярамый. Ярамый!

***

Булган акчамны учка йомарлап ял көнне Ният базарына барасы иттем. Бармый хәлең юк, кыш борын төбендә генә. Фатыйма апа әйткәндәй: «Шаярма, җылы як дигән белән түгел, бездә дә кыш үзенекен итә, битеннән дә, ботыннан да чеметә!» Кары булмаса да салкыны бар, төннәрен кырау төшә. Ә минем җылы киемнәр юк, ике кулымны селтәп килдем бит. Көяз өшеми калтырый, борын асты ялтырый дигәндәй, җинел-җилпе киемнәр белән әлегә сер бирмичә йөргән булам да, түземлек озакка җитмәстер кебек.

Ниятка Әнәс мотоцикл белән илтеп куйды. Мине базар карурманына кертеп адаштырды да үз юлы белән китеп барды. Ә монда чынлап та урман, лабиринт! Бу кадәр дә олы, бу кадәр дә бай базарны гомердә дә күргән юк иде. Әллә ничә чакрымга сузылган. Әйбер өстенә әйбер, абынып егылырсын. Тауар лавкалары тезелгән тыкрыкларны урый-урый, чыгар юл тапмый буталып йөри-йөри, тәмам хәлдән тайдым. Житмәсә тавыш, ыгы-зыгы, бер яктан үзбәк җырлары агыла, икенче яктан ишәкләр кычкыра, өченче яктан сатучыларның чакыру-үгетләүләре борчак булып башка сибелә. Барысы да, мактый-мактый, үз тауарын сиңа такмакчы, ничек тә акчаңны сыдырып калмакчы була:

—Кил, асалим! Кунглингзга холлаган нарсани сотиб олинг, гузал кыз! Ол, асаля!

Үзбәк теле дә, кыргыз теле дә безнекенә охшаш, тырышсаң аңлап була. Сатучыларның бер алдына, бер артына төшеп кыстауларына чыдар әмәл юк, тизрәк берәр нәрсәләрен алып, алардан котыласы килә. Җәтмәгә эләккән балыктай сизәсең үзеңне. Күбрәк ирләр сата, сатучылар арасында хатын-кызлар сирәк очрый. Барысы да җирле халык. Чүпрак-чапракка, табак-савытларга күмелеп, күмер күзләрен ялтыратып утыралар.

Ә базарда көне буе үзбәк җырлары яңгырап тора, әйтерсең, ниндидер зур бәйрәм. Адым саен чәйханә, адым саен шашлык кыза, мантый, чебурек пешә. Хәер, монда гына түгел, Әндиҗанда да, Ташкентта да шулай иде. Хәтта эш көннәрендә дә бәйрәм кәефе, бәйрәм төсе. Мондагы халыкның бер кайгысы юк кебек.

Яшьрәк хатын-кыз күргән саен сагыз кебек ябышырга торган мут ирләр белән бәйләнәсе килмәде, пәлтәне дә, җылы кофтаны да бер үзбәк хатыныннан алдым. Мин татарча, ул үзбәкчә сөйләште. Барыбер аңлаштык. Сум—аларда да сум.

Үзбәк апасы үзеннән тауар алганга сөенеп, рәхмәтләр укый-укый озатып калды:

—Чин юракдан тилийман, жоним, бахтли булила!

Алган әйберләрне көчкә күтәреп базар-каладан чыкканда, үртәлеп уйлап куйдым: «Шәп яши мондагы халык! Ни теләсән—шул бар. Бездә булса икән шул кадәр байлык!» Кулда акча йомарлаган килеш кирәкле әйберне юнәтә алмый аптырыйсың бит. Әгәр Әлмәт халкы Ният базарына килсәме? Бер сәгать эчендә берни калдырмый, бөтен товарны кырып-себереп алып китәрләр иде! Нигә Россия кибетләре шул кадәр ярлы икән?! Нихәтле завод-фабрика көне-төне эшләп тора лабаса. Кайларга китеп югала икән аларда җитештерелгән байлык? Аңламыйм мин шуны, аңламыйм...

***

Минем группада Ситара исемле бер сәер кыз бар. Аны Зита дип кенә йөртәләр. Кайчакта Гитара дип үртиләр. Үзбәк кызы булса да, аксыл йөзле, зур кара күзле, бик нәфис тәнле бала. Шундый матур, сөйкемле, курчак белән бер инде. Үзе кыргый, беркемгә якын килми, аралашмый. Уйнаганда да башкалардан аерылып ялгызы гына берәр аулак почмакка поса. Шул кадәр боек бала инде, озын керфекләреннән менә-менә көмеш тамчылар тәгәрәп төшәр төсле.

Ситара бакчага быел көз генә йөри башлады. Аны башына дүрт кырлы үзбәк түбәтәе, өстенә буй-буй халат кигән ак сакаллы бер бабай китерә. Килеп җиткәч тә, кыз бакчага кереп китәргә ашыкмый, аерылырга теләмәгәндәй, бабасының муенына сарыла. Карт аны үзенчә юмалап-көйләп, аркасыннан кага-кага озатып кала. Һәр көнне бер вакытта, кичке аштан соң, килеп ала. Икәүләп ишәккә атланалар да, тау ягына китеп баралар.

Бу кыз белән уртак тел табарга күпме генә тырышсам да, берни барып чыкмады, башын иеп, иренен ныгытып кыса да тик киреләнеп басып тора. Аннары мин аңа кул селтәдем, еламыймы-еламый, сугышмый, биргәнне ашый, кушканны эшли, тагы ни кирәк. Аның белән, әби әйтмешли, партия җыелышы үткәрәсем юк.

Ләкин бер көнне ишәкле бабай килмәде. Биш тә тулды, алты да, җиде дә... Бөтен балаларны өйләренә алып бетерделәр, буп-буш бакчада Ситара белән икәүдән-икәү аптырап утырып калдык. Җитмәсә, нәкъ шул көнне үч иткәндәй, Вера апа да, туган көнгә барам дип эштән сорап киткән иде.

—Бабаң авырыймы әллә?—дип сорыйм Ситарадан.

Кыз башын чайкый.

—Әниең бармы соң синең?

Бу юлы уңай җавап белдереп баш кага.

—Ә әтиең?

Бусына да уңай җавап алам.

Менә сиңа мә! Бабай бар, әни бар, әти бар, ә кызны килеп алучы юк. Кайларда, ни исәпләп йөри икән бу гамьсез халык?

Икәүләп тәрәзәгә капланып урамны күзәтәбез. Ситара тәрәзә пыяласын тынын өреп парландыра да, бармагы белән сызгалап рәсем ясый: түгәрәк, аның эчендә өч нокта, урак ай...

—Кем бу?—дим.

Тик Ситара дәшми, моңсу елмаеп иңнәрен генә сикертә.

Дүрт күз белән көткән кешебез—ишәкле бабай күренми дә күренми...

Инде карангы төшеп килә. Шулчак тәрәзәгә якты ут килеп сарыла, тырылдаган тавыш ишетелә. Бакча каршына ишәк түгел, арбасыз мотоцикл килеп туктый. Бу вакытта кем йөрер икән монда? Мин шикләнеп куям, ике катлы бинада бездән башка беркем юк. Килүче яман ниятле бәндә булса, ялгызым ни кыла алам?

Ә Ситара шатланып кычкырып җибәрә:

—Әтием!

Ниһаять! Ашыга-ашыга урамга чыгабыз. Ишек төбендә башына шлем кигән бер баһадир басып тора. Баганадан төшкән ут яктысында шлем астыннан чыгып, иннәренә таралып төшкән алка-алка чәчләрен, йолдыз булып балкыган күзләрен, ныгытып кысылган кырыс иреннәрен күреп өлгерәм. Барысы да кинодагы кебек бик тиз була. Ир Ситараны кочагына ала да, бер сүз дәшми, эре-эре адымнар белән мотоциклына юнәлә. Икенче мизгелдә алар күз алдыннан югалалар... Җен шешәсеннән чыккандай зәңгәрсу куе төтен генә бакча коймаларына ягылып кала...

Шул чакта гына башыма китереп суга: «Кем булды бу? Чынлап та әтисеме? Алайса нигә аның биредә бер тапкыр да күренгәне булмады? Әгәр бу кешегә баланы бирергә ярамаган булса? Әгәр ул аны урлап качса?» Нишләдем мин, нишләдем? Өч яшьлек сабый сүзенә ышанып, бер белмәгән кешегә бала тоттырып җибәрдем...

Икенче көнне эшкә курка-шикләнә генә бардым. Әти-әниләр балаларын җитәкләп килә торды, бакча җанлана торды. Тик ни бабайлы ишәк, ни баһадир ир атланган корыч айгыр күренмәде.

Ситараны китерүче булмады...

Мин коелып төштем. Ләкин дәшми калырга ярамый, бер-бер чара күрергә кирәк иде. Гаепле башымны иеп мөдиребез янына киттем. Ярый әле, Эльза Фридриховна күтәрелеп бәрелмәде, сабыр гына тыңлады, аннары шкафтан бер папка алып, шуны актарырга кереште.

—Аның әтисе дә, әнисе дә бар, исән. Торган урыннары—Караташ кышлагы. Моннан өч-дүрт чакрым тирәсе. Баланы чит кеше килеп алмас. Ситара аны таныган бит. Бәлки бабасы авырып киткәндер. Сез тыныч кына эшләгез, бу мәсьәләне мин үзем ачыкларммын.

Эш вакытым тәмамланып кайтырга җыенганда Эльза Фридриховна кабат үзенә дәшеп алды:

—Наргиза Мидхатовна, Бахтияровлардан бер хәбәр дә булмады бит. Әллә өйләренә барып, баланың килмәү сәбәбен ачыклап кайтасызмы?

Белеп торам, мөдирнең миннән киңәш соравы түгел, бу инде аның боерык бирүе. Ул гел шулай, киңәш-табыш иткәндәй иплә кенә, йомшак кына сөйләп, эшне оештыра, кешене тыңлата белә. Аның үтенеченә берничек тә каршы килә алмый идем, әлбәттә. Чөнки гаебем бар, Ситараны гомер күрмәгән ир-атка үз кулым белән мин тапшырдым. Ләкин дүрт-биш чакрым ераклыктагы кышлакка, бер белмәгән җиргә ялгызым ничек барыйм?!

—Җәяү түгел, Наташаның ире белән барырсыз,—диде Эльза Фридриховна.

Наташа—безнең медсестра. Аның ире больница машинасын йөртә, азык-төлек, дару ташый. Кирәк булганда, җае чыкканда безгә дә ярдәмнән баш тартмый.

Шулай итеп, Валерий белән кышлакка юнәлдек. Ул юл буе сукранып барды:

—Мондагы халык шәһәргә күчеп бетте инде. Җыен карт-коры җан асрап яткан була. Ни кибетләре, ни мәктәпләре юк. Юлы юл түгел. Авыл дисәң хәтере калыр, елки-палки.

Поездда барганда ук күзәтеп килгән идем: Азиядәге кышлаклар безнең

як авылларына охшамаган, йортлар тәртипсез рәвештә сибелеп-таралып утыра, урам дигән нәрсә юк. Һәрхәлдә миндә шундый фикер калды.

Караташ ике тау арасындагы үзәнлектә урнашкан. Без барганда, әллә намаз вакыты туры килдеме, анда үле тынлык иде. Урамында бер адәм заты күренмәде. Ситара яшәгән йорт кайсы икән? Кемнән сорарга?

Бәхетебезгә, су буеннан керләр күтәреп кайтып килүче бер яшь хатын очрады. Оялган-кыенсынган сыман карашын түбән иеп тынлады, авызыннан бер кәлимә сүз чыкмады, безгә кирәкле йортны кулы белән генә төртеп күрсәтте.

Бәхтияровларның йорты башкаларныкыннан нык аерылып тора иде. Бердән, ул юлдан читтә, елганың теге ягында, тау итәгендә үк урнашкан. Икенчедән, башка йортлар сыман җилдә җилфердәп утырмый, биек диваркойма белән уратып алынган. Өченчедән, балчыктан түгел, кызыл кирпечтән төзелгән, заманча матур, мәһабәт йорт. Һәм бу йортка тиз генә керәм дип хыялланма, аны тимер капка һәм усал эт саклый. Капкага зур иттереп: «Сак булыгыз, овчарка!» дип зур иттереп язып куелган.

Башта капканы шакып маташкан булдым, почта әрҗәсе янындагы кыңгырау төймәсенә аннары гына күз төште. Харап икән болар, шәһәрчә яшиләр. Төймәгә баскач та тавыш-фәлән ишетелмәде, үле тынлык. Ишеттеләрме мине, чыгучы булырмы? Эчтә ниләр барлыгы күренми, үләм дисәң дә, ни коймада, ни капкада күзәтер өчен бармак сыярлык та ярык юк. Ничек шулай ясап бетергәннәр диген.

Ниһаять, ишек ачылган тавыш ишетелде, кемдер авыр гына атлап, кәлүшләрен өстерәп капкага якынлашты. Менә капка өч бармак кинлегендә генә ачылды, анда бик таныш йөз, чал сакал күренде:

—Нәмә кирәк?

Капканың ябылуыннан, бабайның югалуыннан куркып, ашыга-ашыга тезеп киттем:

—Мин балалар бакчасыннан. Кызыгызның тәрбиячесе. Ситара ник килмәде? Без сәбәбен белергә тиеш! Ул авырыймы? Ни булды?

—Ситара иртәгә бакчага барачак,—диде бабай һәм капканы шапылдатып ябып та куйды.

Өстемнән гүя тау төште: «Ситара исән, югалмаган! Минем гаебем юк! Ур-ра!!!»

Чынлап та, икенче көнне мин эшкә килгәндә, Ситара бер почмакка чүмәшеп, мышный-мышный йомшак куяннар белән уйнап утыра иде. Йөзендә дә, үз-үзен тотышында да андый-мондый үзгәреш сизелмәде. Ни шатлану, ни кайгыру юк. Тып-тыныч таш йөз. Аны, һәрвакыттагыча, ишәккә утыртып бабасы алып килгән...

***

Миңа нидер булды. Кичләрен үземне кая куярга белмим. Аптырагач, бакчага чыгып утырам да, тауларны күзәтәм. Таулар биек... Таулар тыныч. Алар янында кеше шундый бәләкәй. Таулар безне көлемсерәп һәм кызганып күзәтәдер кебек. Адәм балалары ярыша-ярыша үрләр яулый, тау башына менеп исемнәрен язып калдыра. Ләкин мәгърур тауларга барыбер. Гасырлар буе күкләргә төбәлеп серләшеп яталар, кояшны каршылыйлар, озаталар...

Тауларга берни кирәкми.

Ә миңа ни житми?! Кая ашкына, нигә шулай гасабилана бу хыялый күңел?! Нигә шулкадәр өзгәләнеп-зарыгып көтәм аны?! Кем ул миңа, ни хакым бар шулай көтәргә? Өмет бирүче булдымы?

Мин икенче сменада эшләргә ярата башладым. Бигрәк тә кичләрен

күнелемә ниндидер бер билгесез ашкыну кереп оялый. Үзем дә сизми әледән-әле тәрәзәгә күз салам. Балалар белән ишегалдына чыктык исә, карашым үзеннән-үзе бакча капкасына юнәлә. Һәр үткән-сүткән мотоцикл тавышы сискәнергә, шул якка каерылып карарга мәҗбүр итә.

Ләкин ул килми... Ишәккә атланган чал сакаллы бабай гына килә. Ситараны ул алып китә.

Нигә шулай булды? Нигә йоклап калдым, ичмаса, бер-ике сүз булса да әйтергә өлгермәдем икән? Исемен отып калыр, тавышын ишетер идем. Нинди икән аның тавышы?

Шулай өзгәләнәм дә, үз-үземне сүгә башлыйм: айны, җүләр, айны, аның бит кызы бар! Бар шул, үзе булмаса, кызы янымда! Мин гел Ситара тирәсендә бөтерелә башладым, хәзер ана аерым игътибар. Бу матур кызчыкны үземә иядәштерәсем, ышанычка кереп, әнисе, әтисе турында сорашасым килә. Әмма кыз нык тора. Сыйлап та карыйм үзен, майлап та карыйм, юк, читләшәме-читләшә. Ситара белән ботка пешми.

Кыскасы, мин өр-яңадан гашыйк булдым. Гомеремдә бер күргән, исемен дә белмәгән, күктән төшкән бу серле зат минем йөрәк түренә менде дә утырды...

Житмәсә, нәкъ шул көннәрдә мине сорап килделәр. Без кунакта булган Рәшидә апаның милициядә эшләүче туганнан туган энесе өйләнергә кыз эзли икән. Ышанычлы, акыллы татар кызы кирәк, ди. Мине шундый дип тапканнар.

Егетнең исеме Роберт, егерме сигез яшь, югары белемле, бик булдыклы, уңган-тырыш егет. Кияүнең үзен күргәнче үк Фатыйма апа, мина шундый хәбәрләрне житкерде. Алдамаган икән. Бик мөлаем, әдәпле егет. Үзен бик тыйнак тотты. Олы бүлмәдә бергәләп чәй эчкәч, икәү верандага чыгып утырдык. Роберт мина туры карамаска тырыша, карашын әледән-әле тәрәзәгә күчерә. Мин исә, оялчан кызлар сыман башымны иеп, итәк очын бөтереп утырам, маңгай астыннан гына булачак киявемне күзәтәм.

Робертның исеме үзенә туры килми. Бу исемне ишеткәч тә, күз алдыма никтер озын, төз буйлы, аксыл йөзле, зәңгәр күзле, сары чәчле бер егет килеп баскан иде. Ә Роберт моның гел киресе. Беренчедән, ул озын түгел, буйга тиясе өлеш аркылыга киткән: калын кыска муен, киң күкрәк, таза, нык беләкләр, кыска аяк. Житмәсә, казах-кыргызга охшаган жәенке бит, шешенке кабак астыннан ут чәчеп торган чем-кара кысык күзләр. Салмак хәрәкәтле, үткен карашлы, көр тавышлы егет. Сүзләрне бик сайлап кына, сак кына, уйлап кына дигәндәй сөйләшеп утырган булабыз. Әүвәл һава торышы турында фикер алышып алдык, быелгы уңышны тикшердек, аннары сүз агышы әкрен генә минем тормыш елгасына таба борылды.

—Балаларны яратканга шундый һөнәр сайлагансыңдыр, Наргизә?—дип сорый Роберт.

—Аларны ничек яратмыйсың?—дим йөземә харап житди, акыллы кыяфәт чыгарып.—Йоклаганда бигрәк матур була бит алар.

—Уянгач, ямьсезмени?

—Уянгач, матурлыкларын күрергә вакыт юк, тавышлары гына ишетелә.

Ләкин Роберт шаяртуны аңламый:

—Балалар бар да яхшы, тик менә юньсез бәндәләр кайдан килә диген, ә, Наргизә? Аптыраган бу хәлгә, баш житми. Бер үк илдә, бер үк шартларда тәрбияләнәбез югыйсә.

—Гаиләдәндер инде... Әти-әнисе нинди бит. Балаларның да төрлесе бар. Минем группада, әнә, бер пырдымсыз малай кызларны чеметеп, чәчләрен тартып елата. Икенчесе уенчыкларны ватып-ботарлап ташлый, өченчесе

күзе төшкән бар нәрсәне кесәсенә шудыру ягын карый... Кайсы ниндиерәк буласы хәзердән үк билгеле инде. Барысы да бер төсле димәс идем, Роберт. Кайберләрен читлеккә ябып куясы килә.

Роберт чәчен сыпырып, көлемсерәп куя:

—Шул яшьтән үк яба башласаң, читлеген җитмәс...

—Партия кушуы буенча «Һәр балага—бер читлек!» программасын башлап җибәрербез...

Сүзләрем бик сәер тоелгандыр, күрәсең, Роберт миңа гаҗәпләнеп карап куя. Икебез дә дәшмибез. Ләкин авызга су кабып утыру да килешми кебек. Сүз юктан сүз булсын дип кенәдер инде:

—Эне-сенелләрең бармы соң?—дип сорый Роберт.

—Әйе, энем бар, бик сагынам үзен.

—Туганнардан аерылу җиңел түгел. Авыр язмыш сайлагансың.

—Ник алай дисең?

—Чит җирләрдә ялгызына кыендыр.

—Мин ялгыз түгел, Фатыйма апам бар.

—Анысы шулай...

Яңа танышкан, дөресе, читләр таныштырган кешеләргә сөйләшү-аралашу ансат түгел, табигыйлек, гадилек югала. Туганнарың сине мактаган икән, сер бирәсе килми, яхшы, акыллы булып күренергә тырышасың. Роберт та шундый хәлдә иде. Мин сөйләшергә әллә ни атлыгып тормагач, ул тегесен-бусын сорашкан булды. Алар сорашырга өйрәнгән халык бит инде. Ә мин аның эше турында берни белмим һәм белергә атлыгып та тормыйм. Анда мин кызыгырлык ни булсын, караклар, бандитлар дөньясы. Юлдан язган халык белән көрәшүчеләргә Ходай ярдәм бирсен...

—Янгуразның кызы да сезнең бакчага йөри бит.

Мин аптырыйм:

—Кем соң ул Янгураз?

—Минем служак. Әфганда бергә хезмәт иткән идек. Шуннан бирле ике арага тузан төшерми, тәки шул юлны таптый.

Мине Янгураз дигән адәм дә кызыксындырмый, ләкин әдәп саклап тыңлаган булып утырам. Соравым да сүз булмаганнан сүз булсын өчен генә:

—Нигә?

—Бар инде хикмәтләре... Контрабандист ул. Бер-ике тапкыр йолып калдым инде үзен. Тыңламый, һаман кыек юлда йөри. Җиңел акчаның тәмен белеп алган...

Роберт сөйли дә сөйли. Баягы киеренкелекнең эзе дә юк, җанланып китте бу. Тавышы да көррәк яңгырый башлады, «үз күле»енә кереп чумды бит кеше.

—Кеше ышанмаслык хәл, Наргизә, Әфганнан урыс кызы ияртеп кайтты ул. Үзбәк-кыргыз халкы бу яктан ифрат кырыс бит, урысны якын да китерми. Гаиләгә кергән кеше һичшиксез мөселман булырга тиеш. Бу кызый сугышта медсестра була, яралылары белән әсиргә эләгә. Егетләрне үтерәләр, моңа тимиләр, үзләрендә эшләтәләр. Үләсе килмәгәч ризалаша инде бу. Янгураз взводы килеп коткара үзен. Шуның өчен Янгуразга медаль дә эләкте әле...

Алай икән... Бүгенге көн Янгураз дигән бәндәнең тормыш юлы белән танышып үтәр, мөгаен. Игътибарлап тыңла, Наргизә, болар сиңа гаять кирәк. Ә Роберт, сөйләр сүз табуына сөенгәндәй, Алланың кашка тәкәсе—Янгураз турында хикәятен дәвам итә:

—Солдаттан Тамара белән бергә кайттылар. Кышлакта яшәргә ничек ризалашкандыр тегесе, шәһәр кызы бит. Мәхәббәттер инде. Түлке яман көнләште Янгураз. Тамарасы өчен хан сарае төзеп куйды. Хәзер беркем

урлый алмый инде алтын балыгын. Керә торган түгел анда, урта гасырларның замок-кирмәне диярсең.

Аның бу сүзләрен ишеткәч, йокымсырап утырган җиремнән кинәт калкынып куям:

—Алар кышлакта яшимени?

—Әйе, Караташта. Шунда бикләнеп яталар иде. Тик хәзер хатыны нык авырый икән, шуңа күрә Янгураз кызын бакчага илтеп биргән.

Робертның күз алдымнан кинәт югалуына, әңгәмәнең өзелүенә курыккандай ашыгып сорыйм:

—Кызының исеме ничек?

—Мөнә анысын хәтерләмим. Хәзер бик аралашкан да юк инде. Аның үз юлы, минем—үземнеке.

Шатлыгымнан бөтен эчем кытыкланып куя: бу—ул! Бездә Караташтан килеп йөрүче башка кыз юк. Димәк, Ситараның әтисе—Янгураз! Әнекәй генәм, нинди матур, ягымлы исем... үзе кебек... Бу яңгырап торган исемне теленнән төшермәссең, кабатлап туймассың! Ай, рәхмәт яугыры, Роберт, бу кадәр мәгълүмат бирүең өчен кочып-үбәр идем үзеңне. И дөньяда бер игелекле кеше, сөйлә әле, тагын-тагын сөйлә әле шул егет турында. Мин сине көне буе, төне буе тыңларга риза! Сөйлә әле, минем күңел кошым, җан канатым—Янгуразым турында!

Хуш, бертөрле күңелсез тормыш! Исәнме, маҗаралар, серләр дөньясы!

***

Роберт мине ошаткан, кәләше итеп күрергә теләгән икән... Кире кагуымны белгәч, бик хурланган-унайсызланган, имеш. Ул унайсызланган, ә Фатыйма апа да, башкалар да аптырады, мине гаепләделәр. Соң инде, җилкәсендә башы, башында акылы булган кыз шундый асыл егетне кулдан ычкындыра димени?! Кушыл да, иреннән җылы, ышанычлы канаты астында мәче баласыдай иркәләнеп, рәхәтләнеп яшә! Әгәр Роберт белән аз гына иртәрәк очрашкан булсак һәм ул миңа Янгураз турында кызыклы хикәятен сөйләмәсә, бәлки кушылырга ризалашыр, инде җиң сызганып туй мәшәкатьләренә дә керешкән булыр идем. Ләкин егетебез ялгышты, сүз юктан сүз булсын дип, болай да маҗаралар яратучы иләс-миләс кызга артыгын сөйләп ташлады. Орлыгы бик уңдырышлы җиргә килеп төште шул... Хәзер минем күңелдә гөнаһлы уйлар оя корып маташа: барыбер Янгуразны табачакмын, үземә каратачакмын! Нигә? Чөнки ошатам, яратам мин аны! Ул минем кешем! Тик үземә караткач нишләрмен, аның бит хатыны, кызы бар... Монысын әлегә үзем дә белмим. Ни телим мин? Белсәм икән... Тиле башта акыллы уй була димени?!

—Сиңа тагы кем кирәк? Яшең утызга җиткәнне көтәсеңме?—дип дулады Фатыйма апа.

Әллә инде тизрәк котыласы килә... Юктыр ла, миңа начарлык теләми ич ул. Нияте изге: кадерле сеңлесен ышанычлы, җылы кулга тапшырмакчы.

—Мөнә дигән егет, эчми-тартмый, акыллы, тәртипле... Үз квартиры бар, каенана кубызына биисе түгел. Мондый кияүләр адым саен очрап тормый ул, туганым. Дәрәҗәле чагында урнашып калырга кирәк!

Мин куырылып китәм. Әлмәт юлы, Женя, больница—барысы берьюлы искә төшә. Дәрәҗәлеме икән соң?.. Минем хәлне кем белә? Чит кеше түгел, үзем дә белмим әле. Бу хакта уйлый башласам, йөрәгемә шом үрмәли, тәннәрем өшеп-чымырдап китә. Шуңа күрә узгәнемнең ул караңгы көннәрен вакыт пәрдәсе белән каплап, тизрәк онытасым килә.

...Сигезенче март бәйрәмендә Робертны өйләндердек. Туйга мине дә чакырганнар иде, бармадым. Фатыйма апа бик мактап сөйләде. Кәләше бик

чибәр, яшь икән. Туганнары әйбәт кияү эләккәнгә бик сөенгәннәр, имеш, унсигезе дә тулмаган кызларын ир кочагына атканнар. Ярый, бәхетләре булсын...

Ә мин... Ә мин һаман үзем белән култыклашып, хыялымның төтен тауларын гизеп йөрим... Тик Янгураз атлы мәхәббәт кошым башка күренмәде. Өмет өзелде, күңел басылды бугай, көтмим дә кебек үзен. Мина насыйп яр түгелдер ул. Янында, чирле булса да, хатыны бар. Бәлки күзне йомып, Робертка чыгасы калгандыр. Мәңгелек мәхәббәт өмет итеп, әби әйткәндәй, телсездән җыр, динсездән дога көтеп йөри-йөри, гомерең буе карт кыз булып япа-ялгыз калуын да бар.

Беркөнне күңелсез хәл булды. Жизни белән апа Ташкентка никах мәҗлесенә киткәннәр иде. Без өйдә Әнәс белән генә калдык. Ул бик соң кайтты. Үзе лаякыл исерек. Инде йокларга яткан идем. Бервакыт дөбер-шатыр бүлмәгә бәреп кермәсенме бу. Кергән уңайга шәрран ярып боерды:

—Наргизә, ашарга бир! Тамак ачты, табын әзерлә!

Әнәсне кайгырту мина йөкләнгән иде, шуна күрә каршы дәшеп, телләшеп маташмадым. Урынымнан кузгалып өстемә халатны элмәкче идем, кай арада мәче кебек сикереп, Әнәс муеныма асылынды да мине кабат урынга екты. Ниятләре бер дә изгедән түгел, мышный-мышный:

—Үләм, телим бит, әй, бир инде!—дип бәйләнә башламасынмы...

—Әнәс! Җүләрләнмә!—дип үгетләп карыйм, ишетми дә. Хәмердән тәмам акылын җуйган. Көчкә кулыннан ычкынып, урамга йөгердем. Ишекне тышкы яктан бикләп куйдым да, салкыннан, куркудан дер калтырап, байтак басып тордым шунда. Шул хәтле хурландым. Бу мыскылны чит кешедән күрү җитмәгән, үз туганың да шулай рәнҗетсен әле. Нигә шулай кылана икән бу ир-ат халкы, аларга көч-куәт хатын-кызны буйсындыру өчен генә бирелмәгәндер ич?! Күз алдыма Янгураз килеп баса. Әгәр ул да шундый булса? Юк-юк, мәңге юк! Күңелем сизә: Янгураз андый түгел! Гомерен ут астына куеп, Тамарасын әсирлектән коткарган бит ул! Их, мин дә шул Тамара урынында булсам икән! Янгураз килеп коткарасы булса, әсирлеккә дә, әллә нинди әрнү-газапларга да түзәр идем!

Нәүмиз карашымны баш очымда балкыган якты йолдызларга текәп, күңелемнән генә аңа, әле ачылмаган гөлемә—хыялымдагы мәхәббәтемә эндәшәм:

—Янгураз! Янгуразым! Ишетәсеңме мине? Син кирәк миңа!

Икенче көнне Әнәс күземә күтәрелеп карарга да оялды:

—Гафу ит. Эчкәч яман мин, акылым югала...

«Кыз балага хуҗа кирәк. Төшкән урынында таш булсын! Кыз балага хуҗа кирәк!»

Иншар егетләре авылыбызның бер кызын атка утыртып урлап киткәч, әбием шулай дигән иде. Шул сүзләргә хәтер дә калган иде әле: ничек инде алай булсын, безгә хуҗа нигә кирәк ди? Кызлар эт яки мәче баласы түгел лә.

Тормыш аңлатып бирде. Теләсә кем кул сузмасын өчен кирәк икән ул хуҗа... Их, юкка гына Робертка чыкмадым. Зиһен йоклаган, акыл мәрткә киткән чак булды, күрәсең. Йә, нәрсә дип шул җиде-ят кеше, әле җитмәсә, гаиләле дә Янгураз белән саташтым да, шундый шәп кияүне кулдан ычкындырдым инде мин?! Робертка чыккан булсам, ирле хатын булып тәкәббер генә йөрер идем... Һәм беркем мина бәйләнә алмас иде... Чөнки бу асыл кошның хуҗасы бар!

***

Вакыйга кабатланды. Ниһаять, мин теләгәнчә булды: көннәрдән бер көнне Ситараны алырга ишәкле бабай килмәде... Күңел өметләнеп-канатланып куйды: димәк, бүген Ул киләчәк! Ләкин мин өзелеп көткән

кеше дә күренмәде. Теге чактагы кебек «нәни принцессам» белән тагын икәү утырып калдык. Тик бу юлы Вера түтәй беркая китмәгән, бакча ишегалдын себереп йөри иде. Озакламый ул керәчәк һәм әйтәчәк: «Бар, Наргизә, син өенә кайт. Ситараны үзем озатырмын, килүче булмаса, минем янда кунар». Андый хәлләр булгалый. Кайчакта әтисе әнисенә, ә әнисе әтисенә ышанып, икесенең берсе дә килми кала. Йә икесе дә төнге сменада булып, баланы алырга килә алмыйлар. Ул чакта шалтыратып әйтәләр, шундый-шундый хәл, зинһар, бала бакчада гына кунсын.

Ләкин минем өйгә кайтасым килми. Минем Аны күрәсем килә! Күңелем сизә: ул барыбер киләчәк, соңга калып булса да киләчәк!

Шулчак күңелгә бик шәп бер уй килә. Аллага шөкер, миндә үҗәтлек тә, тәвәккәллек-кыюлык та җитәрлек. Ятып калганчы—атып кал, ниятләдекме—эшлибез!

—Ситара! Әйдә, мин сине өеңә озатып куям?!

Кыз миңа аптырап, ышанмыйча карап тора.

—Курыкма, юлны беләм мин. Сезгә барганым бар. Әйдә, илтеп куям!

Ситара дәшми генә киенә башлый. Аның өенә кайтасы килә.

Капкадан чыгып барганда Вера түтәй кычкырып туктатты:

—Надя, сез кая болай?

—Менә... Ситараны өйләренә илтәм.

—Нигә? Йөрмә сана! Калсын, килеп алырлар әле. Килмәсәләр, минем янда кунар. Нигә интегеп йөрисең? Барыбер иртәгә кире китерәсе.

Ләкин мин барыбер үземнекен иттем, кызны җитәкләп, Караташка китеп бардым. Әнә инде ул күренеп тә тора... Озакламый барып та җитәрбез. Ләкин минем һич тә анда барып җитәсем килми. Шуңа юри әкрен атлыйм. Ә Ситара ашыга. Юл буе тәки бер сүз дәшмәде. Күпме сорау бирдем, ишетмәмешкә салыша кире беткән кызый. Шул кирелеге өчен яратам да бугай үзен. Гел кочаклыйсым, иркәлисем килеп тора. Әллә әтисенә күзем төшкәнгә шулаймы икән? Бигрәк бер-берсенә охшаганнар шул. Мина Ситара белән янәшә атлау искиткеч рәхәт, нәни кулларыннан тотып, аның җылысын тоеп бару да күңелемә әйтеп бетергесез шатлык бирә.

Бу бит—Янгуразның кызы!

Бу баланың һәр күзәнәгендә Янгураз яши!

Бу бала—Янгураз орлыгыннан яралган җан!

Бу бала—мине Янгураз белән бәйләп торучы нәфис ефәк җеп!

Шулчак Кифая апа искә төште. Аның Илнарны үз итүенә ышана алмый аптыраган, әтигә ярар өчен юри кылана дип уйлый идем. Үги ана үги баласын яратсын ди, имеш... Әкият дияр идең, әкияттә дә булмый торган хәл ич бу! Әкияттә бәлки булмыйдыр да, ә менә тормышта була икән! Әтисен яратсаң, баласын да якын итәсең икән. Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә... Үз башыма төшкәч, мин дә Кифая апаның хәлен аңлый башладым бугай.

Янгураз мине сөйсәме?! Ситараны иркәләп кенә торыр, кочагымнан төшермәс идем. Хәер, болай да кимен куймыйм әле, бөтен игътибарым шул балада хәзер. Мине яратсын, ияләшсен, әтисенә мактап сөйләсен өчен җан тырмашам. Кыскасы, Янгураз минем дөньяда бер асыл зат икәнемне белсен. Һәм яратсын. Яратсын иде ул мине!

Ашыксаң-ашыкмасаң да, теләсәң-теләмәсәң дә, алга атлый торгач, кышлак якыная... Якыная шул... Бераздан Янгураз йортына да килеп җитәрбез. Капка кыңгыравына баскач, бабай чыгар, дәшми генә оныгын алып кереп китәр. Ә мине кунакка чакырмас, капка төбендә берьялгызым моңаеп басып калырмын... Шуның өчен өстерәлеп килдемме мин бу кышлакка?

Чү, артта мотоцикл тавышы ишетелә түгелме? Минем йөрәк дерт итеп китә. Якыная, якыная... Ситара каерылып артка борылып карый. Аннары кулымнан тарта:

—Әтием...

Шул мизгелдә юлыбызны бүлеп, ком-тузан болытлары куптарып каршыбызда «Ява» мотоциклы пәйда була. Баһадир ир ачу белән миңа төбәлә:

—Кая алып барасың минем кызны?

Тавышы таулардагы кайтаваз кебек күкрәк төбеннән гөрелдәп-янгырап чыга. Бик таләпчән горур тавыш.

Мин аның күмер күзләренә туп-туры карап, булдыра алганча тыныч һәм коры итеп җавап бирәм:

—Кая булсын, өегезгә. Баланы вакытында алырга кирәк!

—Син кем?

Минем күнел үртәлеп куя: ул мине бөтенләй хәтерләми... Димәк, теге чакта күрмәгән дә, исендә дә калдырмаган. Мин аның өчен нуль... Ләкин сорауга бик җитди итеп җавап бирәм:

—Ситараның тәрбиячесе.

—Алайса, колагыңа киртлә: син бары тик бакчаңда гына минем кызның тәрбиячесе була аласың, хуп?! Урамда да, өемдә дә түгел. Минем баланы биш чакрым җәяү интектереп йөртергә бер хакың юк! Мин аны үзем килеп ала идем. Ситараның әтисе бар!

Гаскәр башлыгы сыман харап тәкәббер, кырыс сөйләшә бу, авызыннан сүзләр түгел, ядрә коеламыни! Маңгайга тимәсә дә, күнелгә тия. Күр әле ни кылана, кызлар белә кем шулай сөйләшә инде?! Түзсән—түз, түзмәсән—чыда... Юньсез бандит! Мин кырт борылам да китә башлыйм.

—Әй, тукта. Мин сине илтеп куям. Көт шунда гына.

Үпкәм шундук җилгә оча. Көтәрмен дә шул! Әнекәем, нинди егет! Күзләре ут чәчеп тора. Карашыннан дөрләп янарсың, эреп юкка чыгарсың, валлаһи. Бер-бер сихере бардыр моның, югыйсә шулай саташып йөрер идеммени?! Җәл, шундый чибәр егетне марҗа эләктергән... Ә безгә, Наргизәкәй, ут йота-йота, читтән генә кызыгып, газапланып йөрергә калыр инде... Шулчак Римманың такмагы искә төште: «Уф, йөрәгем, су бирегез, янып үләм бит инде!» Авыз суларын корытып егете турында сөйләгәндә, әллә ничә тапкыр шулай дип кабатлаган иде. Хәле хәл булган икән шул, мәхәббәтең өметсез, җавапсыз булса, бозлы су да коткармас, янып үлми чараң юк...

Чибәр егетем Ситараны өенә кайтарып, тиз арада әйләнеп тә килде. «Генералым»ны күндәм адъютанты сыман аягүрә басып, үземчә бик сөйкемле елмаеп каршыладым. Чем-кара күзләренә туп-туры төбәлеп, гәрчә моның шулай икәненә бер тамчы шигем булмаса да:

—Сез Янгуразмы?—дип сораган булдым.

—Сиңа барыбер түгелмени?

Юк шул, асыл егеткәем, миңа һич тә барыбер түгел. Илаһи амин, бу исем гомеремнең киләчәк юлларында да минем исем белән бергә үрелеп барсын. Янгураз һәм Наргизә! Шәп янгырый бит!

Янгураз миңа зәңгәр шлем суза. Үзе исә бу җәфа шлемны интегә-интегә кияргә маташуымны көлемсерәп күзәтә.

—Бир, үзем кигерәм. Сине көтсән, таң атар.—Янгуразның кытыршы җылы бармаклары яңак-муенымны сыйпап уза. Мин исә шуңа бик риза булып, мәлҗерәп басып торам.

—Курыкмыйсыңмы?

Шундый егет янында да курыксаң!

—Юк.

—Алайса ныгытып тотын. Мин әкрен йөрергә яратмыйм.

«Ныгытып тотын»ны үземә кирәгенчә анлап, Янгуразны кочып алам да, бөтен гәүдәм белән ана сарылам. Анын жылысын, якынлыгын тоеп, йөземә ягылган йомшак чәченнән, шул чәчләрдән килгән болын исләренә башым әйләнеп китә. Бу—минем кеше, минеке! Шул мизгелне генә көтеп торганмы, күнелемә ташкын булып назлы хисләр ишелеп төшә, онытылып китеп Янгуразны иненнән үбеп алам. Мина шундый рәхәт. Дөньяда миннән бәхетле жан юк! Кызу баруның начар ягы шул, күз ачып йомган арада Майлысуга килеп тә житәбез. Янгураз тормозга баса, мина таба борылып:

—Кайда торасын?—дип сорый.

—Чияләр урамында...

Икенче мизгелдә без инде Фатыйма апалар турысында идек.

Әкият шуның белән тәмамланды. Бик кыска әкият булды ул, ахыры да кызык түгел. Янгураз мине төшерде дә, саубуллашып та тормыйча, үзе артыннан бары бөдрә-бөдрә зәнгәр төтеннәр калдырып, күздән дә югалды...

Әгәр өч айга бер тапкыр күрешеп, шул рәвешле генә сөйләшсәк, бу мәхәббәт бик озын гомерле булыр кебек.... Ай-һай... Чәчләрен агарып, тешләрен коелганчыга кадәр житәчәк әле бу кайнар мәхәббәт... Мин үртәлүдән ачуымны кемгә бушатырга белмичә, йодрыкларым белән койманы төям: бернинди өмет юк һәм булмаячак та! Берни булмаячак...

***

Әнәс өйдә һәм исерек иде. Ул тәрәзәдән карап-күреп торган, ахры:

—Сине кем кайтарды?—дип сорады.

—Бер таныш инде шунда...

—Күзләрен бик матур, илтеп куйыйм дидеме? Үпкәләмә, сестренка, ну мин турыдан әйтәм, синен башына ми урынына салам тутырганнар бугай.

—Бөтенләй буш булмагач, ярар инде, саламы да начар түгел.

—Сине тотып... яхшы гына итеп бер... ярасы бар. Башындагы салам көрпәгә әйләнгәнче. Хуп?!

—Карале, ни дип мина бәйләнәсен әле син?

—Бәйләнмим, акыл өйрәтәм. Ник Робертка кияүгә чыкмадын син, яман олан? Хәзер шунын үчен миннән ала. Каныкмаган көне юк.

—Алдашма, Роберт андый түгел.

—Ә син каян беләсен? Анын белән йоклап карадынмы әллә?

Мин Әнәскә үтергеч караш ташлыйм:

—Тиле! Каян башына килде мондый уй?

—Каян да килергә мужыт, әлегә безнен казан варит. Дөресен әйт әле, сестренка, синен егетләр белән йоклаганын бармы?

—Юк!

—Майли, икебез дә фәрештә икән! Минем дә кызлар белән йоклаган юк, хатыннар белән генә... Ха-ха-ха.

Әй, бу Әнәс... ямьсез дә көлә инде. Сүзләре тагын... уф, чирканыч. Кемгә охшап шундый булгандыр?!

—Ритканын ире кайтты. Всё, ожмах ишекләре ябылды, сестренка. Яна түтәй табарга кирәк.

—Өйлән, эзләп йөрисе дә булмас.

—Ну да, хәзер, чапты ди! Өйләнмичә дә бик хуп... Аптырап йөргән юк әле.

Мин Әнәс каршына утырып чәй эчәргә керешәм. Монын томанлы

карашы миңа төбәлгән. Исерек башына иләс-миләс уйлар оялап маташа бугай. Ул да җизни сыман, айнык чакта тел яшерә, аның каравы эчкәч туктата торган түгел. Тыңлаучы бармы-юкмы, рәхәтләнә күңел бушатып. Теле ачылган чакны файдаланып калырга кирәк әле.

—Әнәс, контрабандистлар нишли?—дип сорыйм.

—Тире җыеп күн эшли! Әллә син дә контрабандист булырга җыенасыңмы? Синнән башка да муеннан алар.

—Мин чынлап сорыйм.

—Алайса, мин дә чынлап әйтәм: һавадан акча сугалар.

—Кеше үтермиләрме?

—Деловой кешеләргә комачауларга апп-салутны я-ра-мый!—ди Әнәс, соңгы сүзенә басым ясап.

—Ә Роберт мине контрабандистлар белән куркытты...

Бусы шыр ялган инде, беркем куркытмады. Исәбем—бандитлар тирәсендә озын-озак чуалмыйча, сөйләшүне җайлап кына Янгуразга күчерү, аның турында күбрәк белү. Әнәс гомере буе Майлысуда яшәгән кеше, бәлки кайчан да булса юллары Янгуразныкы белән кисешкәндер, аның хакында ни дә булса сөйли алыр. Сүз агымын иплә кенә шул якка—Янгураз йөргән сукмакларга таба бормакчы булам. Ләкин Роберт исемен телгә алып ялгыштым, Әнәс күркә сыман кабарынып кабат минем «экс-кияүгә» ябышты:

—Үзе кем соң?! Монда барысы да—жулик! Роберт кына әүлия түгел. Акча ачык авызларны яратмый ул. Хочешь жить—умей вертеться! Вертись, но не мешай другому.

Әнәс кызды. Хәзер җизни кебек өстәл төя башлаячак. Башы кыекка китсә, теге чактагы кебек саташып, миңа бәйләнә башлавы бар. Аяк астында яткан ташка беренче тапкыр абыну сукырлык булса, икенчесе йөз процент ахмаклык инде. Үземне акыллылар рәтенә кертмәсәм дә, ахмаклар исәбендә йөрисе килми. Шуңа күрә тизрәк моннан шылу ягын карадым. Бер кечкә кер мичкә диләр, төннәр җылы, түзәрбез дип, мунчага кереп бикләндем.

Йокы качты. Фәлсәфәгә бирелеп, уйга батып утырыр өчен мунча менә дигән урын икән... Үткәннәр искә төште. Яхшысы да, яманы да... Әнине сагынып, үземне кызганып елап алдым. Ниләр күрми бу дөньяда ат башы да ир башы, дигән булалар. Ә кыз бала күргән-кичергәннәрне саный-исәпли башласаң?! Гомере буе куркып-сакланып, юлында очраган һәр ир-аттан шикләнеп яшәргә тиешмени ул?! Кыз бала булып тууына мең кат үкенерсең, валлаһи. Безне күкләргә чөеп мактаучылар, яклаучы-саклаучылар да—ирләр, харап итүчеләр дә ирләр... Кемнең ышанычлы дус, кемнең дошман икәнен чамалап бетерү өчен киек сизгерлеге, аксакаллар зирәклеге, тормыш тәҗрибәсе кирәк. Ә тәҗрибә туплаганчы күпме абынасы-сөртенәсе, хаталанасы бар... Кыз бала бер генә ялгыша, әмма дә ләкин берәгәйле ялгыша. Шул ялгышы аның гомер юлларына кара шәл булып иярә, аягына уралып, алга атларга комачаулый, кояш нурларын каплап, көннәрен төн итә. Кыз баланың намусы—кыл өстендә, кылдан төшсә—ил өстендә...

Ә мин үз хәлемне үзем дә белмим...

***

Берничә тапкыр урамда Робертны очраттым. Минем белән тыйнак-тыйнак кына исәнләшеп китә, сөйләшеп тормый. Яхшысынмыйдыр инде. Күктәге торнага өметләнеп, кулдагы песнәкне ычкындырдым бугай. Бар, тот син хәзер ул Янгуразны! Минем кайгы ди анда. Бу күңелне әйтер идем инде, тапты бит кемгә ягылырга. Шаккатырсың, валлаһи! Хатыны күзенә генә карап торучы тугры ирләр дә булыр икән бу дөньяда! Безнең эти генә ул... Әй, искә дә төшерәсе килми хәтта.

Мина бер сорау тынгы бирми, кызыксынуым баштан ашты. Шуны бик беләсем килә: мәхәббәт нурларына коенып, кадер-хөрмәткә тиенеп яшәүче Тамара атлы хатын нинди зат икән ул? Авыру килеш тә Янгуразны үзенә бәйләп тоткан шул бәхетле хатынга бер генә тапкыр булса да күз саласы, серләрен беләсе иде бит! Әкияттәге патша кызларыдай күз явын алырлык чибәрдер, сылудыр инде ул, шундый асыл егет ни житте кыз өчен утка-суга кермәс.

Беркөнне түзмәдем, эштән соң туп-туры Караташга китеп бардым. Алда ни көткәнен, анда баргач ни кыласымны әле үзем дә аңламыйм-чамаламыйм, мәхәббәт томаны каплаган карашымны алга төбәп, комтузаннар туздырып жил-жил атлавымны гына беләм. Читтән караганда бик зур миссия үтәүче харап эшлекле кеше булып күренгәнмендер инде мин. Чынлыкта исә башта жилләр генә уйный.

Юлыма Янгураз килеп чыкса, ни диярмен икән? Тауга мумие жыярга менәм, аякларым сызлый, диярмен. Хы... Ышанып да инде... Ату башка жирдә тау беткән ди. Майлысу янындагы тауның кай жире ошамый?

Мумие турында элек минем ишеткән дә юк иде. Бөтен чирләрдән дәва имеш ул. Көрән-кара төстәге сагыз кебек әйбер үзе. Аның ни икәнен тәгәл генә беркем дә белми. Тауда яши торган ниндидер кош тизәге дип тә әйтәләр. Имеш, ул кош бик файдалы үләннәрне генә ашый да, шул үләннәр аның организмында эшкәртелеп, әзер дару булып чыга икән. Икенчеләре, юк, ул кош тизәге түгел, тау мае ди. Кояш астында озак ята торгач, ташлардан шундый май саркып чыга, имеш. Аллаһы Тәгалә тау халкына менә шундый могжизаларын бүләк итә, дип сөйлиләр. Ничек булса да, мондагы халык бар чирдән мумие эчә, яраларга, сызлаган жирләргә дә шуны сылыйлар. Әллә ничә төрле чирдән дәва, имеш. Менә шундый могжиза. Белмим, дөрестерме...

Шулай итеп, мин мумие жыярга барам. Соры комлы, вак ташлы сукмактан әкрен генә атлый торгач, Караташка барып життем. Кеше-кара гына очрамасын. Балчык йорт янында чүмәшеп утырган бер кап-кара карчык кулын мангаена куеп миңа озак текәлеп торды. Бу әби дөньяда бик озак яшәгәнгә охшаган. Шул хәтле ябык, кипкән, кигән киемнәре өстендә капчык кебек эленеп тора. Әбидә дөнья дәрте калмаган иде, ахры, йомышын бетереп, киң балаклы ыштанын күтәрде дә, өенә кереп китте.

Мин исә, әрсез бикә, күкрәк киереп Янгураз яшәгән йорт каршына килеп бастым. Шуннан ни? Утырган да шуган ди...

Керәсе иде бит бу йортка! Сары балчык белән сыланган таш ныгытманы аркылыга-буйга иснәнеп йөреп чыктым, тик мәче керерлек тә тишек тапмадым. Ахыр чиге, коймага сөялеп утырдым да уйга чумдым.

Сәер әле барысы да, бик сәер. Хатын саклыйм дип шундый бастион корып куймаса соң! Нигә шулай кешедән качып ятарга инде, йә?! Ашамаслар иде әле Тамарасын. Әнә бит башка йортлар уч төбендәге кебек. Кайсыларының капкасы да юк әле.

Эт өргән тавышка өйдән кемдер чыкты. Бик таныш адымнар. Бу Янгураз түгел, кәлүшләрен чыштыр-чыштыр сөйрәп бабай килә. Аның күзенә чалынмас өчен тауга таба элдерттем.

Их, кулда бинокль булса икән! Югарыдан йорт эче шәйләнә. Тик анда миңа кызык булырлык берни юк: бакча, мунча, сарайлар, эт оясы, кое... Ишегалды буш. Эт күләгәдә йоклап ята. Мотоцикл күренми. Янгураз өйдә юк, димәк. Кайда икән ул, ниләр майтарып йөри икән?

Ниһаять, ишегалдында жанлылык сизелде. Өйдән бабай чыгып әрлебирле йөренә башлады. Коедан су алды. Бакчадан нидер өзеп кереп китте. Аннары кабат чыкты, сарайдан ишәкне ияртеп чыкты. Капканы ачты... Әһә, китте бу!

Эссе кояш астында утырып хәлдән тайган идем, елга суын учларыма алып бит-кулларны чылаттым да, үз көчемә, теләгемә ирешәсемә чын күңелдән ышанып, хыялымдагы Тылсым—Сарайга таба юнәлдем. Койма аша сикерү турында сүз дә юк, бердәнбер юл—капка аша керү. Эт өрә тора, бүре йөри тора. Ниндидер могҗизага өметләнеп, кабат капкага килдем. Бикле капка-ишекләр мине гомергә ымсындырды инде. Юкка гына бикле түгел алар... Анда нидер ба-а-ар... Шул чакта нигәдер Али-Баба әкияте искә төште. Миңа кызык булып китте, капкага сөялдем дә, әкрен генә пышылдадым: Сим-Сим, ач ишекне...

Һәм... могҗиза булды! Могҗизаларга ышанырга кирәк! Сак кына кагылуга капка ачылды да китте! Соң, бу бит... Бу бит, Наргизә жанкисәгем, язмышның, тәкъдирнең, ахыр чиге хәтта Ходайның да синең яклы булып, киләчәгеңә юл күрсәтүе түгелме соң?! Әфсенле сүзләрнең биредә бер катнашы юк, әлбәттә. Онытыпмы, башка сәбәп беләнме (әллә инде минем киләсемне белепме...), бабай капканы бикләми калдырган иде. Олы кешенең хәтере тишек иләк белән бер, әле дә ярый баш муенда; кулда булса, аны да теләсә кайда онытып калдырыр иден, дип зарлана иде шул әбием. Тишек булуы бик яхшы. Карт кешегә ниемә соң ул хәтер, тапкырлау таблицасын өйрәнеп, шигырь ятлап утырасылары юк.

Кача-поса, каймак яларга ашкынган песи сыман шыпырт кына басып ихатага керүем булды, мине күрүенә ифрат сөенгән бозау хәтле этнең «ялкынлы, кайнар сәламнәре» яңгырый да башлады. Чылбырын өзәрдәй булып өрепме-өрә, өстемә ыргылыпмы-ыргыла. Эш юктан эш булды мона. Шул хәтле рәхәтләнеп, киерелеп өрә, кыяфәте—харап эре. Тырышлыгымны күрүче бармы, мин бит сезне яклыйм, дигән кебек бик тәкәббер генә йорт ягына да карап-карап ала. Эт-эт шул инде, хуҗасына ярар өчен мәш килә.

Өрсә өрер инде, Наргизә килде дип кенә чылбырын чәйнәп өзмәс әле,—карван алга бара!—кыюланып ишеккә уздым. Әнекәем, бу ни могҗиза, бүген күк капусы ачылган көнме әллә, ишек тә ачык! Әйтерсең, минем киләсене белеп, юлыма ак җәймә җәеп куйганнар: «Кил, рәхим ит, хөрмәтле михман!» Шатлык белән бергә күңелгә шик тә килеп керде, бәлки, Янгураз үзе дә өйдәдер? Бәлки, бабайдан, авыру хатыннан башка, өйдә тагын кемдер бардыр? Ни диярмен аларга? Һич булмаса, бакчадан Ситараның тормыш шартларын өйрәнергә җибәрделәр, нишләп шулай боек ул бала, ник бер дә көлми, сөенми, дип алдашкан булырмын инде...

Куркып кына ишек шакыйм. Дәшүче, каршыларга чыгучы юк. Эчкә үтәм, өй эчендә—үле тынлык. Озынча коридор буйлап аяк кереп батарлык йомшак келәмнәргә басып туп-туры залга килеп керәм. Биредә һава салкынча, рәхәт. Тәрәзәләргә куе яшел төстәге калын пәрдәләр эленгән, шуңа караңгырак та. Монда байлык житәрлек. Җиһазлар яңа, бер як диварны биләп торган стенка затлы савыт-саба белән шыплап тулган. Контрабандистлар шулай яшидер инде. Шуңа жиде кат йозак астында бикләнеп яталардыр. Әмма да ләкин мин менә шул контрабандистны яратам, берни эшләр хәл юк...

Сак кына икенче бүлмә ишеген ачам. Җиһазларына караганда йокы бүлмәсенә охшаган. Ике кешелек иркен карават. Өстендә—комач кызыл атлас җәймә. Идәндә—кызыл чәчәкләр төшкән бик матур йомшак келәм. Карават янына килэм дә, суга чумгандай талпынып, бар буем белән йомшак урынга сузылып ятам. Гүя җылы мамык эченә кереп сеңәм, арган тәнем рәхәтлеккә чума. Менә шунда... Янгуразга сыенып... иркәләнәсе иде бер... Ах, оятсыз, кызый, ни уйлыйсың син?! Ярамый! Ярый, ярый... хыялланырга ярый. Аннан гына кемгә, ни зыян? Таш түгел ич мин, адәм баласы. Бу җан, бу тән үзе яраткан, үзе теләгән кадерле кешесеннән наз-сөю көтә ләбаса...

Шулчак колагыма әкрен генә ыңгырашкан тавыш ишетелә. Мин татлы уйларымнан мизгел эчендә айнып, сискәнеп сикереп торам. Аяк очларына басып, тавыш килгән якка китәм.

Бу бүлмә тегеләрдән кечерәк иде. Ләкин шулай ук җыйнак, матур. Бүлмәдә кием шкафы, тумба өстәл һәм бер карават тора. Аларны әле сонрак күрәм. Ә ишекне ачуга иң башта күземә ул чалына: урын өстендә яткан сөттәй ак йөзле, алтын чәчле хатын. Аның зәп-зәңгәр зур күзләре туптуры миңа төбәлә. Тик бу караш буш. Аларда аз гына да аптырау галәмәте чагылмый, әйтерсең мин биредә һәр көнне кереп йөрергә тиешле кеше. Хатын кулы белән өстәлдәге пыялага төртеп күрсәтә. Мин аның ни теләвен аңлап, йөгереп килеп сулы касәне сузам. Ләкин хатынның бармаклары тотмый икән, касә идәнгә тәгәри, суы түгелә. Ул кабат кулын суза. Мин касәне күтәреп кухняны эзләп китәм, су алып киләм. Хатын йотлыгайотлыга эчә дә, бернинди уйсыз буш-битараф карашын кабат түшәмгә төби. Шул мизгелдә үк мин аның дөньясыннан югалам, гүя бөтенләй юк...

Әкияттәге патша кызларыдай гүзәл, яшь-яшь хатын ни тере, ни үле булмыйча әрәм булып ята. Тере мәет ич бу! Бичара Янгураз, бичара Ситара!

Мин хатынның кулын учыма алам. Ул бармаклар сөт кебек ак, боз кебек салкын.

Бу йортта кайгы яши... Бу зур, бай йортта бары кайгы яши! Әнисез йортта шатлык та, бәхет тә була алмый. Әнисез йортның ни икәнен мин беләм. Мин беләм... Шул чак күзләремә чеметтереп ачы яшьләр тыгыла. Йөземне учым белән каплап үксеп елап җибәрәм. Мин беркайчан да Кифая кебек булмам, мин беркайчан да, беркемгә дә хыянәт ачылары, хәсрәт алып килмәм...

—Син нишлисең монда?

Ничек сизми калдым, адымнарын нишләп тоймадым, колак төбендә үк яңгыраган тавышка сискәнеп, башым күтәрсәм... бөтен ишекне биләп, бусагада Янгураз басып тора! Мотоцикл тавышы да ишетелмәде ләбаса. Димәк, ул кайдадыр йорт тирәсендә генә йөргән! Ә бәлки өйдә үк булгандыр, шыпырт кына мине күзәткәндер... Эләктем, оятка калдым... Хет тычканга әйләнеп идән ярыгына кереп кач. Елаудан шешенеп беткән күзләремне Янгуразга төбим. Акланырга сүз таба алмыйм. Кеше йортына карак сыман кача-поса рөхсәтсез килеп кергән, дөньяда бер оятсыз, юньсез кыз мин...

Янгураз мине җилтерәтеп бүлмәдән алып чыга. Томан эчендә кебек, берни аңламыйм. Ул хәзер артыма тибеп, урамга атачак. Оят, оят... Әнекәем, нинди хурлык, нишләдем мин, нишләдем?!

Ләкин без йокы бүлмәсенә керәбез. Янгураз мине караватка таба этә. Комач кызыл җәймә өстенә авам... Тукта, ник... Юк... Янгураз... Нишлисең син?.. Ә мин нигә буйсынам? Бу бит хыял түгел, бу—өн... Каршылык күрсәтәсе урында, җылы дулкын иркенә эләккәндәй, Янгуразга сыенам, аның кайнар сулышы ялкынга төрә... Мин ихтыярсыз, тәнем гүя кош каурые. Акыл йоклый, зиһен чуалган, чынбарлык ярларын томан сарган... Дөньямны онытып иксез-чиксез наз диңгезенә күмеләм...

Ә аннары айну, бу хәлгә оялу-читенсенү...

—Ташлама мине, Янгураз... Зинһар, ташлама!—дип ялварам.

—Син бит.. кыз икәнсең... Ник әйтмәдең?

—Син сорамадың...

Үзем дә белмәдем, димәм ич инде...

Димәк, Женя миңа кагылырга өлгермәгән.

Икенче мизгелдә күңелдә әрнү-үкенү хисләре кузгала. Бик кадерле әйбер югалтудан соң туган бушлык салкыны җанымны өтә. Мин гөнаһсыз

булганмын икән... Ә бит күпме борчылдым, яндым-көйдем. Оятка калудан куркып, авылга кайтмадым, чит җирләргә чыгып качтым... Үз кадеремне белми, кеше ире кочагына килеп кердем... Әй, Наргизә, шулмы инде синең гомердә бер генә була торган тылсымлы зәфаф кичен?! Хурлыкмы? Хурлык... Кәләшне өенә барып, бүләкләргә күмеп алып китәләр. Ә мин, җүләр, сөйгән егетем янына карак сыман кача-поса кереп, үзем куенына чумдым. Ах, артык очсызга чыгардым шул үземне. Чыланасы чыланган инде дип, һичнинди каршылык күрсәтми, назларын кабул иттем. Нинди зур үкенеч, никахсыз да, кадерсез дә кәләш булдым мин зәфаф кичемдә. Ләкин нишләмәк кирәк, буласы булган, тузасы тузган... Инде киләчәк турында уйларга кирәк.

Өметләнеп-ялварып сорыйм:

—Син мине ташламыйсынмы, Янгураз?

Соравым җавапсыз калса да, яклау, терәк эзләп җиде ят кешегә—никахсыз киявемнең салкын куенына сыенам...

—Хәзер Сиражетдин әкә кайта. Сиңа китәргә кирәк.

—Юк-юк! Минем синнән аерыласым килми.

—Иртәгә сөйләшербез. Әйдә, җыен, мин сине илтеп куям.

***

Янгураз, Янгураз, Янгураз...

Сулаган саен телемнән, авызымнан шул исем ургылып чыга, бичара йөрәккәем бу исемне кабатлый-кабатлый ыңгырашып-сыкрап тибә. Бергә булган минутлар искә төшсә, шуларны сагынудан күнелем тулып, тәмләп елыйсым килә. Миңа насыйп бәхетле мизгелләр нигә шулай аз икән соң, алары да шундый кыска, күз ачып йомганчы үтеп тә китә.

Ул мине алдаган гынадыр, ул башка килмәс-күренмәс тә инде... Ансат-җинел табылганның кадере булмый, диләр...

Ләкин мин ялгыштым. Янгураз сүзендә торды! Икенче көнне кичен мотоциклы белән килеп тә җитте. Янына атыла-бәрелә чыктым да, тугры колы кебек каршына килеп тә бастым. Янгуразым! Менә бит син янәшәмдә, шундый якында гына. Күзләренә төбәлеп, кулымны йөрәгенә куеп: «Яратам! Яратам!»—дип пышылдыйсым килә. Син янымда булганда, бу дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк. Тик нинди карар котә соң бүген мине? Елатырмы бу кич, елмайтырмы? Утка атармы, бозлы суларга салырмы?

Мин Янгуразны кочып, мотоциклга утырам, асфальт юл буйлап Сарбия бистәсенә таба юнәләбез. Юнәләбез түгел, очабыз! Анда шундый матур алан бар. Ул аланда билдән кереп күмелерлек куе үлән, аллы-гөлле чәчәкләр үсә. Без шул матурлык кочагына авабыз...

—Наргизә... Нәркис... Сагындым, шакарим!

Шулай да ул минем белән кызыксынган икән, исемемне дә белгән.

—Янгураз, син мине ташламыйсыңмы?

—Ташламам, беркайчан да ташламам, Нәркис!

—Ә нигә Нәркис? Минем исемем Наргизә.

—Ә мин сиңа Нәркис диярмен, ярыймы? Назлы гөлем бул!

—Янгураз, син миннән көлмисеңме? Гаепләмисеңме?

Ул озак кына дәшми тора. Карашын миңа түгел, читкә төби:

—Син миңа ошадың,—ди.—Тик янына килергә кыймадым. Мин өйләнгән кеше бит. Ә кичә, йортыма үзең килеп кергәч, түзмәдем... Рәнҗемисеңме миңа?

—Юк... Мин сине яратам!

—Сөям дияргә ашыкма, асылым. Син мине белмисең. Бәлки, мин бик яман бәндәдер?

—Мин дә фәрештә түгел.
—Юк, син—фәрештә.
—Фәрештәләр җирдә яшәми.
—Ә кайда яши?
—Күктә.
—Нишлиләр анда, күктә ни ямь, ни кызык бар? Бушлык ич анда, олау-олау ташлар гына очып йөри. Ә без шуларны йолдыз дип саташабыз.
Мин рәхәтләнеп көлеп җибәрәм:
—Кит инде, әкият сөйләмә. Нишләп йолдыз таш булсын ди? Якты ич алар, балкыйлар. Беләсең килсә, йолдызлар—кояш кызлары алар.
—Ай-вай, алайса, күктә дә күнелсез түгелдер. Шул хәтле кызлар булгач! Фәрештәләр белән уйнап-шаярып яталардыр, әйеме?! Егетләр бармы икән соң анда? Фәрештәләр күктә булгач, шайтаннар җирдә йөри инде алайса. Белеп тор, җаным: мин шайтанның үзе булам. Шайтан мин, шайтан!
Янгураз йөзенә ямьсез кыяфәт чыгарып, мине тешләгән булып кылана. Аннары житдиләнеп:
—Нәркисгөл, мин сиңа берни вәгъдә итә алмыйм бит, асылым. Тамараны кая куйыйм? Ул бит кызымның әнисе. Беренче мәхәббәтем. Кем уйлаган шулай булыр дип... Мин аны кызганам. Авыру кешене ничек ташлыйсың? Бу бит имансызлык була.
—Ә син аны ташлама, Янгураз. Бергә яшәрбез. Үзем карармын, тәрбияләрмен. Хатыныңны да, сине дә, Ситараны да карармын. Теге бабайны да. Синең белән булыр өчен мин барсына да риза. Мин сиңа бик яхшы, тугры хатын булырмын, Янгураз.
Янгураз миңа гаҗәпләнеп карый:
—Вай, уйлап-чынлап әйтәсеңме, җаным?
Җавап урынына аны үбеп алам.
—Нәркис, гүзәл гөлем, алып кайт миңа бер угыл! Иң зур хыялым—угыл атасы булу. Миңа ир бала кирәк!
—Алып кайтырмын, Янгураз. Тик син мине ташлама, яме.
Янгураз серле елмаеп, мине кочагына ала...
Нинди ямьле алан бу! Нинди гүзәл, сихри кич! Безнең мәхәббәткә ят күзләр түгел, бары тик күктәге бихисап йолдызлар һәм күкләргә тоташкан биек таулар гына шаһит. Иксез-чиксез галәмдә без икәү, бары икәү генә!

***

Кайгы үзен яратмаганнарын белә, шуңа күрә ул әрсезләнеп шатлык итәгенә тагылып йөри. Кочак җәеп шатлыкны каршылыйм дисең, ә аның артынннан инде котсыз чырайлы хәсрәтнең мыскыллы елмаюы күренә...
Безнең капкадан да алар икесе бергә килеп керделәр, мин шатлык белән булышкан арада, хәсрәт шыпырт кына өй түренә узган...
Минем җизнәм үлде...
Ял көне иде. Һәрвакыттагыча мунча ягылды. Һәм һәрвакыттагыча беренче парга җизнәм китте. Киткәндә әйткән сүзләрен дә хәтерлим әле:
—Фатыйма, озаклама. Алмаш киемнәр алып килерсең.
Гап-гади сүзләр. Исән кешенең якты дөньяга әйтеп калдырган иң-иң соңгы сүзләре...
—Иркенләп чабын, мин киноны карап бетергәч кенә киләм әле,—дип кычкырып калды аның артыннан апа, аннары миңа дәште:
—Наргизә, кил, телевизор карыйбыз. Хәзер «Ал чәчәк» башлана. Бала-чага сыман мин дә әкият карарга яратам бит.
Тузан сөртүемне ташлап Фатыйма апа янына килеп утырам. Тын да алмый икәүләп мультфильм карыйбыз. Настенька, тылсымлы балдагын

киеп, кабат куркыныч карачкы яшәгән утрауга китеп баргач, Фатыйма апа миңа сиздермәскә тырышып, күзеннән тәгәрәгән яшь тамчыларын сөртеп ала. Шулай кисәк нечкәреп китүе өчен унайсызланыпмы, аклангандай итенә:

—Менә шулай... шулай инде ул... Китәсең шул... Китми кая барасың.

Карачкы чибәр егеткә әйләнеп, гүзәл кыз белән кавышкач, ул балачагадай сөенеп кул чаба:

—И Ходайның рәхмәте!

Югыйсә ничә тапкыр күргән-караган әкияте инде, ахыры ни белән бетәсе дә әллә кайчан билгеле. Барыбер кызык, мавыктыргыч, яттан белсәң дә, йотылып карыйсың.

Фатыйма апа кисәк кенә урыныннан кузгала:

—Ай Алла, дөньямны онытып тәмам! Барыйм тизрәк, Ләбиб көтәдер. Аркасын ышкырга кирәк.

Бу аның ваемсыз ирле чагының иң соңгы бәхетле мизгелләре иде.

Мунчадан ул картайган, суырылып төшкән тол карчык булып кайтты...

Жизнәйне озатырга әллә инде бөтен Майлысу килде. Урам тулы халык иде. Тик Ор каласындагы бердәнбер туганы—энесе генә килеп өлгерә алмады. Бигрәк ерак ара шул. Ташкенттан Рамиләләр кайтты. Мона кадәр аның ирен күргәнем юк иде, танышуыбыз шунда булды. Рамилә елады да елады. Ә Фатыйма апа катып калган иде, ахры. Хәер, бик теләсә дә, рәхәтләнеп еларга вакыты булмагандыр, бар мәшәкать аның өстенә ишелеп төште бит. Әнәс мингерәгән сарык шикелле әрле-бирле буталып йөрүдән узмады.

Жизнәйнең җәсадын машина белән алып киттеләр. Без җәяү генә бардык. Каберлеккә хатын-кызлар кермәде.

Икенче көнне җыештыру-юуу эшләре тәмамлангач, бергә җыелып, жизнине искә алып утырдык.

Рамилә күз яшьләрен сөртә-сөртә:

—Мин әтине күрми дә калдым, без кечкенә чакта ул йә эшкә киткән, йә төнге сменадан кайтып йоклаган була иде,—диде.—Аннары мин китеп бардым... Бигрәк әллә ничек булды, әтинең юклыгына ышанасы да килми.

Әнәснең үз хатирәсе:

—Безнең әти сөйләшми иде бит ул. Эчкәч кенә җыен юк-барны лыгырдап баш катыра иде. Шулай бит, әни?

Фатыйма апа карашын түбән иеп утыра. Күзләрен аяк очларына төбәгән килеш, авыр сулап баш чайкый:

—Мин гаепле... Әгәр янында булсам, ул үлмәс иде. Никләр кенә артыннан ук бармадым, коткарып кала идем мин аны!

Бәлки, чынлап та, шулайдыр, чак кына алдарак барса, коткарып калган да булыр иде... Тик жизнәй үлеп ятканда «Ал чәчәк»не карап утырдык шул... Миңа Фатыйма апа шундый кызганыч. Ул гомере буе җанына тынычлык, юату тапмаячак, үлгәнче шул үкенече белән яшәячәк.

Бу хакта ничә кат сөйләде инде, ләкин тагын кабатлый... Ул мунчага килеп кергәндә жизнәй идәндә тәгәрәп ята торган булган.

—Куллары әле җылы иде, ә аяклары боз кебек. Юынган, чабынган үзе. Ләбиб, дип кычкырам, кул-аякларын уам, йөрәгенә массаж да ясадым. Юк инде, юк... Соңга калдым. Аз гына иртәрәк барган булсам соң...

Рамилә дә инде ничәнче кат әнисен юата:

—Ярар инде, әни, газаплама үзеңне. Йөрәк белән шулай тиз китеп баралар, больницаның үзендә булып та үләләр әле.

—Тем более салган кешеләр,—дип әнәсен кыстыра Әнәс.

—Әтиегез турында начар сүз әйтмәгез. Әчсә дә, гаиләне кайгыртты ул. Әти-әнисен дә карады. Ләбиб бик мәрхәмәтле иде.

—Үзең зарлана идең бит, эчә, фәлән-төгән...

Әй, бу Әнәсне, әгәр бер адәм рәтле сүз чыкса авызыннан! Шундый вакытта да кирегә сукалап утырмаса соң!

—Кызулык белән әйтелгәндер инде. Исән чакта жыен вак-төяк өчен бер-береннән җанын кыйныйсың да, югалткач үкенергә кала.

Рамилә әнисен хуплый:

—Әти юмарт иде, акча алган көнне бездә бәйрәм була иде. Хәтерлисеңме, Әнәс?

—Мин тартып керәм әле.—Әнәс чыгып китә.

—Борчыла ул, эчтән яна. Сиздерми генә,—ди Фатыйм апа.—Ни сөйләгәнен үзе белми, кайгыдан айнымаган әле.

—Да-а... Бөтен забота Әнәскә төшәчәк хәзер. Әти булганда—как за каменной стеной.—Бу сүзләрне Рамиләнең ире Мансур әйтә. Ул шулай урысча кыстырып сөйләшә.

Алар икәү гаилә альбомын актарып утыралар. Рамилә әтисе исән чакларны, үткәннәрнең фотосурәтләрдә яшәп калган бәхетле мизгелләрен сагынып искә ала. Мин белән инде, үз башымнан кичте, кеше мәңгелеккә китеп югалгач, хәтер төбеннән әллә нинди онытылган вакыйгалар калкып чыга да, бик мөһимгә әйләнә.

—Наргизә, Гөлзадә апа үлгәч, сиңа да шулай авыр булгандыр, ә без хәлеңне дә белмәдек. Кичер, гаепләмә безне. Үз башына төшмичә аңламыйсың икән.

Шулай икән шул. Тик ул чакта моңа игътибар ителмәгән.

—Үтте инде... Вакыт әкрен генә дәвалый.

—Чынлапмы? Дәвалыймы? Гел-гел болай авыр булмыймы?

—Гел шулай булса, ничек яшәмәк кирәк?

—Ой, мин әнине югалтуны күз алдыма да китерә алмыйм,—ди Рамилә.

Ә кем күз алдына китерә дә, кем көтә ди ул кайгыны?!

Рамилә белән Мансур кабат альбом өстенә иеләләр:

—Кара, әти нинди яшь монда, шундый матур. Бу кайсы ел? 1959... Бу бит әни белән өйләнешкән еллары. Шулай бугай...

—Әйе,—дим мин.—Алар шул елны өйләнешкәннәр.

Рамилә миңа гаҗәпләнеп карый:

—Ә син каян беләсең?

Моңа кадәр бер сүз дәшми уйга батып утырган Фатыйма апа да сүзгә кушыла.

—Ләбиб белән уртак тел тапты ул, төннәр буе икәү серләшәләр иде. Ниләр сөйләде ул сиңа, Наргизә?

Мин яшереп куйган җирдән үземнең «роман»ны тартып чыгарам да, Фатыйма апага сузам. Ул аны кулында әйләндергәли, күзләрен кыса төшеп, йөзенә китерә. Аннары авыр сулап:

—Булмый, хәзер укырлык рәтем юк,—ди.—Күз ачыта.

—Бир, әни, үзем.

Рамилә кычкырып укый башлый. Менә инде соңгы юлларга да килеп житте:—«Фатыйма, Әнәс, Рамилә! Сез—бу дөньяда минем иң газизләрем! Ул-бу була калса, рәнжемәгез, бәхил булыгыз. Әнәс, әниеңне ташлама!».

Фатыйма апа утырган урыныннан калкынып куя:

—Шулай дигәнме?

—Әйе, әни, үз кулы белән язган.

—И мескенкәм... Китәсен сизгән икән Ләбиб...

***

Тормыш белән үлем гел янәшә. Үлемнән башка тормыш юк, ләкин тормыштан башка үлем дә юк. Кеше шуны аңлап, шуңа күнеп яшәргә тиеш. Рамиләләр китеп баргач, өй тагы да бушап, ямансулап калды. Авыр. Әлегә бик авыр. Ләкин бу үтәчәк. Хәсрәт килгәч, кеше башын учлап бераз туктап хәл ала да, аннары кайгысына күнеп, аны үзе белән ияртеп, тагын алга атлый. Тормыш шулай дәвам итә.

Ләбиб абыйның вафатыннан соң Әнәс тә олыгаеп, җитдиләнеп китте кебек. Хәзер элеккечә җил куып йөрми, үзенә нинди дә булса шөгыль табып, гел йорт тирәсендә чуала.

—Ярый әле янымда син бар, туганым,—ди Фатыйма апа.—Син бар, Әнәс бар... Ялгызым ни кылыр идем.

Ләкин мин дә, Әнәс тә Ләбиб абыйны алыштыра алмый. Беркем дә беркемне алыштыра алмый. Янында ун кеше бөтерелеп йөрсә дә, ялгызлыктан тилмереп, күз яшенә буылып утыруың бар. Һәм киресенчә, яланда берьялгызың басып калып та, синнән дә бәхетле кеше булмаска мөмкин.

Миңа хәзерге вакытта беркем дә кирәкми. Эчем-тышым Янгураз белән тулы. Миңа ул җитә. Ул хәзер миндә. Мин... ул... без—бер тән, бер җан. Чөнки...

—Безнең балабыз булачак, Янгураз. Мин авырлы.

Янгураз дәртләнеп куя:

—Ман сани севаман, фариштам! Угылмы?

—Әлегә белмим... Ләкин ул синеке, синнән башка беркемем юк, Янгураз. Зинһар, оятка калдырма, алып кайт үзенә.

—Угыл булса, алып кайтам.

—Ә кыз булса?

—Минем кызым бар, асаля.

Бу сүзләргә хәтерем калса да, никтер үпкәли алмыйм. Җаны теләгән елан ите ашаган, ди. Сихерләнгән сыман тартылам инде бу кешегә, мине аннан аерса да үлем генә аерыр. Йөзе-кыяфәте, карашы-тавышы, күзләре-сүзләре—барысы-барысы җаныма бик якын, кадерле! Яраткан кешеңә ничек үпкәлисең ди?! Янгураз үзе дә ярата бугай. Килми калган көне юк. Төн уртасында булса да корыч айгыры белән очып килеп җитә. «Сагындым, шикәрем!»—дип кочагына ала. Берничә мәртәбә, бабай базарда, Ситара бакчада чагында, өенә дә алып кайтты. Алтын чәчле авыру хатында дөнья кайгысы юк, ашый-эчә дә, түшәмгә карап ята. Ә мин... Мин әле яшь, сәламәт, бөтен күзәнәгем наз-мәхәббәт сорый. Суга чумган кеше яңгырда чыланудан куркамы?

—Нәркис гөлем, син шикләнмә, мин сине дә, углымны да ташламам,—ди Янгураз.—Тик сине монда алып кайтасым килми. Никтер күнел тартмый. Берәр фатир табарга кирәк булыр. Кайгырма, гөлем, анысын үзем хәл итәрмен. Минем таныш мулла бар, качып кына никах укытырбыз, майли, җаным. Тамараны да, сине дә рәнҗетмәм, шулай ике арада йөрермен. Үпкәләмисеңме, асылым, син шуңа ризамы?

Риза булмый ни кыласың...

—Ә балага үз исемеңне, фамилияңне бирәсеңме, Янгураз?

—Ай-вай, асаля, рәнҗетәсең. Үз баламнан баш тартырга мин имансыз бәндә түгел лә. Угылымның атасы булырга тиеш.

Янгураз, шул көннәрдә үк сиңа фатир эзләп табам, күрешергә аулак, җайлы урыныбыз булыр, дигән иде. Тик мин Фатыйма апаны кайгылы көннәрендә ташлап китә алмадым. Бу эшне кичектерергә туры килде.

Янгураз белән очрашып йөрүемне өйдәгеләр дә, эштәгеләр дә сизенә-белә

бугай. Артымда бәлки чәйниләр-гаеплиләрдер дә, тик йөзгә бәреп әйтүче юк. Әйтсәләр дә исем китмәс иде, үз тормышым, үз бәхетем.

Бәхетем шул! Янгуразым... Күнелемә нур сипкән, йөрәгемне жылыткан, тормышыма җан өргән якты кояшым! Сулышыннан исерәм, кулы түгел, җиле кагылса да, тәнемә ут каба. Мин аны яратам, башымны җуярдай булып яратам! Бар дөньяда гүя икәүдән икәү генә калганбыз. Гап-гади кешене шулай чамасыз ярату ярамыйдыр да бәлки. Ләкин мин шундый инде... Сөйгән бакасы артыннан сазлыкка кереп чумучы исәр гашыйк.

***

Янгуразның әнисе кырым татары булган икән. Сугышка кадәр алар оҗмахта—Кара диңгез буенда яшәгәннәр. Гөлбакча эчендә утырган үз йортлары булган. Сугыш башлангач, Әминә апаның әтисе фронтка китә дә шунда хәбәрсез югала.

1944 елның җәйге бер төнендә аларга хәрбиләр килеп керә... Өйләреннән куып чыгарып, ябулы машинага утырталар да, станциягә алып китәләр. Ул төнне бик күп халык кулга алына. Тик ни өчен—беркем белми-аңламый. Аларны мал вагоннарына төйиләр. Һәм төнге поезд, меңләгән бәхетсез язмышны салкын куенына алып, кайгы-хәсрәт, ачлык-ялангачлык иленә кузгала. Вагоннарда ифрат кысан, тынчу була. Ишекләрне көнгә бер генә тапкыр ачып, су бирәләр, анысы да кемгә эләгә, кемгә юк. Юлда тынчулыктан, сусаудан, йогышлы чирләрдән бик күп кеше кырыла. Мәетләрне туктаган бер җирдә ашык-пошык күмеп, ә кайчакта, күмәргә дә өлгермичә, ташлап кына да калдыралар. Әминәнең әнисе белән ике энесе дә билгесез җирләрдә ятып кала...

Әминәне башкалар белән бергә шыр ялангач далада төшереп калдыралар. Боларны озата барган хәрби: «Дөмекмәсәгез, яшәрсез!»—дип кычкыра. Дала уртасында бернәрсәсез басып калган халык су эзләп китә. Бер чишмә янына туктап казык кагалар: «Без шунда яшәрбез!» Туганнар берләшеп, берберсенә булышып, әкрен генә тернәкләнеп китә, җир казып жылы куыш ясыйлар, ир-атлар якын тирәдәге авыл-калаларда үзләренә эш таба.

Унөч яшьлек ятим кызга хәер теләнеп, сораныйп йөрүдән башка чара калмый. Шулай йөри торгач, Әминә Шымкент вокзалына килеп чыга... Сугыштан кайтып килүче бер үзбәк солдаты аны күреп ала да үзе белән ияртеп китә. Туган кышлагына кайтып житкәч, күгәрчендәй арык, кечкенә кызны әти-әнисенә күрсәтеп, егет болай ди:

—Танышыгыз, сезнең киленегез, минем хатыным шул булыр!

Әминә белән Илморзаның бик озак балалары булмый. Туган берсе үлә тора. Бары Янгураз гына сау-сәламәт булып үсә. Ләкин әнисе аны күреп сөенә дә алмый кала... Баласына ул чынлап та үз җанын бирә...

—Мин әнинең нинди икәнен дә белмим, бер сурәте дә калмаган,—ди Янгураз.—Ул чакта рәсемгә төшүнең ни икәнен белгәнмени безнекеләр.

—Ә син кемгә охшаган?

—Икесенә дә бугай... Әти, күз-борынын әниеннеке, дия иде.

—Янгураз, ә синең хатының милләте буенча кем? Ул бит үзбәккә дә, кыргызга да охшамаган.—Белсәм дә, юри сорыйм.

—Охшамас шул. Ул бит маржа,—ди Янгураз.—Мин дә әти кебек армиядән өйләнеп кайттым.

Роберт алдамаган икән.

Без Янгураз йортында, йомшак түшәкле киң караватта бер-беребезгә сыенып иркәләнешеп ятабыз. Шул ук түбә астында, икенче бүлмәдә генә сүнгән карашын түшәмгә төбәп, аның чирле хатыны ята... Янгураз берничә мәртәбә Тамарасының хәлен белеп килде, ашатып-эчертеп тә алды бугай.

Ә мин, бәхетемә сөенә-сөенә, оятсыз рәвештә аларның уртак ятагында ауныйм... Ай-яй, килешми, Наргизә... Яхшы кыз түгел син, Наргизә. Ләкин оят-намуслар белән исәпләшә башласаң, күпме шатлыктан мәхрүм калырга кирәк... Юк, миннән булмый, мин үз бәхетемнән ваз кичүче түгел. Янгуразым белән үткәргән һәр мизгел үтә дә кадерле, тансык мина. Бар гаебем—ярату гына лабаса. Ә мәхәббәттә гөнаһ юк диләр. Дәрте ташып торган сау-сәламәт ир дә гомер буе чирле хатын көйләп чиләнергә тиеш түгелдер. Аның да кешечә сөеп-сөелеп яшисе киләдер. Ә мин аңа бары шатлык кына бүләк итәм ич.

—Шулай бит, Янгураз?

—Нәрсә—шулаймы?

—Син минем белән бәхетлеме?

—Ничек бәхетле булмыйм ди, Нәркисгөл... Тау артыннан калыккан алтын кояшым бит син минем! Татлы балым син! Ялгыз бүре сыман яши торгач, тәмам кыргыйланып беткәнмен. Авыру хатын... сакау Сиражетдин... Рәхәтләнеп сөйләшер кеше дә юк.

—Ә кем соң ул Сиражетдин агай?

—Әтинең абыйсы. Сугыштан контузия алып кайткан да, тәки шулай өйләнмичә безнең белән яшәде. Миңа нык ярдәм итә ул. Бөтен хуҗалык аның өстендә.

—Алайса, сиңа хатын кирәкми дә...

—Сиражетдин әкә миңа угыл алып кайтып бирә алмый бит, гөлем,—дип көлә Янгураз. Карынымда ир бала булуына шул кадәр ышана-өметләнә инде, җаныкаем. Мин дә малай булуын бик телим, сөйгәнемне шатландырасым, шул бала белән Янгуразны үземә мәңгегә бәйлисем килә. Тик бу асыл ярны минем кебек үк сөендерергә, үзләренеке итәргә атлыгып торучылар тагы да юкмы икән соң?

—Янгураз, син... бер дә читтә йөрмәдеңмени? Башка хатыннар белән дим... очрашмадыңмы?

—Әүвәл аның кайгысы булмады, аннары шул тормышка күндем дә бугай. Үзең кул сузмасаң, сине дә күрми үтә идем.

—Ә Тамара сине ярата идеме? Минем кебек ярата идеме?

—Сөймәсә, ияреп килмәс иде.

Яраткандыр шул... Мондый егетне яратмау мөмкинмени?!

Мин Тамара турында күбрәк белергә телим, тик Янгуразның күңел яраларын кабат кузгатмас өчен дәшмим, сүзсез генә аның йомшак чәченнән, кытыршы яңакларыннан иркәлим. Минем аны, үзем өчен ифрат кадерле булган бу кешене, таулар кебек горур, дала җиледәй кырыс, таулар артындагы кояш сыман серле, ялкын йөрәкле газиземне бик тә, бик тә бәхетле итәсем килә...

—Без үлгәнче бергә булырбыз, әйеме, Янгураз?

—Без үлгәнче бергә булырбыз, Нәркис гөлем!

***

Без палатада дүрт хатын ятабыз. Миннән башкалар үз теләкләре белән бала төшерүчеләр. Инде эшләрен бетереп чыктылар. Шуңа сөенә-сөенә баядан бирле ләтчит сатып яталар. Берсенең тавышы зеңгелдәп тора, колакны ярып керә, башымны әчке яктан үтмәс пәке белән кыралармыни. Кайчан гына туктарлар? Тавыштан арыдым. Тавыштан гына түгел, тормыштан да арыдым бугай, күземне мәңгегә йомып, дөньясыннан ук югаласым килә...

Ә тегеләр ирләре, кайнаналары, тагы әллә кемнәре турында сөйләп бетереп, инде өр-яңадан беренче эзгә кайтып төштеләр:

—Уф, котылдык бит! Токсикоз белән жәфаланганнарымны белсәң, малакаем! Ризыкнын өстенә дә карыйсы килми. Судан да костыра иде бит. Ике ай буе үлә яздым. Бу бала дигәнен туганчы ук җелекне суыра башлый түлке.

—Минем токсикоз булмады. Малай белән булган иде. Бу юлы юк.

—Бәлки бусы кыз булгандыр, табасын калган. Кызлар кирәк, алар бөтен эшенне эшли. Минем кызга сигез генә яшь, савытларны да юа, идәнне дә ялт иттереп куя. Кызлар рәхәт, ә малайлардан файда юк. Алар урамнан кайтып керми.

—Ярар, соңгысы булмас әле. Кызны да алып кайтырбыз. Машина эшләп тора.

Көлешәләр.

—Әй, кызлар, ирләрнен үзләрен бер генә тапкыр булса да монда кертеп карыйсы иде. Нишләрләр иде икән?

—Нишләсеннәр, врачларны тибеп очырырлар иде. Алар авыртуга чыдамый бит, тешләре сызласа да, үлә-үкерә башлыйлар.

—Козлова бигрәк тупас инде. Кызганмыйча рәхәтләнеп тапый, мал суямыни?!

—Абортка килгән хатыннарны яратмый алар.

—Алар яратмый дип хәерче үрчетеп булмас инде.

Мин жан әрнүе белән иренемне тешлим. Салкын кулларымны бушап калган эчемә куям. Ул юк, Ул юк... Улым минем, газизем! Нәни Янгуразым...

Аны мина күрсәттеләр... Шул Козлова дигән табиб булгандыр инде. Чынлап та хәтер саклап торучылардан түгел бугай. Тычкан баласыдай канлы кисәкне учларына салып мина сузды да:

—Менә кара баланңы! Бөтен килеш килеп төште,—диде.—Дүрт саны да төгәл. Ундүрт-унбиш атналык ир бала.

Шул чактагы тетрәнүем... Үз кулларым белән кеше үтердеммени... Бер сүз әйтәлмичә сулкылдап елап җибәрдем. Тик врач апа кызганмый, юатмый, анын тавышы үтә кырыс:

—Сакларга кирәк иде! Шыңшыма, югыйсә кан китүе бар.

Китсен! Кан белән бергә тормыш китә, кайгы-хәсрәтләр, әрнү-газаплар китә... Үлем куркыныч түгел, ул мәңгелек тынычлык алып килә. Кайчандыр, кайдандыр укыган идем: кеше белән үлем беркайчан да очрашмый, без барында—ул юк, ул килгәндә—инде без юк... Бу фикер мина бик ошаган, күңелне юаткан иде, чөнки мин ул вакытта үлемнән курка идем.

Төштән соң Фатыйма апа килде. Ул бу хәлләргә тәмам аптыраган. Ни әйтергә дә белми. Күземә карамаска тырышып, янымдагы тумбага алып килгән ризыкларны тезә:

—Менә бусы—чия компоты. Бик файдалы, канны яхшырта. Анар да алып килдем, гемоглабинны күтәрә. Кайнар килеш токмачны аша әле. Сина ашарга, ныгырга кирәк.

Ашарга, ныгырга... Нигә кирәк?! Озаграк газапланыр өченме?

Сизеп торам, әгәр бу хәлдә булмасам, Фатыйма апа мине эче бушанганчы рәхәтләнеп сүгәр иде. Әйтер сүзләре бәгыренә төелгән, көчкә тыелып тора. Анын сенелесе ирсез бала тапмакчы булган! Бу бит—адәм хурлыгы. Кеше күзенә ничек карарсын, ни диярсен? Хәзер инде беркем дә Фатыйманың кадерле сенелесен кияүгә сорап килмәячәк. Мәҗлесләрдә дә, элеккечә күкрәк киереп түгел, әби әйтмешли, артыннан тын алып, иренен тешләп мыштым гына утырачак. Кыз баланың ялгышы туганнары йөзенә дә күләгә төшерә шул...

Ике арада киеренкелек, сөйләшер сүз табып булмый. Югыйсә икебездә

дә бер үк язмыш. Ул утыз ел яшәгән ирен, ә мин ярты ел очрашып йөргән сөйгәнемне—дөньяга туарга тиеш булып та тумый калган баламның әтисен югалттым.

Айлар, еллар арасында аерма зур кебек. Ләкин гомер минут-сәгатьләр, ай-еллар белән генә исәпләнми. Гомер бәхетле һәм бәхетсез мизгелләр белән исәпләнә. Бәхетле мизгелләр—кеше гомеренең алтын баганасы. Аларны тартып алсаң, гомер ишелеп төшә...

Уйларымны Фатыйма апаның гаепсенгән тавышы бүлә:

—Шулай булуы хәерледер дә әле, сеңлем. Ирсез бала тапканчы дим... Кеше белми калса, тагы да яхшырак буласы иде дә... Бар халык алдында бит... И, Алла...

Мин акланмыйм. Каршы да дәшмим. Арыдым мин.

—Фатыйма апа, йоклата торган укол када әле миңа.

Ул миңа кызганулы караш ташлый:

—Хәзер, кызларга әйтермен.

Ниһаять, бөтен тавышлар тына. Йокы дөньясында җан әрнүләре ял итә.

***

Ситара үлмәгән! Ситара исән! Ул инде бакчага йөри.

Бу хәбәрне хәл белергә килгән Динара китерде.

Ышанмый торуымны күргәч, шатлыклы хәбәрне беренче булып әйтүенә сөенеп, кулыма шәһәр газетын тоттырды.

—Менә укы! «Тәмугтан чыгучылар» дигән мәкалә. Анда барысы да язылган. Рәсемнәре дә бар.

Динара китүгә, газетка ябыштым. Хактан да шулай, Ситара исән икән. Ул гына да түгел, Караташтан тагы өч җан—Сиражетдин, ишәк һәм эт исән калган.

Ул төнне Сиражетдин агай эт өргән тавышка уянып, ишегалдына чыга. Карый, тикшерә—беркем юк. Ә эт бәйдән ычкыныррлык булып котырып өрә. Аптыраган карт Янгуразны чакыра.

—Бу юкка түгел,—ди Янгураз, ашыга-ашыга этне бәйдән ычкындыра, кабаланып олы капканы ача. Аннары кире өйгә кереп, йокысыннан да уянмаган Ситараны күтәреп чыга да, юрганы-ние белән Сиражетдин агайга тоттыра:

—Йөгерегез, үргә, калага таба йөгерегез, таудан ташкын килә.

—Ә син?—ди карт.

—Мин Тамараны алып чыгам. Ашыгыгыз, без сезне куып җитәрбез.

Ләкин өлгерә алмый...

Нигә генә кире кергән ул?! Тамара болай да мәет белән бер иде ләбаса. Янгураз аны җаны-тәне белән яраткан, күрәсең. Миңа, улына карый күбрәк яраткан... Соңгы мизгелдә аны сайлаган, мәңгелеккә аның белән бергә киткән...

—Сиңа анда бармаска кирәк иде,—диде Динара.

Бармаска кирәк булгандыр шул. Ә мин тиле кебек йөгердем, бу коточкыч хәбәрне ишетүгә йөгердем. Өлгерермен төсле тоелды. Кулларым белән җирне казып булса да, аны коткара алырмын төсле тоелды... Ниндидер могҗизага ышанып йөгердем. Ләкин таш, боз, туфрак боткасы белән тулаем күмелгән кышлакны, дөресе кышлак урынын күргәч, аңсыз егылдым. «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырып торырга да кирәкмәгән. Алар болай да анда иде инде. Анда халык күп иде.

Караташны тау ташкыны күмгән дигән хәбәрне ишетеп, һәм минем кебек үк ниндидер могҗизага, якыннарының-туганнарының исән калуына

ышанып килүчеләрнең соңгы өметләре шунда өзелде. Төн булган, кешеләр йоклаган, беркем котыла алмаган. Барысы да җир астында калган, терелэй күмелгән... Йөз яшьлек теге әби дә, безгә очраган оялчан яшь хатын да, Янгузар да... Йә Алла, нинди куркыныч, коточкыч үлем.

Нигә өенә кире борылып кердең соң син, Янгураз?! Син исән калырга тиеш идең! Син безгә кирәк идең—Ситарага, миңа, улыңа, Сиражетдин агайга... Авыру хатынны коткарам дип дөньяга туарга да өлгермәгән сабыеңны үтердең, мине үтердең...

—Нәрсә дип шул кадәр бәргәләнәсеңдер, ул җүнле адәм түгел иде,—ди Фатыйма апа.—Үлгән кеше турында начар сөйләргә ярамый да инде, сине кызганып кына әйтүем. Син түгел, бала гына кирәк булган аңа. Барыбер өйләнәсе, рәхәт күрсәтәсе юк иде.

Беләм инде, юри шулай әйтә. Янгуразны онытуымны, кайгыдан айнып, тизрәк элекке халәтемә кайтуымны тели ул. Инде ничәнче кат миңа Янгуразның әшәке ир булуы хакында сөйли:

—Янгураз—спекулянт, алдакчы аферист... Ул наркотиклар саткан, үзе дә кулланган. Бөтен байлыгы—пычрак акчалардан...

Шулайдыр... Ләкин мин аны яраттым!

—Янгураз—рәхимсез, кансыз бәндә... Ул хатынын тилечә көнләгән, беркая чыгармый өендә бикләп тоткан...

Шулайдыр... Ләкин мин аны яраттым!

—Янгураз сине алдаган! Үзенә ир бала кирәк булганга гына яраткан булып кыланган... Баланны тартып ала иде дә, артыңа тибә иде. Үзбәкләр хатын-кыз белән санлашып тормый, аларның үз законы...

Шулайдыр... Ләкин мин аны яраттым!

Яхшы кешеләрне генә яратырга ярый дип кайда язылган соң?!

***

Минем тизрәк эшкә чыгасым, Ситараны күрәсем килә. Ни хәлдә икән ул? Сиражетдин агай ни хәлдә икән? Аларга бер бүлмәле фатир бирелүе хакында газетта язылган иде. Ул кечкенә таш капчыкка ишәк белән эт сыймагандыр, әлбәттә. Алары кайда икән хәзер?

Ләкин Ситараны күрергә насыйп булмады... Мин эшкә чыкканда ул бакчада юк иде инде. Караташтагы фаҗига турында ишетеп, Тамараның туганнары килгән һәм Ситараны Новгородка алып киткәннәр. Шулай итеп, соңгы юанычымны да тартып алдылар, Янгураз белән бәйле соңгы җеп тә өзелде...

Кеше үз-үзен юата белергә тиеш. Чөнки үз хәлеңне синнән дә яхшырак аңлаучы юк. Менә мин дә үз-үземне үзем юатып маташам. Бар шатлыктан мәхрүм калган шыр ялангач буш күңелемә көзге янгыр булып акылымның салкын тамчылары тама...

Дөньяның яме калмады, тормышның кызыгы бетте, дисең. Уйлап кара әле, Наргизә, Майлысуга килгәндә ниең бар иде соң? Күз төбеңдә беренче мәхәббәтеңнең йодрык эзләре, ә күңелеңдә җилләр уйный иде. Шулай булса да, син тыныч кына яшәдең, тормышыңнан бик риза-канәгать идең. Син әле ул чакта Янгураз дигән кешенең дөньяда барлыгын да белми идең. Ләкин аңсыз да бик яхшы яши идең, синә тыныч иде, рәхәт иде... Шулай бит, Наргизә?! Янгураз сиңа кем соң? Җиде ят кеше... Әйләнә-тирәнә кара, егетләр беткәнме? Аларның кай җире ким? Әллә ярата белмиләрме? Нәрсә дип Янгуразга капландың әле, кызый? Ни гомер җүләр сыман саташып йөрисең. Ул инде, әнә, әллә кайчан үзенең яраткан хатыны янында. Алар теге дөньяда да бергә. Оныт син аны, Наргизә! Якты дөньяга кара, башкаларны күр. Тот та бер шәп кенә егеткә кияүгә чык, җаныңны юатырга

бала тап. Үткәннәрне барыбер вакыт тузаны күмеп китә, аларны үзгәртеп тә, төзәтеп тә булмый. Янгуразны да кайтарып булмый... Борчыма аның рухын. Оныт син аны, оныт. Бүгенге белән яшә, Наргизә, тормышның рәхәтен күр! Син исән ич, үлмәгән...

Мин үземне шулай дип юатам. Үземне юата-юата таш-балчык актарам...

Мин һәр көнне монда киләм. Кайчандыр Караташ дигән кышлак булган урынга....

Таудан төшкән ләм инде тыгызланган, утырган. Башта аны актарып, мәетләрне эзләп алмакчы булганнар да, файдасызлыгын аңлап, бу эшкә кул селтәгәннәр. Караташ хәзер ачык каберлек.

Ә мин казыйм... Тәмам хәлдән тайганчы казыйм да, Аны табуыма өметемне өзеп, өзгәләнеп елый башлыйм. Каршымдагы таулар өстенә көлтә-көлтә үпкә-ләгънәтем ява: «Нигә шулай рәхимсез сез, таулар? Сез шундый биек, шундый көчле! Көчлеләргә рәхимсез булу килешми. Тау астында да тормыш бар! Тау астында сезгә бик кечкенә булып тоелган кешеләр яши. Алар бер-берсен яраталар, аларның бәхетле буласы килә. Сезнең гомер чиксез, ә кешеләрнеке шундый кыска. Нигә сез минем сөйгәнемне тартып алдыгыз, таулар? Ул бит сезне шундый ярата иде! Кайтарыгыз миңа Янгуразымны! Кайтарыгыз!»

Ләкин таулар дәшми. Таулар мине күрми, ишетми. Алар артык зур, алар горур. Алар куеннарына кояш хәтле кояшны яшерәләр...

—Йөрмә кеше көлдереп. Акылдан язган диярләр. Синдә генәме кайгы? Бүтәннәр, әнә, хәтта иң якыннарын югалтканнар да алай кыланмый. Аларга җиңел дип беләсеңме әллә? Сабыр булырга кирәк. Кем инде сөяркәсе өчен шулай өзгәләнә? Җитәр, туганым, артыгын кыланасың, туктат бу эшеңне!

Мин Фатыйма апа белән килешәм. Балчык актарып, ләм-туфрак арасыннан Аны эзләп йөрүләрем бер кирәксез, файдасыз эш икәнен үзем дә аңлыйм. Янгуразның җансыз гәүдәсен табудан миңа ни шатлык та, ни юаныч?

—Башка бармыйм, апа.

—Барма шул! Безнең халык кайгысын эчкә йота ул. Урыс кебек такмаклый-такмаклый уламый, әртисләнеп тә йөрми. Мине дә оятка калдырасың бит. Килешмәгәнне!

Миңа чынлап та оят.

Язмышка күнәргә кирәк. Нигә шул хәтле кайгырам соң әле? Бар газаплардан коткаручы үлем бар ләбаса. Ә үлгәч, анда... Аның белән очрашырбыз, бәлки. Сәер... Үлем мине Әни белән, Аның белән очраштырачак. Йә, җитте инде! Минем башка әллә нинди тиле уйлар оялап маташа. Әллә чынлап та акылдан язам инде?! Фатыйма ападан оят. Ул, әнә, гомер иткән ирен югалтып та, зарланмый, бәргәләнми. Көн саен, елый-елый, каберлеккә дә чапмый. Аңардагы сабырлыкка шаккатырлык.

Әкрен-әкрен генә мин дә айный, үз хәлемә кайта башладым. Янгураз белән бергә үткән көннәр ерагайган саен, алар чынлыгын югалта бара, гүя барысы да бер матур төш кенә булган...

***

Мин кайгы томаны эчендә адашып йөргәндә, Майлысудан унлап гаилә берьюлы күчеп киткән икән. Ничә елдан соң, корган ояларын ташлап, дәррәү кузгалып, Кырымга киткәннәр дә барганнар. Гомерләре бирелә үткән югыйсә. Гаҗәп хәлләр, сәер хәлләр.

Кырым татарларының аягы җиңел булды, алардан соң немецлар

кузгалды... Аннары яхүдләр... Кем Кырымга, кем Алман иленә, кем Израильгә...

Майлысуда күчеш чоры башланды.

Китәм дигән кешегә чикләр, капкалар, юллар ачылды...

Туган як дәшә, Ватан тарта, диләр.

Мин әлегә бу сүзләрнең асылын, мәгънәсен аңлап та бетермим бугай. Әллә яшьлегем белән, әллә инде үзем башкаларга охшамаган үзгәрәк, сәеррәк затмы? Туган якны өзелеп сагыну хисе юк миндә, юк нишләптер...

Алай дисәң, Фатыйма апа да бик өзгәләнми кебек. Югыйсә җаны теләгән вакытта туган якка кайтып китә алган. Беркем тыймаган, юлына киртә кормаган. Үз ирекләре белән килгәннәр, шунда гомер иткәннәр, беркая китмәгәннәр. Димәк, ошаган биредә, начар булмаган.

Ә менә тегеләр китте... Ярый дигән сүз чыгуга дәррәү куптылар да киттеләр. Аларның Ватаннары безнекеннән ямьлерәкме әллә? Нигә миндә Ватан тойгысы, аны сагыну хисе юк икән соң? Бәлки минем Ватаным да юктыр...

Алар бит шулай диләр:

—Без Ватаныбызга кайтабыз,—диләр.

Гомерләре Майлысуда үткән, күбесе шунда туган, үскән, укыган, эшләгән, оя корган кешеләр авыз тутырып, горурланып:

—Без Ватаныбызга кайтабыз!—диләр.

Аларны анда көтәләр, шатланып каршылыйлар...

Ә безне кайда көтәләр? Нигә мин дә немец түгел икән, мин дә Германиягә китәр идем...

—Китәр идеңме?—дип ышанмыйча кайтарып сорый Клара.—Туган җиреңне ташлар идеңме?

Клара безнең бакчада тәрбияче булып эшли. Аның әтисе фашист булган, Сталинград сугышында әсир төшеп, бу якларга килеп эләккән. Шунда бер украин кызы белән танышып, өйләнешкәннәр. Хәзер «фашист абзый» юк инде, ләкин Клара барыбер әнисе, ире, ике баласы белән Германиягә китәргә җыена. Әтисенең туганнарын эзләп тапкан, хәбәрләшкәннәр, тегеләр чакыру җибәргән.

—Синең дә туган җирең Германия түгел, китәсең ич,—дим мин.

Ләкин Клара горур, аңарда ариецлар каны кайный башлаган:

—Минем тамырларым—Германиядә! Минем бабам барон булган!

Кларaның тәккәбберлегенә ачуым килә:

—Әтиеңнең каберен дә үзең белән алып китәсеңме?

Барон оныгы тиз генә җавап бирә алмыйча югалып кала, бер тын уйланып торганнан соң миннән киңәш сорый:

—Ә нишләргә соң?

Менә шулай шул, тамыр анда, ботак тегендә, яфраклар җирдә, чәчәкләр җилдә... Җый хәзер аларны.

Ләкин барыбер китәләр. Җитәкчеләр, укытучылар, табиблар, инженерлар, кыскасы, укымышлы, зыялы халык, яхшы белгечләр китә... Аларның күбесе китүчеләр милләтеннән булган икән. Майлысуда кыргызлар күбәя башлады кебек. Элек болай еш очрамыйлар иде. Безнең бакчада да каратут йөзле, кысык күзле балалар ишәеп китте.

Нәкъ Җину көнендә мөдиребез Эльза Фридриховнаны озаттык. Аның йөзендә сагышның әсәре дә юк, киресенчә, ул шул хәтле шат, бәхетле иде.

Гомер буе Майлысуда яшәгән кешенең Ватаны—Алман иле икән...

Ә аннары... Моңа ышанасы да килми, ләкин шундый имеш-мимешләр йөри башлады: имеш, озакламый, урысларны, татарларны да куачаклар

икән... Кайбер зур калаларда «Русских—в Рязань! Татар—в Казань!» дигән язулар күтәреп митингалар үткәреп яталар ди, имеш...

—Юк, булмас,—ди Фатыйма апа.—Гомер буе шунда эшләдек, дус-тату яшәдек. Без дә китсәк, кем генә калыр соң? Монда күпчелек килгән халык лабаса.

Урыс-татар арасында китүчеләр әлегә күренми. Киресенчә, китүчеләрнең таза-шәп йортларын сатып алып, яхшылап төпләнергә, үлгәнче шунда яшәргә җыеналар кебек.

***

Әмма дөнья тыныч түгел. Әле тегендә, әле монда—чуалышлар. Кемгәдер әрмән, кемгәдер үзбәк, кемгәдер төрек ошамый. Әле бу, әле теге тарафтан шомлы-шомлы хәбәрләр килә. Чәчләрең үрә торырлык хәлләр турында сөйлиләр. Куасайда үзбәк белән мөсхет төрекләре арасында зур гауга чыккан да, бер-берсен суеп йөриләр, имеш. Тавыш юктан гына башланып киткән ди югыйсә. Бер төрек егете базарда җиләк сатучы үзбәк кызына яман сүзләр әйтеп, җиләген җиргә әйләндереп каплаган. Моны күреп торган үзбәкләр кимсетелгән кызны яклап йодрык уйнатып алганнар. Мөсхет төрегенә дә үз теләктәшләре табылган. Кечкенә генә низаг зур гаугага әверелеп, чып-чын сугышка сәбәп булган. Очкыннан ялкын кабына диюләре шулдыр инде. Хәзер ниндидер үзбәк оешмасы халыкны төрекләргә каршы котыртып йөри икән. Мөсхет төрекләрен үз җирләреннән куа, йортларын яндыра башлаганнар. Алар бик елгыр, шома халык, күбесе сату-алу белән эш итә, тормышлары нык, җитеш. Бәлки шул байлыктан көнләшү дә бардыр. Ялгыш корбаннар булмасын өчен, үзбәкләр үзләренекенә яшел әләм тараткан. Түбәсендә шул әләм җилфердәгән йортка тимиләр икән... Талау-үтерештән куркып, төрекләр йортларын, бар мөлкәтләрен ташлап шәһәрдән кача ди... Кокандта да шул ук хәлләр. Ә Әндижанда бер төркем яшьләр әрмән белән яһүдләр яшәгән кварталны пыр туздырган... Наманганда берничә урыс солдатын үтереп ташлаганнар... Мондый куркыныч хәлләрдән соң Фирганә даласыннан төрекләр генә түгел, башка халыклар да качып китә башлаган. Аларның әзер квартир-йортларына үзбәк-кыргыз кереп утыра икән. Аптырап-гаҗәпләнеп сөйләделәр: шәһәр йортын гомерендә беренче тапкыр күргән бер авыл сантые дүртенче каттагы квартирында атын да үзе белән асрый икән...

Тирә-яктагы кала-салалардан көн саен диярлек шомлы хәбәрләр ишетелеп торса да, Майлысуда тыныч әле, тормыш бер көйгә дәвам итә. «Ник син минем кебек түгел?!»—дип, бер-берсенең бугазына ябышучы юк. Безнең күршегә Ош шәһәреннән бер татар гаиләсе күчеп кайтты. Элекке күршебез Зөлфия апа ире белән Кырымга киткән, ә йортын боларга калдырган икән. Румия—Зөлфия апага туган тиешле булып чыкты. Ул поликлиникага шәфкать туташы булып урнашкан. Яшь аралары шактый булса да, Фатыйма апа белән серләре килешкән. Менә шул Румия, безгә кергәч, Ошта булган коточкыч хәлләр турында сөйләп утырды. Бу турыда ни телевизордан күрсәтмәгәннәр, ни газетта язмаганнар. Үз колагым белән ишетмәсәм, ышанмас та идем.

—Быел җәй башында булды бу хәлләр,—дип сөйләде Румия.—Мин эштә идем, бер хатынга операция ясарга әзерләнәбез. Шул чак урамда «гоу-гоу» дигән куркыныч тавышлар, кычкырышлар ишетелә башлады. Тәрәзәдән карасак, урам буйлап кара болыт булып, чалгы, көрәк-сәнәкләр күтәргән ирләр төркеме килә. Башта әле берни аңламадык. Аннары сөйләделәр, имеш, үзбәк белән кыргыз арасында җир өчен бик зур гауга чыккан. Үзбәкләр, бу безнең борынгы җир, монда гомер-гомергә безнең халык

яшәгән дип, кыргызларга дәгъва белдергән икән. Тегеләр дә кызу халык бит, авыллардан барча ир-ат халкын җыйнап үзбәккә каршы күтәрелгәннәр. Менә шул ярсыган халык, кулларына ни эләксә, шуның белән коралланып шәһәргә бәреп керә дә, бер-берсен кыра башлый. Галәмәт бит, Фатыйма апа, карап торсаң, үзбәк ни дә, кыргыз ни, безгә барыбер кебек. Бер үк халык, бер үк дин, шаклар катырлык инде, ни кыланалар бит. Дөньяга сыймагандай бер-берсенә ябырылмасалар соң, аннан башка да җирдә хәсрәт җитәрлек ләбаса.

Ул көнне кечкенә улым өйдә берүзе калган иде. Квартирыбыз беренче катта. Улым тәрәзәдән бөтенесен күреп торган. Миңа шалтырата: «Әни, мин куркам, бүген мине үтерәләр,»—ди. Йөрәгем жу-у итеп китте, көне буе җаныма урын тапмый газапландым. Өйгә йөгереп кайтыр идем, тик, кая ул, җибәрмиләр. Җай чыккан саен: «Зинһар, беркая чыкма, өйдә генә утыр,»—дип улыма шалтырам. Безнең йортка таба килүче котырган халыкны күргән дә, куркуыннан урамга атылып чыккан бит балакаем... Улымны бер солдат күреп, үзе янына танк эченә алган. Рәхмәт яугыры, безнең солдатлар урамда буталып йөрүче байтак баланы коткарып калган шулай. Ләкин үлүчеләр дә шактый. Больницага яралыларны ташып кына тордылар. Чып-чын сугыш булды, атышлар төнгә кадәр барды әле. Фетнәчеләр тәмам акылдан язды. Имеш, шул кичтә, эштән кайтып баручы фабрика кызларын суыткычлы машиналарга төяп, туңдырып үтергәннәр дә, елгага ташлаганнар... Ул бичараларның ни гаебе бар инде?! Бу котырган халыкны көчкә бастырдылар. Армия катнашмаса, белмим, ни булып бетәр иде.

Тагы бер серне ачам инде сезгә. Бу кадәр галәмәтне гади халык оештырмаган, читтән котырту булырга тиеш. Төрле халык арасында юри ызгыш-талаш китереп чыгармакчы булалар, кемнәргәдер фетнәләр, сугыш кирәк. Больницага килеп эләккәннәрне яралардан гына түгел, наркотик сөременнән дә арындырдык бит. Чөнки кыргызларның барысы да диярлек наркотикка коенган, берни аңларлык хәлдә түгел иде. Аларга шул төнне наркотик кушылган аракы эчергәннәр, имеш. Әрҗә-әрҗә китереп торганнар, бушка булгач, рәхәтләнгәннәр шуны эчеп. Шуңа күрә акны карадан аермаслык булып ярсыган, шул кадәр яман кыланган да инде алар. Кыргызлар алай кансыз, агрессив халык түгел. Ничә ел шулар арасында яшәп бер начарлыкларын, кырын карашларын күргән булмады. Юмартлар, сабырлар, ярдәм итәргә генә торалар. Дөрес, бик горур, ирек ярата торган халык. Алла сакласын, Майлысуда шундый хәлләр була күрмәсен тагын. Ике-өч еллар элек, Ошта чакта ук сөйләгәннәр иде, ап-ак сакаллы бер бабай хәбәр таратып йөргән, имеш, СССР бетә дә илдә гражданнар сугышы башлана икән. Әзер торыгыз, дөньялар бик буталачак, ата—улны, ана кызны белмәячәк, дигән. Күреп торабыз бит, ни генә кыланмыйлар, халык акылдан яза бугай. Ахырзаман җитә, имеш. Болай булса, җитәр дә шул... Китәргә кирәк моннан, Фатыйма апа, исән чакта китәргә кирәк.

—Кая китәргә соң, туганкаем?!

—Кая булсын—туган якка!

—Әй, сеңелем! Анда безне кем көтә? Безнең эше гади халыкка кайда да бер тары боткасы инде. Күрәчәгең булса, алдыңдагы ашка капланып та тончыгып үләсең, диләр.

—Мин куркам, Фатыйма апа. Эчем тулы шом хәзер. Улым өчен дер калтырап торам.

—Курыккач, ник монда күчеп килдегез соң, Румия? Бер кузгалгач, Рәсәйгә китәсе булган.

—Һаман яхшыга өметләнәсең бит, Фатыйма апа. Монда тынычтыр, үз йортыбызда иркенләп яшәрбез дип кызыгып кайткан булдык. Ни әйтсәң дә,

Майлысуда урыс-татар күбрәк, укыган, культурный халык. Аннары Зөлфия апа да бик үгетләде, йортларын алучы булмады бит. Ташлап калдырырга жәл.

—Шулай диләр шул, алданрак кубучылар унган, ди. Ә хәзер бәяләр айлап түгел, көнләп төшә, чөнки китүче күп. Әнә, Куасайда квартирларын келәм бәясенә калдырып киткәннәр. Шул хәлгә калмагаек, Алла сакласын! Малга карый җан кадерлерәк, дисәләр дә, малы юкнын жаны да юк шул. Шыр ялангач калып булмый, гомер булса яшиселәр бар...

Фатыйма апа белән Румия шулай уфтанып-зарланышып шактый утырдылар. Мин аларга кушылмадым. Күрше хатыны күнелгә шом салып чыгып китте.

***

Ул төнне мин тынычлап йоклый алмадым, төне буе саташып чыктым. Әллә нинди буталчык, куркыныч төшләр кереп бетте. Имеш, Майлысу урамы буйлап барам икән. Каршыма сәнәк, чалгы күтәргән кап-кара киемле ирләр төркеме килә. Мин алардан куркып тауларга таба йөгерәм. тырыша-тырыша өскә үрмәлим. Шул чак карасам, таудан вак-вак ташлар, балчыклар коела. Мин куркып калам, хәзер инде ни төшеп, ни менеп өлгерә торган түгел. Зур ташларга сыенып басып торам. Әгәр бу гарасат туктамаса, котылу юк. Янгураз кебек жир астында тереләй күмелеп калганчы сикереп үлүен яхшырак дип уйлыйм да, таш кебек түбән атылам. Инде үлгәнмендер мөгаен, шул хәтле биектән сикереп кем исән калсын? Ләкин, ни гажәп мин исән, чөнки Янгураз күтәреп алган, бер сүз дәшми елмаеп карап тора. Аннары мине жиргә бастыра да, кулы белән еракта күренеп торган олы юлга төртеп күрсәтә. Ләкин минем Янгураз яныннан китәсем килми, аны кочакламакчы, күкрәгенә сыенмакчы булам. Тик Янгураз этеп җибәрә, күз ачып йомган арада каядыр китеп тә югала. Анын артыннан йөгерергә телим, аякларым тынламый, бер адым атлый алмый, тораташ катып басып торам. Ниндидер билгесез юл, дала, имеш. Шул чак каршымда әллә кайдан әни белән әти пәйда була. Әнинен өстендә кешелеккә кия торган яшел йон күлмәк, ә әти кыска жинле ап-ак күлмәктән. Әни үлгән иде бит, ул нишләп монда йөри икән, дип гажәпләнеп уйлыйм мин. Әти бик монсу гына миңа карап тора, бер сүз дәшми. Әни исә яныма ук килеп: «Кайт инде, кызым, өйгә кайт син,»—ди.

Шулчак уянып киттем. Йокым качты. Башны уй басты. Әни мина, кайт, диде. Юкка гына төшемә кермәгәндер ул, юкка гына кисәтмәгәндер. Кайтырга кирәктер.

Кайту...

Ничек булыр ул? Уйларым ерак юлга чыга. Иксез-чиксез галәмне колачлап, жир шарын инләп, менләгән чакрымнарны мизгел эчендә үтеп, Шатлыгыма килеп туктала. Туган йортка юнәлгәнче иң әүвәл юл буендагы зиратка керә, әнием кабере каршына тезләнә:

—Исәнме, әни, мин кайттым...

Авылда хәзер кыштыр инде. Урамнарны ап-ак кар күмеп киткәндер. Бәлки менә хәзер дә ишеп-ишеп кар явадыр, буран котырадыр. Моржалардан төтен чыгадыр... Безнен якларда кышлар бигрәк матур бит. Чү, мин дә сагынам түгелме соң? Сагынам икән шул... Һәм бу сагыш ташкыны күнелемә ап-ак карлар булып ишелеп төште.

Мин бит кышны, бураннарны яратам. Кар яуганда күккә төбәләм дә «оча башлыйм». Чынлап шулай, кар агымына озак карап торсаң, жирдән аерылып күккә күтәреләсең сыман тоела. Шундый хыялый, күнелле-рәхәт халәт.

Авыл кышлары тыныч, кичләре озын. Безнекеләр барысы да өйдәдер. Әбием аркасын жылы мичкә терәп оекбаш бәйлидер. Ә әти телевизордан яңалыклар карап утырадыр. Кифая... Ул да бар бит әле бездә... Аны әти янына утыртмыйбыз. Ул өстенә алама халат, иске бишмәт, аягына кәлүш киеп сыер саварга чыгып китсен.... Дилбәре дә шунда, әнисе янында буталсын. Ә малайлар... Илнар алдына китап-дәфтәрен куеп тыныч кына дәрес әзерләп утыра. Әлбәттә, шулай, ул бит акыллы, тырыш малай. Ә тегесе, мин күрмәгән-белмәгәне... Анысын нишләтик икән? Кифая баласы матур да, тәртипле дә булырга тиеш түгел. Ул, юньсез, мөгаен, тавышланып, бөтенесенә комачаулап йөридер....

Шулайдыр, ә мин күнелем белән урам капканы ачып, ишегалдына үтәм, ишеккә кагылам. Тик ачмыйм. Никтер ача алмыйм. Нәрсәдер тоткарлый. Никтер эчкә үтәсе килми. Һәм мин кире борылып чыгып китәм...

Әй, саташу бу, төш белән өн арасында саташып йөрү.

Бу Румиясе тагы... Төнгә каршы кеше куркытып, йокы качырып йөрмәсә соң. Ә мин, җүләр, авыртмаган башка таяк алып, ни дип тыңлап утырдым инде аны? Күп белсәң, тиз картаерсың, дигәннәре шулдыр инде ул.

Мине монда ни генә тота хәзер? Югалтырлык ни-нәрсәм бар? Төенчегенне җый да, яхшы чакта ычкын, Наргизә. Әни әйтте бит, өйгә кайт, диде. Димәк, кайтырга кирәк...

Майлысуны җирле халык баса. Аларга ни әйтәсең, үз илләре. Әлегә тыныч кына йөриләр дә... Әгәр алар да «Русские—в Рязань, татары—в Казань!» дип кычкыра башласа, сәнәк-чалгылар күтәреп урамга чыксалар?

Төне буе мине шундый ямьсез уйлар җәфалады. Төнен өметсезлек бәйрәм итә шул. Иртән торгач, уйларым яктырып китте, бөтен шик-шөбхәләр дә чүп кенә булып тоелды.

Кырым татарларын да, немецларны да, башкаларны да беркем кумады ләбаса. Барысы да үзләре теләп китте. Беркемгә кагылганнары, кимсеткәннәре юк. Майлысу халкы әлегә тыныч кына, матур гына яшәп ята... Бәлки юкка хафаланабыздыр, бу чуалыш-буталышлар вакытлыча гынадыр?

***

Мин аны ерактан ук танып алдым. Балалар белән уен мәйданчыгында йөри идек, урам яклап рәшәткәгә сыенган таныш сын күземә чалынды. Күзләрен кысып безнең тарафка төбәлеп карап торучы кеше Сиражетдин агай иде. Янына килеп исәнләштем тә:

—Әссәламегаләйкүм, Сиражетдин әкә! Хәлләрегез ничек? Ситарадан хәбәр бармы? Кайда ул, кем белән?—дип бер-бер артлы сорау яудыра башладым. Барысы хакында да беләсем килә иде.

Тик җавап бирүче булмады. Сиражетдин агай миңа сәерсенеп карап куйды да, бер сүз дәшми башын иеп китеп барды. Үзбәк картлары хатын-кыз белән сөйләшмый. Алайса, нигә килде икән соң ул бирегә? Ситараны юксынып мы? Әллә үтеп барышлый, болай гына күз салганмы?

Артыннан йөгерәсем, бабайны юатасым килде, тик бу файдасыз эш иде, барыбер сөйләшмәячәк.

Икенче көнне ул тагын килде, тагын шулай рәшәткәгә сыенып басып торды. Әллә акылы зәгыйфьләндеме икән? Мескен бабай, картлык көнендә япа-ялгызы калды. Җанын кая куярга белмичә, ялгызлыктан аптырап-тилмереп йөрүедер инде. Мин Сиражетдин агайга кызганып карап куйдым. Шулчак үз янына чакырып ул мина кул изәде.

Койма аша сөйләшү җайсыз булганга, урам ягына чыктым. Сиражетдин агай миңа ниндидер төргәк сузды. Бер сүз әйтмәде, сагышлы күзләре, ирен

чите белән көчәнеп елмайды да, минем янда озын-озак торкарланмый, аксый-туксый китеп тә барды. Кабаланып төргәкне ачтым, аннан берничә фоторәсем һәм алтын балдак килеп чыкты. Рәсемнәрнең барысында да Янгураз иде. Хатыны, кызы белән, үзе генә... Арада саргаеп беткән бик күптәнге сурәт тә бар, анда бәләкәй Янгураз әтисе белән бугай. Шул фоторәсемнәрне берничә көн кулдан төшермичә, истәлекләргә чумып, ямансулап йөрдем. Аннары: «Житәр, кызый, болай ярамый, йә тагы чиргә сабышырсың,»—дип барысын да ераккарак жыеп куйдым...

Ә бер атнадан Сиражетдин әкәнең үлеме хакында хәбәр житкерделәр. Сагышыннан китеп баргандыр инде бичара. Аның минем янга килүе, Янгуразга бәйле бөтен истәлекләрне кулыма тапшырып калдыруы бик сәер иде. Күрәсең, Янгураз белән очрашуыбыз хакында ул сизгән-белгәндер. Бәлки Янгураз үзе үк сөйләгәндер. Бердәнбер энекәшеннән калган бар ядкарьне тикмәгә генә миңа тапшырмас бит.

Ә алтын балдакны уң кулымның атсыз бармагына киеп тә куйдым. Белмим, кемнеке булды икән ул? Янгуразныкымы, Тамаранықы, әллә Сиражетдин әкәнекеме? Мөгаен, соңгысыдыр... Янгуразның балдагы юк иде сыман. Бәлки булгандыр да, минем янга килгәндә салып куйгандыр... Сиражетдин агай бу балдакны нигә миңа бирде икән? Әллә, Янгуразны онытма, аңа тугры бул, дип әйтергә теләдеме? Хәзер инде мин моны берничек тә белә алмыйм...

***

Румия сөйләгән ак сакаллы картның сүзе дөрескә чыкты: хәзер СССР дигән ил юк. Без хәзер чит ил кешеләре булып калдык. Кыргызстан аерым дәүләт булды. Хәзер инде Россиягә кайтулары жиңел булмас. Гел елмаеп торучы, күп итеп тәмләп сөйләргә яратучы Горбачевны да урыныннан алганнар икән. Борчылма, хөрмәтле президент, тәхетенә дә, үзенә дә тимибез, дәүләтеңне генә тартып алабыз, дигәнәр... Дәүләте булмагач, нинди тәхет, нинди патша булсын ди инде?! Башын иеп китеп барган тамгалы патшабыз. Менә шундый хәлләр...

Серле таулар, чүл-далалар, сусыз күл-дингезләр жирендә бөек күчеш чоры башланды. Инде урыслар да кузгалды... Ләкин йортларын сата алмый интегәләр икән, алучы юк ди. Кыргызларның башы түгәрәк, бик эре кыланалар: «Барыбер калдырып китәсез, сатып алганчы, бушка эләктерербез,»—дигәннәр, имеш.

Бөкресен торгызып төзегән йортын кемнең бушка калдырып китәсе килсен? Миңа юк икән, сиңа да булмасын дип, берәү кызган килеш куәтле бульдозер алып килгән дә, йортын жир белән тигезләп тә куйган. Бернәрсәсез чыгып киткәннәр Майлысудан. Алардан күреп, тагы берничә гаилә шулай иткән. Шуннан соң инде йортларны сатып алучылар да табыла башлаган...

—Китәргә кирәк... Безгә дә китәргә кирәк,—дип кабатлый Фатыйма апа.—Ичмасам, Ләбиб исән булса иде!

Әкрен генә жыенабыз... Тавык-куяннарны суеп ашап бетердек, мунча яккан саен өйдән кирәкмәс әйберләрне жыеп яндырабыз. Арзан бәягә булса да диван, кәнәфиләрне, телевизорны сатып жибәрдек. Әнәс паспортлар, документлар белән йөри. Анда кем ничек булдыра, шулай каера, бөтенесен майларга, акча төртергә кирәк ди. Чит илгә китәргә жыенабыз бит...

Румияләр дә китте, апасы янына, Кырымга. Алар йортында хәзер биш балалы кыргыз гаиләсе яши. Фатыйма апаларның йортын шуларның туганнары алмакчы була икән. Инде килеп карадылар, йортның эчен-тышын тикшерделәр, бәяләр дә килешенгән, бушатасы да китәсе генә.

Безнен бакчада элеккеләрдән Вера апа да, Динара гына калды бугай. Динараның ире кыргыз, теләсә дә, беркая китә алмый. Ә Вера, барыр жирем юк, үлсәм шунда гына үләм, ди. Майлысуда урыс, татар, үзбәк, кыргызлар гына калып бара бугай. Имеш, киләчәктә бакчада да, мәктәптә дә, эштә дә—һәркайда бары кыргызча гына сөйләшергә, укырга кирәк булачак. Таләп шундый: биредә яшәүче һәр кеше, нинди милләттән булуга карамастан, жирле халыкның телен, тарихын, мәдәниятын белергә тиеш! Белмисен икән, эшсез-урынсыз каласың. Замана шуңа бара. Без, татарлар, телләр охшаш булгач, әкрен генә сукалар идек анысы. Ә урысларның мәңге дә ни кыргызча, ни үзбәкчә өйрәнәсе-сөйләшәсе юк. Аларда тәккәбберлек баштан ашкан. Без—бөек милләт, дип саташып йөриләр.

Беркөнне бездә эшләүче кыргыз кызы Алтынай белән сөйләшеп кайттык.

—Китмәсеннәр иде урыслар. Татарлар да китмәсен иде. Аларны беркем кумый ич. Ник китәләр инде?—ди Алтынай.

Мин Клараның сүзләрен искә төшереп:

—Ватан дәшә!—дим.

—Син дә китәргә жыенасыңмы?

—Әйе.

—Кая?

—Үз Ватаныма—Татарстанга.

—Алдама, андый ил юк,—ди Алтынай.—Татарларның Ватаны—Монголия.

Аның сүзләреннән соң мин тетрәнеп китәм, барган жиремнән кинәт тукталып, ачу-үпкә белән Алтынайның күмер күзләренә төбәләм:

—Кем әйтте? Каян ишеттең бу әкиятне?

—Дәреслеккә шулай язылган ич. Монгол-татарлар урыс авылларын яндыралар, чиркәүләрне җимерәләр, кешеләрне суялар, дигән. Унөченче гасырда алар безнең жирләрне дә басып алган әле. Татарлар яман халык, варварлар, баскынчылар.

Минем чын-чынлап хәтерем кала, эчем-тышым ярсый, Алтынайның хаксыз сүзләренә карата йөрәгемдә дөрләп нәфрәт уты кабына: нишләп әле татарлар варвар булсын ди?! Әллә кайдагы монголларга безнең ни катнашыбыз бар? Ни сөйли бу Алтынай?! Тарих китабына чынлап та шулай язылган микәнни? Һич хәтерләмим. Шуңа күрә Алтынай белән бәхәсләшә дә алмыйм. Белмим мин тарихны. Мәктәптә җүнләп укытмадылар. Тарих, география, ботаника дәресләре бездә булмады да диярлек. Институт бетереп, шул фәннәрне укытырга дип жибәрелгән яшь кызларның кайсы кияүгә, кайсы декрет ялына, кайсы шәһәргә китеп бара да, бу дәресләр үзеннән-үзе хезмәт дәресенә әйләнеп куя иде. Көзләрен колхоз басуларында бәрәңге-чөгендер алабыз, язларын мәктәп бакчасында эшлибез, кышын кар көрибез. Инде бернинди дә эш булмаса, алар урынына башка фәннәр керә иде.

Училищеда тарихны укыттылар укытуын, тик анда инде мин үзем укып интекмәдем. Дилбегә буе шпаргалка ярдәмендә имтиһан тапшырып чыктым да, дәреслекләрне сөенә-сөенә китапханәгә илтеп тә аттым. Мине ул чакта үткәннәр түгел, киләчәк күбрәк кызыксындыра иде.

Алтынайның сүзләреннән соң күнелдә икеләнү туды: татарларның Ватаны чынлап та Монголия микәнни?! Юктыр ла, бер дә монголларга охшамаган ич без... Тарих китабын өр-яңадан укып чыгарга кирәк әле. Кеше үз халкының, иленең тарихын белергә тиеш! Әгәр надан булмасам, үз милләтемне яклап, Алтынай белән аяк терәп, бәхәсләшер идем. Наданлыгым аркасында телемне тешләргә туры килде. Ләкин сер бирәсе, кимсенеп каласы да килми:

—Безнең халык варвар түгел!—дим.

Әмма бу сүзләр генә аз иде, дәлилсез, көчсез иде. Бераз уйланып баргач, кыргыз кызы алдында мактанасым, горурланасым килеп:

—Беләсең килсә, безнең Муса Җәлил кебек батырларыбыз бар! Аны бөтен дөнья белә! Ул—герой-шагыйрь!—дип тә өстим.

Алтынай да җавапсыз калмый:

—Ә безнең Чыңгыз Айтматов бар! Аны да бөтен дөнья белә!

Шул мизгелдә үзем өчен мөһим бер ачыш ясыйм: илең, милләтең белән мактанасың, горурланасың килсә, иң беренче булып танылган, затлы шәхесләрнең исемен атыйсың икән. Хәтта аерым бер кеше дә үз милләтенең данын, абруен күтәрә ала! Их, шундый бөек шәхес була алсаң икән ул...

—Без кунакчыл, киң күнелле халык, беркемне дә кумыйбыз, беркемгә дә тимибез,—дип кабатлый Алтынай.

—Аркашаны үтерделәр бит әле,—дим мин.

Теге чакта автобуста ду килеп кыргыз-үзбәкне хурлап кайткан Аркадий безнең бакчада эшләүче Камилә-Клаваның ире булып чыкты бит. Өч көн элек менә шул бәндәнең үле гәүдәсен тапканнар.

—Аның үлемендә безнең ни катнашыбыз бар? Бәлки аны урыслар йә татарлар үтергәндер?

Алтынай хаклы, ул абзыйның үлеме сер булып калды. Аркадийның гәүдәсен Әндижан белән Ният арасында, юл буеннан табып алганнар. Нишләп йөргән ул анда? Әллә теленә салынып, теләсә ни лыгырдавыннан туеп, автобустан бәреп төшергәннәрме? Кем белә инде, кем тикшереп тора моны хәзер?

***

Китәләр, китәләр, китәләр...

Без дә китәбез...

Жизни белән хушлашырга дип бергәләп мөселман зиратына megdek. Биредәге зиратлар безнең яктагылардан аерыла, монда кабер өстенә агач-куак утырту гадәте юк. Бары язулы ташлар гына рәт-рәт тезелеп тора.

Жизнинең кабере әтисе-әнисенеке белән янәшә. Таштагы язуга карагач, исән чакта әйткән сүзләре искә төшә: «Яшәгән көннәрдән сызык кына кала...» Тагы бер илле-алтмыш елдан соң Ләбиб Хәбировнның тормышы да, үлеме дә беркемне дә кызыксындырмас. Тормыш мәгънәсе хакында баш ватулар каберлектә башланадыр да әле. Бу хакта тирән китеп уйлыйсы килми, ләкин ачы булса да мәңгелек хакыйкать шул: һәр кешенең гомере балчык-туфрак өеме һәм ташка уелган «кечтеки генә» сызык белән тәмамлана... Җирдә бары хәтер кала. Ул да мәңгелек түгел.

—Әллә бер уч булса да туфрак алыйкмы?—Фатыйма апа сораулы карашын Әнәскә төби.

—Ниемә кирәк? Аның белән нишлисең?—ди Әнәс.

—Шундый йола бар.

—Әтинең гомер буе яшәгән җире шунда, әби-бабай шунда... Ул туфрак белән нишләмәкче буласың, әни?

—Без монда башка килә алмабыздыр, улым. Инде беркайчан да... Ичмасам, фотога төшерәсе иде. Ни дисәң дә, бөтен гомер шунда үткән. Сагынганда карар идек.

Әнәс монсу гына җавап бирә:

—Мин төшердем, әни. Барысын да төшердем. Йортны да, каберләрне дә. Хәтта урамны да төшердем.

Фатыйма апа сөенеп Әнәснең аркасыннан кага:

—Рәхмәт, улым.—Аннары икебезгә дә карап:

—Сез кайта торыгыз, мин куып житәрмен,—ди.

Гомер иткән ире белән икәүдән-икәү калып сөйләшәсе, ана соңгы сүзләрен житкерәсе киләдер инде. Мәңгегә аерылышалар бит.

Әкрен генә чыгу юлына юнәләбез.

—Китәсеӊ килмидер, әйеме, Әнәс?—дим мин.

—Нишләргә соң?! Барыбер үзебезчә яшәтмәячәкләр. Китәсе килми дип кыргызга әйләнеп булмас инде. Балалар турында уйларга кирәк. Аларның үз илләре, үз Ватаннары булырга тиеш.

Анның бу сүзләре миңа бик сәер тоела. Әле өйләнмәгән дә Әнәс тумаган балалары турында кайгырта...

Кичен мин ялгызым гына Караташ ягына юнәләм. Бусы—кышлак каберлеге, чардугансыз, ташларсыз. Хәзер монда үле тынлык, әйтерсең, биредә беркайчан да тормыш әсәре булмаган. Жир астында күмелеп калганнарның исемен язып, туганнарына уртаклашу белдереп, берәр истәлек ташы куярга кирәк булгандыр бәлки? Тик бу хакта беркем дә уйламаган. Кышлак та юк, кешеләр дә... Хәтер дә юк...

Кышлакны ташкын күмеп киткәндә Янгураз белән Тамара кай тирәдә булды икән? Уртак каберләре кай тарафта?

Мин жиргә тезләнәм дә карашымны жиргә төбим:

—Хуш, Янгураз... Мин сине онытмам. Гомерем буе яратырмын, сагынырмын. Кичер мине, Янгураз, авыр минутларыңда яныңда була алмадым. Син өзелеп көткән газиз улыбызны саклый алмадым. Хуш, рәнжеп калма миңа.

Ул мине ишетми. Ул жир астында... Ясин да укылмаган килеш терелəй күмелгән изге жан. Анның рухына багышлап дога укучы булдымы икән? Сиражетдин агай укыгандыр, тик инде ул да юк. Ә мин бернинди дә дога белмим. Ни дияргә кирәк икән соң? Туфрагын җинел, җаның тыныч булсын, дияргәме? Җаны тыныч булмас инде анның, туфрагы да жиңел булалмас...

Ә таулар тыныч. Үзләренең яман эшләрен кылганнар да, берни булмагандай битараф карашларын күккә төбәп эре генә яталар. Мин бу тауларны беркайчан да сагынмам, мин аларга үпкәләп-рәнжеп китәм. Бу таулар сөеклемне, мәхәббәтемне, бәхетемне, киләчәгемне тартып алдылар...

—Хуш, Янгураз... Мин китәм.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Без Ор каласында аерылыштык. Фатыйма апаларны жизнинең туганнары каршы алды. Поездан төшкәндә мин дә әйберләрен ташышмакчы идем, Сабир абый якын да китермәде. «Борчылма, сеңел, кызларга авыр күтәрергә ярамый. Үзебез карарбыз, җайларбыз! Әнәс белән икебезгә ярты минутлык эш бу,»—дия-дия бик гайрәтләнеп берьюлы икешәр-өчәр төргәк күтәрде. Уртача буйлы, таза-нык бу абыйда жизнәй чалымнары шәйләнә иде. Тик ул, гәрчә аннан олырак булса да, яшьрәк күренә, гәүдәсе шәмдәй төз, йөзе шоп-шома, әби әйтмешли, картинкә кебек. Хатыны иркә, көяз затлардан булса кирәк, фырт киенгән, ясанган-төзәтенгән. Башын югары чөеп, иренен кысып, ханбикә сыман басып тора. Сабир абый Фатыйма апага якты чырай күрсәтеп: «Җиңги-җиңги,»—дип өзелеп торса да, моның авызыннан җылы сүз чыкмады. Кершән яккан йөзендә, сүнгән карашында аптырау-чарасызлык, хәсрәт—газаплар кичергән кешенекедәй мескен бер кыяфәт иде.

Кул бирешеп, кочаклашкандай итенеп күрешкәннән соң Фатыйма апа килендәшен минем белән таныштырды:

—Бу чибәркәй сенелемнең кызы Наргизә була инде.

Нәҗибә апа көчәнеп кенә елмая:

—Бик яхшы... Безнең Азатка әзер кәләш булыр.

Фатыйма апа яратып аркамнан кага:

—Наргизәдә кияү кайгысы түгел әле. Шулай бит, туганым? Үзләренә кайта ул. Әтисе, туганнары янына.

Нәҗибә апаның катып калган хәсрәтле йөзе язылып китә:

—Шулаймыни? И-и-и.. Кайтыр урыны булгач, бик яхшы инде.

—Әйе, яхшы... —дип мыгырданам мин.

Чынлыкта исә миңа ифрат ямансу. Бүген, менә шушы чит каланың җиде ятлар таптаган бусагасында иң якын кешеләрем белән аерылышам... Ә алда билгесезлек кенә көтә.

Хәл-халәтемне аңлап, Фатыйма апа артымнан ияреп кабат вагонга керә.

—Син безгә үпкәләмисеңме, туганым?

—Нигә үпкәлим ди, апа?

—Калырга кыстамаганга, чакырмаганга.

—Кая чакырмакчы буласың соң, апа... Үзегез дә кеше өстенә кайтасыз ләбаса.

—Шулай шул, туганым... Ни хәл итмәк кирәк. Алдагысын уйларга да куркам, ничекләр генә яшәп бетәрбез...—Фатыйма апаның күзләренә кабат яшь тула. Артык боек иде ул, карашында тормыш уты сүнгән, күңел канатлары салынган иде. Мин аны кочып алам. Бер-беребезгә сыенып байтак кына дәшми утырабыз.

Майлысуда чакта ук кай тарафларга барып урнашу турында сүз күп булган иде. Әнәс белән бу хакта байтак бәхәсләштеләр. Фатыйма апаның күңеле үзенең туган авылы Юкәлегә тартты. Анда чыбык очы булса да туган-тумача бар, сыйдырырлар, ярдәм итәрләр, дип өметләнде. Әмма шәһәр һавасы сулап, «асфальтта тәгәрәп» үскән Әнәснең авылга кайтырга исәбе юк иде. «Нишлим мин анда?»—дип аяк терәп каршы торды. Ахыр чиге Ләбиб абыйның энесе белән киңәш-табыш итеп, Ор шәһәренә кайтасы иттеләр. Ә Рамиләләр әлегә кузгалмаска карар кылып, яхшы заманнарга өметләнеп, Ташкентта яшәп калды. Фатыйма апа: «Бергә китик,»—дип аларны күпме үгетләсә дә, күндерә алмады. Кызыннан, оныкларыннан аерылу аның өчен зур тетрәнү, фаҗига иде. Бергә яшәмәсәләр дә, Ташкент кул сузымында гына, теләгән чакта бар да кайт, телефоннан да көн саен сөйләшеп, хәл белешеп була. Ә хәзер ике араны чакрымнар гына түгел, чикләр бүләчәк. Рамиләләр безне озатырга килде, аерылышу кыен булды. Фатыйма апаның йөзенә еламый карарлык түгел, күзләреннән генә түгел, суырылып, саргаеп киткән йөзеннән дә яшь тамар төсле, бу җан гүя тоташ сагыштан тора иде. Соңгы көннәрдә генә түгел, хәтта соңгы айларда да мин аның йөзендә шатлык та, елмаю да күрмәдем. Картлык көнендә гомер иткән оянны ташлап, газизләреннән аерылып, җиде-ят җирләргә чыгып кит әле. Тормышны юктан башлыйсы, өр-яңадан оя корасы...

—Поезд кузгалмасын тагын, төшим мин,—ди Фатыйма апа моңсу гына.—Хәбәрләшеп торыйк, сеңлем, яме. Мин сиңа үзем хат язармын.

Аның калтыранган салкын кулларын кысып:

—Ярар,—дим.

Аннары мине Әнәс килеп кочаклый. Ул да хушлашырга дип менгән икән. Колагыма шыпырт кына:

—Үпкәләп китмә, сестренка. Минем тилелекләрне кичер, кайчакта бик яман булдым,—дип пышылдый.

...Поезд кузгалып китә. Ор вокзалы перрорында төргәк-төргәк чемодан-

сумкалар арасында, аптыраулы-уйлы, сагыш-хәсрәт тулы карашларын китеп баручы поездга төбәп, кадерле туганнарым басып кала. Кыргызстаннан кайтучы качаклар... Аларны хәзер шулай дип йөртәчәкләр. Кайларга гына барып сыенырлар икән илсез-йортсыз калган ул качаклар? Качаклар... Бигрәк котсыз сүз.

Вагонда безнең ише «куылган-сөрелгән» качаклар гына түгел, зур-зур букча-капчыклар аскан кара халык та бар. Болар—Россиягә әйбер сатырга баручылар. Рубль Азия илләрендә бик кыйммәттән йөри, хәзер инде ул валюта булып санала. Кайчандыр Россиядән озатылып, Ташкент, Сәмарканд, Әндижан базарларында еллар буе эссе кояш астында тузан җыеп, көя күбәләге ризыгы булып яткан әйберләр дә безнең кебек поездларга-самолетларга төялеп кабат үз ватаннарына кайта...

Минем янда урын бушагач, каршыма чем кара күзле, шикалат йөзле бер егет килеп утырды. Аның әрсез-комсыз карашы Ташкенттан бирле мине ашап-ялап бара иде инде, тик әлегәчә яныма килергә җөрьәт итмәде, Әнәстән шикләнде бугай. Инде ялгызым калганны белгәч, кыюланды бу, каршыма ук килеп утырды. Ут күзләрен туп-туры төбәп:

—Кайерга боробсан, гузал? Узокками?—дип сорады.

Мин аңламаганга салышып дәшмәдем.

—Сиз узи узбекми, асалим? Узбекча тушунасинми?

—...

Сөйләшергә теләгем юклыгын аңлагач китеп барыр дип өметләнгән идем, кая ул, кымшанмый да! Очкынлы күмер күзләре белән бораулап утыруын белә. Алай булмаса—болай дигәндәй, урысчага күчте:

—Крассависса куда йидит?

Бу әрсез, бәйләнчек юлдаштан тел яшереп кенә котылып булмасын чамалап дәшәсе иттем:

—Мәскәүгә.

-У-у-у, Мәскәүгә?!—дип баш чайкады ул.—Ерак!

—Ерак шул.

—Атың ничек синен?

—Айсара.

—Ирең нигә ташлап китте, Айсара?

Әнәсне ирем дип уйлагандыр инде.

—Ул минем абыем иде.

—Ә ирең кайда?—Егет балдагыма ишарәләде.

—Ул Куйбышевта каршылый.

—Андый шәһәр юк. Хәзер аны Самара диләр.

Мин гаҗәпләндем:

—Шулаймыни?

—Ирең Самарада каршылый, ә үзең Мәскәүгә барам дисен,—диде кара егет.

—Мәскәүгә шуннан бергә китәчәкбез.

Мин аптыраганнан гына сөйләшеп утырам. Югыйсә беркемне дә күрәсем килми. Җаным өши, туганнар белән аерылышканнан соң әйтеп бетергесез ямансу. Сүзләремнең рәте-чираты юк, белмим, бу адәм миннән ни генә өметләнәдер.

—Айсара, әйдә мин синең янга күчеп утырам! Бергә күнеллерәк булыр.

Шул гына җитмәгән иде!

—Миңа болай да күңелсез түгел.

Шактый тупас җавап бирсәм дә, егет бәйләнүдән туктамады:

—Миндә сиңа таман гына ситсы халатлар бар, аласынмы? Сөлгеләр бар,

эчке күлмәкләр, ыштаннар... Алып җибәр, асалим.

Бар икән! Әрсез тигәнәк булды чисти. Күлмәк-ыштан кайгысы ди миндә...

—Кирәкми, акчам юк.

Егет тагын бераз лыгырдап утырды да, ниһаять, үз урынына китеп барды. Миннән өметле сүз булмасын аңлап, кул селтәде, ахры. Бу майлы күзгә юлны тизрәк, вакытны күңеллерәк үткәрү өчен үзе сыманрак бер җилбәзәк юлдаш кирәк иде бугай.

Юлда ялгыз йөрүләре куркыныч икән шул хәзер. Үткән төндә генә бер хатынның сумкасын урлаганнар. Вагон буйлап елап чапты мескен, бөтен документларым, акчаларым шунда иде, ди. Ана беркем ярдәм итә алмады. Каракның бүреге яна дисәләр дә, ул үзен эләктергәннәрен көтеп утырмаган, бүреге-ние белән чыгып шылган. Монда самолет түгел шул, поездда пассажирлар үтәли йөрүче җил кебек, керә тора-чыга тора. Кем кемне күзләп, тикшереп бетерсен? Әле берничә мәртәбә поездыбызга һөҗүм дә булды, төнлә тәрәзәләргә таш аттылар. Бала-чага кызык эзләп шулай кыланамы, әллә өлкәннәр уенымы бу, билгесез. Поездны туктатып кем хулиган эзләп йөрсен ди?! Ташларның берсе безнең вагон тәрәзәсен ваткан иде, аны одеял белән каплап куйдылар.

Менә шундый заман.

Юллар тыныч түгел... Еллар да тыныч түгел.

***

Автобус магнитофоныннан үзәкләрне өзәрлек моң агыла:

—Үз ягыма кайтсам, җиргә ятып,
Тыңлар идем үлән үскәнен,
Тыңлар идем чалгы тавышларын,
Кичке жылы җилләр искәнен...

Әйтерсең лә, минем кайтуымны белеп махсус җырлыйлар.

Кем язган икән бу җырны? Чит җирләрдә тилмереп йөреп, туган ягын өзелеп сагынган бер бичара җандыр инде. Нишләп элек ишеткәнем булмады икән? Әллә ишетеп тә тыңламаганмынмы? Әллә бу яңа җырмы?

Үз ягыма кайтсам, яланаяк
Эзләр идем тәүге юлымны...

Язып та куйган, әй... Күңеленә ишелеп төшкән сагыш болытларын берьюлы күтәрә алмый, барган җиреннән җиргә сузылып ятып, тәгәри-тәгәри еларсың, валлаһи!...

Чү, Наргизә, син сөйлисеңме моны? Синме ул туган ягын сагынып кайтучы нечкә күңелле, хисле зат?

Мин ул, мин... Күрмисезмени, күзләрем дымлы. Ә йөрәгемнән-бәгыремнән тамган яшьләрне беркем күрмәс, беркем күрмәс... Кеше күрсен, тамаша кылсын өчен түгел алар. Үз хәлемне үзем генә беләм, үзем генә аңлыйм... Чит җирләрдә ни югалттың, Наргизә? Ничә еллар буе нигә каңгырып йөрдең син анда, ни эзләдең, ни таптың?

Әгәр автобус тулы халык булмаса, сулкылдый-сулкылдый рәхәтләнеп елар идем. Үз ягымның җылы, йомшак туфрагына йөзем белән капланып, чүп үләннәрен үбә-үбә, елар идем! Ник болай әкрен бара соң бу автобус?!

Ниһаять! Ниһаять, безнең тукталышка да килеп җиттек. Автобустан төшеп, балачактан ук таныш юл чатында ялгызым басып калдым. Безнең

авылга илтүче таш юл озын тасма булып офыктагы ак болытларга барып тоташа. Юлның ике ягында да ямь-яшел иген дингезе чайкала. Күптән түгел яңгыр явып узган ахры, жир дымлы. Дымлы, ләкин шундый жылы. Һәм ул жирдән, ни гажәп, бал исе килә!

—Исәнме, Ватаным!

Мин туфлиләремне салып кулыма тотам да, басу кырындагы такыр юл буйлап авылга таба атлыйм. Аякларыма жир жылысы ягыла, йөземне, чәчләремне йомшак жил иркәли. Ул жил иген исләре, баллы чәчәкләр, дымлы чирәм исләрен алып килә. Гүя өр-янадан яланаяклы балачагыма, кояшлы, ваемсыз балачагыма кайтып төшәм.

—Исәнме, Ватаным!

Бу иксез-чиксез кыр-басулар минеке, бу аяз күк, якты, нурлы кояш минеке, алтын нурларга манылган офык та, шул офыкларга тоташкан яшел болыннар, зәңгәр таулар да минеке, бу жылы, дымлы туфрак та, юл буенда үскән ялгыз каен да минеке! Бу—минем Ватаным! Моннан мине беркем дә, беркайчан да кумаячак, беркемнең дә миңа «килмешәк» дияргә хакы юк. Мин хәзер беләм: һәр адәм баласының Ватаны кендек каны тамган туфрактан, тәүге тапкыр аяк баскан сукмактан, тәүге тапкыр учларына алып эчкән чишмә суыннан башлана.

Ашкына-ашкына авылыма кайтам. Туган авылыма, балачагым, яшьлегем иленә кайтам. Күңелемә тулган хисләрем күзләремнән шатлык яшьләре булып тама. Иңнәремдә гүя очар канатлар талпына. Мин шулай сагындым микәнни? Мин дә шулай сагына алдыммы?!

Алда мине күпме көрешүләр көтә. Күпме гаепләүләр, аңлашулар...

Ләкин барыбер йөрәгемә кунып бәхет кошы сайрый:

Үз ягыма, үз илемә кайттым!

—Исәнме, Ватаным!

*Дәвамы киләсе санда*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма жибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәжбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

*Язучы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, «Казан утлары»ның элгәре булган «Атака» журналының (1930-32) баш мөхәррире Гомәр Галинең тууына 110 ел тулу уңаеннан*



*Гомәр Гали. 1937 ел.*



*Әдип үзенең гаиләсе (хатыны Хәдичә, кызлары Алсу һәм Гүзәлия) белән. 1937 ел.*



*Гадел Кутуй (сулда), Гомәр Гали, Һ. Такташ. 1930 ел.*



*Галимҗан Ибраһимов белән. 1932 ел.*



*Сөргендә. 1952 ел.*




*Казан шәһәрендә Гомәр Галигә куелган истәлек тактасы.*



*Бертөркем язучылар әдипкә мемориаль такта кую тантанасында. 2006 ел.*



Эльвира
Һадиева

## Минем йола

Җанны тышау белән берәү басса,
Сиңа качам—
Һәм бу минем йола.

Сулыш саен барлыгыңны тоям—
Рәхәт шулай,
Шулай очып була...

Кемдер кача-поса гайбәт сатсын,
Ә бит синдә—
Мин үпмәгән ирен.

Каеннарда безнең төсме—саргылт?
Никтер килми
Кайтарасы кире...

Никтер йөрәк яңа җәйләр көтә,
Яшел түгел,
Быел төсе—бишни.

Яңа җәйгә яңа хыял белән:
Хәерлегә!—
Йолаларым төсле!

## Һичкайчан

Бу язым—тәүгесе иң серле язларның,
Иң кайнар яшьләрнең тәүгесе...
Кочасы таңнарың, иңлисе бик килә,
Кулымда—йолдызлар дисбесе.

Эльвира ҺАДИЕВА—*яшь шагыйрә; КДУ студенты, шигырьләре вакытлы матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

Сагышлар эзләмә керфегем астында,
Яман хис үткәннән калалмый...
Йөрәктә—үзгәлек,
Һичкайчан Сөюдән
Каргышлар, үкенү яралмый...

Һичкайчан... Акыллым, йә инде, моңайма,
Яз көлә, күзләрдән үпкәләп...
Кирәкми салкының, уен да кирәкми
Үткәнне яңадан сүткәләп...

Кояштан соң сиңа да кайнарлык йоктымы:
Сүзеңә чуалган наз исе...
Ә миндә язларның башкарак кайтышы,
Иң ярсу язларның тәүгесе!

***

Канга сеңгән сәер бер хис, бер сиземләү
Сирәк кенә җанга салкын өреп ала:
Тагы йолдыз сүнә бүген, күкләр тагы
Бер йолдызга караңгырак булып кала...

Һәм кемнәрдер диңгез буйлап, җилгә каршы,
Адашачак үз йолдызын табалмастан...
Бер яктыга күпме язмыш язган Тәнре.
Тик язмаган яну гына яңабаштан...

Канга сеңгән сәер бер хис, бер сиземләү—
Әнә анда безнен йолдыз җемелдәшә...
Йөрәк кенә белми, югарыда чын яктымы,
Әллә бары... төнге рәшә...

***

Безсез йортлар, ярымтере күлләр аша,
Проспектларны, мең урамны урап-урап,
Синең күзләр мине эзли. Ә мин никтер
Җир читендә онытылып басып торам.

Монда төн һәм август исе катыш яшьлек—
Саташмаска жанның көче җитсен генә:
Рәхәт шундый. Бары синең бүлмәдәге
Каударланган сәгать җыры читсендерә.

Туктат аны—тынычлансын һәм дәшмәсен:
Мәңгелекнең үз вакыты, үз дәвасы...
Син—аймыл бит. Хәзер безне көткәннәрнең
Шәмнән якты тәрәзләрен без кагасы.

Без сүтәсе—хискә мөнбәр хыялларны,
Җанга изге чатырларны—без сүтәсе...
Ә син һаман, үзсүзләнеп, Кояш түгел,
Яңа таңнан мөлдерәмә наз көтәсең...



Гөлзадә Бәйрәмова

# СИН ҺАМАН ШУЛ САНДУГАЧ

КЫСКА БӘЯН

—Сәвия апа, Дулкыния суга батты!

Төшке ашны әзерләп йөргән Сәвия кулындагы пычагын куярга да онытып күрше кызы Ләйсәнгә ияреп елга буена чапты. Кызчыкны инде яр буена чыгарып салганнар, тирә-яктан кешеләр сырып алган. Пычак тотып йөгереп килүче ананы күргәч, кемдер читкә китү ягын карады, кемдер исә, баланы сакларга теләпме, Сәвиянең юлына аркылы басты:

—Сәвия апа, борчылмагыз, Дулкыния исән...

Алай да, үпкәсе ялкынсынып калмасын дип, район хастаханәсенә алып барырга уйладылар.

—Балаларны гел кисәтеп, күзәтеп торырга кирәк,—дип күпме әйтәбез югыйсә,—диде доктор, Сәвияне шелтәләгән сымак итеп, тикшерү үткәреп бетергәннән соң.

—Ә без су кермәдек,—диде Дулкыния, әнисен якларга теләп, курка-курка гына булса да.

—Су кермәгәч, ничек суга баттың соң син?—доктор көлемсерәп баланы алдына алды.

—Тәкыя узыштырдык...

—Тәкыя узыштырдык? Ә ул ничек була?

—Ләйсәннең апалары кинодан күргәннәр, Ләйсән аларның сөйләшкәнен тыңлап торган, кемнең тәкыясы беренче булып агып китә, шул кияүгә беренче чыга икән.

Сигез-тугыз яшьлек баланың кияү турында сөйләшүе олылар йөзендә елмаю уятты.

—Ну, кемнеке беренче агып китте инде?

—Ләйсәннеке беренче китте, минеке яр буендагы талга эләгеп калды... Таяк белән этеп җибәрмәкче идем, аягым таеп суга егылып төштем...

---

*Гөлзадә БӘЙРӘМОВА—шагыйрә; «Әле кайчан гына...» исемле китап авторы. Проза әсәрләре дә яза. «Татнефть»нең С. Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

—И, кызым, ул бит насыйп эше,—Сәвия кызы өчен доктор каршында бераз читенсенеп куйды.

—Башка мондый тәҗрибәләр ясама, алайса бөтенләй дә кияү күрми калуың бар,—дип доктор сабыйны чын күңелдән яратып, сөеп озатып калды.

—Әни, ә нәрсә ул насыйп?—Дулкыния пышылдап кына әнисенә дәште.

—Насыйп ул, кызым, Ходай Тәгалә сиңа кемне бирә, миңа мина әтиеңне, әтиеңә исә мине насыйп иткән. Кемнәрнедер парлы, кемнәрнедер ялгыз да итеп яраткан. Адәм баласының ана карынында вакытта ук өч әйбере язылып куелыр ди. Җыясы ризыгы, кем белән никахланасы, яшисе гомере...

Кыз әнисе сөйләгәннәрне тыңлап бетерә алмады, автобусның тибрәтүеннән, көн буена булган хәлләрдән арып йокыга талды.

* * *

Бу вакыйга турында инде онытып та бетергәннәр иде. Дулкыния шәһәргә укырга китеп, икенче курста укыганда кияүгә чыгарга уйлавы турында кайтып әйткәч: «Кара, чынлап та шулай булды, Ләйсән беренче чыкты бит,»—дип көлешеп тә алдылар.

...Аспирантураны әле яңа гына тәмамлап институтта укыта башлаган Әнвәргә күпләр гашыйк иде. Күрер күзгә әллә ни матур булмаса да, хатын-кызны үзенә тарта торган ниндидер көч бар иде егеттә. Күбесе кызлардан гына торган Дулкынияләр группасында Әнвәр бигрәк тә дәрәҗәле, үзен һавалы тота иде. Кызлар исә лекция беткәч тә юк-бар сорау биргән булып укытучыларын сырып алырлар. Дулкыниягә исә төркемдәш кызларының бу кыланмышлары ошамый гына түгел, укытучы белән студент арасында ниндидер якынлык булырга мөмкинлеген ул башына да сыйдыра алмый иде. Лекция тәмамлануга китап-дәфтәрләрен җыеп тизрәк чыгып китү ягын карар, имтиханнарга тиешенчә әзерләнеп килер иде. Әмма Әнвәргә кайбер студенткаларның әрсезлеге бер төрле охшаса, Дулкыниянең тыйнаклыгы икенче төрлерәк тәэсир итте.

—Сезгә минем фәнем ошамый мәллә?—диде беркөнне коридорда Әнвәр, лекциягә ашыгучы кызны туктатып.

—Ошый,—диде кыз, каушый төшеп.

—Алайса, нигә башкалардагы кебек кызыксыну юк?

Дулкыния беркавым ни әйтергә белмичәрәк торды.

—Сез минем өчен беренче чиратта Әнвәр Рәшитович...

Ошады егеткә кызның җавабы. Төгәл, кыска һәм оста иде җавап. Әнвәр үз хатынының аңа табынып, буйсынып, олылап яши белә торган хатын булуын теләгән иде.

* * *

Бердәнбер кызлары булган Дулкыниянең имтиханнарын биреп бетереп ялга кайтуын әти-әниләре зарыгып көтеп торалар. Олы уллары Самат армиядә хезмәт иткәндә үк марҗага өйләнеп калгач, бөтен өметләре кызларында, аның бәхетле булып, картлык көннәрендә үзләренә дә терәк булырында иде.

—Киткәндә ике сүзне дә кушып урысча сөйләшә белми торган малай ничек итеп марҗага өйләнә алды икән, атасы?—дигән иде Сәвия кулындагы хатка карап, аптырап.

—Өйрәткәннәрдер! Ир-атны армия белән хатын өйрәтә ул,—диде Мәгъсум ачу белән,—авылның иң пүчтәк кызына өйләнсә дә бу кадәр гарьләнмәс идем.

Абыйсы белән дә шулай килеп чыккач, Дулкыния әти-әнисен бик борчымаска, хәл кадәри булышырга тырышып үсте. Быелгы каникулга исә кыз сонарып кайтты... Имтиханнарга ул бик алдан керергә дә, артка калырга да яратмый. Беренчеләрдән булып керсән, сорауны күп бирәләр, артка калсаң, надан булып күренәсен—урталыкта булу кызнын холыкфигыленә хас сыйфат.

Билет алып, сорауларны бераз караштырып утырганнан сон, Дулкыния җавап бирергә Әнвәр каршысына килеп утырды. Сораулар әллә ни катлаулы түгел, артык бәйләнмәсә, «5»легә үк булмаса да, «4»легә бирәсен кыз чамалый иде.

—Яхшы,—диде Әнвәр, кызнын җавабын тынлап бетергәннән сон,—сезгә тагын бер өстәмә сорау,—ул алдындагы кәгазь кисәгенә нидер язып кызга таба шудырды.—Җавапны бер генә сүз белән дә әйтә аласыз, язмача да мөмкин.

Кәгазьдә исә: «Бүген кичке сәгать 7 дә Тукай һәйкәле янында көтәм. Ризамы?»—дип язылган иде.

—Сорауны кабатлыйм...

Укытучысы хәзер кәгазьдә язылганны бөтенесе каршында әйтеп сала дип Дулкыниянең коты очты.

—Әйе,—диде ул пышылдап кына.

* * *

Яшьтәшләренең күбесе беренче мәхәббәт утында мәктәптә укыганда ук янып-көеп алсалар да, Дулкыния үзенең тәүге мәхәббәтен институтта, укытучысына булыр дип һич уйламаган иде. Хәер, уйлап эшли торган эш булса мәхәббәт тә булмый бит инде ул!

Әнвәр тулай торакка килеп, студентларга күренеп йөрергә теләмәгәнлектән, очрашулар беренче көнге җирдә билгеләнер иде. Бергәләп су коенырга йөрүләр, кичке бакчада утырулар бер-берсенә көннән-көн ныграк якынайта, җәйге каникулга—икең ике якка китәсе килмәү теләген көчәйтә иде. Шәһәр белән авыл арасы әллә ни ерак түгел, тагын ике-өч көн кайтмаса, әтисенең борчылып, эзләп киләсен кыз, һәрхәлдә, белә иде.

* * *

—Әле ярый кайттын, кызым, кура җиләкләре коелып бетә инде, карлыганнар да өлгерә,—дип каршы алды Сәвия кызын.—Быел печәннен эше тиз бетте, күршеләргә кунаклар да кайткан иде, алар да керде, көннәр дә әйбәт торды...

Бераз хәл-әхвәл алышып, ашап-эчкәч тә Дулкыния бакчага чыкты. Куралык бәрәңге бакчасынын аргы башындарак, ерак та түгел бәләкәй генә инеш тә ага. Бакчаларынын әлеге тын почмагын ярата кыз. Җиләкләр чынлап та нык өлгергән, кагылуга ук өзелеп төшәргә торалар. «Җиләк кебек чагы,» дип кыз баланың шундый чагын әйтәләрдер инде»,—дип уйлап куйды. Кулы җиләк өзсә дә, башында бер генә уй: «Әнвәр кайда икән хәзер? Ул да: «Ялга китәм, укулар башлангач кына очрашырбыз»,—дигән иде. Хат язышырга да сөйләшмәделәр. Яшьтәш егет түгел, ни әйтәсең килсә шуны әйтеп булмый шул...

Кинәт янәшәсендә генә ниндидер кошчык ярсып-ярсып, әйе-әйе, нәкъ менә чын мәгънәсендә ярсып сайрый башлады. Дулкыния кулы белән кура агачларын аралап кошчыкны эзләде. Сандугач! Бу бит сандугач! Кошчык анын янәшәсендә генә бер ботактан икенчесенә күчеп бәргәләнә иде. Юк, бу сайрау түгел, кошчыкнын хәвефләнүе иде. Шундаен дә бәләкәй җан иясендә нидән бу кадәр зур курку, ярсу, хәвефләнү? Дулкыниянен күзе яшел яфраклар

арасында үрелгән сандугач оясына төште. Менә ни өчен хәвефләнә икән бичара кошчык. Хәтеренә әтисенен апасы Хәмисәттәйнен шулай урманга жиләккә баргач сандугач турында сөйләгән бер риваяте килде.

—Сандугачнын үзен дә—оясын исә бигрәк тә—күпләр үз гомерләрендә бер мәртәбә дә күргәне юк. Сандугач кунып сайраган ботак белән күзен төшеп йөргән кешеннең аркасыннан бер мәртәбә генә сыйпап алсан да, ул—мәнгегә синеке!

Дулкыния белән Ләйсән ышанмыйча көлделәр, «әкият, бөтен кеше сөйгәнен үзенә шулай каратыр иде»,—диделәр. Карчык та бирешмәде, хикмәте дә менә шунда шул, алар бит сандугач кунып сайраган ботакны таба алмыйлар. Әле башыгызга гыйшык хәлләре төшмәгән, төшсәме...—дигән иде кызларны ирештереп...

...Сандугач бер ботактан икенчесенә шулкадәр тиз күчеп өлгерә, Дулкыния абайламыйча да кала. Менә монысы, юк, юк монысы. Кызнын кабаланудан күз аллары әлже-мөлже килде. Кинәт кенә, әллә кайдан гына жил исә башлады. Тукта, исмә, жил! Өзмә кыз баланың өметен!..

* * *

...Теге вакытта Хәмисәттәй әйткән сүзләрнең мәгънәсен менә хәзер генә анлады Дулкыния. Сагыну катыш көнләшүдән аккан күз яшьләре белән жәйге каникулын чак-чак үткәрде. «Сонга калып килсәң әйбәт бүлмәләрне алып бетерәләр, урын да ишек төбеннән кала»—дип, юк сәбәпләрне бар итеп тәки каникулы тәмамланганчы китү бәхетенә ирешге.

—Санаулы көн тиз үтә шул, кайтуын кая да, китүен кая,—дип кызынын сумкасына кучтәнәчләрен тутыра-тутыра Сәвия үзалдына сөйләнеп куйды. Күрмимени ана кеше, сизмимени, китәсе булгач, кызнын кәефе бердәй күтәрелде.—Күңелләрең калада, балакаем, хәерлегә булсын...

—Әни!

Сулышына кабып өйгә атылып килеп кергән кызынын тавышыннан Сәвия сискәнеп куйды.

—Кая минем сумка?

—Әнә ич, кызым, ишек төбендә тора. Бөтен әйберләрен әзер.

—Сон, ул бит чәчәкле, ә минеке яшел төстә иде...

Эшнең асылын анлап алган Сәвия көлеп жибәрде:

— Ә-ә, аны әйтәсен икән... Кура жиләге кайнатмасын зуррак банкага салган идем, әйберләрен ул сумкага сыймагач, икенчесенә күчердем.

Дулкыния минут эчендә әйберләрен идәнгә таратып ташлады. Анын өчен иң кирәкле, иң кадерлесе урынында иде.

* * *

Институтка Дулкыния, мөгаен, иң беренчеләрдән булып килгәндер. Бүлмәдәш кызлары быел яна кызлар булганлыктан, кичке сөйләшеп ятулар әллә ни озакка сузылмады. Килеп керү белән расписаниеләр эленеп торган такта янына ашыкты. Бөтен уе, теләге Әнвәр Рәшитовичнын дәресе кайчан—шуны белү. «Беренче дәрес аныкы гына булса ярар иде!» Эзләгәнен тиз тапты. Биология! Менә ул! Йә, Аллам! Тик ни бу?! Биологиясен-биология, тик укытучынын фамилиясе башка иде. Ул бармаклары белән сызыкларны кисештерә-кисештерә кат-кат укыды, студентлар күпләп жыела башлагач кына игъланнар тактасы яныннан китте.

Кинәт анын уенда: «Ә бәлки бүген генә башка укытучыдыр?»—дигән шатлыклы бер уй чагылып үтте, аудиториягә ашыкты. Группадашлары белән исәнләшүе дә салкын гына булды, анын бу гамәленә кайберләре үпкәләгән сымак та итте. Дулкыния күзен ишектән алмады.

—Быел биологияне сездә мин укытачакмын, минем исемем... Яңа укытучының ишектән керә-керешли үк башлаган сүзен Дулкыния әллә ишетте, әллә юк, аның үз кайгысы кайгы иде, биология фәне әллә бар—әллә юк, аңа хәзер барыбер иде...

Калган дәресләрдә Дулкыния утырса да утырды, утырмаса да утырды. Тәнәфестә коридорларга чыгып йөрсә дә, сагынып көткән кешесен очрата алмады.

—Өйләнгәндер, хатыны яшь кызлар янына җибәрмәгәндер,—дип группадаш кызларының гайбәт сатуын ишеткәч, елап җибәрүдән чак тыелып калды.

Әнвәр Рәшитович икенче көнне дә күренмәде, өченче көнне дә... Озакламый Дулкыния укытучыларының башка эшкә күчкәнлеген, аларны инде укытмаячагын белде.

Институтка баруның кызыгы бетте. Төне буе елап яту үзенекен итте, ул бүген укырга бармады. И ул яратудан туган күз яшьләре! Әгәр дә һәрбер гашыйк җанның сагынудан түккән күз яшен бергә җыйсаң, зур бер диңгез хасыйл булыр иде. Юк, диңгез генә дә түгел, океан!

Кечке яктарак каты итеп ишек шакыганга кыз сикереп торды. Ул! Үзенең нинди кыяфәттә икәнлеген дә онытып ишеккә ташланды, тышкы якта бер малай басып тора иде.

—Кем монда Давыдова? Мәгез, записка!

Малайга Давыдованың кем булса да барыбер икәнлеге күренеп тора. Язуны Дулкыниянең кулына төртте дә, «тапшырдыммы—тапшырдым,» дигәндәй юкка да чыкты. Кәгазь кисәгендә исә: «Бүген кич шул ук урында, шул ук вакытта көтәм,»—дигән сүзләр иде. Дулкыния тиз генә сәгатькә күз салды. Йә, Ходам, әллә ни күп вакыт калмаган, әле төзәтенәсе, рәткә керәсе, барып җитәсе... Өлгермәсәм, китеп барса?!.

Урамга чыккач кына, ул, кура куагының онытылып калганын белеп, кире тулай торакка торып чапты. Үч иткәндәй, лифт урта катта туктап калган, кыз сигезенче катка ничек менеп җитеп, кай арада төшкәнен белеп тә җиткерә алмады. Урамга чыккач та трамвайны көтеп тора алмаслыгын чамалап, очрашу урынына йөгерде.

Әнвәр инде килгән, кулына чыбык тотып йөгерүче кызны күргәч, көлеп җибәрде.

—Әллә бу кызый мине чыбык белән чәбәкләмәкче була инде?—диде ул, Дулкынияне килгән шәпкә күтәреп, кочагына алып.

Инде тын ала алмас хәлгә җиткән, ашыгып-кабаланып тәмам хәлдән тайган кыз кулындагы ботакны шунда гына шәйләп алды.

—Ә бумы, бу ни... сандугач,—диде ул каушый төшеп.

—Син үзең сандугач,—диде егет, яратып, иркәләп,—сандугачым син минем, былбылым...

Кипкән яфраклар егетнең чәченә коелды, сандугач кунып сайраган кура куагы тоткан нәфис-йомшак куллар иңнәреннән сыйпады...

* * *

Икенче уку елы тәмамланып, имтиханнар тапшырылып беткәч, Әнвәр кызга тәкъдим ясады.

—Хатыным бул!—диде ул Дулкыниянең күзенә карап.

—Ә уку?—диде кыз, сөенүле дә, аптыраулы да сорау катыш җавап белән.

—Соң хәзер укытучың өеңдә була бит инде, сиңа институтка барып йөрү нигә кирәк?—дигән булды егет шаяртып.

—Әниләр укып бетермәгән килеш риза булмаслар,—диде кыз уйга калып.

—Алайса, без болай итик,—диде егет, ниндидер бер нәтиҗәгә килеп,—бу атнада без икебез дә әти-әниләр янына кайтып, ул турыда сөйләшик, киләсе атнада исә мин үземнекеләр белән сезгә кайтырбыз. Ризалыкларын алырбыз да, җәйне бездә уздырып, туйны исә көзгә таба ясарбыз...

Дулкыния яратып Әнвәргә сыенды.

* * *

—Әни, мин кияүгә чыгам,—диде Дулкыния, әтисе табын яныннан кузгалып киткәч.

—Укып бетермәгән килешме?

«Кемгә?» дигән сораудан да алдан бу сораунын биреләсен белә иде кыз, ашыгып аңлата башлады:

—Әни, Әнвәр Рәшитович акыллы, төпле кеше, укып бетерергә кирәклеген белә, булышыр.

—Нишләп Рәшитович соң ул, кызым, бик карт кешемени, бездә бит колхоз персидәтеленә генә шулай дәшәләр?

—Юк ла инде, әни,—Дулкыния көлеп җибәрде,—ул безне бераз укытты, әллә ни зур түгел, алты-җиде яшькә генә.

Дулкыния киләсе атнага Әнвәрнең әти-әниләре белән кайтасын, туйны көзгә таба алар ягында үткәрәселәрен тәфсилләп сөйләп бирде.

—Әни, әтигә үзең әйтерсең инде, яме, мин оялам,—диде кыз ахырдан, әнисенең инде йомшарып килгәнен күргәч.

—Кыз бала үстергәндә генә синеке инде ул, үсеп җиткәч—кешенеке,—диде Сәвия, күңеленнән генә ире белән булачак сөйләшүгә әзерләнеп,—хәерлегә булсын...

* * *

—...Алай икән...—диде сузып кына Мәгъсум, хатынын тыңлап бетергәннән соң.—Кайсы яктан була инде кияү буласы кеше?

—Уруссудан диме... Бик ерак була түгелме соң ул, атасы?

—Соң, Уруссуда туган гынадыр инде, яшәвен Казанда яшәрләрдер,—диде Мәгъсум, үзе дә шулай булуын теләп.

—Уруссу белән ике арада урык-сурык килеп йөри алмаслар, әти-әниләре белән дә кайткач, никахын да укытып җибәрәсе булыр, Шәмсетдингә әйтеп куй, ялга лесник малае янына урманга киткәли ул, өйдә торсын...

—Тукта әле, син бигрәк, кайтсыннар, күрик, сөйләшик...

—И, атасы, алар үзләре сөйләшәсен сөйләшкән инде, Дулкыния «Әнвәр Рәшитович» дип кенә тора. Әнә, малаең, армиядә хезмәт иткән жирендә өйләнде дә куйды, нишли алдык, балалары бакчага барыр яшькә житкәндә генә кайтып күренделәр.

—Ул Шәмсетдиннең муллалыгын әйтер идем инде, үз хатынын да кыйнап үтерде бит ул,—диде Мәгъсум, Шәмсетдинне өнәмәгәнен белдереп.

—Соң, башка авылга мулла эзләп китмәссең бит инде, туганда да, үлгәндә дә бөтен кеше аңа әйтә,—Сәвия бераз туктап торганнан соң сүзен дәвам итте,—әле Дулкыния «Әнвәр Рәшитович» дип сөйләгәндә сөенеп тә куйдым, укыган, түрә кешегә чыга икән дип. Укуын бетереп авылга кайтса, кем бар монда? Берәр шофердан артыгы булмас иде...

—Әй, гомерең үтте инде шул түрә хатыннарына кызыгып,—Мәгъсум кызып китеп, узган атнада печән өйгәндә сынган сәнәк сабына барып ябышты.

—Үтте шул,—Сәвия дә башлаган сүзен ярты юлда калдыра торганнардан түгел иде,—син артынны кыздырып көне буе чөгендер басуында ятканда мәктәптә синнән күчереп утырган кыз яныннан пред машинасында узып китсен әле...

—Сон, Жиһанша ана өйләнгәндә пред түгел иде ләбаса, укыганда да гел әйтә иде, мина укыган хатын кирәк түгел, миннән акыллы булып мине өйрәтеп яшәмәсен, чиста-пөхтә булсын, тәмле пешерсен, дип..

—Ул пешергәнне, ул юганны без дә кимен куймыйбыз!

—И карчык, нәчәльство хатыннарының төнлә туккән күз яшьләрен син күрмисең шул, үз ирең төннең кайсы вакытында уянып киткәндә дә янында булгач... Мин бит син сыер сауганда да кырыеннан китмим, типмәсен дип муенын кашып торам...

Балаң башлы-күзле булырга җыенганда үткәннәргә сәяхәт ясап алу табигый хәл. «Акыллы егет булырга охшап тора дип, шуннан ары әби-бабалар гореф-гадәтен саклап, әти-әнисе белән кыз сорарга кайтуын хуплап, үзләренең хәрби хезмәттә вакытта беркемгә әйтми-нитми, кинәшләшми өйләнеп куйган улларын искә төшерә-төшерә, алай да аласын алып, җыештырасын җыештырып, әзерләнеп торырга кирәк,» дигән нәтиҗәгә килә алды ата белән ана.

* * *

Икенче атнада авылда хәбәр таралган иде инде.

—Дулкыния кияүгә чыга икән...

—Бу атнада сорый кайтасылар ди...

—Әйтәм аны Мәгъсум Шәмсетдиннәргә кереп бара иде...

Атна юып-пешеренеп үтте. Җомга көн таң алдыннан чатырдап яшен яшьнәгәнгә Дулкыния урыныннан сикереп торды. Күк йөзен кара болыт каплаган, яңгыр коепмы-коя гына. «Йә, Аллам, Әнвәрләр ничек кайтыр?» Алгы бүлмәдә әтисе белән әнисенең дә сөйләшүе яңгыр, кайтасы кунаклар хакында иде.

—Әйтер идем шушы Жиһаншаны, ярты чакрым арага асфальт салдыра алмыйлар бит...

—Әллә берәр трактор сөйләшеп куясыңмы соң, әтисе, төштән соң тау башына менеп торыр идегез?

—Сон, Дулкыния йә җомга, йә шимбә кайталар диде бит. Тәгаен генә билгеле булмагач... Бәлки, озак та яумас әле, җәйге яңгыр тиз туктый ул.

—Ай-һай, бер дә туктарга охшамаган, көтүне дә чыгармый торалар, һай, Аллам, хәерлегә генә булсын, чит-ят җирләрдә адашып кына йөрмәсәләр ярар иде,—Сәвия чын-чынлап хафага төшкән иде.

Иң нык борчылучы, билгеле, Дулкыния иде. Ишек алдында да аяк атлап йөрерлек түгел. Көтү чыкмады, кырда эшләүчеләр эшкә бармады, кемдер мунча ягып җибәргән. Авыл кешесенә мунча кереп, ял итеп алу өчен иң кулай көн. «Киләсе атналарга дөньяны су басса да сүзем булмас иде, Раббым, бүгенгә генә туктат бу яңгырыңны, һич югы тау башында яудырма, мәрхәмәтле бул юлдагы бәндәләреңә...»—Дулкыния белгән һәм белмәгән догаларын укып көне-төне Ходайга ялварды...

Тәүлек тулганда яңгыр туктады, һәммәсенең дә күңеле бераз күтәрелеп китте. «Төшкә кадәр юл да төшәр,»—дип бер-берсен юата-юата янәдән кунакларны каршы алырга әзерләнә башладылар.

—Тау башыннан машиналар тавышы ишетелгәли башлады, кызым, юл әйбәтләнгәндер, кайтып житәрләр, Аллаһы боерса,—төштән соң Мәгъсумнең әйткән бу сүзе бүгеннең иң кадерле сүзе иде.

Ялтырап кояш чыкты, инде житәрлек дәрәҗәдә кыздырырга ук тотынды. Урамда ишетелгән һәрбер машина тавышына Дулкыниянең йөрәге дертләп куйды: «Кайттылар!» Ишек алдына мең чыкты, мең керде. Дусты Ләйсәннең әнисе Мәрзия апасы килеп кергәч, Дулкыния аның сораштыра башлавыннан куркып бакчада утырыбрак торуны кулайрак күрде. Тик йөрәк

дөп-дөп килә, бер урында озак утыртып тормый. Кинәт Дулкыниянең башына бер уй килде: «Тау башына менеп каршы алырга кирәк!» Шундук уеннан кире дә кайтты: «Килешмәс, әтисе дә өнәмәс. Кайтмасалар, ни йөзең белән урам буйлап үтәрсең?»

Сәгать теле күзгә күренеп кичке якка авыша башлады. Ул арада капкада култык астына Коръән китабы кыстырган Шәмсетдин күренде. Гарәпчә укый белмәсә дә, рәвешен китереп, Шәмсетдин чакырылган жиргә китабын да калдырмас иде.

—Әллә кодалар кайтып житмәделәрме, машина-фәлән күренми?—Шәмсетдиннең кerә-керешкә башлаган сүзенә Мәгъсумнең акланган сыман әйтелгән жавабы ишетелде.

—Күренмиләр шул. Янгыры да явып та күрсәтте бит, бөтен Татарстанны тигезләгәндер, шәт. Ватылып, батып ятмыйлар микән инде?..—Бу—Мәгъсумнең ни әйтергә белмәгәннән генә әйткән сүзе иде.

Ярсып, бакча капкасыннан атылып килеп чыккан Дулкыния Шәмсетдин кулыннан Коръәнне тартып алды.

—Мин аны... Мин аны мәңге кичермим,—кыз күз яшьләренә буылып, отыры ярсый төште,—менә Коръән, ант итәм...

Ишек алдындагы сөйләшкән тавышларга кунаклар кайтты дип уйлап килеп чыккан Сәвия кызының соңгы сүзләрен ишетеп кулындагы Китапны тартып алды.

—Ни сөйлисең син, балакаем, рәнжеш ни гадел булса да уртак төшәр ди. Ил бетмәсә—ир бетмәс. Йә Раббым, хәерлегә генә булса иде...

Дулкыния каршысына очраган Мәрзия апасын да күрмичә атыла-бәрелә өйгә кереп китте...

Әнвәрләр икенче көнне дә килмәде, өченче көнне дә... Авылда бу турыда бераз сөйләп алдылар да тындылар. Беркемнең дә бурасы буш түгел, бүген бер өйдә нindидер вакыйга булып аны сөйләсәләр, артыннан ук башка берәүнеке килеп чыгар иде. Тик кыз баланың абруе кыл өстендә, кылдан төшсә ил өстендә, Дулкыния атна-ун көнләп урамга чыкмады, каникулы бетәр-бетмәс ук группадашлары килеп житкәнче, укулар башланганчы дип китеп тә барды.

Авылда чакта инде бер тапкыр хурлык хисе кичергән кыз, группадашлары белән очрашкач, янә ул халәтнең янарасын белгәнгә күрә, анык кына бер карарга килеп өлгергән иде: башка институтка, яки читтән торып уку бүлегенә күчәргә.

...Соңгы курста укыган бүлмәдәше Ирина әллә инде каникулга кайтып та тормаган, әллә Дулкыния кебек нindидер сәбәп килеп чыгып иртәрәк килгәнме—бүлмәдә берничә егет-кыз кәеф-сафа корып утыралар иде.

—О-о! Новоиспеченная невеста,—дип каршы алды ул Дулкынияне.—А где жених?

—Ул аста калды, машинада—диде Дулкыния үз ялганына үзе ышанасы килеп.

—Нельзя же так, безнең котлауларны кабул итәсе килмимени?

—Ә мин ана тапшырырмын,—ул үзенә кирәк кайбер әйберләрен алып тизрәк чыгып китү ягын карады.

Барсы да аяк өсте басып, Дулкыниягә котлаулар яудыра башладылар.

—Чтоб жили долго и счастливо, и умерли в один день.

Урамга чыккач та Дулкыния Әнвәр белән очрашкан урыннарына барып күңеленә бер төрле дәва алып кайтырга теләгән иде, шундук кире уйлады: кирәкмәс—үткәннәрне искә төшерү, үткәннәр белән яшәү—үз-үзеңне җәзалау гына булачак, вакытны әрәм итмичә эш эзли тору хәерлерәк.

Кыз Казанда ике ел яшәү дәверендә кайда нинди оешма урнашканлыгын

да, ихтыяҗ булмагач, әллә ни белми иде. Укырга бара, авылына кайта, буш вакытларда Әнвәр белән сөйләшенеп куйган җиргә очрашуга йөри. Ун класс, ике коридор — белем белән нинди генә эш таба алыр икән... Тирә-ягына карана-карана урам буйлап атлавында булды. Китапханә, мәктәп, балалар бакчасы... Шуларның берәрсендә нинди дә булса эш табылмый калмас бит инде? Ходай Тәгалә авырлыктан соң җиңеллек бирермен, дигән, дип әйтә иде бит әнисе.

Ишегенә «Казан микробиология фәнни-тикшеренү институты» дип язылган бинаны күреп туктап калды. Ул да булачак биолог бит. Ишеген ачып, эчкә үтеп карыйсы итте. Аның кына кемгә мөрәҗәгать итәргә белмәгәнлектән, коридор буйлап атлавында булды, кулына чынаяк-чәшкә тоткан яшь кенә кызны күргәч, эченә җылы йөгерде.

—Мин эш эзли идем,—диде Дулкыния каушый төшеп,—читтән торып укыйм, сезнең белгечлек буенча, биолог...

—Бөтен кеше үз белгечлеге буенча эшләсә, кешелек дөньясы әллә кайчан шундый да үсеш дәрәҗәсенә ирешкән булыр иде инде,—дип көлде чынаяклы кыз,—минем, мәсәлән, бер белгечлегем дә юк. Карандаш, блокнот биреп утырыр өчен белгеч булу кирәкми, канцеляриядә эшлим, исемем Света.—Шулай юк-барны сөйләшеп бераз торгач, кинәт кызның йөзе балкып китте.

—Слушай, синең очравың миңа идея бирде бит әле,—диде ул ашыга-ашыга,—күрәсеңме, мин бит авырлы,—кыз түбәтәй хәтле генә авырын сыйпаштырып, масаеп Дулкыния каршында бөтерелеп алды,—бүген эштән китәр идем, әле декрет ялына кадәр күпме көтәсе, шундый матур җәйдә кабинетта сөрсеп утырырга, фу, туйдым, ирем хәрби кеше, ялга чыккач кайтып алам диде, баланы монда табасым килгән иде, ә эштән бүген үк китәм, әниләре ашатсын, аларның внуклары ич ул,—диде кыз чытлыкланып.

—Ә мине алырлармы икән соң?

—Безнең директор бер-ике елдан ялга китә. Начальство бит ул эшли башлаганда һәм эштән киткәндә әйбәтләнеп ала. Әйдә, керәбез үзенә. Урыныма кеше тапкач, мине дә җибәрми тормас.

Бер көн эчендә эшле булды да куйды Дулкыния. Өстәвенә институтның тулай торагы да бар икән, Света ярдәме белән анда да урнаша алды. Менә бит дөнья, якын кешең төртеп екса, бөтенләй белмәгән, юлында очраклы гына очраган берәү торып басарга ярдәм итте.

* * *

Акчасы әллә ни күп булмаса да, биредә эшләү ярады үзе. Укуын да тәмамлап чыга алды, шимбә-ялларны авылга кайтып йөрергә дә җайлы булды. Сессия вакытында ара-тирә очраган группадашлары аның инде кияүгә чыгуына ышанганнар иде. Алар гына түгел, хәтта үзе дә ирен каядыр ерак сәфәргәме, хезмәткәме озатып тугры көтәргә тиешле җан ияседәй хис итә иде. Уйлый-уйлый да, уелыплар китә Дулкыния: Нигә Әнвәр аның белән шаярды икән? Җитди, акыллы кеше иде бит югыйсә... Әллә Дулкыния артык нык яратуы, яшьлеге белән Әнвәрнең холык-фигылен, кимчелекле якларын күреп бетермәдеме? «Яраткан кешенең күзе сукыр, колагы чукрак була», диләр бит.

Ә менә күршеләре Мәрзия апаларының әнисенә әйткән сүзләрен аерымачык ишетте ул. Беркөнне бакчада керләр элеп маташканда аларга ниндидер йомыш белән кергән Мәрзия әллә Дулкыния ишетсен дип:

—Дулкынияне әйтәм, һаман кияүгә чыкмый, укуын да тәмамлады югыйсә, атна саен авыл белән ике арада йөрмәс иде, кешесе юктыр

инде,—дип бер урынсызга гына әйтте дә куйды. Сәвиягә кызып китәргә житә калды.

—Үзе чыкмый. Әнә, иптәш кызларының да кайсы инде аерылып бетте, кайсы исерек ире белән интегә.—Ахырда, үрдәгенә каз куям әле мин синең дигәндәй, өстәп куйды,—Ләйсәннең ире дә кайткан саен исерек, ничек түзәдер, бичара.

—Ә-ә, ул монда гына шулай. Чаллыда эчеп йөри алмый ул. Ләйсән әйтә: «Аның эше бик җаваплы, кешеләр юл буенда таяк болгап тора дип юкка көләләр,» ди. Ничек ди әле, расслабляться итә ул, әни, монда кайткач,—ди.

Әйе, шәһәрләрендә шунда хет талашсыннар-сугышсыннар, ата-анага баласының кеше каршында гаиләләре белән кунакка кайтып, кода-кодагый белән йөрешеп яшәве күңелле. Дөнья шулай яралган. Машинасыннан төшеп кияүнең: «Нихәл, бабай?»,—дип килеп күрешүе, кызның күчтәнәчләр салынган сумкаларны чак күтәргән сымак итеп кереп китүе, машинадан чыр-чу килеп онык-онычкаларның коелуы—озатулар, каршы алулар—дөнья шуның белән күңелле. Ә Дулкыния нәрсә? Тыныч кына кайтып керер дә, тыныч кына китеп барыр.

Беркөнне әнисе алай да, ничә еллар туплап килгән, бирнәгә дип җыйган чүпрәк-чапракларны җилләтергә чыгарып элде дә, ахырда өстәп куйды:

—Яткан таш астына су үтми, җилләткәләп, кузгалткалап торырга кирәк.

* * *

Быелгы җәйге ялында Дулкыния абыйларына—Анапага барырга уйлады. Дөресрәге, әтисе белән әнисе шулай теләде. Бигрәк тә әнисе инде.

—Хатыны марҗа булса да, абыең үзебезнеке, сез яшьләр, тел беләсез.

Киткәндә идән астында үскән бәрәңге үрентесе кебек аксыл чырайлы кыз кайткан чакта кояшта янып, диңгез суы, диңгез җиле белән йөзләре шомарып, чәчен заманча килешле итеп кистереп, күзгә күренердәй үзгәреп кайткан иде. Сыланып торган ак чалбарлы, үтә күренмәле кофточка кигән бөтенләй башка кыяфәтле кыз килеп кергәч, хезмәттәше Нәҗия бермәлгә аптырап та калды.

—Слушай-ай,—диде ул Дулкынияне әйләндерә-әйләндерә,—әллә анда башка төрле итеп ясап кайтаралармы? Бир адресларын, мин дә шунда барам,—диде ул көлеп-шаярып.

—Көзгегә карагач, үзем дә аптырап калам. Мин дә кебек, мин түгел дә. Ярар, чәч үсә ул, баш исән булсын.

—Мин бүгеннән ялда, дустым. Көзгегә карап утырырга вакытың бик булмас. Син ялда чакта Әдип Маликович пенсиягә китте, яна директор килде. Әле теге әйбер кирәк, әле бу әйбер дип көн саен исемлек тоттырып чыгара. Мә, боларын син алырсың инде.

Дулкыния Әдип Маликовичны ялга озатканда була алмавына чын мәгънәсендә уфтанып куйды. Бик рәхмәтле иде ул аңа.Тормышының иң авыр вакытында, җиде юл чатында басып торганда ярдәм кулы сузганына киткән чагында үзенә үк рәхмәтләрен җиткерәсе килгән иде.

...Яңа директор кушкан әйберләрне алып бетереп кире эшкә кайтканда инде төшке аш вакыты якынлашып килә иде. Кабул итү бүлмәсендәге сәркәтип кыз ашханәгәме киткән, Дулкыния тартмаларын күтәреп, директор бүлмәсенең беренче кат ишеген ачып, шакырга үрелим дигәндә генә икенче кат ишек ачылып китте.

—Сез сораган әйберләрне...—Дулкыния сүзен әйтеп бетерә алмыйча ярты юлда бүленеп калды. Аның каршында, тар гына ике ишек арасында йөзгә-

йөз диярлек бәрелеп Әнвәр, дөресрәге, яңа директор Әнвәр Рәшитович басып тора иде.

* * *

—Кайчан да булса бер очрашырбыз кебек тоелса да, биредә үк булыр дип уйламаган идем,—диде ул кызның кулыннан әйберләрен алып.—Күптәнме монда эшлисең?

«Син ташлап качкан көннән бирле»,—дип әйтәсе килгән иде Дулкыниянең, әллә каушаудан, әллә чарасызлыктан ни әйтергә дә белмәде, тизрәк чыгып китү ягын карады.

Үзенең бүлмәсенә атылып килеп керү белән Дулкыния тизрәк ишекне бикләп куйды. Әнвәр әйтерсең лә аны куа төшәчәк! Утырып бераз тын алганнан соң башына килгән беренче уе шул булды: Нишләргә? Китәргәме эштән, калыргамы? Әгәр дә Әнвәр китүен үзе сораса?

Йә, Ходам! Бу дөньяга гел сынар өчен генә тудырдыңмы әллә син мине?! Дулкыния йөрәгенең ярсуына түзә алмыйча ачык тәрәзә янына барып басты. Ә анда, аста үзенең кара машинасына утырып Әнвәр төшке ашка китеп бара иде. Дулкыниягә ул өске катка, аның тәрәзәсенә күтәрелеп караган сымак булды.

* * *

Соңгы вакытларда Дулкыния эшкә барлык кешеләрдән дә алданрак килә башлады. Әнвәр белән коридорда кара-каршы очрашмас өчен. Үзе шулай дип уйласа да, бүлмәсенә килеп керүгә аяклары тәрәзә каршына алып килер. Менә хәзер Әнвәр килеп туктар, өскә, аның тәрәзәсенә күтәрелеп карар—карамаса да караган кебек тоелыр, шалтыратыр, кирәкмәсә дә, теге яки бу әйберне сорар, аның белән очрашырга, аңлашырга теләр—кыз янәдән хисләр дулкынында кайный башлады.

Ә беркөнне чынлап та шулай булды. Төшке аш вакытлары узып китеп барганда бүлмәдә телефон чылтырады.

—Дулкыния, миңа узган кварталда алган әйберләрнең исемлеген кертә алмассыңмы икән?—Әнвәрнең тавышын ишетүгә үк Дулкыния коелып төште, көткән иде бит ул бу шалтыратуны, бөтен жаны-тәне белән сизеп көтте.

—Уз әле, Дулкыния, утыр—диде Әнвәр һәм аның кулындагы кәгазьләрне алып, карап та тормыйча өстәлнең бер почмагына куйды.—Болай аңлашмыйча эшләп булмас...

Кыз коелып төште. «Эштән китәргә кирәк булыр сиңа, дип әйтәчәк, ул әйткәнче әллә үзем беренче әйтим микән, тагын хурлыкка калганчы,»—дип уйлап бетермәде, Әнвәр сүзен дәвам итте,—аңлашырга кирәк безгә.—Аннары өстәл артына, кәнәфиенә барып утырды да тартмадан папкалар тартып чыгарды.—Мин монда синең анкеталарың белән танышып чыктым, әллә-ни озак эшләмисең икән әле, тулай торакта да вакытлыча прописка белән генә яшисең... Эш менә нәрсәдә: институтта кыскартулар булырга тиеш, кыскартулар беренче чиратта, билгеле, яңа эшли башлаучыларга һәм пенсионерларга кагыла. Гомумән, фәнни-тикшерену институтларының күбесе ябылу алдында тора,—егет урыныннан торып бүлмә буйлап йөренеп алды да, Дулкыния каршысына килеп утырды,—мин биредә бераз эшләп киткән идем, шуңа эчке кухняны бик яхшы беләм,—ул сүзен бүлеп сәгатенә карап алды,—монда стеналарның да колагы бар, көн матур, әллә табигатькә чыгып сөйләшеп бетерәбезме?

Дулкыния теге вакытта—имтихан биргәндәге кебек сизелер-сизелмәс кенә баш какты.

—Син тукталышка бара тор, мин бераздан чыгып житәрмен,—диде Әнвәр елмаеп.

Дулкыния кешеләрдән аерылыбрак, кырыйгарак барып басты. Кая бара ул? Бәхетенәме, бәхетсезлегенәме? Тик ул бу сорауларга җавап таба алырлык хәлдә түгел иде. Каршысына кара машина килеп туктагач, бераз аңышмыйча да торды, аның бит әле Әнвәрне машина руле артында беренче күрүе иде, егет үрелеп ишекне ачты.

Машина, шәһәрне калдырып, «Аккош күле» ягына бара торган юлга чыкты. Гадәттә мондый вакытта киеренкелекне бераз йомшартыр өчен гомуми сүзләр—көн матурлыгы, табигать гүзәллеге турында сөйләнелә. Ләкин Дулкыниядә бүген табигать кайгысы түгел иде, ничә еллар күңелне бимазалап, төннәрен күз яшьләре түктереп, авыл халкы алдында оятка калдырган, инде «оныттым» дигәндә янадан очраган Әнвәрнең сүзе ни турыда булыр—акланырмы, яратмаганымны аңладым диярме—Дулкыния көтте.

—Беләм, Дулкыния, син миңа үпкәлисең,—диде Әнвәр дәшмичә алга гына карап барган кыз ягына күз ташлап.—Ләкин бу дөньяда бездән генә тормаган әйберләр дә бар шул.—Ана, күрәсең, әле яндагы тәрәзәгә карап-карап алып, әле тизлек рычагын тарткалап, эш арасында дигәндәй сөйләшү җайлырак иде.—Теге вакытта синең белән сөйләшеп, авылга кайтып төшсәм, безнекеләр инде минем өйләнергә кайтасымны белеп, әзерләнеп диярлек торалар. Әтинең бик тә үзебезнең якларга кайтарып, өйләндереп, туган якларда төпләндерәсе килә иде...—Әнвәр әтисе турындагы сүзне юри алданрак әйтеп куйды, гаеп анарда гына түгел, янәсе,—тиздән кайтам, өйләнергә дә исәп, дип хат юллаган идем алданрак, ну, ялларда кайтканда азрак озаткалап, сөйләшеп йөргән кыз бар иде, күрәсең, шуңа дип уйлаганнардыр. Өстәвенә гаилә дусларыбыз да. Ике якның да әти-әниләребез бик тели иде туганлашуны. Әтигә Мәүлидәгә түгел, Казанда башка кызым барлыгын, сиңа өйләнергә теләгәнемне аңлата башладым. Ишетергә дә теләмәде. Әллә кайдан, күз күрмәгән, колак ишетмәгән яктан кыз алалармени, кода-кодагыең белән бәйрәмнәрдә очрашып, кунак-кунак йөрешмичә яшәгәч нинди тормыш була ул,—дип кызып ук китте. Кемдә калмаган ул кызлар дип үзенең яшьлеген искә төшерә-төшерә, укыйсың-укыйсың, һаман акыл керми, дип сәгатьләр буе вәгазь укыды. Ул арада минем кайтуны ишетеп сеңелкәш белән Мәүлидә килеп керде. Әтигә шул җитә калды. «Әйдә, килен, түкле аягың белән,»—дип әйтеп тә куйды. Йә, бу очракта мин нишли ала идем? Өйдән ду кубып, әти-әниләр—һәммәсе белән кычкырышып-талашып, мәңгелек бәддога алып чыгып китәргәме, яки килеп чыккан хәл белән килешергәме? Мәүлидә дә күземә карап тора. Өйләнешеп, районда әйбәт кенә эшкә урнашып, яшәп киттек. Ике як та канәгать. Әдип Маликович, пенсиягә китәр вакыты җиткәч, министрлыкта минем кандидатураны тәкъдим иткән, институтны да, фәнне дә яхшы белә, алга җибәрә торган, перспективалы иптәш дип. Менә шулай итеп мин янадан Казанда.

Дулкыния Әнвәр сөйләгәннәрне тыңлап барып, искәрмәгән дә, машина ул арада халык телендә «Тирән күл» дип атала торган җиргә килеп туктаган иде инде. Юл буена бер сүз дә дәшмәгән кыз машинада утыруында булды. Әнвәр төшеп, ишекне ачкач кына җиргә басты, ике янагы буйлап ага башлаган күз яшьләрен күрсәтмәс өчен акрын гына сукмак буйлап атлады.
—Сандугач,—диде Дулкыния янында гына сайраган кош тавышына игътибар итеп,—әллә һаман да шул сандугач инде?!

—Син үзең һаман да шул сандугач,—диде ир, кызны кочагына алып, иреннәре белән кызның яшьле күзләреннән үбеп,—сандугачым син минем, былбылым..

Бу минутларда Дулкыния өчен арада булган хыянәтле елларга үпкә саклауга караганда бүгенге көн, бүгенге аңлашу, сандугачлы җәй өстенрәк, кадерлерәк иде...

* * *

...Илдә барган үзгәртеп корулар җәмгыятьнең байтак тармакларына кагылган кебек, аларның институтын да читләтеп үтмәде. Ябылуга ук барып җитмәсәләр дә, берничә бүлек берләштерелеп, хезмәткәрләрне кыскартырга, кемнәрнедер ялга җибәрергә туры килде Әнвәргә.

—Өстән катырак куйсалар мәсьәләне, мин генә дә саклап кала алмам,—диде Әнвәр бер очрашуларында,—анарчы кайбер эшләрне эшләп калырга кирәк, Дулкыния. Минем берничә планым бар. Беренчесе сине фатирлы итү. Яңа эшкә күчәргә туры килсә, фатир бирергә бик ашкынып тормаслар үзеңә. Кемнәрнендер ачуын китермәс өчен, моны берничә кешегә фатир бирү юлы белән эшләргә кирәк. Әйтик, ике бүлмәле фатирда торучыга өчлене бирәсең дә аныкы кемгәдер кала, тегенеке сина була. Өйрәнеп чыктым, андый мөмкинлекләр бар.

Шулай итеп, Дулкыния өч-дүрт ай эчендә бер бүлмәле фатирлы да булып куйды. Билгеле, бу эшләрнең башында Әнвәр тора иде. Авыр вакытта институтны саклап кала алу, берничә гаиләнең торак хәлләрен яхшырту бәрабәренә Әнвәрнең үзенең дә директор буларак дәрәҗәсе күзгә күренеп үсте. Дулкыниянең фатирлы булуына үзеннән дә бигрәк әти-әнисе сөенде. «Ирсез яшәп була, өйсез яшәп булмый, фатиры булса, кешесе дә табылыр иде әле,»—дип кызларына әйтмичә генә кооператив фатирга акча да җыя башлаганнар иде дә, алышынып куеп, ул да янды. Үзләре исән-сау вакытта бик тә урнаштырып, башлы-күзле итеп калдырасылары килә иде шул әниләренең. Кайткан саен эш арасында, артык басым ясамыйча, әнисе әйтеп куяр иде: «Ирле хатын Идел кичкән, кызым». Мондый чакларда Дулкыния мәктәптә укыганда язгы ташу Мишә елгасы аша салынган басманы алып киткәч, классташ малайларның күз салып йөргән кызларын аркаларына кочып, күтәреп алып чыгуларын, Дулкыния исә язгы бозлы суны ерып чыгарга резин итеген сала башлагач кына кайсынындыр килеп ярдәм кулы сузуын күз алдына китерер иде. Бозлы суга ялан тәпи керәсе килмәгәнгә генә ризалашыр иде...

Әнвәр белән очраша башлагач, фатирлы да булгач, Дулкыния авылга чын-чынлап та сирәгрәк кайта башлады. Тик әнисенә Әнвәрне янәдән очратуын да, аның кул астында эшләвен дә әйтмәде. Үзе әнисенә Әнвәр турында сөйләмәгән кебек, Әнвәрдән дә гаиләсе турында сорашмады, монда алып килгәнме, туган якларында калып торамы, баласы бармы—икесе генә тудырган дөньяда чит-ятларның исеме яңгыравын, кемнәрнендер шәүлә сыман аларны күзәтеп торган күз карашларын тоясы килмәү хисе икесендә дә бар иде, күрәсең. Кайбер шимбә-ялларны Әнвәр: «Әти-әни янына кайтып килөм, мине югалтма,»—гына дияр иде.

Тиздән Яңа ел. Гадәттә гаиләле ирләр Яңа елны гаиләләре белән каршы алалар. Яңа елда нидер ачыкланыр, Дулкыния беләсе килеп тә сорый алмаган, сорыйсы да килмәгән хәлләргә ачыклык керер сыман. Ул түземсезлек белән Яңа елны көтте.

* * *

—Үзем чакырып кертмәсәм, кереп хәлне дә белмисең, бер дә сагынмыйсыңмени соң?—дип каршы алды Әнвәр кызны кочагына алып.

—Фатир алганнан бирле болай да кырын караучылар, шикләнүчеләр күп,—диде Дулкыния акланган сыман.

—Мин исән вакытта беркемнән дә курыкма,—диде Әнвәр, кызны юаткан сыман бераз һаваланып.—Эшләреңне төгәллә дә, тизрәк кайтып китәргә тырыш. Сөйләшәсе мөһим сүзләр бар.

...Өенә кайткач дулкынланудан кыз әллә ни әзерли дә алмады. Әнвәр дә озак көттермәде, өстәлгә салат, гөмбә ише әзер әйберләр генә куелды.

—Мин Казанга зур планнар белән килдем,—дип сүз башлады ул бераздан.—Күрәсең, илдә ниләр булып ята! Үсәргә, югарыга менәргә теләгән ир-ат өчен бик әйбәт бер мөмкинлек бар—ул карьера ясау. Тиздән сайлаулар булачак һәм ул бик күп кешегә монарчы төшләренә дә кереп карамаган мөмкинлекләр бирәчәк. Мин дә үзебезнең институттан кандидатурамны тәкъдим итмәкче булам...—Әнвәр сүзеннән бүленеп шкафка ымлады.—Бирәр чәркә алып бир әле.—Аннан портфеленнән коньяк алып тулыр-тулмас кына итеп эчеп куйды, кабымлык капты.—Синең дә ярдәмең кирәк булыр, Дулкыния. Бу безнең штаб-квартирага әйләнәчәк, телефон кертербез, листовкалар, өндәмәләр әзерлисе, ышанычлы кешеләрдән команда туплыйсы... Сайлау алды программам инде әзер...

Дулкыниянең тамагына төер утырды. Сайлаулар, штаб-квартира... Яраткан кешесеннән башка сүз ишетергә өметләнеп утырган кыз өчен никадәр күңелсез иде бу сөйләшү!

Ул тышына өч йолдыз төшерелгән коньяк шешәсен кулына алды. «Монда да өчәү,»—дип уйлады кыз кулы белән шешәне сыйпаштырып,—әллә тотырып бирәрне салырга да башка киткәнгә сылтап Әнвәргә барсын да—монарчы сөйләмәгәннәрне чыгарыргамы? Ничек итеп бөтен гаиләләре белән аны көткәннәрен, авыл кешеләре каршында оятка калганын, аның аркасында ил теленә меңгәнен... Әллә Яна елдан соң ук эштән китәргә дә, барсына да нокта куяргамы? Тик Әнвәр бит сайлауда аның ярдәменә өметләнә, эше, мәшәкате, агитация эшләре белән йөрисе күп, ди. Ә бит Әнвәр өйләнгәнен яшермәде, аерылам, сина өйләнәм, дип тә ышандырмады. Хатынын, шәхси тормышын гел сөйләп торып Дулкыниянең йөрәген генә яралыйсы килмәгәндер, бәлки?

Әнвәрнең сайлау, илдәге сәясәт, зур үзгәрешләр турында сөйли башлавына инде сәгатьтән артты. Күрәсең, ул шушы тормыш белән яши, калганы Әнвәр өчен кечкенә, гадәти, үзеннән-үзе бара торган вак әйберләр, ахрысы.

Кыз урыныннан торып балконга чыкты. Әнвәр каршында үзенең көчсезлегенә, акылсызлыгына ачуы килде. Күңелен: «Их, башта ук, аның директор икәнлеген белгән көнне үк эштән киткән булсам!—дигән үкенечле уй биләп алды. Үз тиңе очраган булыр иде әле.

—Дулкыния!

Кыз Әнвәрнең гадәти булмаган эндәшүенә атылып кухняга керде. Әнвәрнең бөтен йөзе кып-кызыл, әллә-нинди аксыл таплар чыккан, үзе туктаусыз укшый, коса иде.—Үләм, «Скорый» чакыр, бөтен эчем яна.

Кыз пальтосын гына элде дә урамга чыгып чапты.Үзе курыкты, кире әйләнеп кергәнче, «Скорый» килгәнче Әнвәр үлсә?! Һәм—аның фатирында үлсә? Йә, Аллам! Нигә һәрчак рәхимсез син мина?!

Дулкыния йөгереп кире өенә кайтканда Әнвәр хәлсезләнеп, ярым аңында килеш идәндә ята иде. Пульсы күпкә түбәнәйгән, битеннән борчак-борчак тир ага...

Артыннан ук диярлек килеп кергән докторның сорауларына Дулкыния ничек җавап биргәнен дә хәтерләми. Өлкән яшьтәге врачның «Ирегезме?» дигән соравын ишеткәч кенә бераз айнып киткән сыман булды.

—Нәрсә эчтегез?—доктор өстәлдәге шешәгә ымлады.

—Белмим, коньяк бугай... Мин эчмәдем.

—Үзең ник эчмәдең?

—Мин эчмим,—диде кыз акланган сымак.

—Бер дә эчмисеңме, бүген генәме?—Дулкыниянең җавабын көтеп тормастан янындагы ярдәмчесенә эндәште.—Агулану булырга охшап тора, тизрәк, бернинди светофорларга да туктап тормаска.—Аннан Дулкыния ягына борылды.—Милициягә хәбәр итәргә тиешмен.

Калганы детектив фильмнардагы кебек булды. Сорау алу, беркетмә... Коньяк шешәсе, рюмкалар, өстәлдәге ризыклар экспертизага алынды, бармак эзләре төшерелде, повестка көтәргә, беркая чыгып китмәскә кушылды.

...Яңа елны өчесе өч җирдә—Уруссудагы фатирларында Мәүлидә һәр шылт иткән тавышка «кайтты бугай,»—дип шатланып ишеккә ташланып, Дулкыния аз гына аяк тавышлары килсә дә, урыныннан селкенергә дә куркып, Әнвәр исә реанимациянең акшарланган түшәменә карап каршы алдылар.

...Ләкин Әнвәргә Мәүлидәнең һич кенә дә Казанга ирен эзләп килеп йөрүе кирәкми иде.Дулкыниягә нинди куркыныч янаганын ир чамалый, кайчакта үзенең дә күңеленә: «Әллә Дулкыния үткәннәр өчен үч алырга теләде микән? —дигән шикле уй килсә дә, исән калганына сөенеп, алда торган сайлауларны да күздә тотып, тизрәк бередән чыгып мәсьәләне тавыш-тынсыз гына хәл итәргә уйлый иде. Тик анарчы тикшерү эше ачып Дулкынияне генә тинтерәтә башламасыннар.

* * *

Билгесезлек—мөгаен иң авыр җәзадыр. Дулкыния Әнвәрнең хәлен— исәнме, юкмы икәнлеген дә белә алмыйча интекте. Бераздан аның башына: «Әгәр дә аны Әнвәрне агулап үтерергә теләүдә гаепләсәләр? Доктор агулануга охшаган диде бит,» дигән уй килде. Көннәрен-төннәрен елый-елый Әнвәрнең исән калуын Ходайдан сорап йокламыйча уздырса, күзенә ничек күренермен, аны, тикшерүчеләрне, әти-әнисен ничек ышандырырмын дигән уйдан кызның башы чатнады. Ник үзе дә ашамады икән ичмасам шунда, икесе бергә агуланырлар, икесе бергә үләрләр, беркем алдында җавап тотасы булмас иде.

Дулкыниянең үтереп ашыйсы килеп китте. Шунда гына менә ничәнче көн инде авызына бер тәгам ризык капмавы исенә төште. Бәрәңге кыздырырга уйлады, тик аңа өйдәге бар әйбер дә—май да, бәрәңге-суган да агулы сымак тоелды. Ичмасам дуслары да юк икән бит. Әнвәрнең килеп-китеп йөргәнен күрмәсеннәр дип таныш-белешләре белән дә артык якынаймады. Бар яшәве, бөтен тормышы Әнвәр иде. Бераздан башына бер уй килде: хат язарга! Әниләренә, Әнвәргә. Аның белән нәрсә булса да—хәзер ачтан үлеп китсә дә, иртәгә сорау алырга чакырып бикләп куйсалар да, өендә үз кулы белән дөресен әйтеп язган язуы калсын.

Дулкыния кәгазь-каләм эзләп тартмаларда актарына башлады. Дәфтәр табып, өстәл артына утырыйм дигәндә, эченнән дүрткә бөкләнгән бер бит кәгазь килеп төште.

Кайчандыр, әле Әнвәр белән очраша башлаганчы ук: «Безнең әбинең әкәмәт кызык бер китабы бар. Ул аңа әнисеннән калган, әнисенә әбисеннән. Мин берәр нәрсәгә борчылсам, егетем белән ачуланышсам да әбидән гел шуны ачтырам. Әби орыша «язмыш китабы бу, балам, фал китабы, аны гел ачарга ярамый, тормышыңның иң авыр чагында, җавап таба алмаганда, чыгу юлын эзләгәндә генә карарга кирәк,»—ди. «Сина да каратыйммы?»—диде Нажия бервакытны авылга кайтырга җыенганда. Ишеткән, күргән әйбере булмагач, Дулкыния берни дә әйтмәде, «белмим шул», дигән сымак иңнәрен

генә жыерып куйды. Авылдан килгәч, Нажия әлеге бер бит кәгазьне Дулкыния алдына китереп салды да:

—Менә, дустым, язмышын үз кулыңда хәзер,—диде.

—Нәрсә соң бу, аңламыйм,—диде Дулкыния, кәгазьдә язылганнарны укып, чынлап та берни аңламыйча.

—Башыңа төшкәч аңларсың әле,—диде Нажия, әллә үзе дә берни аңламыйча, әллә әбисе аңлатып биргән булса да, Дулкынияне борчыйсы килмичәме.

...Дулкыния кәгазьне ачты. Акрын гына, янәдән һәрбер сүзенә тукталып, аңларга тырышып укый башлады.

«Синең күңелең Юныс пәйгамбәр күңеле кебидер, ул кайгыны күп чикте, соңга яхшы була, сиңа да шулай күренер, бер жирдә кулыңнан чыккан нәрсәң бар икән, кулыңа керә. Ничә кешеләр сине күздә тоталар, ярамаслыгыңны теләрләр. Вә Хак Тәгалә һәр эшеңне хәерле итә, сиңа яхшылык бирә, морадыңа ирешерсең, иншалла.»

Кыз язуны кат-кат укыды, укыган саен күңеле бераз тынычлана төште. Язмадагы «соңга яхшы була» дигән жирендә туктап-туктап торды.

Әнисенә дигән хатында ул ничек итеп Әнвәр белән яңадан очраша башлауларын, Әнвәрне аның фатирлы итүен жайлап кына әйтеп куйды. «Хәтерлисеңме, әни,—дип өстәде ул ахырдан,—сабый чакта тәкыя узыштырып уйнаганда мин суга баткан идем. Менә хәзер дә тормыш тәкыясе язмыш чытырманлыкларына эләгеп яр буенда туктап калгач, мин аны урыныннан кузгатып жибәрмәкче генә булган идем, югыйсә...

Хәтерлисеңме, әни, Әнвәр кайтмагач, мин аны мәңге кичермим,—дип Коръән тотып ант иттем. Син курыктың. «Рәнжеш ни гадел булса да уртак төшәр»,—дидең. Бу минутларда Әнвәр, минем гомер буе яраткан Әнвәрем, үлем белән тартышып реанимациядә ята, мин исә төрмәгә килеп алып киткәннәрен көтеп утырам.

...Икенче көнне Дулкынияне ике оперативник егет килеп сорау алырга алып киттеләр.

—Урамда суык, жылырак киен,—диде аның яшендәге егет, ниндидер жәлләүле караш ташлап. Бу Дулкыниягә: «Әллә кайтасың, әллә юк,»—дигән сымак тоелды.

Тикшерүче өлкән яшьтәге абзый үзен Әндижан Кәримжанович дип таныштырды. Әнвәр Рәшитовичның агулануы буенча тикшерү эше ачылганын, Дулкыниягә берни дә яшермичә—аны кайчаннан белә, институт директорының ни сәбәпле аның фатирында булуын, агулы гөмбәнең кайдан килеп чыгуын—барсын-барсын дөрес сөйләп бирергә тиеш булганлыгын аңлатты.

Дулкыния бергә эшләүләрен, директорның депутатлыкка чыгарга жыенуын, киңәшергә, ярдәм кирәк булырга мөмкинлеген әйтергә кергәнлеген сөйли башлаган иде, Әндижан Кәримжанович усал карап аны сүзеннән бүлде:

—Мин сезгә яшьлегегездән үк башларга киңәш итәр идем. Сезне укытканын, өйләнешергә жыенуыгызны, кайтмавын, башкага өйләнүен...

—Әти-жаным...—дулкынланудан кызның теле буталды,—минем гаебем юк,—кыз өстәлгә сыгылып төште.

—Тынычланыгыз,—диде тикшерүче су биреп,—сезне бит гаепләргә жыенган кеше юк. Агулы гөмбә сезнең өйгә кайдан килде, ник үзегез ашамадыгыз? Безнең бары тик шушы сорауларга гына жавап аласыбыз килә.

Дулкыния алар ягында кешеләрнең капка төбенә чиләк белән чыгарып куеп жиләктер, алма-бәрәңгедер, тозламаган да, тозлаган да гөмбәләр

сатуын, шунда бер карчыктан алып китүен, Яңа елга дип махсус саклавын сөйләп бирде. Инде хәзер Әнвәр белән арадагы мөнәсәбәтләрне яшереп торуның кирәкмәгәнлеген аңлап—аны яратуын, һаман да яратуын әйтте.

—Ул исәнме?—диде яшьле күзләрен тикшерүчегә төбәп.

—Исән. Бу сезнең хәлне күпкә җиңеләйтә, ләкин җавап тотудан азат итми.

Әндиҗан Кәримҗанович уйга калды. Нишләргә? «Шәһәрдән чыгу тыела» дигән кәгазь биреп янә сорау алырга чакырганчыга кадәр өенә кайтарып торыргамы? Кыз нык борчыла, бәлки ул гөмбәнең нинди булганлыгын, чынлап та, белмәгәндер дә, очраклылык аркасында хәзер ул җинаятьчегә дә әйләнергә мөмкин. Кайбер фактлар шулай ук шик тә тудыра. Ә фактлар кире кәҗә кебек—син бер якка тартасың, ул үз урынына китә. Кыз ялгыз яши. Ә ялгыз башка нинди уй килмәс? Тикшерү барышында үз-үзенә кул салу очракларын да күрмәде түгел бит, күрде Әндиҗан. Изоляторга ябып тору исә законга каршы килми.

* * *

Тикшерү изоляторының ишеген ачкандагы көлешкән тавышларны ишеткәч, Дулкыниянең күнеленнән яшен тизлегендә бер генә уй сызылып үтте: «Мондый җирдә дә шулай гамьсез көлеп була микәнни?»

—Нәрсә, әллә биредә елап кына утыралар дип уйлаган идеңме?—Бу сүзләр, аның уйларын белгән сыман, кайдандыр түрдәнрәк ишетелде.

—Монда әле туалар да, үләләр дә...

Кулындагы кечкенә генә пакетын кочаклап, Дулкыния ишек төбендәге топчан кырыена чүмәште.

—Син дә мәхәббәт корбанымы?—Яшь кенә кыз аның янына килеп утырды. Дулкыния эндәшмәде.—Бераздан үзең үк сөйләшә башларсың әле, иначе монда акылдан язасың.

Шалтырап тәрәзә ачылды.

—Кузьмина! Передача.

Кузьмина дигән озын буйлы, таза гына гәүдәле кыз пакетын бераз караштырганнан соң өстәлгә китереп бушатты. Барысы да өстәл янына җыелдылар, Дулкынияне дә төрткәләп китереп утырттылар.

—Атабыз Адәм белән анабыз Хәва җәннәттә хилафлык кылмаган булсалар, бәлки, җир йөзендә дә ир-ат белән хатын-кыз бер-берсенә җәбер-золым күрсәтми яшәрләр иде...—диде кемдер.

Дулкыния кулына алган пирогын ничек ашап бетергәнен сизмәде дә. Бәлки ул аны кемгәдер сындырып бирергә тиеш булгандыр, ләкин ул аңын югалтып егылырлык дәрәҗәдә ач иде. Үзе ашады, үзе курыкты—хәзер шуның өчен кыйный башласалар? Киноларда шулай күрсәтәләр бит...

—Төрмәдә ирләр камерасында : «Ирләрнең башына хатын-кыз белән аракы җитә,»—дип язып куелган диләр, ә хатын-кызларныкында ни дип язганнар икән?—диде әлеге яшь кыз.

—Барып җиткәч күрерсең инде. Бәлки, берәр оригиналь нәрсә уйлап табарсың?

—Кечкенәдән үк ирләргә нәфрәт белән үстем,—Кузьмина, күрәсең, Дулкыния килеп кергәндә нәрсәдер сөйләгән булган, хәзер дәвам итә иде,—хәтта әтине дә яратмадым. Әни—картаеп бара торган кыз, гаиләсен ташлап киткән берәүне йортка керткән. Последний шанс. Егет кеше көтеп утырса, минем тумый калуым бар. Әти әнине гел көйләтеп, куркытып яшәде. Үтүкләнмәгән носки кимәде, тәлинкәсе янына кашыгын куярга онытса да, бу өйдә миңа хөрмәт юк, китәм,—дип

тавыш чыгара иде. Шуларны күреп үскәнгәме, кияүгә дә чыкмадым. Ләкин барыбер ир-атның корбаны булып бирегә килеп эләктем.—Ул сигаретын тирән итеп суырды, беравык тын торды.—Кешеләр яртышар ел акча алалмыйлар, ә без оборотта акча әйләндерәбез, процент эшлибез. Өч баласы булган берәү кергән, кычкырып елый. Ә мин ана акырам, каян алыйк, янәсе, хөкүмәт бирми. Чат саен банк ачалар, халыкка акча юк, диләр. Директор үзе эшләгән шухыр-мухырларыннан котылды, мине монда китереп тыкты... Әнә хәзер, гаебен юмак булып передача җибәреп ята, сволочь!..

Дулкыния башын өстәлгә куеп йокыга киткән иде. Йокылы-уяулы хәлдә топчанга илтеп яткырдылар.

—Бичара,—диде Кузьмина,—нинди җинаятьче булсын инде бу!

* * *

Икенче көнне тагы әллә ничә сорау биреп җанын талкыганнан соң Дулкынияне ялган детекторына утырттылар. Башына нидер урап, бармакларына резин шнурлар кидерткән оперативниктан килгән тир исеннән аның күңеле болганды. Шнурлары-ниләре белән сикереп торып кырыендагы чүп чиләгенә иелде. Аппаратның күрсәткеч уклары сикергәли башлады.

—Өйрәтеп тә өлгергәннәр. Тәҗрибәлеләр бар шул анда,—диде әлеге оперативник мыскыллы елмаеп.

—Һава юк бит монда. Тынчу,—диде кыз сабыр гына.

...Кире изоляторга кайткач, бүген инде ул андагыларга үзенең бирегә ничек килеп эләккәнен сөйләп бирә алды.

—Әйттем бит, мәхәббәт корбаны дип,—диде кечәге кыз Дулкыния сөйләп бетергәннән соң. Үзе исә ялган товар сатып бирегә эләккән икән.

—Да-а,—дип суzды Кузьмина,—сине моннан коткарса, янадан шул кеше генә коткара ала. Тик белмим, алынырмы ул мона—бер саткан кеше тагы сата. Өстәвенә хатыны да бар. Ирләр сөяркәләре белән янгач, хатыннары җырын җырлый башлыйлар.

Кичкә таба Дулкыниянең тәне ут кебек кызыша башлады. Үзе саташулы-йокылы хәлдә, янындагыларның сөйләшкәннәрен дә ишетә, бөтен топчаны, кешеләре белән изолятор йөзеп йөргән кебек. Тонык кына янган ут зур кызыл шар сыман. Ул яткан топчан ниндидер зур сәхнә, имеш, төрле яктан прожекторлар яктырталар, сәхнәнең бер почмагында оркестр уйный, аның белән Әндиҗан Кәримҗанович дирижерлык итә, имеш. Менә берзаман дирижер таякчыкларын аның кулыннан Әнвәр алды. Залда алар институты кешеләре утыра, имеш. Дулкыния җырларга чыгарга тиеш икән. Әнвәрнең күзе анарда. Дулкыния оркестрга кушылып, моңарчы беркем дә җырламаган да, беркем дә ишетмәгән яңа җыр җырлый, имеш. Көе дә оркестр уйнаган көй түгел, кайчандыр әбисеннән ишеткән көй сымаграк.

Ап-ак идем, кара төстән йөзем жуйдым,
Гаепсездән гаеплегә булдым-куйдым.
Һәр чат саен дошманыма азык куйдым,
Чын дөресен бары Ходай белер имди.

Акылсызы, әй, сөенер, сөенеп туймас,
Акыллысы бары әйтер: булмас-булмас.
Бу баланы рәнҗетүдән мәгънә тумас,
Чын дөресен бары Ходай белер, имди.

Хөкеменә син ашыкма, әй, кардәшем.
Минем хәлем үз башыңа, әй, төшмәсен.
Дөнья шулай каралта да, агарта да,
Җәзасын да Ходай белеп бирер, имди.

—Саташа, бичара,—диде янында кемдер,—врач чакырырга кирәк.

—Килделәр ди, бар, төн уртасында...

—Әллә башына суга башлаган инде?!

—Зинһар, уятмагыз, тагын җырламас микән, бигрәкләр дә мина туры килә,—дип өзгәләнде күз яшьләрен сөртә-сөртә өлкән яшьтәге татар апасы.—Мине моннан чын төрмәгә озатачаклар, шунда җырлап юаныр идем, сүзләрен язып бирмәс микән?

—Төрмәдә күп кеше шагыйрьгә әйләнә, бик хисчән күренәсен, үзең язарсың,—диде Кузьмина аңа каршы.

Әлеге апаның да хәле мөшкел иде. Ире үлгәннән соң, тормышы бераз җиңеләймәсме дип башка берәүгә кияүгә чыга. Салырга яратканын да белгән югыйсә. «Син миңа чыксаң, авызыма да алмыйм, хатынымны яратмыйм, өйгә кайткач аны күрмәс, тизрәк ятып йоклар өчен эчеп кайтам,» дип Нисаны ышандыра . Кая ул, Нисага килгәч, син тормышымны боздын, сине күрмәс өчен эчәм дип теңкәсенә тия икән. Күрәчәктер инде, чираттагы бер ачуланышканда Ниса аны этеп җибәрә, аягында көчкә басып торган ир ишек яңагына барып бәрелә, җан-тәслим кыла. Өстәвенә шаһитлар да бар, күршесе кергән була. Кызларына шул җитә кала, фатирны үз кызына калдырыр өчен әтине юри үтерде дип, суд юлында йөри башлыйлар.

Төннәре Дулкыния белән матавыкланып үтте. Уятып кайнар чәй эчерделәр, салкын су белән чылатылган чүпрәкне туктаусыз мангаена, тәненә куйдылар.

Икенче көнне шалтыр-шолтыр килеп ишек ачылганда да Дулкыния әле ятагыннан тормаган иде.

—Давыдова! На выход!

Ул акрын гына урыныннан торды. Башы әйләнеп , әллә кичә чәйне күп эчергәнгә күңеле болганып куйды. Кизү торучы ачкычлары белән ишеккә кага башлады.

—Тизрәк!

Дулкыния баскан урыныннан кымшанмыйча да торуында булды. Юк, кагу ишектә генә түгел, кайдадыр түрдәрәк—бәгырь түрендәрәк, касык турындарак иде.

—Әйберләреңне алырга да онытма!—Кизү хатын тагы бер әмер биреп алды.

—О, әйберләр белән булгач, өмет бар монда,—Кузьмина анын янына килеп басты.

Эчтәге талпыну янә кабатланды. Дулкыния биреға килеп кергәч тә кемнендер: «монда әле туалар да...» дигән сүзен исенә төшереп, елмаеп куйды.

*

Рөстәм
Зарипов

# КОЯШКА КАРШЫ ҺӨҖҮМ...

*Иң яманы—олы юлга чыгып,*
*Кешеләрнең малын талаучы;*
*Чын кабахәт—симез түрәләрнең*
*Майлы табакларын ялаучы.*
Мөхәммәтдин Закиров

## Бу да үтәр...

Р. Юнисның «Карабыбыз батып барганда» дигән (К. У.,2008 ел, 12 сан) гыйбрәтле язмасына кайбер шәрехләр шәкелендә М.Юнисның «Батып барган карабны кем, ничек коткара алыр» дигән, шулай ук әрнүләрдән торган «кайтаваз» мәкаләсе дөнья күрде (К.У. 2009 ел, 8 сан). Күтәрелгән фикерләр тәҗел һәм мондый эчтәлекле язмалар сан саен чыгып барса да артык булмас иде кебек. Җөмләдән, русларның милләтләрен, дәүләтчелекләрен кайгыртулы язмалардан гына торган басмалары да шактый... Әле крокодил күз яшьләре түккәннәре күпме?. Ә безгә, карабыбыз бөтенләй төпкә киткәнче, җан әрнеткеч фикерләрне ничек тә әйтеп каласы иде бит...

...Кайда да булса бары тик бердәнбер «дөрес» фикер үткәрелә башласа, ул үтләтә, тешкә тия. Укучы өчен газета-журнал битләрендә «бер капкага тибүчеләр»нең фикер алышу пародияләре түгел, ә тормыш тәҗрибәләре төрле, биографияләре мул булган затларның ихлас бәхәсләрен, әңгәмәләрен урнаштыру отышлы. Җөмләдән, Миргазиян аганың һәр язган юлын сеңдереп баручы булсам да, әйткән бер фикеренә ләббәйкә дип торучылардан түгел. Нәни бер мисал, телгә алынган мәкаләсендә «Большая книга» ярышында өченче урынны яулаган Рөстәм Рәхмәтуллинның, Мәскәүнең барлыкка килүен—көчәюен ике хәлиткеч көчкә—православиегә һәм абсолют монархиягә бәйләп аңлатуын ул кабул итми. Аныңча, Мәскәүнең үсеп зураюы турыдан-туры татар калалары җимерелүгә, шуннан агып кергән ганиметкә бәйле. Тик болар нәтиҗә, ә татар калалары җимерелүен, ганимәт малларының Мәскәү тарафына агылуын Рәхмәтуллин әйткән шул ике көч азмы яисә күпме тәэмин иткәндер ич? Бик хикмәтле, Аллаһы Тәгаләгә бәддога укылышлы дин бит ул православие. Көчләп чукындырганда ислам диненнән яздыру процедурасы чөчләрне үрә бастырырдай нинди сорауга уңай җавап бирдерү аша үткәрелгәнен искә төшерик: «...Отрицаешилися всех льстивых и хульных учителей турецких, и всех богохульных и бля...вых басней Мухаммедовых, и по нем бывших всех, яже суть о боге некоем всекованном... и яко богомерзка проклинаеши ли их?..» («Мәдинә әль Ислам» газетасы, 2008 елның 8 февраль 5 нче саны. Түбән Новгородта нәшер ителгән). Әйтерең бармы, мондый нәзакәтле сорауны текә братва авторитетлары зонада түгел, ә дин әһелләре чиркәүдә куя!?..

Шунысы мәгълүм, Аллаһны каргаучылар дәүләте Византия юкка чыккан... Әмма ул хәзер дә карагруһчы шовинистларның кара йөрәкләре түрендә яши бирә. Тарихи факт, Византия императоры Василий II җәнапләре, әсирлеккә төшкән болгарларны сукырайта. Җәмгысе 15 мең кешедән һәр йөзенчесенең бер, ә калганнарының ике күзен дә тишеп агыздырта. Ни өчен һәр йөзенче аяла дип аптырарга кирәкми... Дөм сукырларга илләренә кайтыр юлны табышсыннар өчен кылына мондый «миһербанлылык». Хикмәти хода, шул чара «ярдәмендә» болгарларның «күзләре ачыла», Византия тоткан мәзһәбнең хаклыгын тирәнтен аңлап, православие кабул итәләр һәм шуңа җан-тәннәре белән тапшырылалар. Әле алай гынамы, Византия рухы белән эретелгән коммунист Тодор Живковның бәби тудыру йортына кергән илдәш төрек хатыннарын бүтән бәби тапмый торган итеп чыгаруны җайга салуы хакында да язган иде Тәүфикъ Әйди үзенең «Оҗмах утравы» дигән китабында...

Мәгълүм ки, немец фашистлары «Өченче рейх» дип шашынган, ә урыс карагруһчылары «Мәскәү—Өченче Рим, дүртенчесе булмаячак!» дип ярсыган. Шулай дип кабарынучылар бүген дә юк түгел. Ягъни, мәсьәләнең асылына төшенү өчен икенче Рим булган Византияне генә түгел, ә борынгы асыл Римны да урап кайту фарыз. Тарих китабында Рим—цивилизация учагы, ә аның тирәсендәге ил-халыкларның һәммәсе вәхшиләр дип тамгалана. Рим, Троян атлы император хакимлеге чорында үзенә ясак түләп торган Дакия дәүләтенә басып керә һәм бер кешесен дә исән калдырмый кырып бетереп, йөзләрчә олау алтын-көмеш, барча булган мал-туарын талап алып кайта. Һәм кылынган геноцид хөрмәтенә Римда һәйкәл—колонна торгыза. Һәйкәлдә үтерү , талау күренешләре гәүдәләнә. Ә Юлий Цезарь, хәзерге Франция төбәгенә яу чабып, җиңелгән галларның бер миллионын үтертә, ә бер миллионын кол итеп ала. Мәскәүдә 2007 елны рус телендә нәшер ителгән Терри Джонс һәм Алан Эрейра язган «Вәхшиләр» (Варвары) дигән китапны укысаң, Римның дөньядагы цивилизация учакларын туздыручы беренче фашист дәүләт булуы аңлашыла. Боларның кылган тиңдәшсез вәхшилекләре һәм Рим тирәсендәге ил халыкларының фәндә, караблар төзүдә, архитектурада, төзелештә, башка күп кенә өлкәләрдәге алардан алдынгылыгы, авторлар тарафыннан, тарихи, археологик истәлекләргә таянып, тәфсилле дәлилләнгән. Римнең көче—профессиональ армия тотуга гына кайтып кала, һәм биредә кеше үтерүне шоу-бизнес дәрәҗәсенә күтәрүгә ирешәләр.. Ошбу явызлык империясеннән эстафетаны алда телгә алынган, Аллаһны каргарга җөрьәт иткән Константинополь кабул итә. Өченчелекне кемнәр дәгъвалавы инде искәртелде . Ни әйтим ? Суфичыл бер хикәяттәге сүзләрне кабатласаң гына инде: бу да үтәр...

## Без әле кайда яшибез?

Мин яшәгән Шәмәрдән бистәсендә, белмим, Балтач районына чиктәшлектәнме бу, сәбәп бүтәнме, бәгъзеләр «ң» хәрефен кулланып мәшәкатьләнми. Әйтик, берәр гүзәл ханым «нишләп алай сунул?», ди икән, моны, рус фонетикасына салуламый гына, «нишләп алай соң ул?» дип кенә аңларга кирәк. Татарстанда уздырылган бәйрәмнәргә дә «нишләп алай сун ул?» дип аптырарга кирәкми. Ике теллелек гамәлгә кермәве уңаеннан «конституциябез гарантына» үпкә белдерүләрне дә бала-чагалык, юләр сату дип кенә бәһаләргә ярый, миңа калса... Проблеманың асылына төшенү өчен, иң әвәле Ленин бабакайның «Россия—халыклар төрмәсе» дигән гыйбарәсен искә төшерик. (Беренче булып ошбу ачышны Герцен ясаган бугай...) Әлеге белдерү, патша хөкүмәтен гаепләү җәһәтеннән булмыйча, рус дәүләтчелегенә хас үзенчәлекне шәрехләү, фирканың колагына шуны киртләү, һәм киләчәккә аны шигарь итү ихтыяҗыннан чыгып та яңгырагандыр бәлки? Ә ГУЛАГ—шул сәясәтне даими күз уңында тоту, тормышка ашыру нәтиҗәседер? Хәлбуки, милләт, тел, киләчәгебез турында нәрсәдер әйткәнче, безгә иң әүвәле нинди дәүләттә, нинди иҗтимагый корылышта яшәвебезне ачыклау зарур. Әгәр Ленинның Рәчәйгә биргән шул билгеләмәсен дөрес дип кабул итсәк, (ә аны кире кагулар булмаган), халкыбыз Россия ихтыярында, «зэк» шәкелендә ярты мең елдан артык срокны ураган булып чыга. Үктәбр түнтәрелешеннән соң

хакимияткә килгән большевиклар да дәүләтчелекнең төп асылын үзгәртмәде, бары тик режим, диннәрне тыю нәтиҗәсендә күпкә катылана, ерткычлана гына төште дигән фикерне куәтли Авторханов, Солженицын , Шаламов һәм Астафьевларның җан тетрәткеч бәяннәре...

1552 елдан бирле байтак сулар акты, ә безгә карата даими рәвештә «тарих» китаплары һәм шундый фильмнар, мультфильмнар, дәреслекләр аша һаман гаепләр тагу—ниндидер амнистиягә өмет калдырмый. Төрмә шартларында зэклар жаргоны, блатнойлар теле өстенлеге дә бәхәссез. Туган телнең кануннарга таянып кына бәгъзе шартларда яклануына өмет багълауны һич тә акылга муафыйк талпыныш дип булмый. Россия дәүләтчелеге—рус рухы, рус акылы җимеше һәм анда пахан теле генә ихтирам ителүе, бүтән телләрнең «компонент» дигән кликухага таруы табигый. СССРдан азат булып башка чыгучы илләрне рус теле җитмәсеннән ычкындырмаска мәтәләнүләр дә тикмәгә түгел, ә кабат мәхбүслеккә төшерүне күздә тоту мәрәкәсе буларак аңлашыла. Чөнки бу тел, һич кенә дә тел генә түгел, урыс үзе әйтмешли, аннан да зуррак нәмәрсәкәй . Телнең русчасы—язык , бу сүз татар телендә гөнаһ дигәнне аңлата һәм русның үз телендә дә «язычник» шәкелендә аның тискәре мәгънәсе сакланып калган. Телдә —халыкның рухы, коды. Әлеге ләгать ияләре, гасырлар дәвамында ничәмә-ничә халыкның ил-көнен яулап, талап-көчләп , үтереп кенә түгел , ә шушы тел ярдәмендә алдап-йолдап та аларны, коллыкта яшәүләрен дә аңышмаслык хәлгә төшереп, коллыкта яшәтәләр... һәм бу тел магиясе теләсә кайсы халыкның рухын параличлап, язмышына битарафлыкка кәшәләп кенә калмый, ә шуңа зарурият тә тудыра бугай. Искә төшерик, 1945 елдан алып үзгәртеп кору чорына кадәр арада гына ГДР дәүләтендә рус теле өйрәнделәр. Андагы немецлар, рус рухы белән, безнең белән чагыштырганда аз сугарылды. Алай да Берлин дивары җимерелеп , кавышу сәгате суккач, шулар кабат чын немецлыкка кайта алмый иза чиккән, имеш... Казахстаннан Германиягә киткән немецләрнең дә СССР гражданнары, руска хас менталитетларын югалтасылары, ташлыйсылары килмәве хакында мактанычлы рапортлар яңгырамады түгел.

Ирексезлек шартларында ниндидер гаделлеккә өмет баглап, смотрящий вазифасына куелучыга (сайлап кую хокукыбыз бетерелгәч, шулай дими хәл юк, бигайбә) «конституция гаранты» дип олылыклап үпкәләр белдерү, миңа калса, арттырып җибәрү. Демократик илләр тәртипләренең Россиядә урнашуына өметләнү—шәп хыял, әлбәттә, бирсен Ходай, әмма андый көн инде килде дип куану иртәрәк ич... Күп гасырларга сузылган рухи коргаксыту шартларында җан асраган халкыбызга азат халыкларга хас таләпләр кую, алардан үрнәк алмауда гаепләү, «безнең татар фәлән инде, тәгән инде» дип сыкрану-карганулар мантыйк киртәсенә сыймый. Аннары милләтне изүчеләргә, сатлыкҗаннарын конкрет атамый гына тулаем милләткә «татар башын татар ашый» ише пычрак ату иң кулай чишелеш. Һәм безнең байтак кына сай фәһемле каләмзатларыбыз әнә шундый конформистлык юлын сайлап, «кыюлыкта» ярыша да.... Югыйсә, азатлык алган тәкъдирдә дә озак дәвер ирексез яшәүнең зыкымы, утырып кайткан аерым кешеләрнең табигате бозылу да моны куәтли— милләтебезнең киләчәк язмышында озак кына чагылыш табачак дип фараз кылам. Янә килеп, СССР чорында халыкларны сортларга, әйтик шестеркаларга (союздаш статусына ия республикалы халыклар), работягаларга (автономияле җөмһүриятле милләтләр) һәм түбәнсетелгәннәргә (округ яки ил биләмәсендә бөтенләй казыгы кагылмаган кавемнәр) бүленү принцибы да «төрмә дәүләтчелеге» дигән версияне куәтли. Ә ил дәрәҗәсендә миллионлы телеаудитория каршында нәни халык—чукчаларны идиотлар дип аһаһайлап, армый-талмый мәсхәрәләү—төрмә дәүләтчелеге шартларында яшәвебезгә шулай ук саллы дәлил...

## Һәм соңгылар беренче булырлар...

Рус патриотлары «Россиянең үз юлы бар» дип әзми-куймый тәкрарлый. Димәк ул юлның асылы нидән гыйбарәт булуын белү, Ленин бабайча әйтсәк, архимөһим.

Теләсә нинди теле-сорашулар илдәге бар халыкларны уртак ваклаучыга китерүе буенча ил тарихында беренчелекне, һичшиксез, И. В. Сталин тотканын раслар иде. Аның ысулы кадими, тамырлары тарих төпкеленә китә. Алдан ук искәртеп куям: бәян ителәчәк нечкәлекләр рус патриотларын ирештерүне күздә тотмый, бер халык та ап-ак һәм йомшак кына түгел, ә чал тарих—кан белән язылган. Җөмләдән, 6 нчы сыйныф өчен «История Отечества (авторлары А. А. Преображенский, Б. А. Рыбаков) дәреслегендә татарлар «иго» күрсәтүчеләр генә түгел, ә сабыйларны ботарлап ашаучы кыргыйлар итеп тә тасдыйкълана. Чаллыда яшәүче милләтпәрвәрләребез, ерак бабаларыбызны болай идентификацияләү белән ризалашмыйча, судка мөрәҗәгать итеп караганнар, әмма безнең адәм тоганәләре дәвамчылары булуыбызны Россиянең суд инстанциясе дә раслады.. Шуны гына искәртәсе килә, тарихы дәвамында әледән-әле Ачлык Патша хакимлеге урнашкалап торган бу илдә кеше ашау турында сүз чыгару—асылынган кеше йортында бауны телгә алу белән бер... Украиннар да рус белән бергә сайрашып яшәгән чорларында шундый гастрономик тәҗрибәгә таруларын яшермиләр, ачыктан-ачык белдерәләр...

Димәк, баштан башлыйбыз. Православие чиркәвенең беренче номерлы изгесе, Русьне чукындырган Владимир кнәзгә алданрак ислам динен дә тәкъдим итеп караган булалар, әмма ул хәмер чөмерүне өстен күреп, «на Руси пити есть веселие» дип, аракы хакына исламнан баш тарткан. Урыс чиркәве тарафыннан канунлаштырылган беренче изге, шул Владимир кнәз, Полоцк каласын яулап алгач, җирле княжнаны атасы, абыйлары күз алдында көчли. Ә соңыннан, мәсхәрәләнгәненә җавап итеп үзеннән үч алырга талпынганы өчен аны җәзалатып үтертә. (Илнең хөкем эшләрендә шундый прецедент булу тәэсир иттеме, полковник Будановны да присяжныйлар суды аклаган иде...) Иван IV, үзенең шул әлгәренең бөек башлангычын дәвам итә: көчли, үтерә һәм хөкем итә. Нәкъ менә аның дәверендә кыерланган аксөяк боярлар урынын канлы опричиначы әтрәк-әләмнәр ала. ...Ягъни бу патша Библиядәге, «һәм соңгылар беренче булырлар» дигән маддәне тормышка ашыруда конкрет гамәлләр кыла...

Петр I дә Россиянең аерым юлын интуиция белән сиземләп алып, илдә һәркемне диярлек коллыкка төшерүче крепостное право кертә һәм инде аякка баскан боярлардан торган элитаны кабат кыерлый; двор, ягъни сарай хезмәтчеләреннән, лакейлардан, ягъни әтрәк-әләмнәрдән яңа элита укмаштыра... «Двор» татарның туар, мал-туар дигәненнән алынган һәм бу сүз урысның тварь дигәненә дә барып чыга. Ә «ян» дигән иҗек, җан дигәнне белдерә, әлбәттә. Һәм төркиләрдә генә түгел, ә әрмәннәрдә дә. Грек мифологиясендә Минотавр ярым-үгез, ярым кеше булса, Кентавр ярым кеше, ярым ат, һәм бу сүзләрдәге тавр—туар булуы аңлашылса кирәк. Руслар, Кырымны яулап алгач, андагы исем-атамаларны асылына кайтарабыз дигән легенда ярдәмендә греклаштыра башлап, яуланган биләмәне Таврида дип тәгаенлиләр. .. Әмма алай да исем төрки асылын югалтмый булып чыга.. Озын сүзнең кыскасы, Русиядә дворҗан-тварьҗаннар элита булып куя. Үз халкын кол итеп талаучы, талаганын чит илләрдә, балларда туздыручы, туган телен санга сукмаучы катламга мондый атама һәр заман өчен дә бик тә таман кебек. Табигый ки, грэздән кнәз булучы зэк менталитетлы әтрәк-әләмнәргә казна талау, ришвәтчелек саф һавадай газиз, ә намуслы тырыш хезмәт—артык дәртсендерми, алар чын хезмәтне сөйми. Нәтиҗәдә, фетнәләр, революцияләр, үзгәртеп корулар һәм кризислар...

## Соравына күрә җавабы

Бер юмористик тапшыруда эстрада йолдызы Михаил Задорнов «славян» дигән сүз латин һәм инглиз телләрендә кол дигәнне аңлата дип ычкындырды. Аннары, русларны буйсындырырга теләгәнгә шулай дигәннәр алар, дип әйткәнен бераз йомшарта төште. Алайга китсә, төрки телдә дә славян сүзе—охшаш дигән мәгънәгә ия кебек. «Ян» төрки телләрдә һәм әрмәнчә дә җан дигәнне белдерә, ә селәү—яңгыр суалчаны дигәнне аңлата ич. Мондый

этимологиягә үпкәләү урынсыз, чөнки һәр җанлы туфрактан чыккан. Әле селәүнең чели дигән мәгънәсе дә бар һәм бәлкем человек сүзе чикләвеккә охшаш сүз—«челәвек»тән чыккандыр. Татарча тимер—төрекчә демир булуын истә тотсак «Тын Дон» дигән роман исеменең мәгънәсе тавтология. Тын Тын булып чыга. Ә «земля» дигән сүзнең төп чыгышы җимле булып, «земля-кормилица» дигәннәре дә «җимле җимле» дигән мәгънәгә тоташа. Берег—берек, лес—ылыс, волк—уылык, бирюк (одинокий волк)—бир, бер дигән сүздән яралган. Мондый мисаллар китерү, руска туган булып тагылырга омтылыш булып аңлашылмасын. Алай да күп миллион тиражлы китаплар авторы Александр Бушковның русның төрки тамырдан килеп чыгышы турындагы фикерләре дә буш урында гына тумаган, ахры...

Иван Болотников, Степан Разин, Емельян Пугачев җитәкчелегендәге баш күтәрүләр—террордан башка бүтәнчә идарә итәргә сәләтсез әтрәк-әләм хакимиятнең әшәке изүенә табигый реакциясе булып аңлашыла. Әмма террор һәрвакыт булды һәм аның исемнәре күп: опричина узынуы дип тә, кырылыш дип тә, ачлык муры дип тә, уңышлардан баш әйләнүләр дип тә атадылар аны. Штрафбатлар, заградотрядлар, мобилизацияле экономика—болар һәммәсе террорчыл идарә билгеләре. Армиядәге террор һәм бандитизм—бабайлык һәм уставтан тыш мөнәсәбәтләр дип аталса, Ленин чоры терроры гражданнар сугышына кайтарып калдырылса, Сталин дәверенеке—шәхес культы дигән атамага ышыклана... Никита Сергеевич та эш ташлаган эшчеләргә карата террор кулланды. Хәтта Горбачев чорында, алда да әйтеп уздык, Литвада, Бакуда, Тбилисида тыныч демонстрантларга карата террор кулланылды. Кичәге-бүгенге хакимиятне дә ап-аклар һәм йомшаклар дип атарга нигез азрак.... Сер түгел, террор ярдәмендә Кызыл Империя подданныйларын гомум-әләкчелеккә күндереп, үзләрен кеше итеп тою хакына нинди дә булса көрәшкә үзбаш күтәрелерлек рухын тәмам сүрелдерүгә ирешә. Алай да югарыдагылар башлаган үзгәртеп кору чорында тезләндерелгән халык берара аякка баса башлап, исән һәм мәрхүм лидерларының кемлеген аңлый. Әмма, рухы бозымга тарган дәүләт тотучы халык авызлыктан, йөгәннән арынырга, тәртә арасыннан чыгарга, азатлыкка ашыкмый. Нәтиҗәдә люмпень-элитариат, елгырлык күрсәтеп, ил дилбегәсен кабат эләктерә.. Кем белә, КПСС җитәкчеләре демократия белән шаярган гынадыр, үзләштергән ил байлыгын законлаштыру өчен генә вакытлыча демократиягә мөрәҗәгать иткәннәрдер?..

## Планлы эш таркалмас

Оруэллның «1984» һәм «Скотный Двор» әсәрләре СССРга сатира дип кабул ителә... Хактан да СССРдагы тәртипләр әсәрләрдә бәянләгән хәлләргә аваздаш. Сталин чорында халыктан «артык» икмәкне алу һәм колхозларга каулау турындагы күрсәтмәләрнең фельдъегер хезмәте ярдәмендә урыннарга җиткерелүе һәм нәтиҗәдә канлы бәрелешләр килеп чыгып, крестьяннарга каршы танклар куллануга кадәр барып җиткәч, хакимиятнең документларны көч ярдәмендә бөртекләп кире җыйнап алуы һәм элек кабул ителгән карарларның үзгәртелеп редакцияләнүе игътибарга лаек. Димәк, җинаятьнең очын яшерү ысулы да Оруэлл язганча... Әсәрдә тәкъдир ителгән «яңа тел»дә сүзләр капма-каршы мәгънәне белдерә, әйтик, үсеш—тәпкелгә тәгәрәү, тынычлык өчен көрәш—сугышка әзерләнү, дәреслек—ялган, тәгәллек—хаосны аңлата. Ягъни, без яшәгән илдә «1984» һәм «Скотный двор» әсәрләрендәге хәлләр бергә-бер, хәтта арттырып та кабатлана. (Әйтик Әфганстанны оккупацияләү—«интернациональ ярдәм күрсәтү максатында чикләнгән хәрби контенгент кертү», дип тәгаенләнде.) Ә нишләп әле авыз кыеклыгы өчен көзгегә үпкәләмәскә, мондый вәзгыятьнең чишмә башын, әйтик, татар «иго»сына сылтамаска, ә аңа ябышмаган очракта, бүтән дошманнар этлегенә кайтарып калдырмаска?

Тарихта дөньяга баш булырга омтылышлар борынгыдан билгеле. Мондый гонаһка греклар, римлылар, фарсылар, төркиләр, монголлар, гарәпләр, инглизләр, французлар, немецләр тарган һәм башка Аурупа халыклары

да хатадан хали булмаган... Шул юнәлештә мәгълүм уңышларга ирешкән полководецлар бөек дип санала. Милләттәшләре алар белән горурлана. Русия дәүләте мәктәпләрендә руслар экспанциясе хуплана, данлана. СССР гимнында да «сплотила навеки великая Русь» дип изгеләштереп тәгаенләнә иде. Дәүләт тота белүе генә түгел, үз дәүләтчелегенә теге яки бу дәрәҗәдә кимлек китерүче көчләргә каршы куәтле оборона оештырырга һәм шуннан этенеп җиңү арты җиңү яуларга, башка дәүләтчелекләрне түкәндереп, үзенекен һаман ныгытырга, биләмәсен даими киңәйтергә, һәм кулына эләккән колонияләрне ычкындырмавы белән бердәнберлеккә дәгъва итәрдәй бер ил бар—ул Русия... Нинди генә хаким килсә дә, нинди генә иҗтимагый строй урнашса да үз юлыннан тайпылмаучы әлеге дәүләтнең адашмавын, төп сыйфатын җуймавын тәэмин итүче нәрсәседер бар бугай һәм мин аны, тәхет китабы, ахрысы дип гөманлыйм... Алтынланган тәхет залында, тышлыгы әллә ниткән асылташлар белән бизәлгән шул китап—алтын шүрлектә тора һәм аны уку, хакимияткә килүченең миен лашпырдатып әйләндереп каплау сәләтенә ия булса, ни хәл итәрсең. Миңа калса, китап Константинопольдә, ә бәлкем Римдә үк иҗат ителгән. Кем белә, Мәскәү заказчыларына бәгъзеләр тарафыннан шул империяләрнең ниндидер нәмәгълүм борынгы чыганакларга таянып әтмәлләгән булуы да бик ихтимал. М. Булгаковның «Мастер һәм Маргарита» китабында Воланд (Шайтан), кешегә дөнья белән идарә итү өчен һич югы мең елны күздә тоткан план кирәк, ди. Әлеге Китап та мең ел чамасы элек иҗат ителгәнгә охшап тора. Ихтимал, анда империяне саклау һәм киңәйтү алымнары тәгаенләнгәндер? Әйдәгез, «тәхет китабы»н бар дип саныйк. Анда, янә килеп, дөньяга хуҗа булу планы урын алган, имеш... Ихтимал текстны сихер, магия белән эш итүче, православ дәүләтнең киңәюен кайгыртучы иерархлар агулы кара белән язганнардыр... Әйтик, тәхет иясе, француз романнарындагыча бармагын төкереклэп китап битләрен ачканда шовинизм агуы авызына эләгеп, башта канына, аннары миенә барып ирешә дип фаразлыйк... Бүтән илбашларын әйткән дә юк, хәтта чын демократ Горбачев чорында Вильнюс каласында литвалыларны БТРлар таптады, әзербайҗаннарны Бакуда танклар изде, грузиннарны Тбилисида сапер көрәкләре белән кыйнадылар. Демократ Ельцин заманында Чеченстанны бастырдылар, серб вәхшилекләрен хупладылар... Фаразымча, шул китапны уку аркасында русның кан кардәше украиннарның азат дәүләткә ирешүе дә хупланылмый, ә безнең мәктәпләрдә татарча уку буыла, латин хәрефенә күчү тыела... Туган телләрне җан тәслим кылу идеясен җүләрләрчә тискәрелек белән канунга әверелдереп, тормышка ашырылуны да тагын ни дип аңлау мөмкин?

Милләтпәрвәр язучыбыз Нурихан Фәттах Фест дисбесен, ә Олжас Сөләйманов русларның «Слово о полку Игорове»ләрен төркичә укып биргән иде. Менә шулар ысулына таянып, Россиянең дөньяга хуҗа булу планы бәянләнгән тәхет китабының кайбер сәхифәләрен булса да фаразлап укып карыйсы иде... Босфорларны яулау, Иранга хуҗа булуны күздә тоткан, «Казан утлары» журналы (1992, № 1) бастырып чыгарган Петр I васыяте дә, ихтимал, шушы китап белән рухланудан тугандыр, ә бәлкем шуннан өзектер?

## Сүз җәтмәсен—халыкка

Мәскәүдән килгән Антоненко атлы ханым сүз эквилибристикасы җәһәтеннән Татарстан җитәкчеләренә, аның халкына мастер-класс күрсәтеп китте. Русия мәгариф министрлыгы җитәкләгән бу төркемгә үзенә күрә «бозваткыч» миссиясен үтәү йөкләнгәнлеге аңлашылды.. Рәхмәт, сүз магиясе ярдәмендә адәм аңламаслык тел белән язылган кануның документның асылын җепкә-җеп төшендереп бирергә Рәшит Әхмәтов чыгарган «Звезда Поволжья» газетасының фәһеме җитте. Ә болай, әлеге канунда туган телебезне юк итү хакында сүз баруын ни укып, ни ишетеп тотып алу һич мөмкин түгел!

Сүзләрдән үрмәкүчнекедәй җәтмә тукып була икән ләбаса. Кемгә ничектер, мин фәкыйрьгә әлеге десантка каршы торырга тиеш вазифалы агайларыбызның һәм түтәйләребезнең рәсми сөйләшүләре, телеэкран аша биргән интервьюләре—Чарльз Диккенсның бер романындагы Джингль такылдавын

гына хәтерләтте. Җиңел, ансат, кыска-кыска җөмлә өемнәре хәрәкәткә килә; сүзнең темасы бар, әмма анык фикер укмаштыру хәлдән килми, белем амбары такырлыгы сәбәпле аерым җөмләләр ни грамматик, ни мантыйкый яктан мөкәммәллеккә ирешми. «Әйтте,—өзде бу»—дип сокландырырлык чыгышларны күптән ишеткән юк һәм мондый фәһем белән, якага үрелүче мәскәүләрне тәртипкә чакыру, гомумән, өметсез... Якага ябышучылар, бугазга үрелүчеләр белән аңлашу өчен Миркасыйм Госмановныкыдай корыч логика, Рафаэль Хәкимгә хас такт, Фәндәс Сафиуллинныкыдай аналитик акыл, Айдар Хәлимгә хас кыюлык, яшендәй кабынуларга сәләтле талант, киек сизгерлеге, интуиция һәм халкыңны ихлас ярату кирәк... Ә бездә «майсызландырылган коры сөт заводы» дигән атамага аваздаш, нурсызландырылган карашлы, моңсызландырылган шалтыравык көйгә күнгән, фикерсезләндерелгән сүз ияләре генә мөнбәрләргә чакырыла...

## Түрәгә акыл кайчан керер?

Миргазиян агай бәянында, Баулы районында, администрация тәхетенә менгән Наил Зариповның (миңа туган түгел, шулай да фамилиядәшлек уңайсыз) туган телне кысрыклавы аркасында Баулы халкының татар теленнән баш тартуы бик сәер яңгырый. Мөслим районында, мәсәлән, туган телне яратмый торган шундыйлар «тәхет» тирәсендә пәйда булгач, җирле халык бердәм кубып, коннарын калдырмый куып озатты үзләрен! Әле дә истә, Мөслимдә эшләгән чагым, туган ягына кунакка кайткан Флүс Латыйфи очрап, борын тишекләрен киңәйтеп, миңа ябырылды:

—Нишләп ятасыз сез монда? Анда бит бер фәлән кабахәтович, «Мөслим мәктәбен тәмам татар мәктәбенә әйләндереп бетердегез», дип тавыш кубарган!

—Флүс туган, мин бит Саба ягыннан, бу мәсьәләдә тәртипне Сез, мөслимлеләр, үзегез салсагыз дөресрәк булмасмы?—дим.

—Ә мин моны болай гына калдырмыйм да!—дип ярсыды Флүс. Һәм сүзендә торды, үзәк матбугатта утлы-яшенле мәкаләсе дөнья күрде. Ә аннан алданрак «Телне кем боза?» дигән сатирик язмасы белән Фоат ага Садриев, чабаталарын түргә элүчеләрнең «чапаннарын сырып, иманнарын өшкерде». Чуен өстенә кутыр дигәндәй, шул чорда Мөслимгә килеп киткән, чыгышы белән Лениногорск ягы егете Җәүдәт Дәрзаманның «Татарстан яшьләре»ндә бер-бер артлы «Кара сызык» исеме астында басылган ике утлы мәкаләсе исә Мөслимдәге ул чор хакимиятенең мәнсезлеген, фикри банкротлыгын ике икең дүрт дәрәҗәсендә ачып салды. Рухи планда җөмһүрият матбугаты дәрәҗәсендә тар-мар кителгән хакимиятне, урындагы куәтле оппозиция басымы тәэсирендә сайлауларда да бетемсезлеккә чыгуыннан соң, алмаштырдылар. Дөрес, аерылышу моңсурак килеп чыкты, чөнки китәсе команда инде туган телне ярата, шуны җай чыккан саен ассызыклый ук башлаган иде... Баулы ягында да фәһемле, милли хисле кыю кешеләр житәрлек. Мин белгән, ил күләмендә классик көрәш өлкәсендә югары урыннар яулаган, Казанның «Востокстройтрансгаз» оешмасында төзелеш участогы башлыгы буларак Шәмәрдәндәге оешмабызда подряд эшләре башкарган Ризван агай Фәйрушин үзе генә ни тора иде! «Иван син!—дип сүгә иде ул һәркемне, мөселман-татар өчен нинди дә булса хилаф гамәл, әйтик сүгенсә, хәмер капса, идәнгә тәмәке төпчеге ташласа, йә җиргә төкерсә... Елап, сыкрап йөрүдән фәтва юк, күрәләтә «утка керергә» әзер бер шәхес калкуы кирәк булган баулыларга. Ул чакта аңа ияручеләр дә табылыр һәм туган телне үтереп, сәяси капитал туплауны җайлаган, кәнәфи хакына дуңгызга да җизни диярге әзер әтрәк-әләм хакимият, шуны югалтмау хакына Тукайны яттан өйрәнер, һәм кирәкле кирәксез урында белгәнен дә белдереп йөрер иде...

Заманасында «ак кешеләр» кыргый папуасларны пыяла муенсалар белән бүләкләп куандырса, бүгенге, «үсепеснең папуаслар» өчен юаныч—танк хәтле җиңел машинада йөрү. Европалыларга, сәнәктән көрәк, грәздән кнәз булуны, ягъни, әтрәк-әләмлекне дәлилләүче күренеш—мәзәк һәм көлке тоела, дип язды «Звезда Поволжья» мөхәррире Рәшит Әхмәтов. Шундый машиналарның

җепкә тезелгән хәрәкәте дә сәер тойгылар уята. Тирескә баткан фермаларга туктап, дәү-дәү машиналардан әкәмәт мөһим эш кырган кыяфәттә ишелеп чыккан сөмсез йөзле шеп гәүдәле агайларның җилкәләренә ак халатлар элеп, тамаша күрсәтеп йөрүләрен күрүчеләр бардыр. Татарның киносы юк диләр, ә ул шушы , һәм аны телеэкраннан да күрсәткәлиләр... Авыл халкының аяныч хәлен күреп тә күрмәүче, талаучы, рухын таптаучы, кызларын аздыручы, әле араларында кеше үтерүчеләр булмаса рәхмәт әйтерсең, шушындый буш кешеләрнең үз ирекләре белән туган телне кайгыртуларына өмет баглау, әлбәттә, ахмаклык...

## Милләткә сүз әйтмәгез...

...Утызынчы елларда бер авылда җыелыш бара, колхозга алуны сорап язган гаризалар карала, укылган берсен тавышка куеп уңай хәл итә торалар. Менә бермәлне колхоз рәисе:

—Ә Сәләхине алмаска тәкъдим итәм, чөнки инде ул өч кереп өч чыкты, колхозның дәрәҗәсен генә төшерә,—дип белдерә. Бар да «алмаска!» дип шаулашалар. Шунда кемдер торып Сәләхине якларга алына:

—Ул бит тере хәерче, колхозга кертмәсәк, балалары ачтан үләчәк,—дип авылдашларының күңелләрен йомшартмакчы була.

—Катсыннар! Алмаска! Ничу!—дип, аяк тибә-тибә акыра гавәм.

Менә Бөке Ахун кушаматлы берәү урыныннан тора һәм залда тынычлык урнашканын көтеп ала да әкрен генә:

—Алабыз Сәләхине, нишләп алмаска,—дип куя.

Залда тагын тавыш куба, тузан чыга:

— Алмыйбыз! Алмаска!—дип гүли халык.

Бу юлә, залның тынычлануын сабыр гына көтеп ала да, бер җөмлә әйтә. Һәм кайчан гына Сәләхине изеп ташларга әзер авылдашларның фикере 180 градуска үзгәрә. Бар да: «Алырга!»—дип үкерә башлый.

Баксаң Бөке Ахун:

—Алабыз Сәләхине, ул да «фәлән ителсен»,—дип ычкындырган була, атыюлы белән.

Әлеге кыйсса уңаеннан, бәгъзеләр: «Менә, күрдеңме татарының кемлеген!»—дип тырпаерга мөмкин. Ә хикмәт бу очракта да татарның милли сыйфатында түгел. Бу бит әртәк-әләмнәр җыены. Затлылар биредә катнашмый. Алар юк ителгән, читкә сөрелгән, төрмәләргә, лагерьларга озатылган. Озатылмый калган затлыраклар—хокуклардан мәхрүм ителгән... Озын сүзнең кыскасы, «татар башын татар ашый» дигән «иман»га дүндерү—татарның затлы өлеше тәкәнгәнлеген, ул тулаем әтрәк-әләмләшкән булуын тану ул .

Хәлбуки, үзгәртеп кору елларында кайбер кемсәләр хәтәр генә баеп китте. Әмма, зур портфельле түрә яки депутат булу, хәтсез байлыкка тиенү автомат рәвештә затлылыкны тәэмин итми. Затлы чыгышны сатып алып булмый. Сәнәктән көрәк булганнарны ачы телле каләмзатлар люмпень-элитариат дип тәгаенләде. Андыйлар, үз кавемдәшләрен кайгыртмый гына түгел, ә һәр даим талап кинәнә, ә шул омтылышына карышучыларны өскә күтәрелүче милләттәшенең аягына асылынучы дип «фаш» итә. Димәк, татарны тулаем чүплек башында калдыру өчен җитәкчелек дилбегәсе милли люмпень элитариат кулына тапшырыла! Һәр өлкәдә! Әдәбият һәм сәнгатьтә, мәгариф һәм мәдәният эргәләрендә беренче чиратта! Бу токымда саклану инстинкты куәтле, кәнәфиләре хакына, милләт кенәме ди сиңа, туган әниләренең башын кисеп китерергә дә күп сорамаячаклар.

Бер мәлне Ельцин ,Черномырдин, Лужков, Путин кебек күренекле шәхесләребез Казанга кунакка килеп, очрашуларда, бәйрәмнәрендә түбәтәй киеп йөрделәр. «Просто Мария» сериалында миллионнар йөрәген яулаган Виктория Руффо да мәчеткә мөселманча киенеп, ак яулык ябынып кереп шаккатырды. Казанга мөселман кинофестиваленә рәхим иткән Катрин Деневның да каплаулырак күлмәк киярга зиһене җитте. Бу аларның затлы, мәнле кешеләр булуын күрсәтте. Ә менә безнең ханым-әфәнделәр шул ук

мөселман фестиваленә «ими виду» рухындагы күлмәктән йөрде! Һәм без, моны күреп, алга таба «кендек виду»га ук барып җитеп куандырырлар әле дигән өметтә калдык! Ни генә димәсеннәр, мондый нәрсәләр безнең өчен—татар авылларында дуңгыз асрату дәрәҗәсендәге «казаныш»... Янә килеп текә түрәләремезнең хакыйкый олуг милләттәш шәхесләребез җеназасында руслар үрнәгендә яланбаш йөрүләре дә игътибарга лаек...

Тагын бер гыйбрәтле мисалга туктап узыйк, булмаса. 2008 елда бер төркем татар, шул исәптән театр әһелләре чартер рейсында хаҗ сәфәренә юлга кузгала. Мәккәгә кадәр тукталыш ясалган илдә, бәлкем бәгъзеләр тарафыннан махсус шулай планлаштырылгангадыр, анысы караңгы, боларны ниндидер сылтау табып тоткарлыйлар. Очасы очкычлары китеп бара, ә яңасына эләгү мөмкинлеге күренеп тормый. Әлеге илдәге сәүдә вәкиллегендә эшләүче бер милләттәшләре турыдан-туры түрәсе белән киңәшләшеп тормастан, үз белдеге белән шул илнең кемнәрендер борчый һәм булачак хаҗи-хаҗияләрне көн төнгә авышты дигәндә озатуга ирешә. Сәфәрчеләр, соңармый барып җиткән шатлыктан, ярдәм итүчене мактап, «югарыга» рәхмәт хаты юллыйлар. Гаилә елында яңа гына өти булган әлеге хезмәткәр, чабатасы түргә эленгән татар түрәсе карары белән, шунда ук эшеннән азат ителә, аның урынына кемнеңдер тән сакчысының туганы юллана. Менә шундый җәһәтлекләр, әлбәттә, үткәрелгән кадрлар сәясәтенең өтрәк-әләмлекне куәтләвен тагын бер кат раслый.

*Дәвамы киләсе санда*

---




*Бөек Җиңүгә 65 ел*

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЕЛЪЯЗМАСЫ

## ЖУРНАЛЫБЫЗ—БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА

**1941 ел.** «Совет әдәбияты»ның 4 (апрель) санында Нәби Дәүли, Әхмәт Исхак, Мостай Кәрим шигырьләре, Афзал Шамовның «Днепр буенда», Гадел Кутуйның «Илһам» һәм Газиз Иделленең «Үбү» хикәяләре дөнья күргән.

**1942 ел.** «Совет әдәбияты»ның 4 (апрель) санында Муса Җәлил, Шәйхи Маннур, Фатих Кәрим, Хәйретдин Мөҗәй шигырьләре, итальян язучысы Ж. Жерманеттоның «Туры Тукай» шигыре, Афзал Шамовның «Буранлы төндә» хикәясе, Тажи Гыйззәтнең «Давыллы көннәр» («Ташкыннар» трилогиясеннән) драмасы дөнья күргән.

**1943 ел.** «Совет әдәбияты»ның 4 (апрель) санында Сәйфи Кудаш, Сибгат Хәким шигырьләре, Әмирхан Еникинең «Ана һәм кыз», Идрис Туктарның «Афоризм» хикәяләре басылган.

**1944 ел.** «Совет әдәбияты»ның 4 (апрель) санында Ибрай Газиның «Алар өчәү иде» хикәясе, Нәкый Исәнбәтнең опера өчен «Түләк батыр» либреттосы, «Ватан сугышы кырларында» сәхифәсендә Кави Нәҗми белән Гази Кашшафның «Диңгез батыры» дип исемләнгән очеркы басылган.

**1945 ел.** «Совет әдәбияты»ның 3-4 (март—апрель) саннарында Гомәр Бәшировның «Намус» романыннан өзек, Салих Батталның «Тын диңгез ярларында» поэмасы, Фатих Кәрим, Миргазиз Укмаси, Әхмәт Фәйзи, Гали Хуҗиев шигырьләре, Фатих Кәримнең һәлак булуына карата кайгынамә, каләмдәшләренең аңа багышланган мәкалә, шигырьләре тупланмасы дөнья күргән.

# ХАЛЫККА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

МАНСУР ХӘСӘНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Бу мәкаләне яза башлаганда Мансур Хәсән улы Хәсәнов әле исән иде. Телефоннан сөйләшкәндә тавышы элеккечә нык, көчле булмаса да, шактый ышанычлы, әйткәннәре, аның кебек абруйлы фикер ияләренә хас булганча, эзлекле, тирән мәгънәле иде. Башка эшләр арага керде дә, мәкаләне язу бераз бүленеп торды, ул арада Мансур әфәнденең сәламәтлеге шактый какшап китүе турында хәбәрләр ишетелә башлады. 13 мартта эфир дулкыннары исә аның вафаты турындагы хәбәрне ирештерде. Бу хакта телефоннан шалтыратып җиткерүчеләр дә булды. Шуларның берсе—күренекле әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамов—болай дип куйды: «Мансур Хәсәнович үзе белән тулы бер чорны алып китеп бара». Казан милли-мәдәни үзәгендә уздырылган матәм җыенында ул вакыттагы Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев тә бу зур югалтуны шулайрак бәяләде. Аның сөйләгән сүзләрендә дә, үз-үзен тотышында да сизелеп тора: берничә дистә ел буена ингә-иң торып хезмәттәшлек иткән шәхес белән мәңгегә хушлашу җомһүрият җитәкчесенә дә җинел түгел иде. Әйткәннәре ихлас, чын йөрәктән булулары белән тыңлаучыларның күңел түрендә уелып калды.



Мәңгелеккә килгәндәй яшәсәк тә, сулар һавабыз да, эчәр суыбыз да билгеле бер микъдар белән чикләнгән. Артыгына өмет итеп булмый. Кеше артыннан замандашлары күңелендә хатирәләр генә кала. Игелекле гамәлләр хатирәләрнең матур булуын тәэмин итәләр. Мансур Хәсән улына килгәндә, аның дөньялыкта яхшы эшләре бихисап күп булды. Ул 1964 елда олы әдибебез Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган китабын мондый сүзләр белән башлап җибәрә: «Әдәбият тарихында исемнәре алтын белән язылган бөек шәхесләр бар. Гадәттә әйтелә торган «язучы» сүзе генә аларның асылын ачып бирә алмый». Мансур Хәсәновның үзен дә без, фән һәм әдәбият әһеле, әдәбият галиме дисәк тә, ул бу гаять тә киң төшенчә кысаларына һич кенә дә сыя алмый. Аннары әлеге дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесенең хезмәт юнәлешләре шулкадәр төрле ки, аларны иңләү, күз алдына китерү дә шактый кыен бер эш булып әверелә. Әлеге шәхеснең җәмгыятьтәге урынын билгеләү, аңа бирелгән бәя, әлбәттә, аның гаять олы хезмәтләренә бәрабәр булырга тиеш.

Сигез дистә ел гомердә туган Татарстаныбыз, газиз халкыбыз, фәнебез, әдәбиятыбыз өчен шулкадәр олы хезмәт күрсәтелгән ки, бу зур юлның кайбер штрихлары хакында сөйләп бирү өчен генә дә үзенә, киеренке акыл хезмәте белән мавыгып, шактый дәвамлы эш итәргә туры килә. Чөнки, уңае туры килгәндә, Мансур Хәсәновның шәхесен, аның олы нәтиҗәле хезмәтен халкыбызга мөмкин кадәр тулы күрсәтәсе килә.

Бездә кайчакта авыл балаларына кимсетеп, ничектер, арттa калганрак итеп карау бар. Ә тормыш монын киресен раслап тора. Саф сулы, чиста һавалы, тургайлы болын-басулы, сандугачлы урманлы авыл мохите кешене жисми яктан гына түгел, акыл жәһәтеннән дә камил итеп үстерә һәм тәрбияли. Иң мөһиме, авыл баласы кече яшьтән үк хезмәткә күнегеп үсә, шуңа күрә һәр нәрсәнен кадерен белергә өйрәнә. Зәй районының Бигеш исемле татар авылында туып-үскән Мансур Хәсән улы да моннан чыгарылма түгел. Ул да кечкенәдән үк өлкәннәрнең кул арасына керә башлый, тырмасын да тырмалый, печәнен дә чаба, колагында жил шаулатып атка да атланып чаба, кыскасы, нык үзәкле булып үсә. Ана нәкъ унбер яшь тулганда, ил өстенә афәт килә—сугыш башлана. Ф. Хөснинең «Без яшь идек»,М. Мәһдиевнең «Без кырык беренче ел балалары», В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» әсәрләрендәге кебек хәл-әхвәлләр Мансурлар өчен дә типик иде. Тормышның бөтен авырлыгына әле нығырга өлгермәгән жилкәләрен куйды алар. Ул салам, печән тарттырулар дисенме, төннәр буена ындыр табагында ашлык жилгәрүләрме, Чаллы элеваторына ашлык ташуларны—ниләр генә күрмәде аларның яшь башлары. Иң кыены житәрлек йокы күрмәү иде. Басуда эшләп йөргәндә аяк сөрлегеп китә дә жиргә барып төшәсен. Әмма күтәрелеп китәргә көч юк. Шушы егылган килеш, күзләрне йомып, ун-унбиш кенә минут черем итеп аласы килә. Ләкин, юк, торырга кирәк, кешедән аерылып йоклап ятар чак түгел. Ничек итсә итә, унбиш яше белән барган яшүсмер жиңү көнен инде чыныккан ирләрчә житлегеп каршы ала.

Шуның өстенә Мансур бик кызыксынучан малай була. Кулына килеп эләккән бер китапны, гәзитне «йотып» барырга тырыша. Ләкин сугыш аны урта мәктәптә уку мөмкинлегеннән аера. Бигеш мәктәбендә жиде сыйныфны тәмамлагач, ныклап колхоз эшенә керешә ул. Жиңү яуланган елның көзендә Алабуга китапханә техникумына укырга керә. Менә кайда ул белем хәзинәсе! Мансур йотлыгып, мавыгып укый. Алабугада тагын бер уку йорты бар, ул—укытучылар институты. Биредә рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасы мөдире булып кырым татары Кәрим Рәшидов (Кәрим Жаманаклы) эшли. Ул еш кына китапханә техникумына килә, анда укучы яшьләр белән очраша. Кайвакытта аларның үзләрен институтка чакыра, рус, француз, инглиз, алман һәм башка әдәбиятлар, аларның язучылары турында мавыгып сөйли. Татарлардан исә аның иң яраткан шагыйре—Габдулла Тукай. Дөрес, Бигеш мәктәбендә укыганда да укытучылар бөек шагыйребез хакында бик күп мәгълүмат бирделәр. Әмма Кәрим абыйлары дәреслекләрдә язылмаганнарны сөйли. Бигрәк тә татар шагыйрен башка халыклар карашыннан чыгып бәяләүгә нык игътибар итә. Мансур ул сөйләгәннәрне йотлыгып тыңлый. Әмма Кәрим абыйлары шулай да әллә ни артыгын сөйли алмый. Ник дигәндә, 1944 елның 18 маенда аның халкын туган жирләреннән—Кырымнан—сөрәләр. 1945 елда аның Татарстанга килеп югары уку йортында укытучылык эшенә урнаша алуы үзе бер могжиза. Ул биредә дә үзен күзәтеп торуларын яхшы белә. Шуңа күрә ана бик сак сөйләшергә һәм эш итәргә туры килә.

Мансур бу бик күпне белә торган һәм бик тә ягымлы абыйның техникумга килүен көтеп ала (күрәсен, Кәрим Рәшид улы биредә дә дәресләр алып барган). Ул биргән яки тәкъдим иткән китапларны вакытында укып, аларда язылганнарны нык үзләштерә. Шунадыр, үз яшенә караганда шактый житди һәм мөстәкыйль фикерләргә яраткан унжиде-унсигез яшәр егеткә Кәрим абыйсы нык ышанып караган.

Көннәрдән бер көнне алар Тойма елгасы буенда сөйләшеп йөриләр. Кәрим абыйсы ана үзенең туган ягы Кырым, Кара диңгез турында сөйли. Һәм кинәт күңеленең яшерен жирен ача.

—Хәтерлисеңме,—ди ул,—син бер көнне иптәшләрең алдында авылыңда чакта укыган бер китап турында сүз чыгардың. Анда Закир исемле бер малайның атка булган жылы хисләре язылган. Ул атны ихлас ярата.

—Әйе, әйе. Ул китап миңа бик ошады. Аны миңа авылдагы бер малай биреп торды. Аларда андый китаплар тагы да бар. Аның әтисе укытучы булган. Китаплар шуннан калган. Әниләре аларны утка яккан. Берничә китапны минем дустым яшереп калдырган.

—Шулай булгандыр дип уйлаган идем аны. Беләсенме, мин ул китапны язган кеше белән менә синең белән кара-каршы сөйләшкән кебек сөйләшкәнем бар. Бик яхшы кеше иде, мәрхүм. Ул Казан университетында укырга теләгән, әмма революциягә кадәрге шартларда анда керү бәхете аңа тәтемәгән. Мин аны 1937 елда Кырымда күрдем. Минем Симферополь педагогия институтында аспирантурада укыган вакытым иде. Диссертация якларга Казан университетына барырга ул тәкъдим итте. Сиңа бары тик Казанга барырга кирәк, башка бер җиргә дә түгел, диде. Менә мин дә сиңа, Мансур энем, техникумны тәмамлагач, бары тик Казанга, андагы университетка барырга киңәш итәм, синең урының шунда!—ди ул.

Кәрим абыйлары әлеге язучының исемен әйтми. «Онытылган инде, аннан соң күпме еллар үткән бит» дип кенә куя. Дөрес, Мансур, авылга кайткач, язучысын белер өчен, дустыннан ул китапны тагын биреп торуын сораган иде дә, әмма тегесе «әни аны мичкә ыргытты инде», дип кенә куя. Шуның белән ул тукталып кала. Югыйсә, күңеле изге иде. Кәрим абыйга теге язучының исемен исенә төшерергә иде нияте.

Техникумны тәмамлагач, 1949 елда үз районындагы Поповка авылында уку йорты мөдире булып эшли. Ел буе баш күтәрми дигәндәй китап укый, белемен арттыра. Мондый егет өчен иң табигый юл, әлбәттә, югары уку йорты. Егерме яшьлек егет икеләнеп тормый—бары тик Казан университетына керергә! Аның да тарих-филология факультетына. Болай карар кылганда, һичсүзсез, ул Кәрим абыйсы киңәшен дә истә тота. 1944 елда биредә татар теле һәм әдәбияты бүлегенең оештырылуы белемгә сусаган яшьләр өчен күк капусы ачылуы кебек була. Әле яңа гына фронттан кайткан Мәхмүт Хөсәен кебек утны-суны кичкән егетләр белән укый Мансур. Ни дисәң дә, ул да җиңүне якынайту өчен тирне аз түкмәгән. Сугыштан яраланып кайткан, инде укуын тәмамлап, аспирантурада фән нигезләрен тирәнәйткән Ибраһим Нуруллиннар янында ничек инде эленке-салынкы йөрисең? Укый, тырыша Мансур һәм кызыл диплом алуга ирешә. Факультетның татар теле һәм әдәбияты бүлеге җитәкчеләре Рабига Афзалова, Хатип Госманнар мондый ачык фикерле һәм унган егетне читкә җибәрәләрме соң?! Алар аңа аспирантурада калырга тәкъдим итәләр һәм ялгышмыйлар. «Татар әдәбияты» белгечлеге буенча аспирантура да узып китә. Ләкин катлаулы тормышның эчендә кайнап яшәгән Мансур көчен төрле юнәлешләргә куярга мәҗбүр. Аны «Татарстан яшьләре» газетасына баш мөхәррир итеп тә билгелиләр. Ләкин ул университеттан аерыла алмый. 1958 елдан кафедрада ассистент, бер үк вакытта декан ярдәмчесе вазифасын башкара.

Югары уку йортында укыткан кеше бер үк вакытта фәнни-тикшеренү эшләре дә алып барырга тиеш. Шуннан башка ул үзенең вазифасын җиренә җиткереп башкара алмый, хезмәтендә яңа биеклекләр яулау өчен дә бу иң мөһим шартларның берсе булып тора.Өйрәнү, тикшеренүләр өчен дә тема эзләп азапланасы юк, бу мәсьәлә аның өчен ачык. Ул университетны тәмамлаган вакытта, бигрәк тә шәхес культы фаш ителгән 1956 елда язучылар, галимнәр арасында гаепсезгә юк ителгән яки төрмәләрдә, сөргеннәрдә тотылган әдипләребез аклана икән, аларның әсәрләре дә җәмәгатьчелеккә кире кайта икән дигән сүзләр ишетелә башлый.Яшереп куелган урыннардан ул әсәрләр әкренләп дөньяга чыга. Алар кулдан-кулга йөртелеп укыла, кызып-кызып сөйләшү өчен нигез була. Әлбәттә инде, андый әсәрләр Мансур кулына да килеп керә тора. 1956 елда Галимҗан Ибраһимовның өч томнан торган сайланма әсәрләре дә басылып чыга. Ул андагы әсәрләрне йотлыгып укый. Ни өчен дигәндә, университет елларында алар белән танышу мөмкинлеге юк иде бит. Аның исе китә, без моңа кадәр никадәр байлыктан мәхрүм булып яшәгәнбез икән бит! Боларны халыктан яшереп тоту үзе бер җинаять дип саналырга тиеш. Әлеге томнарны укып барганда, ул «Алмачуар» повестена юлыга. Үсмер чакта иптәшеннән алып торып укыган, шуннан бирле ничә еллар күңелендә йөрткән әсәрнең Галимҗан Ибраһимовныкы икәнлеген белеп, аның исе китә. Менә кем турында сөйләгән икән бит теге Алабугадагы абый Кәрим Жаманаклы. Ул, әлбәттә, авторның кем икәнен белгән, тик ул вакытта олуг әдипнең исемен әйтергә ярамаган. Шулай да ул аны «бик яхшы кеше иде» дип атарга җөрьәт иткән. Мансур өчен мәсьәлә ачык иде—ул, һич тә читкә тайпылмыйча, Галимҗан Ибраһимов иҗатын өйрәнәчәк! Башта ул

анын барлык әсәрләрен, фәнни хезмәтләрен, публицистикасын укуны максат итеп куя. Аннан соң тормыш юлын нечкәләп күздән кичерәчәк. Сүз дә юк, язучы яшәгән һәм иҗат иткән заманны өйрәнмичә, нинди дә булса төпле сүз әйтермен димә. Шулар турында белгәннәренә таянып кына хакыйкый фәнни карашлар уздырырга мөмкин булачак. Яшь галим муеныннан тикшеренү эшенә чума. Ниһаять,1961 елда ул «Галимҗан Ибраһимовның Октябрьгә кадәрге иҗаты» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый, доцент була.

Утыз бер яшьлек фәннәр кандидаты, төпле сүзле, чын мәгънәсендә эшлекле яшь галим, әлбәттә, республика житәкчеләре күзенә дә чалына. Аны 1961 елда партия өлкә комитетының лекторы итеп эшкә чакыралар. Шул ук елның көзендә инде ул шушы югары органның мәдәният бүлеге мөдире булып эшли башлый. Өч елдан аны исә фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире итеп билгелиләр. Ул гаять күпкырлы һәм мөһим бу эштә 1971 елга кадәр, ягъни Татарстан Республикасы Министрлар Советы Рәисе урынбасары итеп билгеләнгәнче, эшли. Инде 1984-1992 елларда без аны Хөкүмәт житәкчесенең беренче урынбасары дип беләбез. Бу югары урыннарда эшләгәндә М. Хәсәнов мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт, социаль тәэминат тармакларына житәкчелек итә. Ул республикабызда гомуми һәм урта махсус, югары белем системасын камилләштерүгә, сәнгать һәм мәдәният учреждениеләре эшен ныгытуга, министрлыклар һәм ведомстволар, шәһәр һәм район структураларының төгәл эшләвен тәэмин итүгә, халык хуҗалыгы һәм мәдәният өчен кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирә.

Хөкүмәт житәкчеләренең берсе буларак, М. Хәсәнов белем, мәдәният, сәламәтлек саклау, спортның матди-техник базасын ныгытуга бөтен көчен сала. Бу тармакларга ул житәкчелек иткән егерме ел вакыт эчендә республикада 500 мең укучыга исәпләнгән 1100 типовой мәктәп төзелә. Әгәр дә барлык укучылар санының ул елларда ярты миллион булганлыгын искә алсак, шул ике дистә елда нигездә мәктәпләрнең укыту-материаль базасы яңартылганлыгы аңлашыла. Һөнәр училищеларының да шушы чорда нык тармаклануын искә алыйк. Һәр районда авыл хуҗалыгы, төзүче профессияләре буенча училище ачыла. Кукмара кебек житештерү челтәре аеруча үсеш алган кайбер районнарда алар хәтта икешәр дә була. Яңа уку елына Татарстанда ел саен 20-22 мең укучыга исәпләнгән 55 яңа мәктәп өлгерә, шунысы мөһим, алар заманча таләп буенча салына, тиешле техник әсбаплар белән жиһазлана. Бер елны, мәсәлән, бу эштә Татарстан Мәскәүнең үзен дә артта калдыра. Республикабыз Бөтенроссия ярышында еш кына беренчелекне яулый.

Житмешенче еллар башында мәктәпкәчә балалар учреждениеләре белән тәэмин ителү Татарстанда нибары 20-22 процент кына була. Бу хәлгә иң әүвәл Мансур Хәсән улы борчыла. РСФСРның күп регионнарында бу юнәлештәге эш күпкә яхшырак бара. Эш анда гына да түгел, иң мөһиме—үзебездә ихтыяж гаять зур. Өлкә комитеты бюросындамы, иң югары житәкчелек белән аерым сөйләшүләрдә дисеңме—РСФСР, СССР житәкчеләренә үтенеч-гозер белән керүләр дисеңме, берсе дә калмый. Мансур Хәсән улы көн-төн чаба. Болар нәтиҗәсез калмый. Республикада балалар бакчалары төзү темпы бик нык тизләнә. Алар үзәкләштерелгән капиталь чыгымнар исәбенә генә түгел, сәнәгать предприятиеләре, нефть, химия, машина төзелеше, колхоз-совхозлар исәбенә дә күтәрелә һәм жиһазландырыла. Мансур Хәсәнов менә шундый күп кенә мәсьәләләрне күтәреп чыга, өлкә комитеты бюросы һәм Хөкүмәт карарлары проектларын әзерли, алар гамәлгә ашырыла башлагач, үзе үк, жиң сызганып, шул эшләргә житәкчелек итә. Инде сиксәненче еллар ахырына таба республикада балалар бакчалары белән тәэмин ителеш 80 процентка житә. Моның исә балаларны мәктәпкә яхшырак әзерләүдә, ата-аналарның тыныч күңел белән хезмәт итүләрендә, тормышларын алып баруда уңайлыклар тудырудагы әһәмияте әйтеп бетергесез зур була.

Житмешенче-сиксәненче елларда Татарстанда хастаханәләр, поликлиникалар, санэпидстанцияләр һәм башка учреждениеләрне төзү дә бик күп алып барыла. Бигрәк тә авыл кешеләренең сәламәтлеген саклауны яхшыртуга зур игътибар бирелә. Күп кенә район хастаханәләрен һәм амбулаторияләрен төзү, һәр районда санэпидстанцияләр булдыру, табибләрне һәм кече медицина хезмәткәрләрен

торак белән тәэмин итү—кичектергесез бурыч буларак карала. Шулай ук мәдәният йортлары, авыл клублары һәм китапханәләр дә нәкъ менә шул унъеллыкларда күпләп калка.

Шундый мәһабәт төзелешләр арасында аеруча мөһимнәре бар. Алыйк, бөек шагыйребез Г. Тукайның туксан еллыгына багышлап Кырлай авылында ачылган мемориаль комплексны. Әллә ул җинел генә калкып чыктымы? Юк, әлбәттә! Каршылыклар зур булды. Бу мәсьәлә буенча Министрлар Советы биш тапкыр карар кабул итә. Аларны әзерләү, унай хәл ителүләренә ирешү М. Хәсәновтан яхшы мәгънәсендә үҗәтлек сорый. Комплексның проектын рәсем сәнгатендәге бөек шәхесебез Бакый ага Урманче әзерли. Мансур Хәсәнович үтенүе буена ул үзе үк карап эшләтә дә.

Без ел саен Г. Тукай туган апрель аенда Кырлайда булырга тырышабыз. Баруларыбызның берсендә авыл агайлары төзелеш көннәрен искә алып болай сөйләшеп тордылар:

—Бакый ага бигрәк таләпчән булды инде. Һәр бүрәнәне, агачны шәхсән үзе кабул итеп алды. Күбесен, яраксыз дип табып, читкә алып куйдырды. Бу ниндидер каприз түгел иде. Мансур Хәсәнов аның сүзен сүз итте, бөтенесен Бакый ага теләгәнчә эшләтте. Кирәкле материалларны Татарстанның әллә кайсы почмакларыннан китертте.

Чыннан да, бу комплекс һәрвакыт татар халкы өчен иң кадерле урыннарның берсе булып торыр. Аның алдындагы Г. Тукай скульптурасы, хаклы рәвештә, Бакый ага Урманченың иҗат көчен раслый. Болар, һичсүзсез, М. Хәсәновның оештыру талантының да матур чагылышы.

Казанда мәдәният институтын (хәзерге мәдәният һәм сәнгать университеты), Чаллыдагы педагогия институтын, шулай ук физик культура һәм спорт институтын ачуда башлап йөрүче М. Х. Хәсәнов булды. Моның өчен ул ничә тапкырлар СССР Югары белем министрлыгына, СССР Дәүләт план комитетына, КПСС Үзәк Комитетына барды һәм аларны ачу буенча махсус карарлар кабул ителүгә иреште. Татар халкының дәүләтчелеген торгызу юлында корбан булган Мулланур Вахитовка Казаныбыз уртасында һәйкәл кую да Мансур Хәсән улы тырышлыгыннан башка булмады. М. Вахитовның татар халкын ил күләмендә яклауда, аның таләпләренә колак салу кирәклеген катгый итеп куюда өлеше аз булмады. Шуның өчен, тарихыбызда мөһим роль уйнаган эшлеклебезне шул рәвешле мәңгеләштерү дөрес гамәл иде. Ә менә С. Сәйдәшев, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ һәм башка хөрмәтлеләребезгә һәйкәлләр кую мәсьәләсе, М. Хәсәнов тарафыннан берничә тапкыр күтәрелүгә карамастан, тиз генә яклау тапмады. С. Сәйдәшевкә бюст куяргамы, әллә аны тулы гәүдәсендә сурәтләргәме дигән мәсьәлә Казанда түгел, Мәскәүдә хәл ителә торган заманнар иде ул.

Мансур Хәсәнов—республикабызда югары хакимият кәнәфиләрендә иң озак утырган, шуңа да карамастан, халык арасында чын мәгънәсендәге кешелеклелек абруен саклап кала алган шәхесләребезнең берсе. Бу фикерне раслау өчен бер генә мисал китерәм. Милләт мәнфәгатьләрен яклау иң кызган көннәрнең берсендә ТДАТ бинасында Татар иҗтимагый үзәгенең беренче корылтае җыелды. Республика житәкчелегеннән вәкил булып анда М. Хәсәнов катнашты. Ул елларда корылтайлар да урам митингларыннан әллә ни аерылмый иде. Ораторлар, берсеннән-берсе уздыра-уздыра, кайнарланып сөйлиләр, сүзләрне дә артык сайлап тормыйлар, кем әйтмешли, турыдан гына бәрәләр. Театр бинасы кайнап тора, һәр кеше «радикаль» дулкынга көйләнгән, нервлар соңгы чиккә житеп киерелгән. Кемдер «кирегә сукалый» торган сүз әйтсә, тегенең якасыннан алуга ук барып житәргә мөмкин. Шул рәвешле, корылтай көн буе кайнады, кызды һәм... иң югары ноктасына житкәндә, сүз Мансур Хәсәновичка бирелде. Уйлап карасаң, әлеге мизгелләрдә никадәр җаваплылык иде бу кешенең җилкәсендә. Бер яктан, корылтай рухын дәвам иттереп сөйләргә кирәк, икенче яктан, кайбер арттырып җибәргән кайнар башларны суыта төшү бурычы да тора. Акыллы һәм тәҗрибәле Мансур Хәсәнович биредә тиешле интонациясен дә, бу очракта гына әйтергә мөмкин булган сүзләрне дә тапты. Кискен итеп куелган барлык сорауларга җавап бирде, алай гына да түгел,

алга таба хәрәкәтнен корылтай кабул итәрлек программасын да бирде. Һәм бу чыгыш хәлиткеч булды. Инде алга таба сөйләшү жайлы гына тиешле эздән китте. Мансур Хәсәнович тормышыннан мондый мисалларны күп китерергә мөмкин булыр иде.

Әйе, кайда авыр, яна бурычларны хәл итәсе бар, М.Х. Хәсәновны шунда куйдылар. 1991 елнын азагында республикабызнын Фәннәр академиясе оешты. 1992 елнын февралендә академиянен гомуми жыелышында анын президенты итеп Мансур Хәсән улы Хәсәнов сайланды. Бу—галим, житәкче, оештыручы буларак, анын зур хезмәтләрен тану, бәяләү иде.

Галимлек баскычлары шулай ук сикәлтәле, бормалы. Ул үзеннен бөтен барлыгынны жигеп эшләүне таләп итә. Бигрәк тә хөкүмәт, жәмәгать эше белән бергә үреп алып барганда шулай. Ассистенттан—профессорга, аспиранттан академикка кадәр күтәрелү өчен, ай-һай, нинди зур хезмәт куярга кирәк! Әгәр дә М. Хәсәновнын гыйльми эзләнүләрне һәрвакыт житәкчелек һәм жәмәгать эшләре белән бергә үреп алып барганлыгын истә тотсак, анын үз-үзен «эшкә» жигә белү сәләтенә сокланырга гына кала!

М. Хәсәнов фәнни тикшеренүне берничә юнәлештә алып барды. Ин әүвәл ул татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә зур көч салды. Халкыбызнын тарихын оныттырырга теләгәннәре кебек, анын үткәндәге әдәби мирасын барлау да хупланмаган заманнар бар иде. Хәтта «Идегәй» кебек дастаннар да тыелган әсәрләр исәбендә йөртелде. Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, К. Тинчурин һәм башка классикларыбыз ижатларынын фәлсәфи нигезләрен ачу, эстетик кыйммәтләрен бәяләү юнәлешендә галим нәтижәле эшләде. Анын ин мавыккан һәм эзлекле тикшеренү объекты, инде әйтелгәнчә—XX гасыр татар әдәбияты классигы, олы әдип Галимжан Ибраһимов. Әлбәттә, Г. Ибраһимовнын бер үк вакытта олы әдип, күренекле галим һәм жәмәгать эшлеклесе булуы да кызыксындырды аны. Шул ук вакытта бу шәхеснен фажигале язмышы да өйрәнүне, гадел бәя бирүне сорый иде. Утызынчы еллардагы фажигале хәл-әхвәлләрне шундый затларыбызнын язмышлары аша ачу да мөһим бурычларнын берсе булып алга килеп басты. Мәгълүм булганча, Г. Ибраһимовка да «халык дошманы» дигән кара мөһер сугылды, 1937 елдан алып 1956 елга кадәр исеме тыелды. Чөнки Сталиннын бөтен мәкерлеге шунда булды, ул, социализм идеяләренә тугры булган шәхесләрне юк итеп, Ленин юлы белән барган булып кыланып, чынлыкта исә илдә явызлык нигезләренә корылган система урнаштырды. Бу юлда ана уйлы-фикерле кешеләр кирәк түгел иде. Сталинга фанатикларча бирелгән, анын әйткәннәрен үзеннән дә арттырып үтәүче роботлар булса, шул житә иде. Г. Ибраһимов шуна күрә «артык» шәхесләрнен берсе булып чыкты һәм рәхимсез рәвештә юк ителде. Әмма халыкта анын белән кызыксыну бик көчле иде. Ник дигәндә, ул, теләсә кайсы әдәбиятнын йөзек кашыдай әсәрләр язып, укучыларнын мәхәббәтен яулап өлгергән зур талант буларак танылган иде. Шуна күрә 1956 елда басылып чыккан томнарын халык ябырылып укыды. Афәтле елларда шактый коргаксып калган әдәбиятыбызга Г. Ибраһимов, М. Жәлил, Х. Туфан, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш һәм башка олы исемнәрнен, аларнын әсәрләренен әйләнеп кайтуы әдәби үсешебезгә яна сулыш өрде, ижат биеклекләре үлчәмен югары күтәрде. Әлеге исемнәрне белми үскән буыннарга гына түгел, гомумән, тулаем халкыбызга хакыйкатьне ачып салырга кирәк иде. М. Хәсәнов шушы эшкә алынды.

Фән әһеле буларак, М. Хәсәнов төп бер нәрсәгә тугрылыклы: ул һәрвакыт кире кагылгысыз дәлилләргә, чыганакларга таянып кына эш итә. Нинди дә фаразларга, имеш-мимешләргә таяну ана хас түгел. 1964 елда чыккан «Галимжан Ибраһимов: тормыш һәм ижат юлы» дигән монографиясен язганда ул классик әдибебезнен 279 әсәрен һәм хезмәтен, анын турында бик күп авторлар тарафыннан язылган 432 хезмәтне жентекләп тикшергән, күнел күзе аша үткәргән. Бу кадәр фәнни әдәбиятны барлап, системага салу үзе—тау кадәр эш. Әмма бары тик шундый зур эзләнү нәтижәсе булган хезмәтләр генә житди ачыш санала һәм озын гомерле була ала. Алда телгә алынган татар һәм рус телләрендә алтмышынчы елларда чыккан монографияләр—бүгенге көнгә кадәр классик әдибебез Г. Ибраһимов турындагы төп фәнни хезмәтләр. Галим бу темага гомер буе тугры булып калды. «Язучы, галим һәм революционер» (рус телендә) дигән монографиясе 1987 елда Мәскәүдә «Фән»

нәшриятында басылып чыгу татар әдәбиятының, аның фәненең абруе артуга тагын бер житди нигез булды. «Татар әдәбияты тарихы»ның дүртенче томындагы (1989) Г. Ибраһимов хакындагы күләмле мәкаләнең авторы да М. Хәсәнов. Яна шартларда, бөтен белгәннәреңне хакыйкый нигезләргә таянып әйтү мөмкинлеге булган чорда, Г. Ибраһимов иҗатына һәм шәхесенә карата булган фикерләрен ул даими бәян итә килде. 1971 елда Г. Ибраһимов иҗатының Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорына багышланган докторлык диссертациясенең СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында яклануы да үз вакытында бик әһәмиятле вакыйга булган иде. Чөнки Г. Ибраһимов, чыгышы белән татар булса да, бер үк вакытта барлык Көнчыгыш халыклары әдәбиятлары өчен бер якты үрнәк булды. Галим М. Хәсәнов шуны тәфсилле итеп күрсәтә алды. Бүгенге көндә мәктәп укучылары, студентлар, аспирантлар өчен дә бу хезмәтләр бик файдалы чыганак булып хезмәт итә. Шулар өстенә М. Хәсәнов бөек язучыбыз Г. Ибраһимов әсәрләренең сигез томлыгын чыгаруны башлап йөрүче һәм шуны тормышка ашыручыларның да берсе булды (1974-1987). Дөрес, шактый соңрак тагын бер том пәйда булды. Ләкин әле хәзер дә Г. Ибраһимов әсәрләре китап хәлендә тулысынча укучыга ирештеләр дип әйтеп булмый. Инде бу эшне М. Хәсәновның яшь коллегалары дәвам иттерерләр дип ышанырга кирәк.

М. Хәсәнов—татар әдәбиятының алты томлык тарихын әзерләүгә һәм бастырып чыгаруга да житәкчелек иткән затларыбыздан. Шул ук вакытта ул урта мәктәпләр өчен дәреслекләр, кулланмалар язуга да житди өлеш кертә. Шәхсән минем үземә аның белән 1994 елда гомуми урта белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек язуда катнашырга туры килде. Тагын А. Әхмәдуллин һәм И. Нуруллиннар катнашында дөньяга килгән бу дәреслек укытучылар, укучылар, җәмәгатьчелек тарафыннан унай кабул ителде. Ул бүген дә укучыларга белем һәм тәрбия бирүгә хезмәт итә. Р. Харрасова аның турында болай дип язды: «Минем уйлавымча, соңгы елларда язылган дәреслекләр арасында бусы иң уңышлысы. Ул бүгенге унынчы класс укучысының фикерләү сәләтен үстерүне, әдәби әсәрне яраттыруны үзмаксат итеп куйган. Билгеле, укучы бу дәрәҗәдә әсәрне аңласын өчен аның алдагы елларда да төпле белем алуы шарт. Дәреслекләр иң түбән дәрәҗәдә фикер йөртүче, белемгә тәмам омтылышсыз укучылар өчен язылырга тиеш түгел. Алар, чынлап әйткәндә, әле безнең күп кенә укытучыларыбыз өчен дә берданбер таяну ноктасы. Нинди генә дәреслек язылса да, мәктәп укытучылары белән очрашканда «бала өчен түгел, минем өчен дә катлаулы» дигән сүзләрне ишетергә туры килгәли. Математик теоремаларны чишә ала торган укучыларны без әсәр өстендә дә эшләргә өйрәтә алырга тиеш. Бу юнәлештә зур эш башкарган дәреслек авторларына чын күңелдән рәхмәтемне житкерәсем килә»*(Шәһри Казан. 1994. 23 декабрь)*. М. Хәсәнов педколледжлар өчен дә татар әдәбияты программалары төзүгә житәкчелек итте.

М. Хәсәновның фәнни эшендәге тагын да мөһим юнәлешләрнең берсе—әдәбият белеменең методологик проблемаларын эшләү, халкыбызның иҗтимагый һәм фәлсәфи фикерен, милли мәгариф һәм педагогика тарихын өйрәнү. Бу мәүзуларга аның шактый мәкаләләре һәм фәнни конференцияләрдә укылган докладлары багышланган. Шул исәптән, соңгы елларда фәнни тикшеренүләрдә мөһим роль уйнаган бер мәкаләгә аерым игътибар итәсе килә. Ул «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре» дип атала. Автор әйткәнчә, «электән килгән караш-принциплар җимерелә, гасырларда яшәр сыман булып лозунгка әверелгән купшы вәгъдә-ышанулар сына, ватыла, ишелә» барган бер вакытта эстетиканың һәм мәдәният теориясенең бик мөһим, фундаменталь положениеләре, милли культураның, әдәбиятның һәм сәнгатьнең тормыштагы, кеше язмышындагы роле, миллилек һәм интернациональлек төшенчәләренең мәдәнияттә, сәнгатьтә, гомумән, рухи тормышта үзара мөнәсәбәте мәсьәләләре янадан» каралырга тиеш. Һәм галим шушы гаять зур бурычларны хәл итүнең методологик нигезләрен билгели. Күренекле галимнәр Тәлгат Галиуллин, Азат Әхмәдуллин, Әбрар Кәримуллин, Миркасыйм Госманов, Нурмөхәммәт Хисамов, Флүн Мусин, Резидә Ганиева, Зөфәр Рәмиев, Флүн Мусин, Марсель Әхмәтҗанов, Хатыйп Миңнегулов, Дания Заһидуллина, Ким Миннуллин, Назим Ханзафаров, Фәрит Бәширов, Рим Салихов,

Эльмира Галиева, Фәрит Хатипов, Әнвәр Шәрипов һәм башкаларның гыйльми эзләнүләрендә болар чагылыш тапты. Кыска гына вакыт эчендә алар тарафыннан әдәбият фәненең күп төрле аспектлары әтрафлы тикшерелде, байтак фундаменталь характердагы хезмәтләр язылды. Бу юллар авторының да 1998 елда «Мәгариф» нәшриятында «Эстетика һәм социологизм» дигән һәм егерменче, утызынчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәтен өйрәнүгә багышланган китабы басылып чыкты. Бу—докторлык диссертациясенең монографиясе иде. 1999 елның 25 февралендә Казан дәүләт университетының күренекле галим Т. Н. Галиуллин рәислегендәге махсус советында әлеге диссертациямне яклаган чагында рәсми оппонетларымның беренчесе М. Х. Хәсәнов булды. Ул минем хезмәткә әтрафлы һәм тирән анализ ясады, алга таба эшләү өчен бурычлар билгеләде һәм мина фән докторы булырга үзенең фатихасын бирде. Ул докторлык диссертациясе яклаган ике дистәгә якын кешегә оппонент булган икән. Шуларның берсе үзем булу белән бик тә горурланам.

Мансур Хәсән улы олы фән юлына фатиха биргән галимнәр арасында без Р. К. Ганиева, Ә. Г. Мәхмүдов, М. Х. Бакиров, Ә. З. Нигъмәтуллин, Н. Г. Ханзафаров, Х. Й. Миннегулов, Э. Р. Галиева, Р. С. Мөхәммәдиев һәм башкаларны күрәбез. Аның житәкчелегендә 6 докторлык, 12 кандидатлык диссертациясе язып якланган. Шунысы мөһим, ул юл күрсәткән галимнәр фәнни тикшеренүләрдә, укыту-педагогик эшчәнлектә, жәмәгать эшләрендә актив булып калалар, куанычлы нәтижәләргә ирешәләр. Монда остаз үрнәгенең йогынтысы күренеп тора. Чөнки М. Хәсәнов үзе дә Казанда һәм Мәскәүдә дистәгә якын монография, Казан, Мәскәү, Лондон һәм Анкарада татар, рус, инглиз, төрек һәм башка телләрдә йөзләрчә мәкаләләр бастырды. Ул XIX йөздән алып XX йөзнең икенче яртысына кадәрге чорда татар һәм рус әдәбиятлары бәйләнешен дә өйрәнде. Бу циклдан булган хезмәтләрне язуда профессор Ф. Мусин да катнашты, әлеге юнәлеш СССР Фәннәр академиясенең Рус әдәбияты институты (Пушкин йорты) белән хезмәттәшлектә башкарылды. Бу эзләнүләрнең нәтижәсе 1988 елда Ленинградның «Фән» нәшриятында «Взаимодействие и взаимообогащение» дигән махсус жыентыкта һәм журналларда басылды.

Татар халкының рухи мирасын торгызу проблемалары буенча алып барылган тикшеренүләр М. Хәсәновның заман таләпләре белән бергә атлап баручы галим икәнлеген яңа көч белән раcладылар. XIX гасырның икенче яртысы һәм XX йөзнең башында яшәгән һәм ижат иткән Ш. Мәржани, С. Максуди, Г. Исхакый, Р. Фәхретдинов, М. Бигиев һәм башка фикер ияләренең мирасын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре аеруча игътибарга лаек. Алар, бердән, танып-белү әһәмияте ягыннан кыйммәтле булса, икенчедән, аларда мөһим методологик күрсәтмәләр дә бар. Бу мәсьәләләргә багышлап галим монография дә яза башлаган иде. Ул аны төгәлли алмады булса кирәк. Түбән өлкәсендә яшәп, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Гаяз Исхакый ижатына багышлап докторлык диссертациясе язган Хәбибә Шаһбанованың фәнни тикшеренүенә житәкчелек итүен дә М.Хәсәновның шушы юнәлештәге бер игелекле эше дип карарга кирәк. Шунысын да әйтергә кирәк, сиксәненче еллар ахырында һәм туксанынчы еллар башында әдәбиятыбыз классигы һәм зур жәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның исемен һәм мирасын ватаныбызга кайтаруда да М. Х. Хәсәновның өлеше зур булды. Ул фатиха бирмәгән очракта бу эшнең әле тагын беразга сузылу ихтималы бар иде. Алай гына да түгел, Г. Исхакый мирасының унбиш томлыгын бастырып чыгару турында карар кабул итүнең дә башлап йөрүчесе ул булуын бүген канәгатьләнү хисе белән искә алабыз. Ул китапларның берничәсе аның житәкчелегендәге редколлегия тарафыннан әзерләп чыгарылды да инде. Хәзерге көндә Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында чираттагы томнарны бастыруга әзерләү буенча эш алып барыла.

Безгә халкыбызның тарихын да чын мәгънәсендә тирән тикшереп, хакыйкый итеп аякка бастырырга кирәк. Чөнки моңа кадәр чит-ят авторларның махсус идеологиягә корылган хезмәтләре халкыбыз үткән юлны еш кына бозып күрсәтеп килделәр. Ә менә Л. Гумилев, М. Худяков кебек намуслы галимнәр мөмкин кадәр дөреслеккә туры калып эш иттеләр. А. Халиков, С. Алишев, Р. Фәхретдинов,

Ә. Мөхәммәдиев, М. Госманов, И. Таһиров, Р. Вәлиев кебек галимнәребез бу өлкәдә тикшеренүләрне нәтиҗәле дәвам иттерделәр. Әмма заман бу эшне тагын да киңрәк колачлы итеп оештыруны таләп итә. Менә ни өчен М. Хәсәнов, Татарстан Фәннәр академиясе президенты буларак, махсус Тарих институтын аерып чыгару бурычын куйды. Һәм шундый институт оешты да. Аның җитәкчесе итеп халкыбызның күренекле һәм абруйлы шәхесе Рафаэль Хәкимов билгеләнде (әле яңарак кына аның рәсми рәвештә тарих фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алуы барыбызны да сөендерде). Галимнәребезнең көчен берләштерү үзенең нәтиҗәләрен дә бирде. Әйтик, моннан берничә дистә ел элек галимнәр Казанның төзелә башлавына ничә ел икәнлеге мәсьәләсендә уртак бер фикергә килә алмаганнар иде. Башкалабызның тарихын өйрәнү буенча да методологик нигез кирәк булды. Татар халкы тарихында Казан элек-электән хәлиткеч роль уйнады, күп кенә мөһим вакыйгаларның үзәге була килде. Казанның тарихын дөрес билгеләү—халкыбызның үткәненә ачык караш булдыру дигән сүз. Бу эшкә әле генә искә алынган Тарих институты, Казан университеты, Мәскәү, С.-Петербург, чит илләрнең егермеләп фән үзәкләре тартылды, шәһәребезнең җитәкчелеге дә читтә калмады. Эш барышында өч тапкыр халыкара фәнни конференция җыелды. Аларда соңгы вакытларда тупланган археологик табылдыклар һәм башка тарихи чыганаклар файдаланылды, бик күп фәнни мәгълүматлар әйләнешкә кертелде. Боларның нәтиҗәләре Татарстан Фәннәр академиясенең президиумында һәм Россия Фәннәр академиясенең тарих бүлегендә тикшерелде. Шуларга таянып, 2005 елда Казанның 1000 еллыгын уздыру турында Татарстан һәм Россия Федерациясе президентларының фәрманнары барлыкка килде. М. Хәсәнов шушы бәйрәмгә әзерләнү буенча Дәүләт комиссиясенә әгъза итеп кертелде. Мәгълүм булганча, әлеге комиссиянең утырышы уздырылды, әзерлек программасы тәгаенләнде, аны чынга ашыру буенча гаять киң колачлы һәм төрле юнәлешле эш алып барылды. Мең еллык—дөнья күләмендә яңгырарлык олы бәйрәм булып әверелде. Иң мөһиме—җир шарының барлык кыйтгалары татар халкының борынгы кавем булуын, аның дәүләти тарихы бик бай икәнлеген белде һәм таныды, бу исә аның бүгенгесе белән кызыксынуны да арттырды.

М. Х. Хәсәновның җитәкчелек итү таланты Татар энциклопедиясе институты директоры вазифасын башкарганда тагын бер тапкыр расланды. Ул күптомлы Татар энциклопедиясенең баш редакторы итеп тә билгеләнде. Бу зур эшнең беренче нәтиҗәсе озак көттермәде. Энциклопедиянең сүзлеге 1999 елда Лондонда басылып та чыкты. Аны тәкъдир итү вакытында М. Ш. Шәймиев галимнәр коллективының бу эшенә югары бәя бирде. Мин шушы сүзләр әйтелгән вакытта Мансур Хәсәновичның йөзен күзәттем. Әлбәттә, аның күзләрендә җитәкчебезнең бу бәясен тыңлаудан канәгатьлеге чагылды, ләкин шул ук вакытта ул бөтен кыяфәте, торышы белән әле зур эшнең башы гына икәнлеген дә аңлата иде. Халкыбыз «башланган эш—беткән эш», ди. Менә бүгенге көндә әлеге зур хезмәтнең рус телендә—дүрт, татарча бер томы басылып, халкыбыз һәм дөньяның гыйльми җәмәгатьчелеге кулына килеп керде. Хезмәт татар халкын танытуда гаять мөһим эш башкара. Мансур Хәсән улы аны алга таба инглиз телендә дә бастыру турында хыяллана иде. Олуг остазыбызның бу васыятен тормышка ашыру юнәлешендә бүгеннән үк хәрәкәт башларга кирәктер.

Әйе, чын галимнән һәрвакыт тау кадәр башкарылган һәм тормышка ашырыласы эшләр кала, диләр. Мансур Хәсән улының да хыяллары зур иде. Ул бөтен аңлы гомерен туган халкына багышлады, яшәвенең бөтен мәгънәсен аңа хезмәт итүдә күрде. Шуңа күрә халык хәтере аның өчен мәңгелек һәйкәл булыр.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

# УЙЛАНДЫРА ТОРГАН УЙЛАР

Җамал Вәлидинен (1887-1932) гыйльми эшчәнлеге һәм күп санлы хезмәтләре, кабатланмас бай мирасы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, файдаланылмаган. Билгеле бер чорларда алар махсус рәвештә тулаемы белән оныттырылып торган, хәтта актив төстә кире кагылган иде. Кыскасы аның мирасы бары соңгы елларда гына әкеренләп, өлешләп кенә кайтарыла башлады. Мәсәлән, монарчы басылган аерым мәкаләләрдән тыш тирән фикер иясе, киң колачлы галимнең тел белеменә караган хезмәтләренең бер өлеше генә аерым китап рәвешендә янадан дөньяга чыкты («Мәгариф», 2007 ел). Анысы да галимнең тууына 120 ел тулу мөнәсәбәте белән.



Ләкин бу китап һәм мәкаләләр галим вә фикер иясе эшчәнлегенең бер почмагын гына яктырта. Чынлыкта Җамал Вәлиди ул киң колачлы, тирән белемле, сизгер телче булу белән бергә, үткер күзле, югары зәвыкле әдәбият белгече дә, тормыштагы, элекке чынбарлыгыбыздагы фактларның, катлаулы социаль-иҗтимагый күренешләрнең сәбәпләрен, табигатен, аларның эчке бәйләнешләрен күрә белгән, анлата алган көчле тарихчы да–боларның һәммәсенә югарыдан карап этрафлы, эзлекле бәһа бирә торган фикер иясе, ягъни философ та иде. Ниһаять, публицистик рухлы үткен каләмгә ия булган Ж.Вәлиди гаять оста, ләкин бер вакытта да объективлыкка анлы рәвештә хилафлык итмәгән гадел, туры сүзле вә көчле полемист, гомумән намуслы кеше буларак та танылган шәхес иде. Җыеп әйткәндә, Җамал Вәлидинен киң колачлы, күпкырлы мирасын тулаемы белән инләп алыр, иҗади үзләштерер өчен безгә әле бик күп эшләргә туры киләчәк. Әгәр дә мәдәни мирасыбызны төгәлрәк, объектив рәвештә үзләштерүне максат итеп куйсак...

Мәсьәләнең шушы ягын исәпкә алып, «Җыен» фонды «Шәхесләребез» сериясеннән Җамал Вәлидигә багышланган бер җыентык әзерли (төзүчеләре–мәрхүмә Диләрә Абдуллина һәм доцент Җәүдәт Миннуллин).

Әлбәттә, бу җыентык та галим эшчәнлегенең, аның бай иҗатының барлык тармакларын да яктыртуны максат итеп куймый–анардан калган мирас бер-ике генә китапка сыярлык түгел. Тәкъдим ителә торган җыентыкка исә төрле характердагы документлардан, материаллардан тыш, нигездә әдәбият тарихына, әдәби тәнкыйтькә караган, кайбер күренекле шәхесләребезгә багышланган һәм шул чор мәдәни тормышыбызның аерым сәхифәләрен яктырткан материаллар тупланачак.

Менә шул җыентыкны редакцияләп утырганда, кайчандыр Җамал Вәлиди күтәреп чыккан мәсьәләләрнең XX гасыр башында гына түгел, бәлки йөз елдан соң да актуаль булып калулы игътибарны җәлеп итте. Татарлар үз чынбарлыгының кайбер төп мәсьәләләре буенча 1910 елларда ничек борчылган, газапланган булсалар, 2010 елларда да шул ук халәттә кала биреп, шул ук мәсьәләләр белән башларын авырттырып, «Нишләргә?» дигән сораудан һаман арына алмаган икән!

Әйтерсең лә, 1917 елгы инкыйлап та булмаган, 60-70 ел дәвамында «ин гадел» вә «иң кешелекле» җәмгыять тә төзеп маташмаганбыз... Гуяки, тарих боҗрасы буйлап бара-бара, нәкъ элекке хәлебезгә кайтып төшкәнбез...

Дөрес, беркадәре аермалар да бар сыман. Ләкин алда торган мөкаддәс максатлар һәм аларга таба булган омтылышларда, әгәр төптән уйласаң, әлләни үзгәрешләр дә юк шикелле...

Җамал Вәлидинең үземне шундый каршылыклы уйларга батырган бер борчулы мәкаләсе белән-ә андыйлар җыентыкта буйдан-буйга диярлек–журнал аша киңрәк катлам укучыларны да таныштыруны кирәк дип таптым.

Бергә-бергә уйлансак, узган гасырда ук алда торган әлеге мәсьәләләр һәм «Нишләргә?» ише сорауга җавапларның янарак вариантлары табылыр, бәлкем?..

Төптәнрәк уйланыйк...

**Миркасыйм ГОСМАНОВ**

---

Җамал
Вәлиди

# МИЛЛИ МӘКТӘП ВӘ МИЛЛИ ТЕЛ

Казанда Фатыйха ханым Аитова тарафыннан тәэсис ителгән[1] мөселман кызларына махсус гимназиянең ачылу мәрасиме булды.

Бу эшне Казан матбугаты бер зур милли вакыйга итеп тәләкъкый[2] итте. «Йолдыз»ның бу тугърыда Г. Баттал имзасы белән язылган баш мәкаләсе: «Татар халкы дөньяда яши башлагандан бирле булмаган бөек бер вакыйга», диеп башлана.

Берничә еллардан бирле дәвам иткән бер мәктәпнең министр тарафыннан тасдыйк ителүе олуг татар кавеменең тарихындагы иң бөек бер вакыйгамы, юкмы, буны, әлбәттә, һәркемдән элек «Татар тарихы» язучы Г.Баттал әфәнде белергә тиеш. Ләкин шулкадәресе бар ки, Г.Баттал әфәнде бу сүзе белән татарның мескин күнеленә вә беркатлы вөҗданына мәгъсум[3] тәрҗемандыр.

Русияне тәшкил иткән милләтләр арасында безнең татар вә мөселман халкы шулкадәр мескин вә шулкадәр канәгатькяр ки, ул бер милли мәктәпнең хөкүмәт тарафыннан тасдыйк ителүенә булган шатлыгыннан үзенең тарихында булган олуг вакыйгаларны онытадыр.

Буның өчен, әлбәттә, Баттал әфәндене һәм аның язганы кебек уйлаучы башка бик күп мөселман кардәшләрне гаепләп булмый. Буның өчен тарих гаепле, фәләк[4] гаепле. Йорты вә малы янып, тәләф булган бер бичара, күмер вә көлләр арасында эзләнгәндә, эшкә ярарлык кечкенә генә бер әйберен тапса да, башлары күккә тиячәк түгелме?

Фатыйха ханымның мәктәбе әллә кайчаннан бирле бар иде һәм аның дәрәҗәсендә эш күрүче башка мәктәпләр дә юк түгел. Министрның тасдыйкы аңа һичбер права[5] бирми. Андан укып чыгучының хөкүмәт нәзарында һәнүз шул гади татар мәктәбендә укучы нелегальный шәкерттән гамәлдә бер аермасы юк.

Шулай булдыгы хәлдә, буның өчен татарның күңеле бер мәмләкәт алган кадәр күтәрелә.

---

[1] Тәэсис ителү – төзелү, оештырылу.
[2] Тәләкъкый итте – кабул итте.
[3] Мәгъсум – гөнаһсыз, керсез, кимчелексез.
[4] Фәләк – язмыш, тәкъдир.
[5] Право – хокук.

Бу мәкаләне язучы үзе дә бундан мөстәсна[6] түгел. Беренче тәэсир мина да шулай булды. Ләкин инде анга килеп, мәсьәләгә аек караш салырга вә бунын сәбәпләрен, нәтиҗәләрен тикшерергә кирәк.

Буннан 15—20 еллар элек хөкүмәтнен безнең тәгълим мәсьәләмезгә мөнәсәбәте безне бер милләт итеп танымау әсасына[7] бина кылынган иде. Һәм анын буна, бер яктан караганда, хакы да бар иде. Чөнки безнең үзебездә дә бер милли әмәл вә милли хәрәкәт юк иде. Без миллиятнең иң беренче рөкене[8] булган телемезгә әһәмият бирми, мәктәпләремездә төркичә китаплар илә бергә гарәби вә фарсыйны дә укыта һәм мәдрәсәләремездә бөтенләй гарәпчә белән кайнаша идек.

Хөкүмәткә якын торган бәгъзе бер даирәләр безнең шушы иске нигеземез өстенә руслаштыру орлыгын чәчеп карарга теләделәр, халыкнын аңсызлыгындан файдаланырга мөмкин булыр дип уйладылар. Ләкин халыкнын бу аңсызлыгы шулкадәр нык, бер тәгассыб уты берлән кыздырылмыш иде ки, анда руслаштыру орлыгына жимеш бирү түгел, тишелеп жир йөзенә чыгарга да имкян юк иде. Бу сәясәт сизелер-сизелмәс халыкны ифрат дәрәҗәдә сискәндерде. Хәтта бу, хөкүмәтнең дин вә миллияткә тәгаллекы[9] булмаган эшләренә дә куркып, шөбһә белән карауга сәбәп булды.

Шунын өчен Ильминский вә иптәшләренә бары бер генә чара калды. Ул да бу халыкны үз көенчә куеп, аның бетүен, инкыйразын көтү. Иштә бундан чирек гасыр элек башлаган ысулы җәдидә хәрәкәте шуна протест булып туды. Бу: «Юк, сез аны көтмәнез, без инде яшәмәкче буламыз, татар вә мөселман булып дөньяда торырга телимез!»—дигән сүз иде.

Теге тәгассыб уты белән кыздырылган аңсызлык чүле, әлбәттә, бу орлыкны да бер юлы кабул итеп бетерәсе килмәде. Чөнки инде ул артык куркытылган, үзенең мулласына, хәлфәсенә ышанмаслык дәрәҗәдә өркетелгән иде.

Шулай булса да, бу тишелде, үсте. Хәзер без аның чәчәк атканын, жимеш бирүен көтәмез, иштә Казанда булган соңгы вакыйга бундан күп еллар элек утыртылган шундый бер орлыктан тишелеп чыккан агачның чәчәк атуы булмаса да, чәчәккә мөрәләнүедер[10].

Казанда бундан кырык еллар элек ачылган беренче тәртипле кызлар мәктәбе хакында без 1909 нчы елда чыккан «Живая старина» журналының II—III нче нумерларында[11] Радлов хакында язылган бер мәкаләдә ошбу сүзләрне укыймыз:

«Радлов хезмәткә башлагандан бирле, татар хатынынын карангы бүлмәсенә бер тишек тишүне, аңа бераз якты кертүне максат итеп тота иде. Ләкин озак вакытлар кызлар мәктәбе ачу фикере мәйданга килүдән ерак торды. Чөнки мөгаллимә булырлык бер татар хатыны табу мөмкин түгел, мөгаллим янына татар ничек кызын җибәрсен. Ләкин озак эзләгәннән, соң бер татар кызы табылды һәм мөгаллимәлеккә генә түгел, хәтта мәктәпне үз йортына урнаштырырга өстенә алды. Мәктәп ачылды. Укырга җиде фәкыйрь кыз табылды. Ләкин министерство җиде кыз өчен нигә акча әрәм итәргә дип эшне туктатты. Шулай итеп, Радлов татар хатынын яктырту юлында атлаган беренче адымында ук егылды ».

Радловның тәшәббесе[12] белән ачылган бу мәктәпкә мин яна тасдыйк ителгән Аитова гимназиясе вә Казандагы башка кызлар мәктәбенең анасы диеп карамыйм. Радловның кызлар мәктәбе безгә читтән китерелеп ябыштырылган бер нәрсә иде. Шунын өчен ул бик тиз кубып төште. Әмма Аитова мәктәбе вә иптәшләре татарның үз куәтендән туган вә үзе илә берлектә органический үскән вә үсмәктә булган мөәссәсәләрдер[13]. Радлов мәктәбен бунда зикер итүдән максат— бундан 30-40 еллар элек бездә хатыннарны укыту эшенә мөнәсәбәтнен ничек булуыны, булган бер

[6] Мөстәсна – аерым, башкалардан аерып алынган.
[7] Әсас – нигез, төп.
[8] Рөкен – багана, терәк.
[9] Тәгаллекъ – бәйләнешле, бәйле.
[10] Мөрәләнү – бөреләнү.
[11] Штернберг Л. Из жизни и деятельности Василия Васильевича Радлова (Берлинский, Алтайский и Казанский периоды) // Живая старина, 1909.-Вып: II-III.-С. I-XXVII. С.-20-21 (ред.).
[12] Тәшәббес – бер эшкә тотыну, керешү.
[13] Мөәссәсә – оешма.

вакыйга белән күрсәтү һәм ул чагында безнең эшләрне кемләр эшләгенлекне искә төшерүдер. 17 нче октябрь манифесты безне никадәр шатландырса, өметләндерсә, андан сонгы 8—9 еллык реакция (кысынкылык) безне шулкадәр ябыктырган, боектырган иде. Түгел ана телендә урта мәктәпләр ачу, хәтта ибтидаи укунын үз телемездә булуына өметләр какшаган иде. Бу елларда Русиянен мәгариф эше Кассо кеби бөтен сәясәте кысудан гыйбарәт булган бер түрәнен кулында булуы өстемездә олуг бер таш белән бастырып куйган кеби хис ителә, затән, бу ташнын агырлыгы Русиядәге бөтен милләтләрне баса вә хәтта русларнын үзләренен дә җанын сыкрата иде.

Безнең Русиядә унбер елдан бирле парламент бар. Анда безнең мөселманлар да үз вәкилләре аркылы иштиракь[14] итәләр, ләкин бездә парламентнын әһәмияте шулкадәр аз, анын эше шулкадәр акрын вә сәмәрәсездер[15] ки, мәсәлән: анын унбер еллык гомерендә безнең татар халкынын уку эшенә даир китергән файдасы мәгариф министры граф Игнатьевның ошбу бер-ике ел эчендә китергән файдасына тормыйдыр. Шуның өчен күнел ихтыярсыз бундый сөкүт[16] туган «парламент»ка караганда, зыялы моталәкыйтны (просвещенный абсолютизм) әллә никадәр артык күрә, өметне әүвәлгесендән сонгысына күчерәдер.

Бездә хәзер куәт думада түгел, министерствода. Бу факт. Безнен мөселман депутатларынын Петроградта торуларына ин зур бер файда да анларнын үзләренен депутатлык дәрәҗәләре белән файдаланып төрле министрлар хозурына керә алулары вә анларга мөселманларнын төрле ихтыяжларын вә теләкләрен анлата алуларыдыр.

Министрларның мәрхәмәт вә сәдакаләре белән яшәүгә караганда, үз вәкилләремез аркылы канун юлы белән алынган хокук белән яшәү, әлбәттә, шәп булыр иде, ләкин ни эшләмәк кирәк, фәкыйрь булсан, көчсез булсан, сәдака сорамый нишлисен. Бу көндә Русиядәге поляк милләте Германия тарафыннан бирелгән зур бер сәдаканы кабул итмәслек дәрәҗәдә бер галиҗәнаплык күрсәтә, әмма шул ук вакытта без үземезгә кечкенә генә бер сәдака бирелүгә —тарихымызда булмаган бөек вакыйга дип карыймыз.

Дөрест, бу зур вакыйга. Ләкин бундан сон бундый зур вакыйгаларнын һәрвакыт булып торуын вә бунларнын бара-тора бөтенләй кечкенә вә гади вакыйгага әйләнүен көтәмез. Бервакыт бунлар хакында баш мәкаләләр вә бундый озын фельетонлар да язылмасын, тик бунлар дахили[17] хәбәрләрдә генә күренеп узсын иде.

Шул көнләрне көтәмез.

Аитова кызлар гимназиясе 1914 ел беренче июльдә хосусый мәктәпләр хакында падишаһ тарафыннан тасдыйк ителгән закон буенча ачыла. Бу закон буенча хосусый кешеләргә яки җәмгыять вә мөәссәсәләргә хосусый мәктәпләр, класслар, курслар ачарга рөхсәт бирелә. Бунлар гомуми тәгълим бирүче (общеобразовательный) булган шикелле ихтисасый[18] (специальный) һәм сәнагый[19] (профессиональный) да булырга һәм ибтидаи, урта вә гали дәрәҗәдә булырга мөмкин.

Бу законнын 7 нче матдәсендә бәян ителүенә күрә, бундый мәктәпләрдә тәдриснен[20] нинди телдә йөртелүе аны таэсис вә тәрбия итүче кешенең ихтыярына тапшырыла. Тик рус теле, рус тарих вә җәгърафиясе генә рус теле белән укытылачак.

Бундый хосусый мәктәпләрнең мөәссәсе вә мөдирләре һәм башка хадимләре, шул дәрәҗәдә булган хөкүмәт мәктәпләрендә хезмәт итүче кешеләрнең хокук вә имтиязлары[21] белән файдалана алмыйлар. Шулай ук мәктәп үзенең шәкертләренә дә бундый бер хокук бирә алмый.

Буна башлыча сәбәп бунларда тәдриснең ана телендә йөртелүе булса кирәк.

[14] Иштиракь — уртак булу, катнашу.
[15] Сәмәрә — нәтиҗә.
[16] Сөкүт — дәшми тору, сөйләшми тору.
[17] Дахили — эчке.
[18] Ихтисасый — берәр әйбергә хас булган, махсус, хосусый.
[19] Сәнагый — һөнәргә бәйләнешле.
[20] Тәдрис — укыту, белем бирү.
[21] Имтияз — өстенлек.

Димәк ки, без бунын белән мөкатдәс телемез өчен праводан ваз кичкән буламыз. Шулай булгач, хәзер безнең каршымызда ике нәрсә тора:

—Ана теле һәм право[22].

Әгәр право теләсәк, яшьтән үк хөкүмәт мәктәбенә кереп укыймыз да милли тел вә әдәбияттан мәхрүм каламыз. Әгәр милли тел вә әдәбиятка малик[23] булырга теләсәк, үз гимназиямезгә керәмез дә праводан мәхрүм буламыз.

Бездә хөкүмәт мәктәпләренә кереп уку, ирләр дә булсын, кызлар да булсын, әлбәттә, тукталачак түгел, ул һәнүздә артачак. Милли гимназияләр буна манигъ булачак түгел. Монда шөбһә юк, ләкин мәсьәлә шунда: бездә Аитова гимназиясе рәвешендәге милли урта мәктәпләргә ихтыяҗ котыймы? Һәм әгәр ихтыяҗ булса, буларның санын кубәйтеп, тиешенчә дәвам иттерергә имкян бармы?

Бу сөальләрнең әүвәлгесенә, әлбәттә, ижаби[24] рәвештә җавап бирәмез. Бер милләт булып яшәү өчен, шөбһәсез, милли булган урта мәктәпкә ихтыяҗ зур. Бу көндә Яуропаның мәхкүм[25] булган мәдәни милләтләре хәтта үзләренә милли дарелфөнүн дәгъва кылалар. Австриядә чехларның үзләренә махсус милли университетлары 1882 нче елдан бирле дәвам итә. Хәлбуки, шул ук Прага шәһәрендә чехларның илә янәшә немес дарелфөнүне дә бар.

Һәрбер мәктәпнең—ул теләсә генә нинди дәрәҗәдә булсын—рухы милли тел вә әдәбият һәм милли тарихтыр. Шунын өчен кайсы халыкның мәктәбендә укысаң, шуның рухы белән сугарыласын. Ул синең милли мәгънәвиянне югалта, сине үзенең мәгънәви баласы итеп чыгара.

Милли гимназияләр право бирмәсә бирмәс, дөньяда бит һәркем право өчен генә укымый. Безнең кебек күбрәк тәшәббесе шәхси[26] белән яши торган халыкка праводан бигрәк гыйлем кирәк. Бездә мещан сыйныфы баласын хөкүмәт гимназиясенә бирә алмый. Буна беренче манигъ анда мохитнең вә телнең чит булып, рус балалары белән рәкабәт[27] итү агыр булуы вә баланың милли тәрбиядән чи калуыдыр. Иштә милли урта мәктәпләр безнең правога ул кадәр ихтыяҗы булмаган сәүдәгәр вә бай балалары өчен бик уңайлы бер гыйлем учагы булачак.

Милли урта мәктәпләренең кызлар өчен әһәмияте тагын да зурррактыр. Әүвәлән бездә халыкның иң күп бер өлеше кызларыны рус мәктәбенә илтеп кертүне күңелләренә сыйдыра алмыйлар. Икенчедән, кызлар өчен правоның әһәмияте ирләргә булган дәрәҗәдә түгелдер. Ана булачак бер кыз өчен праводан бигрәк милли рух вә милли гыйлем вә тәрбия зарурдыр. Өченчедән, кызлар ирләр кеби төрле һөнәр вә сәнәгать мәктәпләренә (профессиональный школаларга) китмәгәнлектән, хөкүмәт гимназияләренә керү өчен яшь вә мәгълүмат җәһәтендән йортлар агыррак булганлыктан, анлар өчен милли урта мәктәпләр иң уңайлы бер уку йорты хезмәтен итәчәктер.

Бунда шуны әйтеп китәргә кирәктер ки, бу милли урта мәктәпләрдә рус теле бик киң бер урын алырга тиеш.

Болай булган вакытта право мәсьәләсен дә рәтләргә мөмкин. Шөйлә ки, урта мәктәп дәрәҗәсендә фәннәрне яхшы укып, рус телен дә яхшы белгән шәкертка хосусый рәвештә имтихан тотып право алырга бик мөмкиндер.

10 нчы июль канунында бу махсус искә төшерелә (матдә 29). Бунда әйтелүенә күрә хосусый мәктәп шәкертләре әгәр право алырга теләсәләр, хөкүмәт мәктәпләре хозурында яки махсус комитетларда имтихан бирә алырлар. Хәтта мәгариф назиренең рөхсәте белән бу имтихан шул хосусый мәктәпнең үзендә, үз мөгаллимәләре хозурында, ләкин мәгариф округының вәкиле карамагында да булырга мөмкин.

Инде бундый хосусый урта мәктәпләрнең безнең мөселманлар арасында мәйдан алуына имкян бармы мәсьәләсенә килик.

Бу мәсьәләдә, әлбәттә, иң мөһим җәһәт —акча ягыдыр. Бундый уку йортларының

[22] Право – хокук.
[23] Малик – ия, хуҗа.
[24] Ижаби – уңай, уңайлы.
[25] Мәхкүм – хөкем ителгән.
[26] Тәшәбесе шәхси – шәхси гамәл, шәхси инициатива.
[27] Рәкабәт – ярыш, көндәшлек.

мәсарифын[28] кемләр күтәрәчәк. Бундый бер эштә хосусый кешеләрнен һиммәт вә сәдакаләренә таяну, әлбәттә, мөмкин түгел. Шундый зур милли планны хәйер вә ихсан[29] кеби иттифакый нәрсәләргә генә ышанып корырга ярамый. Хәлбуки, бу көнгә кадәр зуррак милли уку йортларымызнын һәммәсе дип әйтерлек шул хосусый вә иттифакый[30] булган хәйер вә ихсанлар белән яшиләр. Хөкүмәт тарафыннан тасдыйк ителгән өч урта мәктәбемезнең өчесе дә (икесе Троицкидә) Яушев балаларының кесәсеннән тәрбия ителәдер. (Фатыйха ханым Аитова да Троицкилы Яушев кызыдыр).

Киләчәктә байларымызнын һиммәте киселмәвенә, хосусый булган иганә вә ихсанәләренен истикъбальдә[31] дә милләтемезнең мәгариф эшендә зур урын тотачакларына ышандыгымыз хәлдә, санлары көннән-көн артуы мәтлүб[32] булган дөньяви, милли мәктәпләремезнең матди якларын тәэмин итү өчен тагын да ышанычлырак мәнбәгъләр[33] эзләү тиешлегендә шөбһә итмимез. Бу тугрыда безнең иң элек мөрәҗәгать итә торган урынымыз, әлбәттә, земство вә шәһәр идарәләре булырга тиеш. Мөселман күп булган җирләрдә хәзинәнең матди ярдәменнән мәхрүм булган бундый уку йортларыны күтәрешү земство вә шәһәр идарәләренең вазыйфасыдыр.

Без бундый уку йортларына күп урында җирле җәмәгать һәм хәйрат[34] ияләреннән кирәкле булган фонд (баш сәрмәясе)нең хәзерләнүенә ышанамыз. Шәһәр вә земство идарәләренең иң беренче вазыйфалары, әлбәттә, шундый халык теләге вә халык көче белән аякка баскан гыйлем йортларын аяктан екмыйча саклау, анларны бара торган юлларында житәкләүдер.

10 нчы июль законының 30 нчы матдәсенә бинаән[35], бундый хосусый мәктәпләргә земство вә шәһәр мөәссәсәләре ярдәм бирә алырлар. Ләкин шул ук законның 7 нче матдәсендә әйтеләдер: земство вә шәһәр тарафыннан тәэсис вә тәрбия ителгән яки бунларның ярдәме белән файдаланган хосусый мәктәпләрдә, дин вә ана теленнән башка бөтен фәнләр рус телендә тәгълим ителергә тиеш.

Болай булганда, земство вә шәһәрдән файдаланган хосусый мәктәпләрнең миллилеге ноль дәрәҗәсенә якын калачак. Милли мәктәпләрне бу кысынкы шарттан коткару өчен ничек тә бер чара күрелергә тиеш.

Хәзергә мәсьәләнең мәгънәви җәһәте дә бик мөһим. Акча мәсьәләсе илә бергә үк дәрес китаплары вә мөгаллимләр мәсьәләсе тора. Бундый рәсми уку йортлары гәрчә шәкертләренә права бирмәсә дә, анда укытучы мөгаллимләр шул дәрәҗәдә булган хөкүмәт мәктәпләрендәге мөгаллимләрнең мәгълүмате кадәр мәгълүматкә (ягъни шәһадәтнамәгә) малик булу шарт ителә (матдә IV).

Әгәрдә бунларда мөгаллимлек итү өчен гали тәхсил[36] шарт ителә торган булса, бу кысынкы шарт бундый мәктәпләрнең арамызда таралуына мотлак бер киртә булачактыр. Бездә хәзергә гали тәхсил күрүчеләрнең саны бик аз булу белән бәрабәр бунлар арасында да мөгаллимлек мәсләгендә булганлары иң аз бер процент тәшкил итәдер. Мөселманларга урта дәрәҗә рус мәктәпләрендә мөгаллимлек итүгә канун мөсагадә[37] итмәгәнлектән, гали тәхсил юлына керүче яшьләремез дарелфөнүннең мөгаллимләр хәзерли торган филология шөгъбәсен һәм учительский институтларны ихтыяр итмиләр.

Ләкин бу мәсьәләнең бунда да мөһим бер җәһәте бар. Шөйлә ки, бу милли мәктәпләрдә тәдрис ана телендә булганлыктан, анда мөгаллимлек итү өчен татар әдәби теленә малик булу иң беренче шарттыр. Хәлбуки, гали тәхсил күрүче яшьләремезнең бик күбесе хәзергә моннан мәхрүм тору мәҗбүриятендәдерләр.

---

28 Мәсариф – тотылган акчалар, чыгымнар.
29 Ихсан – ярдәм, бүләк.
30 Иттифакый – очраклы.
31 Истикъбаль – киләчәк, булачак.
32 Мәтлүб – соралган, таләп ителгән.
33 Мәнбәгъ – чыганак.
34 Хәйрат – изге эшләр, яхшылыклар.
35 Бинаән – нигезләнеп, таянып.
36 Гали тәхсил – югары тәрбия, югары белем.
37 Мөсагадә – мөмкинлек бирү, булышу.

Хәзергә урта мәктәптән шәһадатнамә булуда шарт ителмәсә, безнең өчен яхшырак булыр иде. Чөнки безнең арамызда Русиянең урта мәктәпләрендән мәэзүн[38] булмасалар да, аерым-аерым фәннәрдә урта мәктәп дәрәжәсендә яки андан да артыграк мәгълүматка малик булган кешеләр байтактыр. Тәдрис ана телендә булгач, мөгаллим өчен рус телен бик яхшы белүнең дә ул кадәр лөзүме булмаса кирәк.

10 нчы июль законында бәян ителүенә күрә, бу тугрыда бәгъзе бер истисналар[39] ясарга мөмкин. Ләкин һәр аерым хәлдә попечительның махсус рөхсәте белән (матдә18).

Аитова гимназиясенең ачылу мәжлесендә дә бу мәсьәләне искә төшергәннәр. Фатыйха ханым Аитова мәктәбенә мөгаллимәләр житештерү өчен татарчалары яхшы булган алты кыз баланы үз хисабына Шумкова гимназиясенә укырга биргән икән. Мәжлестә хазир булган Габдулла хәзрәт Апанай үз тарафыннан киресенчә эшләүне гарыз кылган. Ягъни хәзерге көндә гимназияне тәмам итмәктә булган кызларны хәлфәләрдән мөселманча укытып алу мәгъкүлрәк булыр иде, дигән.

Минемчә, бу бик мөһим вә әсаси бер мәсьәлә.

Мин буны мөгаллимлек мәсьәләсенә генә хасламыйча, гомуми бер милли мәсьәлә итеп карыйм. Милли тел вә милли әдәбиятта жәяү булган хәлдә хөкүмәт мәктәбенә барып керергә мәжбүр булган вә булачак егет вә кызларга—гәрчә анлар тәгълим эшенә хәзерләнмәсәләр дә —ана теле вә әдәбияты укытуга зур бер милли ихтыяж итеп карарга вә бунын мөмкин булган чараларына тизрәк керешергә тиеш.

Безнең бөтен бер милләт булып яшәвемез өчен милли тел вә милли әдәбият мөгаллимләргә никадәр зарур булса, безнең арамыздан житешкән доктор, адвокат вә мөһәндисләргә[40] дә шулкадәр зарурдыр. Бунлар шундан башка үзенең халкы кашында тиешле булган урынны тотачаклар түгел.

Бунын өчен, минемчә, ин табигый вә гади булган бер чара —татар теле вә әдәбияте курслары ачудыр. Кышкы кичләрдә яки жәйге көннәрдә булачак курсларга һәртөрле урта вә гали мәктәпләрдә укучы татар шәкертләре йөргән кеби, башка сыйныфтан булган һәртөрле яшь һәм яшьли кешеләр дә керә алырлар.

Хәзергә бунын бер тәжрибәсен мөселман мәркәзе һәм гали мәктәпле булган Казан шәһәрендә эшләп карарга мөмкин булса кирәк.

Гасырлар буенча тыныч тәрәккъый иткән һәм шулкадәр нык вә олуг бер мәдәният төзегән Яуропада хәзер коточкыч бер сугыш вә кырылыш бара. Бу сугыш үлем өчен түгел, яшәү өчендер. Бу сугышны хәят сусыны тудырды. Шунын өчен бу сугыштан сон халыклар яна бер куәт белән яшәргә, мәдәниятка яна нигезләр коруга башлаячаклар.

Бу сугыш инглиз, француз, рус вә немес кеби берничә олуг милләтләр исемендән эшләнсә дә, сугышка катышучы вә анын агырлыгын күтәрүче бунлар гына түгел, бунларнын кул астында булган башка кечерәк милләтләр дә сугышка алар кеби үк катышалар вә сугышнын агырлыгын алар дәрәжәсендүк чигәләр. Шунын өчен сугыштан алынган ганимәттән (хокук вә гайрәттән) бундый мәхкүм милләтләргә дә өлеш чыгарылырга тиеш.

Без, ошбу сугышта руслар кадәр үк мал вә кан түгүче татарлар, олуг Русиянен жиңүен өмет итәмез. Безнең бу өметемез никадәр куәтле булса, сугыштан сон Русиянең гражданы булган хокуклы бер милләт булып яшәү юлында хөкүмәтнең кысынкылык итмәвенә дә өметемез шулкадәр куәтледер.

Тик безгә шул мөсагадәдән[41] файдалану өчен хәзерләнергә милли тәрәккъый вә тәмәддең[42] юлында сугыштан соң атланачак беренче адымга хәзердән үк аякларны күтәреп торырга кирәк!

*«Вакыт». —1916. —9, 11 ноябрь(№ 2125, 2126).*

[38] Мәэзүн – рөхсәт ителү.
[39] Истисна – чыгарма, чыгарып алу.
[40] Мөһәндис – инженер
[41] Мөсагадә – мөмкинлек бирү.
[42] Тәмәддең–мәдәниятле булу, культуралашу.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Татар Янтыгы

Татар Янтыгы авылы Лаеш районында, район үзәге Лаеш эшчеләр бистәсеннән 35, Казан шәһәреннән 52 чакрым ераклыкта урнашкан.

Казан ханлыгы чорында яшәгән авыл атамаларын билгеләгән исемлектә Нугай юлы өстенә, Брыс суы ярына утырган Янтык авылы күрсәтелгән (1565 елда ул Бушлык дип бирелгән). Янтык бушлыгы атамасы Казан крае документлары тупланган тарихи белешмәдә дә (XVI гасырның икенче яртысы—XVII гасырның уртасы) телгә алына. 1766—1861 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында авыл искә алына, анда яңа керәшеннәр яшәгәнлеге күрсәтелә. 1898 елда басылып чыккан белешмәдән Татар Янтыгы авылында татарлар көн иткәнлеге күренә. К. П. Берстель бастырып чыгарган тарихи белешмә мәгълүматларына караганда, Татар Янтыгы авылында 1235 татар кешесе гомер кичергән.

Олылар авыллары оешуны болай сөйли. Элек авыл олы юл буенда, хәзерге урыс авылы Смолдеярово урынында булган. Урыс патшасы Явыз Иван Казанны басып алгач, татарларны чукындыра башлыйлар. Үз диненнән аерылмас өчен халыкның күбесе качып китә. Янтык урынында үтеп булмаслык сазлык, калын урманнар булган. Качып китүчеләр өчен бу бик унайлы урын булып тоелган. Урманнарны төпләп өч агай авылга нигез салган. Аларның өчесе өч нәселдән булган: Мәнәй Бохаретдин—татар, Чүри Садыйк—калмык, Тәкә Камалетдине казакъ нәселеннән булган. Хәзерге вакытта да авылга нигез салучыларның нәселләре дәвам итә. Әлеге нәселләр йөрткән кушаматлар, еллар аша узып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Менә алар: чүриләр, тәкәләр, мәнәйләр һ. б. Җыелган халыклар нигез салганга күрә авыл башта Җыентык дип, аннан Җантык, соңыннан Янтык дип аталган.

Революциягә кадәр Янтык 2 мәхәлләле зур авыл булган.

Татар Янтыгы табигатьнең матур почмагына урнашкан. Аны һәрьяктан урманнар чолгап алган: Алмаз урманы, Каршы урман, Брыс урманы, Чигә тавы, Киртә башы һ. б.

Авылда ике зират бар. Берсен халык Олы зират дип атый. Янгыр яумаса, авыл халкы эссе җәй көннәрендә шушы зират янына барып янгыр сорый. Ни хикмәт, шуннан соң янгыр килеп ява икән. Икенче зиратка хәзерге мәрхүмнәрне күмәләр. Ике зират та халык тарафыннан каралып һәм тәрбияләнеп тора.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

## Смәел

Смәел авылы район үзәге Балтачтан 24 чакрым ераклыкта урнашкан. Авыл Казан ханлыгы чорында ук булган. Аның зиратында XVI гасырга мөнәсәбәтле ике кабер ташы сакланып калган.

Шушма суы бассейнында укмашып урнашкан Смәел, Йөрек, Нөнәгәр, Чутай, Комзавут авыллары халкы бергәләшеп июнь аеның уртасында Йөрек исемле җыен бәйрәме үткәргән.

Монда яши торган аксакаллар сөйләвенә караганда, авылны иң беренче булып Исмәгыйль исемле кеше нигезләгән. Авыл тирәсендә элек калын урман булган. Аргы як болында юан имәннәр үскән, хәзер бу урын болынга әйләнгән. Оешкан вакытларында авыл халкы тирә-юньдә башка авыллар барын белмәгән әле. Авылдан чакрым ярым ераклыкта Арбор (Урбар) суы ага. Шул судан алар йомычка агып килгәнен күрәләр һәм авыл эзләп су буйлап югарыга менеп карыйлар. Шулай итеп алар Арбор (Урбар) авылын табып кайталар (шушындыйрак хикәятне башка авылларда да ишетергә туры килде). Бу вакытларда Арбор (Урбар) суы тирәләре дә буйдан-буйга урман белән капланган булган. Бәшир, Гыйлман, Хәбир ышналары, Ибрай, Нәзир әрчүе дип аталган басуларны шул кешеләр урманнан чистартып ясаганнар. Югары Тарлау, Түбән Тарлау атамалары да урманнан арчылган җирне аңлата. Авыл янында Кирәмәт урыны, Изгеләр зираты дип йөртелгән зират бар. Аны икенче төрле Ташбилге зираты дип тә әйтәләр. Бу зират янындагы бер урынга сәдака итеп акча кую гадәте сакланган. Аның янында әле дә зур чыршы агачы үсеп утыра. Шунда ук Изгеләр коесы сулары ага. Бу кое суын бик ерак җирләрдән кайтып алып китәләр. Ләкин аннан суны кеше үзе дога кылып алырга тиеш икән.

Смәел яныннан Шушма суы ага. Элек аның суы мул булган, күпсанлы тегермәннәр эшләп торган. Бу суда Текә яр, Дингез күзе, Кызлар комлыгы дип йөртелә торган урыннар бар. Дингез күзе дип элек бик тирән урынны атаганнар, анда берничә кеше батып та үлгән дип сөйлиләр.

Авылны чыккач Чутай таулары башлана. Җәй көне тау битләрендә бик күп җиләк пешә. Таууга менәр алдыннан бер елганы кичәсе. Әлеге су кешене тота дип сөйлиләр.

Авылда Советлар Союзы Герое Г. Г. Гыйлметдинов туып үскән (1913—1944). 1967 елда авылда аның скульптор Г. Г. Гыйззәтуллин ясаган бюсты куелган.

Малмыж ягындагы Яңа Смәел авылы исә шушы Смәелдән 1926-28 елларда күчкән. Мари иле республикасында да бу авылдан күчкән Смәел пучинкәсе бар.

## Олы Карауҗа һәм Кече Карауҗа

Олы Карауҗа һәм Кече Карауҗа авыллары Зеленодол районында урнашкан. Олы Карауҗа район үзәге Зеленодол шәһәреннән 31 чакрым ераклыкта утырган.

XVIII йөз мәгълүматларын эченә туплаган тарихи чыганакта Олы Карауҗа авылында 264 ясак түли торган, Кече Карауҗала 15 йомышлы, 7 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелгән. Олы Карауҗада бер агач мәчет, мәктәп, мәйханә, җил тегермәне, вак-төяк сата торган 5 кибет булган һәм кече атна көнне базар уздырылган. Кече Карауҗа халкы Олы Карауҗа авылы җәмгыятенә кергән, анда 21 хуҗалык булып, бер җил тегермәне эшләгән.

Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә, Олы Карауҗа, Кече Карауҗа, Олы Җәке, Кече Җәке, Уразлы, Каратмән, Биктә заводы авыллары җыелып, июньнең унбишендә Упса җыены үткәргәннәр.

Карауҗа авылы барлыкка килү 1552 елда Казан ханлыгының бетүе белән бәйләнешле. Карауҗа авылы оешу турында мондый риваять бар.

Карауҗа исемле егетнең атасы Кара би булган. Кара би Казан янындагы Каравай авылында ил тотып яшәгән. Аның улы Карауҗа, Кече Карауҗа урынына килеп, авыл корып утырган.

Берчакны боларга бер карт кереп, су сораган. Хуҗалар су бирмәгән. Шуннан әлеге карт: «Алты өйдән артмагыз!»—дип теләк теләп чыгып киткән, имеш.

Карауҗа бу эштән бик шөбһәләнеп калган һәм өч улын чакырып, аларга өч ук биргән.

—Шушы укларны атыгыз, алар кая төшсә, шунда барып нигез корыгыз,— дигән.

Егетләр укларын атып җибәргәннәр. Укларның берсе Каратмән авылы урынына килеп төшкән. Ул урынга Карауҗаның олы улы нигез корган. Аның исеме Кара Төмән икән. Икенче улының исеме Чура би булган. Аның угы хәзерге Карауҗа авылындагы Чура би чокыры турысына килеп төшкән. Карауҗа Чура би исемле улы белән шул урынга килеп нигез корган. Өченче улының угы Күлбаш авылы урынындагы бер күл башына төшкән, анысы шул җиргә урнашкан.

Карауҗа, Иван Грозныйга каршы сугышта, Казан ханына хыянәт итә. Хан, аның бу эшен сизеп, Карауҗаның авызына эретелгән алтын тутыра. Аның кабере Чура би чокыры дигән урында.

Чура бинең улы Чура батыр була. Иван Грозный гаскәрләре Казанны алган вакытларда, Чура батыр шушы Карауҗа авылы җирләре өчен сугышып үлә.

Авыл халкының төп кәсебе игенчелек булган. Ләкин ул гына авыл халкының ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый. Шуна күрә халык көзге һәм кышкы айларда чыпта суккан.

Авылда кибет тотучы сәүдәгәрләр дә яшәгән. Алар халыкка карата миһербанлы һәм шәфкатьле булганнар.

Бөтен илне тоташтан коллективлаштыру сәясәте зур каршылыклар һәм ризасызлыклар китереп чыгара. Бу хәл Карауҗа авылында да чагылыш таба. Ирексезләп колхозга кертелгән кешеләр тиз генә аннан кире чыга да башлыйлар. 1931—32 елларда Зур Карауҗада «Яңалиф», Кече Карауҗада «Киров» колхозлары оеша. Колхозга керергә теләмәгән кеше кулак яисә кулак иярчене дип игълан ителә. Аларның мал-мөлкәте тартып алына, ирегеннән мәхрүм ителә һәм Себернең ерак районнарына сөрелә.

1927 елдан авыл районнарында машина-трактор станцияләре (МТСлар) оештырыла башлый. Колхозга беренче тракторны Жамалиев Шиһабетдин үз акчасына сатып ала.

Хәзерге вакытта авылда 235 хуҗалык бар. Аларда барлыгы 800 кеше яши, шулардан 348 ир-ат, 452 хатын-кыз. Авыл халкы терлекчелек һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнә.

Олы Карауҗа җирләреннән Чума, Тирмән, Сәмит, Туктар әле, Чураби, Урыс, Тубалак, Алмагач, Ташлы Тау, Корык һәм башка елгалар ага.

Авыл кырыенда Туктар әле исеме алган калкулык бар. 1918 елда чехлар Казанны алганда авылга да куркыныч яный. Шул вакытларда картлар, карчыклар, балалар, хатын-кызлар шушы калкулыкка юнәләләр. Дошман безне куып җитә алмас, безне күздән югалткач туктар әле, дип уйлыйлар. Бу атама шул вакытларның истәлеге булып калган, имеш.

Мәми тавы—калкулык. Аның астында су җыелып тору сәбәпле, сазлык барлыкка килгән. Бу пычракны мәми дип атаганнар. Тау атамасы шуннан килеп чыккан.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Мөдәррис
Вәлиев

# ТЫНГЫСЫЗ ҖАН ИДЕ...

## НӘБИ ДӘҮЛИНЕҢ ТУУЫНА100 ЕЛ

*Кеше гомере—олы бер тау.*
*Вакыт аны ватып ала,*
*Һәм каберга куяр өчен*
*Бер кечкенә ташы кала...*

Нәби Дәүли

Ул үзенең шигырьләренә охшаган: алар кебек үк ярсу-кайнар, эчкерсез-хыялый иде... Һәр сүзе-ымы, һәр ишарәсе белән шуны раслап торды. Яшьлегендә шактый гаярь, кыз-кыркынның һушын китәрерлек мут егет булгандыр, дип уйлыйсың.

Әле дә истә: әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш бара, болай д.. зур булмаган залда алма төшәрлек тә урын юк, әмма шул эшлекле ыгы-зыгыда аны—Нәби Дәүлине—күрми калу мөмкин түгел иде. Юк, киеме, килеш-килбәте белән бүтәннәр арасында әллә ни аерылып тормый ул, урындыгы да күзгә ташланырлык төшкә туры килмәгән. Иң гаҗәбе шунда: трибунадан поэзия турында доклад укыйлар, Нәби ага исә, аның һәрбер сүзен үз учыннан очырып җибәргәндәй, бик әсәрләнеп, ашкынып, дәрт биреп утыра иде. Таләпчән-катгый фикерләр әйтелгәндә, ул, кулы белән һавада кискен хәрәкәт ясап, «нокта куя»: трибунадан яңгыраган сүз нәкъ менә шул «нокта»да ябышып-расланып кала сыман. Дусларча чеметү-шаярту ишетелеп китсә, залдагы җанланып алуны чал чәчле язучының кычкырып көлүе көчәйтеп җибәрә. Бу мәлдә аның йөзендәге җыерчыклар челтәре шундый язылa,—ул әбиләр чуагы чорындагы җиңел пәрәвез җепләренә әверелер дә очып китәр төсле!..



Әйе, таләпне зурдан куеп, әле байтак бәхәсләргә азык булырлык сүзләр әйтелде ул чакта, һәм әлеге чыгышның «дирижеры» гына түгел, авторы да Нәби Дәүли булуы (тамагы авыртып торганлыктан гына аны башка берәүдән укытуы)—залдагыларның һәркайсына мәгълүм иде. Сүз үзенең иясеннән аерылмаган булып чыкты. Бәлки, шуңа күрә дә ул икеләтелгән тәэсиргә—үзенә күрә «стереофоник» янгырашка ирешкәндер.

Каләмдәшләре, кордашлары Н.Дәүлине уяу янартау шикелле кайнап-күкрәп

торучы әдип буларак беләләр. Кемгәдер аның холкы яхшук дуамал булып та тоеладыр. Ләкин ул янартау күкрәгендә нинди давыллар уйный?.. Нинди көчләр аны хәрәкәткә китерә?

Белгәнебезчә, Нәби Дәүлигә чын мәгънәсендә танылу шактый сонарып, әмма көтмәгәндә, дәррәү килде. Көннәрнең берендә укучы бу исемне «Яшәү белән үлем арасында» дигән повесть белән бергә, ин беренче чиратта, әнә шул китап авторы буларак күтәреп алды. Әлеге әсәр кайнар чынбарлыгы белән җәлеп итте, фаҗигале язмышлары белән тетрәндерде.

Яңадан-яна буын укучылардан утыз ел буе хатлар килеп торган икән, бу хәл «Яшәү белән үлем арасында» повестенын зур тәэсир көче турында сөйләмимени!

Әмма Вакыт елгасы ага тора, инде хәрәкәттәге тәнкыйтьнең игътибар үзәгенә башка, яңа әсәрләр килеп керүе—табигый хәл. Һәм нәкъ менә хәзер, шау-шу басылгач, таныш сәхифәләргә кабат әйләнеп кайту, тәэсир-кичерешләрне янарту язучының иҗади йөзен тулырак күз алдына китерү максатында кызыклы булыр иде.

Тормыш язучыны утлы сиратлардан еш кичәргә мәҗбүр иткән, кырыс сынауларда сынатмаска-сыкранмаска өйрәткән, һәр өйгә фаҗига-афәт алып килгән сугыш аның өлешенә хәтәр борылмалар әзерләп куя... Ил туфрагына дошман аяк басканның икенче көнендә үк яу кырына киткән Нәби Дәүли авыр бәрелешләрнең берсендә йөзләгән иптәшләре белән чолганышта кала һәм тоткынлыкка төшә. Язмышы бөтенләй билгесез сукмакларга кереп китә, илдәгеләр өчен «хәбәрсез» югала. Ләкин язучы—гади солдат, гади әсир түгел, ул, яшенне үзенә тарткан имән кебек, бөтен хәтәр хәлләрне үз йөрәге аша уздыра. Башкалар бер кичергәнне мең кабат кичерә. Хис-тойгылар чынлыгы, мең көзге аша үтеп бер ноктага туплангандай, аерым шәхеснең генә түгел, тулы бер буынның фаҗигасен күз алдына бастыра. Менә ни өчен ул безнең бөтен күзәнәкләргә үтеп керә, көйдереп ала...

Тегe яки бу әсәрне язарга этәргән сәбәпләр, аларның «чынлыгы» турындагы сорауларга язучы халкы күнеккән инде. «Яшәү белән үлем арасында» повесте унаеннан исә бу сорау аның әхлакый нигезе белән бәйле рәвештә дә булырга мөмкиндер. Йомылып килүче яраларны янәдән кузгату кирәкме? Әсирлекнең күзгә күренмәс фронт сызыгын, «алгы сызыктан да алдарак булган окоплар»ын тасвирлаганда, бүгенге укучыны ышандыра алырсыңмы? Н.Дәүли әлеге сорауларга әсәрен язарга керешкәнче үк җавап бирергә тиеш булган. Повестьны укыганда, без язучының шул хакта сөйләвен көтәбез, кинәт кенә тоныкланып киткән күкрәк тавышын ишеткәндәй булабыз. Кешеләр, сез бу сүзләрне кабат-кабат «әйләндереп» тыңлагыз һәм уйланыгыз, ди сыман ул.

«Сугыштан соң Казанга кайткач, мин һәр көнне диярлек вокзалга барып йөри идем. Ул көннәрдә демобилизацияләнгән солдатлар белән шыгрым тулы эшелоннар бер-бер артлы килеп кенә тора. Вокзалда туганнарын, дусларын каршыларга төшүчеләр хәтсез күп... Кичкә таба перрон бушап кала. Шул вакытта мин бер карт кына хатынны күрә торган идем. Ул да, мескенем, кемнедер каршыларга килә иде, күрәсең...

Шулай беркөнне без тагын буш перронда икәүдән-икәү генә калдык. Менә ул хатын миңа якын ук килде дә: «Кайтмадымы?»—дип сорады. «Юк, кайтмады шул»,—дидем мин. «Кемне көтәсез?»—«Дусларымны». Хатын яшь тулы күзләре белән миңа карады да: «Мин дә улымны көтәм, ә ул бик сагындырып кына кайтырга уйлый, ахрысы»,—диде, авыр сулап».

Язучының йөзендәге җыерчыклар, чәнечкеле тимерчыбык сыман, тирәнрәк уела төшә, ул бөтен гәүдәсе белән, кемнедер әче җилдән ышыкларга теләгәндәй, алга таба талпынып куя.

«Ялгыз ананың бердәнбер улы сугышның башында ук фронтка киткән,—дип сүзен дәвам итә ул.—Бары бер генә хаты килеп калган. Ә инде өч айдан соң аның хәбәрсез югалуы турында военкоматтан язу китергәннәр... «Хәбәрсез югалды,

дисәләр дә, йөрәгем ышанмый,—диде хатын.—Йә бүген, йә иртәгә кайтып төшәр шикелле...»

Мин өйгә кайтып барам. Ә башымда уйлар кайный. Күпме алар ялгыз аналар, ятим калган балалар?! Тукта, мин ул «хәбәрсез югалганнар»ны белмимме икән? Мин аларны күрмәдемме? Бәлки, алар минем белән янәшә булганнардыр!.. Әйе, мин ул «хәбәрсез югалганнар»ның адресларын беләм. Ләкин ул адрес буенча хат бармый, аннан хат та килми. Ул адресны аналар, балалар белсеннәр иде, дидем мин. Аларның язмышларын, көрәшләрен күрсеннәр иде. Шул теләк белән мин шушы повестьны яздым...»

«Яшәү белән үлем арасында» әсәренең публицистик җегәре, үзенчәлекле стиле, әнә шулай, нинди укучыга йөз тотып һәм нинди ният белән язылуыннан башлана. «Мин хәбәрсез югалган идем» дигән кереш өлештә төп максат ачыктан-ачык күрсәтелә: «Кем иде соң ул фашист? Мин сина шул турыда сөйләргә телим»,—ди язучы. Мондый конкретлык безне ике юл чатына куеп, бераз сагаерга мәҗбүр итә: сурәтләр чынлыгы һәм аналитик фикер тирәнлеге белән җәлеп итәрме: ул; гомуми пафос дулкынында, әзер өлгеләр буенча алып китмәсме?

Н.Дәүли беренче юлдан китә һәм, реалистик буяулар сайлый-сайлый, немец халкының фаҗигасен ачуга керешә. («Германия нинди матур ил икән!.. Чәчәк аткан гүзәл табигать эчендә фашистлар да яши дип ышанасы килми иде».) Ул, кайбер әсәрләрдәге кебек, фашистларны ахмак юлбасар итеп кенә сурәтләсә, аларның «барыннан да элек кешегә охшаган булулары белән куркынычлы» икәнлекләренә ышандыра алмас иде. Иң мөһиме шунда: укучыга фашизмның кара йөзе якты җирлектә—тәннәре әсирлеккә төшсә дә, рухлары белән хөр булып кала алган кешеләрнең тормышка мәхәббәте фонында күрсәтелә. Лагерьда «парикмахерская», «лазарет», төрле «мастерскойлар» ачылу күренешләрен генә искә төшерик. Бу оптимистик трагедиянең нигезендә—ватан солдатының күңел сафлыгы, рух ныклыгы. Теткәләнгән киемнәрдә калган йолдызлы төймәләр дә котылгысыз үлемнән куркып-каушап калмаслык көч бирә. Әнә шуна күрә фашистларга хәтта үз өннәрендә тынычлык юк, әсирнең яшәүгә, җиңүгә омтылышын нинди рәхимсез шартлар да сүндерә алмый. Әсәр тигезсез һәм тиңдәшсез көрәшнең драматик эчтәлеген сурәтләп, тантаналы финалын шушындый гомумиләштерү рәвешендә тәкъдим итә: «Без Германия җиренә үзебез белән немец армиясенең җиңелү хәбәрен алып килдек».

Бу лейтмотивның «Җимерелгән бастион» романында саклануын, дәвам итүен күрүе кыен түгел. Иң хәлиткеч минутларда роман геройларыннан берсе—Нәҗия, мәсәлән, турыдан-туры: «Сүз яшәү белән үлем турында бара»,—ди. Билгеле, «Җимерелгән бастион»ның әдәби «ачкыч»ы бүтән, андагы язмышлар төене бөтенләй башкача чишелә. Ләкин язучы әлеге әсәрендә дә тормышның «яшәү өчен генә түгел, барыннан да элек, явызлыкка каршы көрәш» булуы турындагы сүзен дәвам итә, «фашизм белән кылычка-кылыч килгән» иң кискен бәрелешләрне сурәтли, шул көрәштә «бер Германиянең ике Германиягә» аерылуын күрсәтә... Укучы, бәлки, игътибар иткәндер: сүз «Җимерелгән бастион» турында барганда да, мин әлеге өземтәләрне «Яшәү белән үлем арасында» повестеннан китердем, һәм менә ни өчен. Безнең кайбер тәнкыйть мәкаләләрендә, әлеге ике әсәрне бер-берсенә каршы куеп, «Яшәү белән үлем арасында» әсәре фашист концлагерьларындагы авыр тормышны гына тасвирлый, әсирләрнең илбасарга каршы көрәшен күрсәтми, дигәнрәк фикерләр ишетелгән иде. Хәлбуки, көрәшне кулга корал алу гына дип күз алдына китерү—бик беръяклы түгелме соң? Әсирлектә «шырпы кебек янып сүнгән» ир-егетләрнең: «Ничек тә исән каласы иде»,—дип өзгәләнүләрен хәтерләгән кеше, яшәү өчен көрәш гадирәк, җинелрәк, ул—дошманга каршы көрәш түгел, дип уйлый алмас. «Бу сәгать осталары, бу тимерчеләр, бу игенчеләр, бу инженерлар, врачлар, балта осталары әле дөньяга күпме байлык, күпме матурлык бүләк итәрләр иде...» Коры риторика белән түгел, әдәбиятның

могжизалы көче ярдәмендә, бер шәхес хатирәләреннән буыннар хәтеренә күчү күренеше белән очрашабыз. Әсәрдәге бер кушуч якты сагышның, меннәрчә күңелләрдә тәкрарланып, олы масштабларга ирешүен күрәбез. Ул, һәр танда чыккан кояш кебек, безне тормыш-яшәеш кадерен белергә өйрәтә.

Әсәрләрдә сурәтләнгән һәм бүгенге укучыларны дулкынландырган вакыйгалар моннан кырык ел элек һәм бер үк вакытта безнең күз алдында бара. Хикәяләүнең үзенчәлекле стиле ачык билгеләнгән: әсирлек көндәлеге, хатирә-репортаж! Язучы үзе тасвирлаган вакыйгаларны бүгенге көн биеклегеннән торып күздән кичерә, кирәк урында ачыктан-ачык аңлатып-шәрехләп ала, кичерешләреннән оялмый, мөнәсәбәтен яшерми. Әмма ул, башыннан кичкән хәлләрне генә сөйләсә дә, игътибар үзәгенә хәбәрсез югалган дусларын куя, күбрәк аларны күрсәтергә тырыша, аларның аманәтен тапшырырга ашыга. Әсәрнең унышы—менә шул кешеләргә икенче яшәеш бирүдә, алар исеменнән сүз алуда. Чөнки хәбәрсез югалганнар һәм яу кырында һәлак булганнар, җирдә фашизм яңадан баш калкытмасын өчен, көрәш сафында калалар. Алар үткәнгә түгел, бүгенге көнгә, киләчәккә төбәлгән һәм дөньяда тынычлык өчен көрәшкә, яңа буыннарны ватандарлык рухында тәрбияләүгә хезмәт итәләр.

“Яшәү белән үлем арасында» повесте—язучы иҗатындагы иң биек нокталарның берсе. Шигъри әсәрләренең дә чын кыйммәте әлеге биеклеккә нисбәтле бәһаләнә.

Язучының хәтта үткәндәге иҗатын да яңа мәгънәләре белән ачкан төсле булды повесть. Мәсәлән, шигырьләрендә дә автор шәхесенең, лирик «мин» дәрәҗәсендә генә калмыйча, фикер-хәрәкәт активлыгына ия булуы игътибарны җәлеп итте. Аның «мин»е—шәхси дөньяга кереп бикләнү чарасы түгел, ә тормыш чынбарлыгын үз күңеле аша үткәреп, укучыга якынайта торган тәрәзә икән бит. Бу тылсымлы «тәрәзә» төп игътибарны, вакыйганың үзен хәбәр итүдән бигрәк, аның турында уйлануга, аны кичерүгә юнәлтә.

Шагыйрьнең гомумиләштерүче фикере нигезенә тормыш тәҗрибәсе һәм яшәү принциплары салынган. Аңа язмышның беренче һәм авыр сынауларын нарасый бала чагында ук кичерергә туры килә. Бер-бер артлы әтисе белән әнисе дөнья куя. Бу җиһанда ач-ялангач һәм, барыннан да бигрәк, япа-ялгызы калу ачысын татыган малайның күңеле, бәлки, туган җирләреннән еракта, тамак ялы өчен көтү көтеп йөргән заманнарда ук мөлдерәп торган моң чишмәсенә әверелгәндер. Булачак шагыйрьнең холкы-фигыле Донбасстагы зур заводларның берсендә тимерче булып эшләгән чакларында ныгый, формалаша башлагандыр. Аның иҗатка омтылышы да шунда уяна, беренче язмалары татар шахтерлары өчен чыгарылган «Пролетар» газетасында басыла. Бик күп еллар үткәч, Н.Дәүли: «Тирән шахталарда кап-караңгы юллар узган бар, тормыш юлларында адашып калмаска шунда өйрәндем»,—дип язар...

Язучының гыйбрәтле язмышы, үз башыннан кичкәннәрне бәян иткәндә аеруча унышка ирешүе өч китаптан торырга тиешле автобиографик романга керешкәч тә бик ачык күренде.

«Казан утлары» журналында «Язмышка юл» басылып чыгу белән, аның дәвамын сорап язган хатлар ява башлады. (Журнал редакциясе, үзенең эш планнарын үзгәртеп, әлеге әсәрнең икенче кисәген басарга мәҗбүр булды.) Ә бер хат эченнән язучыны балачагы үткән төбәккә чакыру килеп чыкты. Нәби Дәүли Царицын даласында үскән әрем кебек әче, әмма исерткеч хуш исле балачагына кайтып килде. Дүрт яшендә үк аерылган туган яклары белән дә байтак сулар аккач кына күрешергә насыйп булды аңа. Сугышны, концлагерьларны кичеп кайткач, шул хакта әсәр язып танылгач кына.

Ә язучының туган ягы—Кече Чирмешән буендагы бәләкәй генә Мәүләшә авылы. Телгә, җырга кермичә, тыйнак гомер сөргән, игелекле төбәк. Нигезе—борынгы Болгар туфрагында. Биегрәк үргә менеп карасаң, Гаяз Исхакый, Абдулла Алиш, Хәсән Туфан, Салих Баттал авыллары күренер төсле. Туфрак уртак. Язмышларында да ниндидер уртаклык сизелә...

Газаплы, бәхетсез көннәрне күпме генә кичерергә туры килмәсен, Н.Дәүли үзен бәхетле кеше дип санаган. Фашист тоткынлыгыннан исән кайтуы, иҗаты белән йөз меннәрчә укучылар күңелен яулавы—язмыш елмаюы түгелмени?

Шагыйрьнең 1937 елда басылган «Бәхет» исемле беренче китабы, чыннан да, бәхетле булып чыга. Иҗатының башында ук ул зур өметләр уята һәм, Хәсән Туфан фатихасы белән, Язучылар союзына кабул ителә. Сугышка ул язучы булып китә...

Н.Дәүлинең катлаулы иҗат юлы турында уйланганда, төрле чор әсәрләре күз алдыннан үтә. Башлангыч чорда ук язылган, самими сурәтләргә, хыялга юмарт юллар... Җырга әверелгән «Чулпан», «Татарстан—минем республикам» шигырьләре... Яңа төсләр, интонацияләр белән баеган соңгы еллар лирикасы... Н.Дәүлинең балалар драматургиясе, публицистика, ниһаять, прозадагы хезмәтләре барыбызга да мәгълүм. Шулай да, иң яраткан әсәреңне сайлап ал, дисәләр, мин «Өч тамчы су турында баллада»га тукталыр идем.

...Сугыш юлы узган җирдә яралы солдат бер йотым суга тилмереп ята. Командир үз флягасында калган суны аңа бирмәкче: «Эч, туганым, һәм уйлама, аерылам, дип, дуслардан». Җылы сүз, иптәшлек тойгысы үлем белән көрәшкән сугышчыга хәл керткәндәй була, ул инде суны эчми, башка яралыларга суза... Солдат флягасы кулдан кулга күчеп, сусауны һәм йөрәкләр сызлавын басып, комбатның үзенә кире кайта. Ә анда нибары... өч кенә тамчы су булган икән! «Өч тамчы су» балладасы—җәлилчеләр язмышын тасвирлаган «Берлинда окоп» поэмасы, шагыйрь-солдат Фатих Кәрим истәлегенә багышланган «Госпитальдән хат» шигыре белән аһәңдәш. Укучыны алардагы аерым образлар, детальләр, чагыштырулар түгел, ә күңелне кузгатырлык хис һәм гыйбрәтле фикер җәлеп итә.

...Нәби Дәүлинең туган якларында язгы ташуларга мөнәсәбәтле «сыза» дигән матур бер сүз бар. Күңел сызуларын хәтерләтә ул! Бәлки, борынгыдан ук килгән төшенчәдер... Мәгәр сызасыз ташу—кайсы заманда да ташу булмаган инде!

Күз алдыгызга китерегез: язның сәгатьләп түгел, минутлап килгән чагы. Яр битләрендәге кар юешләнгән соры чабуын боз өстенә җәелгән судан ала алмый башлый. Шулай да елга-инешләр кузгалырга уйламый әле... Менә, ниһаять, таң алдыннан авылны ниндидер гөрелте уята. «һай, сыза төшкән!»—диләр картлар. Урман-кыр суларының—сызаларның килеп әйдәвен генә көткән икән Чирмешән бозы! Шашкын-дәһшәтле, шул ук вакытта үзенең көче-кодрәте белән дә, соңыннан бушану-котылу шатлыгы алып килүе белән дә гаҗәеп матур күренеш ачыла.

Сүзне болай ерактанрак урап алып килүнең сәбәбе шул: сызалы язлар белән Н. Дәүли иҗаты арасында әчке бер уртаклык, якынлык бар сыман. Аның яшенләп-күкрәп килгән шигъри ташкыннары да шулай, әлегәчә сызыла алмый торган күңелеңне кузгата, авыр уйларыңны төбе-тамыры белән куптарып алып китә, җаныңда рәхәт-аяз иркенлек, киңлек кенә кала:

*Җил тибрәтә көмеш башакларны,*
*Бөртек йоклый ефәк бишектә...*

Катлаулы тормыш юлы узса да, шагыйрьнең күңеле суынмады, хисләре тупасланмады. Аның әсәрләрендә иркәләп-шаяртып, ә кайчак шактый усал һәм ачы итеп көлү дә, публицистик ачыклык та, ил-көн, табигать һәм кеше язмышы турында уйланулар да урынлы яңгырады.

Шигырь техникасы мәсьәләләрендә Н.Дәүлинең эчке каршылыклары—яңа күренешләргә ияләшеп җитә алмыйча, шикләнебрәк каравы мәгълүм. Кискен бәхәс рухы аның фикерләрен, бәлки, икенче чиккә дә алып киткәләгәндер. Әмма төннәр буе хәреф эзләүчеләр»не тәртипкә чакыруга кадәр барып җитсә дә, бу—шигырьнең мәгънәви тирәнлеген һәм образлы яңгырашын көчәйтү юнәлешендәге иҗади эзләнүләргә каршы чыгу түгел иде. Менә шагыйрьнең үз әсәрләре үк шаһит. Гапгади кабатлаулар ярдәмендә, ул Хатынь авылындагы кыңгырауның тирбәлүен генә күрсәтеп калмыйча, моңын да ишеттерергә тырыша. Яшьлегендә рәссамлыкка әзерләнгән әдип иҗатындагы төсләр үзены игътибарны җәлеп итә. Прозасыннан,

хәтта публицистик әсәрләреннән моңа кызыклы гына мисаллар китереп булыр иде. «Яшәү белән үлем арасында»гы доктор Василий Петровичның күзләрен хәтерлисезме? «Шырпы сүнгәч тә, ул күзләр һаман янып торалар иде кебек». Сатлыкжан полицайның исә күзләре юк, алар—«буш тартмага уелган ярыклар» гына... Немец хатынының күзләре «ояларына ут төшкән чыпчык балалары кебек сискәнеп китә». Кыю татар кызы Нажия «кар суының тамчысы кебек саф» күзле булып күнелне били.

Янә шуна игътибар итәсен: Н.Дәүли сүзләрне үзенчә сайлап ала, үзенчә тезә икән. Алар, алдагы җөмләләрнең логик дәвамы булудан бигрәк, яна фикер учаклары булып кабыналар. Нәтиҗәдә, бу стиль—прозада булсын, шигырьдә булсын—йөрәк тибеше кебек кысылып-киңәеп торучы хәрәкәте, пульсы белән истә кала. Ялтыравык тәңкәләре белән күзне чагылдырмый, сукырайтмый ул. Киресенчә, сугышчан юлын разведчик булып башлаган шагыйрь күнел күзләребезне ачыбрак карарга, күбрәк күрергә чакыра:

*Кеше гомере—олы бер тау,*
*Вакыт аны ватып ала,*
*Һәм кабергә куяр өчен*
*Бер кечкенә ташы кала.*

...Беренче очрашудан соң инде байтак еллар үткән. Вакыт күп күренешләрне хәтердән юган, күнелдә калганнарына яна күз белән карарга өйрәткән. Әмма язучының иҗатын якыннанрак белгән саен, аның ярым-йорты дөреслек, әзер хакыйкать белән килешмәүчән, тынгы белмәс бер җан булуы ачыла гына бара. Шушы юлда хаталанып үкенгән мәлләре, башкаларны һәм еш кына үз-үзен «унайсыз» хәлгә куйган чаклары да булгандыр, бәлки... Тынгысыз кешегә дөньяда яшәү җинел түгел. Бу—иҗат утында януның бер рәвеше булганда, бигрәк тә. Истә әле, ул үзенен бер китабын да «Тынгысыз йорт» дип атаган иде. Гәрчә әлеге җыентыкта шундый исемдәге әсәр очрамаса да, авторның «тынгысыз йорт» итеп үзенең күнелен һәм иҗат дөньясын күз алдына китерүе ачык аңлашыла. «Юл башы» исемле поэмадагы, Такташ һәм Туфаннар «мине бу тынгысыз йортка дәштеләр», дигән юллар да нәкъ шул фикерне раслап тора.

Н.Дәүли иҗатына, аның «тынгысыз йорт»ына—тынгысыз җанына—якынлаша башлагач, бер сәер тойгы уяна: үзенне җиде җил чатында калгандай хис итәсен. Бу тикмәгә генә түгелдер...

... Биек имән хәтәр яшеннәрне үзенә тарткан кебек, зур шәхескә дә заманның көчле, кайчакта шактый шомлы да җилләре кагылучан. Нәби аганың 100 еллыгын каршылаганда, аның иҗат һәм тормыш сәхифәләрен янә күздән кичереп, әлеге хакыйкатькә тагын бер кат ышанабыз.

Сәяси басымга бирешеп яки партия түрәләренә яраклашып түгел, күп очракта ул чорның идеологик тәгълиматына чын күнелдән ышанып иҗат иткән язучыларыбызның берсе иде Нәби Дәүли. Яна заман әдәбиятыбызның шактый кызыклы, үзенчәлекле дәверен тарихка теркәп калдыруда аның иҗаты да катнашты. Уйлы-гамьле укучы Нәби ага Дәүли һәм аның замандашлары иҗатына кабат-кабат әйләнеп кайтыр, сагыну катыш ихлас кичерешләр ләззәтен кичереп, ул чор әдәбиятының үзенә якын сыйфатларын ачар әле.

## Мәрзия Фәйзуллинага 80 яшь



Мәрзия Фәйзуллина — үзенең әдәби иҗатын тулысынча диярлек балаларга багышлаган шагыйрәләрнең берсе. Ул 1930 елның 11 июнендә Арча районы Шушмабаш авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казанга килеп, төрле оешмаларда: халык судында — сәркәтип, милиция бүлегендә—инспектор, Татарстан китап нәшриятында бухгалтер булып эшли. Илленче елларда яза башлый. 1955 елда мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Салават күпере» исемле беренче китабы басылып чыга.

1956-62 елларда ул балалар бакчасында тәрбияче, аннан Казан Укытучылар йортының балалар тәрбиясе бүлеге мөдире булып эшли. Ул елларда шагыйрәнең нәниләр өчен бер-бер артлы «Чәчәкләр сәгате», «Ике көрәк», «Зур дулкыннар», «Гөлнар мәктәпкә бара» исемле җыентыклары дөнья күрә.

1958-64 елларда М. Фәйзуллина читтән торып Мәскәүдәге М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укый. 1965 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. Шагыйрәнең иҗаты белән Мәскәү балалар нәшриятлары да кызыксына башлый, нәтиҗәдә 1963-65 еллар арасында «Детгиз», «Малыш» нәшриятларында русча тәрҗемәдә «Цветочные часы», «Стихи», «Пропала кошка» исемле өч китабы басылып чыга. Тәнкыйтьче В. Дементьев, балалар язучысы С. Баруздин, күренекле балалар шагыйрәсе А. Бартоларның мәкалә һәм чыгышларында бу китаплар авторның иҗади унышы дип бәяләнә.

«Гаилә әлифбасы» исемле китабы өчен М. Фәйзуллина 2004 елда Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләгенә лаек була.

Аның шигъри иҗаты балалар поэзиясе белән генә чикләнми. Ул «Сугыш юлларының тузаны», «Чиккән яулык» җыентыклары, «Алмагачлар күләгәсендә» кебек поэмалар, шулай ук көндәлек матбугатта басылган публицистик мәкаләләр авторы буларак та билгеле.

Бүгенге көндә ул татар һәм рус телләрендә дөнья күргән ике дистәдән артык китап авторы. Шагыйрәнең аерым әсәрләре украин, үзбәк, чуаш һ. б. телләргә дә тәрҗемә ителгән.

Балалар әдәбиятындагы хезмәтләре өчен М. Фәйзуллина Татарстан хөкүмәтенең Мактау грамотасы (1980) белән бүләкләнә, 1990 елда ана «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелә.

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

*Ак җилкән*

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ ШӘРӘФИ

## Төшләр юш килә диләр

Без бит авыл малайлары. Тормыш авыр дип тә тормадык, һаман шук булдык. Аның җиңелрәк тә, әйбәтрәк тә булырга мөмкинлеген кем белгән? Барыбыз да сәләмә киемнәрдә, ачлы-туклы дигәндәй, аннан соң безгә сугыш еллары да эләкте. Ил хәсрәте миндәй малай-шалайга, әби-бабайларга, апаларга төшкәнен үзебез дә сизмирәк йөргәнбез. Гомергә рәхәт күрмәгән бала-чагага «рәхәт тормыш» дигән нәрсә—әкият булып тоелгандыр. Хәер, төшкә кергәли иде хыялый дөньялар. Беркөн Сталинны күрдем. Ап-ак кительле, мин сиңа әйтим. Шул кителен киеп безнең Тегермән тавына менеп бара. Пропеллерларына утырып, без белмәгән җирләрне күреп әйләнәсе килгән жил тегермәне канатлары яныннан үтеп, Табан асты дигән җиргә китте. Мин иртән шул хәтле рәхәт уяндым. Миннән дә бәхетле кеше юк иде кебек ул көнне. Сталин хәтле Сталинны күр әле син! Дусларыма шул төшемне сөйләп ушларын алдым. Берсе: «Мылтыгы бар идеме?»—дип сорый. Икенчесе: «Сине күрдеме?»—ди.—Күрде,—мин әйтәм. Баштан сыйпап китте. Әле сиңа да сәлам әйтте,—дигән булам. Малайлар: «Миңа нәрсә диде?»—дип интектереп бетерделәр.



Шуннан соң, кыш житкәч, безнең алагаем зур ап-ак кәҗәбезне бер бүре шул Сталинны күргән жирдән—Тегермән тавыннан алып китте. Ул елларны бүреләр бик азган иде. Күрәсең, без ач, бүреләр тагын да ачрак булганнар. Авылдан ерак түгел жирдә кәҗәбезнең гәүдәсен таптык. Ашап бетерә алмаган. Әйткәнемчә, зур иде шул. Ап-ак кительле Сталин белән ап-ак кәҗәбезнең төшемә керүен нәрсә дип аңлатырга да белмим. Ил бәлагә батты, без сөтсез калдык.

Тагын бер төшне сөйлим әле. Сугыш вакыты. Әти сугышта, бер абыем да шунда. Әни мине өйдә бикләп ялгызымны калдырып эшкә китә. Мин сугыш беткәнче өйдә утырдым. Өстемә кияргә кием дә, аягыма гәлүш тә юк. Пес итәргә чиләк калдыралар. Оялдына чыгам. Тәрәзәсе юк. Берзаман күрәм—пыяла ишек. Каян килгән бу? Күзләремне уып карыйм, өнемме-төшемме? Алдымда ап-ак сарык бәрәне арт аякларына басып пыялага шакый. Ишекне ачып, кертмәкче булам. Келәне күтәрә алмыйм. Маташтым, тырыштым—ул ара бәрәнем югалган да.

Хәзер гомерләр узгач уйлыйм: миңа изге бәрән килгән булгандыр. Агнец божий диләрме әле икенче телдә? Аны миңа Ходай жибәргәндер. Кертергә кирәк булган да бит, килеп чыкмады шул. Кертә алган булсам, бәлки, тормышым икенче юлдан киткән булыр иде.

Хәер, биргәненә шөкер.

## Ат көткәндә

Без үскәндә җәйләр жылырак кебек иде. Көннәр озын. Нигә дисән, иртүк торыла. Кояш чыгышын күрми калган иртә юк иде инде ул. Йоклап яту гарьлек санала, йокы симертү гадәткә кермәгән—оят. Җәйләр жылы дигәннән, янгырлары да йомшак, назлы иде бугай. Шәп-шәрә килеш коеп яуган янгыр астында «үсәсе» килеп тора идек. Әле урамны инләп аккан гөрләвектә коену рәхәтен белсәгез!

Мин үзем яшенле янгырларны, давылларны ярата идем. Әле хәзер дә шулай. Лермонтовнын: «Как будто в буре есть покой...»—дигән сүзләре әле дә күнелемә хуш килә. Телевизорда күргән мотоциклчыларның әллә нинди трамплиннардан сикереп, ушларны ала торган трюклары җаныма адреналин бирә. Чангычыларны кара инде син! Ничек кенә бөтерелмиләр, гомер күрмәгән кульбитлар ясыйлар. Сокландыра! Кызыктыра!

Без укыганда, булачак артистларга төрле-төрле трюклар ясарга өйрәтеп маташмыйлар иде. Менә бик кирәк булган да бит... Хәзер үзем шатлыкларны белдерү өчен тәгәрәпләр китәр идем—юк, тәгәри дә белмибез.

Шулай да ат көткәндә артистлыкка байтак тәҗрибә жыелган. Элек атлар колхозның тракторлары, машиналары иде бит. Ни тарттырсаң да, ни төясәң дә—на-а! Әйдә, малкай! Төннәр буе ат көтү—безнең бурыч.

Шулай бервакыт безнең белән бергә бездән 2-3 яшькә кечерәк малай—Зиятдин да көтә. Әй ярата инде атка атланып чабарга. Кулларын канатландырып җәеп җибәрә дә, үрәләп чапкан ат өстендә тилгән кебек оча. Беркөнне моны өйрәтелмәгән атка атландырдык. Биеп торган яшь тайга менеп кунаклавы булды, Зиятдиныбыз сырты белән жиргә мәтәлеп тә төште. Егет икән, еламады. Аяк-куллары, кабыргалары да исән. Әй, яшь малайга ни булсын! Без әле көненә унар мәртәбә егыла идек. Чуртым да булмый иде. Мин үзем атка атланырга шул хәтле остардым—атның арт ягыннан йөгереп киләм дә, теге спортзалдагы «ат» бар бит әле, шуна сикергән кебек, сыртына менеп кунаклыйм. Кечкенә чактан ук хәзерге кебек озын идем инде мин. Атлангач та барлы-юклы атларның биленнән аякларым жиргә тиярдәй асылынып тордылар. Малайлар көләләр. Ләкин бернәрсә көлке түгел иде—ат көтү. Аларны качырмаска кирәк. Ат качыру ул бик зур оят. Егетлек түгел. Әлбәттә, йокламыйча уяу булсаң, качырмыйсың инде. Ләкин йоклап китү куркынычы бар. Шуна күрә олы абыйлар безне дилбегәләр белән атка бәйләп куюя белән яныйлар. Бәйләсәләр, беттен, йоклап китәрсең һәм ат сине өстерәп авылга чабар. Исән калырмын димә.



Шулай да сабан туйларда яраткан, үзең тәрбияләгән ат өстендә лачындай очып мәйдан булган жиргә ыргылу—тасвирлап бетергесез ләззәт. Ул арт саннын чиләнеп, кутырлап бетүен исәпкә алу юк. Анысы төзәлер, ә менә ул вакытта үзенне чын егет итеп тою—әйтеп бетергесез горурлык! Без әле хәзер дә баш бирмибез. Сынатмыйбыз әле!

## Оялу бәласе

Сугыштан сонгы еллар. Өйдә бер нәрсә юк. Ризык-фәлән дә таман гына. Әле нәрсәдер пешерим дисәң дә йә табасы, йә чуены юк. Кемнәрнең нәрсәсе бар икәнен беләбез белүен. Ләкин сорап торырга кыенсынабыз. Бик кирәк булгач нишлисең инде? Кереп китәсең. Житмәсә, әни гел мине кертеп жибәрә. Һаман шул бер Сабира апаларга инде. Оялам. Шул хәтле оялам! Капка төпләрендә таптанам, ишек алларында йөренәм, ишек тоткаларына тотынырга куркам, кергәч сүземне башлый алмыйм. Сабира апа:

—Нәрсәгә кердең?—ди.

Бу юлы иләккә кергән идем.

—Сабира апа, әни иләгеңне биреп тормассыз микән дигән иде.

—Иләгемә су салып куйдым бит,—ди бу.

Озак кына ялындыргач, бирә үзе.

Мин дә җавапсыз калмыйм. Кыюланып:

—Мин кердем, алдым, кирәк булса, үзегез кереп алырсыз,—дип чыгып йөгерәм.

Ул вакытларда кыю балалар бик сирәк иде. Нәрсәдән килде икән ул? Оят белү, әлбәттә, тыйнаклык сыйфаты. Ә хәзер ничек? Әйдәгез, уйланып карыйк әле.

## Гафу ит, Әминә апа!

Мин бик тиз үстем. Буйга укыганда ук бөтенесеннән дә озын идем. Химия укытучысы Әминә апа тактага чыгара. Һәрвакыттагыча бу фәннән бернәрсә дә белмим, лакмус кәгазенең төсе үзгәргәнен, «су»ның формуласын беләм, гомумән, мин химияне беркайчан да яратмадым. Әминә апа сизмәгәндә аның баш очында кулымны сузам. Бөтенесе көлә. Әминә апа ялт итеп миңа карый. Ә мин матур гына басып торам. Тагын класска борылуы була, мин тагын—рас, кулны! Тагын көләләр. Гел шулай дәвам итә. Берәр чакны сизде микән ул бу кыланышымны? Хәзер үкенәм.

Ә химияне белмәвемнең файдасы тиде. Авыл хуҗалыгы институтына кергәндә бу фәннән икеле алдым һәм авылга җырлап кайттым. Кергән очракта, Равил Шәрәфиев дигән артист була алмас идем.

## Директор Хәлифә апа

Без укыганда мәктәп директоры булып Ленин орденлы бик чибәр, бик усал Хәлифә апа эшләде. Шуның нәтиҗәседер, мәктәбебездән танылган язучылар чыкты. Роберт Әхмәтҗанов, Вакыйф Нуруллин, Әхәт Сафиуллин, Мидхәт Метшин һәм тагын бик күпләр...

Бер вакыт аның дәресенә соңга калып кердем.

—Равил, нигә соңга калдың? Әнә Чирмешәннәр өч чакрымнан ук килеп җиттеләр,—ди.

Мин:

—Алар тау башыннан чаңгы белән шуып төшәләр. Шуңа күрә тиз килеп җитәләр,—дип, акыллы җавап биреп котылмакчы булдым.

Хәлифә апа:

—Алай булгач, чаңгы ал да Чирмешәндә торып, мәктәпкә йөр,—дип авызымны йомдырды.

## Өрәк

Чүт олырак чак. Булачак җиңги—Мәүлия апа—минем икенче абыйның хатыны, күрше Габделфәрт абый белән кич клубка баралар. Ах син, карале боларны! Кызык итим әле үзләрен! Мин аларның кайчан кайтасын беләм. Гариф абыйларның мунчасы артына качып торам. Дөресен әйтим, мин үзем мунчадан бик куркам. Әллә инде кечкенә вакытта мунча пәриләре, җеннәре белән куркытып үстергәнгәме? Шуны белә торып, ак простина бөркәнеп көтеп торам. Әһә, кайталар. Күрми үтеп киттеләр, кыштырдаган булам. Ишетмиләр. Елгага борылдым, күрмәсләр, ахрысы. Шунда Мәүлия апа нигәдер борылып карады.

—Габделфәрт, өрәк!

Болар кирегә йөгерәләр.

Мин дә артларыннан калмыйм. Болар тагын да тиз элдертәләр. Үзләре һаман бөтен авылга оран салалар.—Өрәк, өрәк!—дип кычкыралар. Шунда кемдер урамда очрап:

—Нинди өрәк булсын! Тавык Равиледер ул!—дип әйтеп салмасынмы!

Тегеләр хәзер:

—Ах, Равил тәре, юньсез!—дип миңа киләләр. Хәзер үзем качам.

Артистлык чалымнары шул чакның шуклык галәмәтләре булгандыр инде.

## Сүгенү

Безнең авылның казак Миннулласы шул хәтле шәп сүгенә иде. Мин үзем сүгенә белмәдем. Хәзер дөньясы өйрәтте.

Ул Миннулла бер тотынса Алласы, бәндәсе калмый, дененне дә ишә, иманыңны да изә, муллаңны да өшкерә, анаңны да...

Бер көнне яшенле яңгыр килә. Теге Әмрикандагы торнада кебек, бик әшәкеләнеп. Әкәмәт инде! Миннулла белән салам эскертенә кереп качтык. Сәнәк-сәнәк саламнар оча башлаган иде, Миннулла:

—Әгүзе билләһи минәшәйтан ирражим, йә илаһи иллааллаһы мөхәммәде рәсулла,—ди-ди изге китап сүзләрен вата-җимерә укырга тотынды.

—И Аллам, бәгърем, күз нурым, коткар мине, синнән дә яраткан, хөрмәт иткән кешем юк, гомумән, син, гафу итегез, рөхсәт итегез сина Сез дип эндәшергә?!.

Шулай була ул теленне тыя белмәсән. Әле шул тел аркасында фани дөньяларда үземә дә байтак иза чигәргә туры килгәләде.

**Равил ШӘРӘФИЕВ**

---

ФӘН
ӘҺӘ!
НӘФ

## ҮСМЕР ЧАКТАГЫ «АЧЫШЫМ»

Үсмер чагымда күргән бер сәер төшемне үземә аңлата алуым ул чакта ачыш булганын олыгаеп, «лаеклы» дип атала торган ялга чыккач кына аңладым. Мина сигез яшь иде. Әти фронтта. Әни эштән бик арып кайта. Керосин да юк. Кичен йокларга бик иртә ятабыз. Без тишек борыннар, ягъни ике энекәшем белән мин, жылырак урында, ягъни сәндерәдә «төнибез». Туганыбыз Рәүф абый килеп, бихисап әкиятләре белән әсәрендермәсә, тиз арада «мәртка китәбез».

Шундый төннәрнең берсендә чынбарлыкта булса бик озак, айлар буена дәвам итәрлек мажаралар белән дыңгычлап тутырылган төш күреп куркып уяндым. Фронтка, әтием янына ашкынам имеш. Фашистларга каршы сугышасым килә икән. Поездан поездга күчкәләп фронтка да барып життем. Әмма әтиемне тапмадым. Һәм мине берниндн частька да кабул итмәделәр. Ничектер фронт аша үтеп партизаннар отрядына кердем. Тимер юлда дошман эшелоннарын шартлата башладым. Бер заман фашистлар кулына эләктем. Фашист офицеры, миннән сорау алганда берни дә әйтмәвемә жен ачуы чыккач, кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды да көпшәсен чигәмә китереп терәде һәм...шул мизгелдә уянып киттем. Баксаң, янда йоклаган энем ябык кына терсәген чигәмә терәткән икән.

Бу төшем турында озак кына уйланып йөргәч, шундый нәтиҗәгә килдем: бик озак дәвам итәрлек вакыйгаларны тасвирлый торган төшләрне кыска гына вакыт эчендә, мөгаен, бер мизгелдә күреп була икән. Үзенә күрә бер ачыш инде бу. Әмма моның ачыш икәнен аңлар өчен белем дигәнен дә кирәк бит әле. Бу очракта психофизиология дигән фәнне яхшы белү зарур. Ләкин мәктәптә яңа гына укый башлаган малайның башында нинди психология яисә физиология, бигрәк тә аларның гибриды булсын ди инде?

**Ким ШАКИРОВ**

# Йолдыз

## Исем

**Булатлар бозавы белән**
**Икебезгә бер исем.**
**Булат үчекләгән була,**
**Ә минем китми исем.**

**Бозаулары матур чынлап**
**Сикерә генә уйнап,**
**Мангаенда бар агы,**
**Мөгезләре бар тагы.**

**Минме? Мин гади бер кыз.**
**Борыным да сипкелле.**
**Төскә дә бик матур түгел**
**Никтер әни шикелле.**

**Тик...**
**Башка төрле күренәм бугай**
**Күрше малай Булатка.**
**«Йолдыз, Йолдыз!» дигән тавышы**
**Сеңде тәмам колакка.**
**Үзе бозавын чакыра,**
**Күзе гел минем якта.**

## Өйрәнсен!

**Сыерыбызга печән салдым,**
**Куеп киттем сәнәк тә.**
**Чәнечке белән ашасын,**
**Өйрәнсен дип әдәпкә.**

## Пычранмаган

**Урамда да,**
**Урманда да**
**Кышын ап-ак кар ята.**
**Энем кышны ярата,**
**Энем карны ярата.**
**Тотып карый**
**Кулы белән,**
**Татып карый**
**Теле белән,**
**Ятып ауный**
**Туны белән,**
**Үзе көлә, шаяра.**
**Ап-ак була кай ара.**
**Әйтәм инде:**
**«Ярамый!»**
**Ә ул аңа карамый.**
**Әйтеп булмый**
**«Шапшак» дип .**
**Пычранмаган—**
**ап-ак бит!**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru.*

## «МАТБУГАТ.РУ»ДАН БЕЗНЕ УКЫГЫЗ

### Туфан Миңнуллин. Минһаҗ маҗаралары. 2010, февраль

Менә, Миргазиян абыйга 80 тулганчы чыккан булса бу язма, бәлки файдасы да тияр иде. Әлегә мин моны: «Тукай бүләгенә өметләнерлек әсәрләр соңгы елларда язылмады, өметләнмәсеннәр дә!» дигән кебек аңладым. Әйе, язылмады ул, берничә ел элек тә язылмаган иде. Аңа карап кына... Тиешләр калмаган, димәк.

**Күке**

### Адлер Тимергалин. Ике сандык йакут. 2010, февраль

Бер мәкаләгә бар да сыйган. Тукай—бөек. Классика искерми. Бар чорда да актуаль. Киләчәктә, ген-клон технологияләре кулланып, бөекләрне «янадан тудырырлар». Тәннәрен генә димим, бәлки, үз «җаннарын» да кире кайтарырлар. Тукай да булсын иде алар арасында.

**Нух**

Тукайның бөеклеген татар аңлап житкерми. Яшьлегем кумиры Равил Фәйзуллиннан: «Безгә Тукай хәтле генә язсак та ярар иде,»—дигән сүз ишетү, йөрәгемне тураклап ташлау белән бер иде. Бүген Тукай кебек тагын бер гений тусамы!? Без бүгенге урында утырмас идек, әлбәттә.

**Ирка**

### Фирүзә Җамалетдинова. Исемнәре Искәндәр. 2010, март

Яхшы әсәр язучылар бар икән әле. Бик ошады.

**Укучы**

Исемен «Көзнең көннәре төрле була» дип куйса яхшырак булыр иде, минемчә.

**Искәндәр**

Искәндәр, килешәм сезнең белән. Йөгерек язса да, әйтергә теләгән моралена үзе ышанмавы ярылып ята. Бу мораль хикәядә сөйләнгән вакыйгалар белән ачылмый. Монда икенче мораль укыла—и хочется, и колется, и мам не велит.

**Әйе**



Татарстан Республикасының Башкарма комитеты әгъзалары. Уңнан сулга—Х. Гайнуллин, Б. Мансуров, Н. Яруллин, Конов. Үткән гасырның 20нче еллары.



Бөтендөнья Татар Конгрессының Башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров. 2003 ел.



Казан пристане күренеше. XX гасыр башы.



*Чаллыда яшәп иҗат иткән язучылар. Сулдан уңга—Эдуард Касыймов, Рәшит Юнысов, Рәшит Бәшәров. 1981 ел.*



*СССР язучыларының VIII съездында төшкән рәсем. Уңнан сулга—Г. Рәхим, Т. Миңнуллин, Р. Вәлиев, Ю. Грибов, М. Госманов, Р. Гаташ. Мәскәү. 1986 ел.*

## Миңзифа Әхмәтшина



1955 елны Чистай районы Татар Сарсазы авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Чистай сәгать заводында эшли. Читтән торып Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумының Әлмәттәге филиалын, аннан Алабуга культура-агарту училищесын тәмамлый. Авыл хуҗалыгы алдынгысы. 1985-90 елларда XI чакырылыш Татарстан Югары Советына депутат булып сайлана. Яхшы күрсәткечләргә ирешкәне өчен 1989 елда ВДНХның мактау кәгазенә лаек була.

Беренче шигырьләре, авыл вакыйгаларын чагылдырган язмалары районда чыга торган «Ленин юлы», (хәзер «Чистай хәбәрләре») газетасында дөнья күрә. 1997 елдан авыл мәдәният йортында үзешчән сәнгать җитәкчесе булып эшли башлый. Шул вакытта район китапханәсе каршында оештырылган «Энҗеләр» әдәби түгәрәгенең актив әгъзасы булып, каләм тибрәтүче яшь талантларны барлауда башлап йөри.

Шигырьләре Республикабызның «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Татар иле», «Ватандашлар», «Казан утлары», «Сөембикә», «Мәйдан», «Идел» журналларында басыла. Үзенең шигырьләренә көйләр дә яза ул. 2000 елдан— Үзешчән Композиторлар Берлеге әгъзасы. 2001 елда беренче «Мәхәббәт дастаны» дигән шигырьләр, ноталары белән җырлар китабы дөнья күрә.

2003 елдан бирле ул Әлмәт шәһәрендә яши. Районда чыга торган «Әлмәт таңнары» газетасында әледән-әле басылып килгән язмалары, шигырьләре аша халыкка яхшы таныш. 2004 елда «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте каршындагы «Рухият» рухи янарыш Фонды нәшриятында «Күңелем канаты» дигән икенче шигырьләр җыентыгы басылып чыкты.

Минзифа Әхмәтшина бүгенге көндә Әлмәт Дәүләт Нефть институтының студентларның ял һәм сәламәтләндерү үзәгендә «Әдәби кунакханә» җитәкчесе. Яшь талантларны барлауда актив хезмәте өчен «Татнефть» профсоюзларының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Институт ярдәме белән «Хыялымда кайтам» дигән яңа шигырьләр китабы басылып чыкты. Тиздән шагыйрәнең «Болытлар артында кояш бар» дигән китабы чыгачак.

Быелның 22 апрелендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Минзифа Хәйретдин кызы Әхмәтшинаны үзенә әгъза итеп кабул итте.

# БЕРДӘМ БУЛЫЙК!

## Октябрь аенда үткәреләчәк халык исәбен алу уңаеннан, Татарстан язучыларының татар халкына МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле милләттәшләр!

Россия Федерациясендә янадан халык санын алалар. Бу җәһәттән башка шундый уй килә: чыннан да, татарларның саны күпме? Безгә моны белү гаять әһәмиятле. Тукаебыз заманында «10 миллион Идел буе татары» дип язган. Тукай әйтсә хак әйтер. Ә хәзер халык исәбе дөрес алынамы, дөрес алынган хәлдә, нәтиҗәләре дөрес игълан ителәме?.. Соңгы елларда үткәрелгән сан алулар исә татарның киләчәк язмышына бәйле бик күп сораулар тудырды. Без, туган халкыбыз язмышын кайгыртучы татар язучылары, әнә шуларны күздә тотып, сезгә мөрәҗәгать итәргә, борчулы уйларыбызны сезнең белән уртаклашырга булдык, кадерле милләттәшләр!..

Йә, санасыннар соң, беренче тапкыр түгел бит, гел санап торалар, ни зыяны бар аның, дияр кайберәүләр. Әйе, күпмилләтле Рәсәй илендә тугыз-ун ел саен халык санын алу тәҗрибәсеннән һәм хәзерге четерекле милли хәл-әхвәлләребездән туган уйлар борчуга сала да инде безне...

Уяу булыйк: алдагы еллар олы тарихлы халкыбыз өчен житди сынау еллары булачак, ә быелгы халык исәбен алу нәтиҗәләре халкыбызны таркату-корыту вәзгыятенә дә әйләндерелергә мөмкин. Элекке сан алуларны оештыру тәҗрибәсе Рәсәй кинлекләрендә таралып яшәгән татар халкына карата алып барылган сәясәтнен бик үк унай булмавын күрсәтте.

Россиядә беренче тулы сан алу 1897 елда үткәрелде.

СССР дигән мәмләкәттә дә сан алуларда асылда шул 1897 елгы тәртип саклана. Ләкин бу чорда әлеге гамәлгә татар халкын киметеп күрсәтүгә йөз тоткан ялгышлар да кушыла башлый.

СССР таркалгач, 2002 елда Россия Федерациясе беренче тапкыр халык исәбен алды. Кызганыч ки, монда да сан алу нәтиҗәләрендә татар халкын киметеп күрсәтү катышмый калмады. Демократик илләрдә нинди халыктан (милләттән) булуы турындагы сорауга кеше үзе теләгәнчә җавап бирсә, бездә исә хакимият алдан халыклар һәм телләр исемлеген төзеде. Әлеге исемлектә татарлар таркатылып, 45 (!) исемгә бүлгәләнеп теркәлде. Бу хәл санау нәтиҗәләренә тәэсир итмичә калмады, әлбәттә. Татарны бүлгәләр өчен бүтән төр «тырышлыклар» да куелды.

Ләкин халкыбызның зиһенен кемнәрдер теләгәнчә саташтыра алмадылар. Башкортстанны санамаганда, без беркайда да зур югалтулар кичермәдек, 1989 елгы җанисәп белән чагыштырганда, беркадәр (32,5 мен кешегә) арттык та әле. Сан алу нәтиҗәләре хакында Россия Фәннәр академиясенең әлеге исемлекне әзерләгән Этнология һәм антропология институты идеологларының берсе: «Татары воспользовались переписью и произвели консолидацию»,—дигән иде.

Әмма быелгы халык санын алу, республикаларның болай да юк дәрәҗәсендәге мөстәкыйльлеге тәмам бетерелеп, милли мәгариф бик нык тарайтылган бер чорда үткәрелә. Халык исәбен алуны да шушы максатка ярашлы итеп үткәрү куркынычы бар. Коткыга да, басымга да, мәкер-хәйләгә дә бирешмик, газиз милләттәшләр! Тарихи бергәлегебезне, бердәмлегебезне саклыйк! Җавап бер һәм аермачык булсын: без—татарлар, туган телебез—татар теле. Шуны тирән аңларга кирәк: бербөтен татар милләтенеке булу үз кавеменнен этник-этнографик төркеменнән йөз чөерү түгел ул. Без бергә булганда гына үзенчәлекле тарихи этник-этнографик йөзебезне, ягъни туган телебезне, мәдәниятебезне һәм гореф-гадәтләребезне саклап калачакбыз. Моны балаларыбыз-оныкларыбызга да аңлатыйк. Безне олы тарих, уртак әдәби тел, уртак культура, уртак яшәү рәвеше берләштерә.

«Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», ди милли уртак мәкалебез. Ан булыйк: киләчәгебез кыл өстендә торган бу чорда безне берәү дә сакламаячак та, якламаячак та. Моны без бары үзебез генә, бер йомгак булып тупланып кына эшли алабыз. Бергә булыйк! Бердәм булыйк!..

## ТУГАН ТЕЛ. ШИГЪРИЯТ. ТУКАЙ.

Апрель аен Тукай исеме белән билгеләргә өйрәнгәнбез. Шагыйрь әйтмешли, «ул бу айда туган һәм янган».

Быел шагыйрьнең туган көнендә—26 апрель иртәсендә башкалабыз үзәгендәге Г. Тукай һәйкәленә чәчәкләр салуда Татарстан Президенты Р. Миңнеханов, Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З.Вәлиева, Президент аппараты җитәкчесе Ю. Камалтынов, Казан шәһәре мэры И. Метшин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, республика парламенты депутатлары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

«Туган тел көне—зур һәм якты бәйрәм,—диде Ф.Мөхәммәтшин журналистлар белән әңгәмә корганда—Безнең республикада ул бөек шагыйребез Г.Тукайның туган көнендә билгеләп үтелә. Шушы уңайдан шагыйрь һәйкәле янына бик күп кеше җыела. Монда шигырьләр генә укылмый, шундый мөһим фикер дә һәркемнең аңыннан сызылып үтә: туган телдән башка милләт һәм халыкны саклап булмаячак».

***

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы янындагы мәйданда үткәрелгән Шигърият бәйрәме быел шул ягы белән үзенчәлекле булды: анда совет халкының 1941-45 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүенә 65 ел тулу чыгышларда әледән-әле искә алынды. Бәйрәм программасының башында ук Г. Тукай, М. Җәлил һәм Ф. Кәрим шигырьләре яңгырады, Ватан сугышында барлыгы 114 татар язучысы катнашуы искәртеп үтелде.

Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева ТР Президентының 2010 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турындагы Указын игълан итте, яңа лауреатларга иҗат уңышлары һәм саулык-сәламәтлек теләде. Аннары быелгы бүләк ияләре шагыйрь Р. Зәйдулла, язучы Ф.Садриев, баянчы В. Федотов, скульпторлар А. Миннуллина һәм И. Ханов, иҗатларының югары дәрәҗәдә бәяләнүе өчен, җәмәгатьчелек алдында республикабыз җитәкчелегенә ихлас рәхмәт сүзләрен белдерделәр.

Бәйрәмнең шигъри-музыкаль өлешен шагыйрь З.Мансуров алып барды. Анда Р.Фәйзуллин, Р.Миннуллин, Р.Вәлиев, Г.Рәхим, Р.Гаташ, Р.Вәлиева, Л.Шагыйрьҗан, И.Гыйләҗев, Л.Газизова, М.Тузов, Н.Сафина, Ф.Тарханова, Ш.Җиһангирова, Х.Мөдәррисова, Д.Булгакова, Г.Садә, Г.Гыйльман, Р.Рахмани, Р.Аймәт, Р.Зәкуан, Х.Бәдигый, С.Әхмәтҗанова, Л. Гыйбадуллина, Э.Һадиева, Р.Мөхәммәтшин һ.б. чыгыш ясады. Шигърият бәйрәмендә И.Әхмәтҗанов, Р.Галимова, А.Габдинов, А.Габдинова, И.Кашапов һ.б. сәнгать осталары башкаруында Г.Тукай шигырьләре, җырлар яңгырады, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле төркеме, «Айгөл» ансамбле һ.б. коллективлар катнашында җырлы-биюле тамашалар күрсәтелде.

Шул ук көнне Казанның Бауман һәм Университет урамнары кисешкән урында инде бишенче ел рәттән татар теленең шәһәрдәге кулланылыш даирәсен киңәйтү, татар шәһәр мәдәни мохитен булдыруны төп максат итеп куйган «Мин татарча сөйләшәм» акциясе үтте.

***

Менә инде егерме елга якын апрель аенда Балтач районында да Шигърият бәйрәме оештырыла. Быелгы тантанада әдәбият галиме Ф.Галимуллин, шагыйрьләр З. Мансуров, Л.Лерон, Р.Зәкуан, А.Зарипова, Балтачта яшәп иҗат итүче каләм әһелләре Г.Мөхәммәтшин, Б.Зыятдинов, Ф.Шакирова, Э.Закирова катнашты. Алар иң әүвәл Г.Тукайның Сасна Пүчинкәсе зиратында җирләнгән әнисе Бибимәмдүдә абыстайның каберенә чәчәк салдылар. Аннары аның рухына дога укылды. Шуннан соң Субаш авылы Мәдәният йортында Г.Тукайның тууына 124 ел тулуга багышланган әдәбимузыкаль кичә булды. Анда Балтач районы күләмендә үткәрелгән күптөрле балалар иҗат конкурсларына йомгак ясалды, җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды.

* * *

27 апрельдә Шигърият бәйрәме Г.Тукайның туган ягына күчте. Казаннан кайткан бер төркем язучыларны Арча

чигендә муниципаль район башлыгы А.Нәзиров, район башкарма комитеты житәкчесе урынбасары Н.Мифтахетдинова, гармунчылар ансамбле, милли киемнәрдән киенгән, кулларына чәк-чәк тоткан кызлар каршы алды.

Кунаклар ин әүвәл район үзәгендәге яңа спорт комплексын карадылар, «Казан арты» этнография-тарих музеенда булдылар. Район мәдәният йортында үткәрелгән бәйрәмдә каләм әһелләренең чыгышлары жирле үзешчәннәрнең жырбиюләре белән үрелеп барды. Арчалылар алдында район хакиме А.Нәзиров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе И.Ибраһимов, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары—шагыйрь Р.Вәлиев, Татарстанның халык язучысы Т.Миннуллин, шагыйрь Г.Рәхим, шулай ук әдәбият галиме Х.Миннегулов, Язучылар берлеге рәисе урынбасары В.Нуриев, шагыйрьләр Х.Бәдигый, Б.Ибраһимов сөйләде. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенең быелгы ияләре Р.Зәйдулла, Ф.Садриев, В.Федотовлар чыгыш ясады.

Кунаклар һәм яңа лауреатлар Г.Тукайның Тукай-Кырлайдагы музей комплексында, Кушлавычтагы музеенда булдылар, шушы авылда шагыйрьнең әтисе Мөхәммәтгариф каберен зиярат кылдылар, Кырлай паркында агач утырттылар.

* * *

Г.Тукайның тууына 124 ел тулу уңаеннан Төркиядә дә мәдәни чаралар үткәрелде. Төрек кардәшләребез һәм милләттәшләребез белән очрашуларда Татарстаннан шагыйрь М.Закир катнашты.

* * *

Татарстанның Санкт-Петербургтагы һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге Россиянең төньяк башкаласында Г.Тукайның туган көненә багышланган Шигърият бәйрәме оештырды. Шәһәр үзәгендәге шагыйрь һәйкәле янында үткән әлеге тантанада Казаннан килгән шагыйрьләр Г.Морат һәм Ф.Мөслимова чыгыш ясады. Аннары алар Л.Гумилевның музейфатирында, Дәүләт Эрмитажында һәм Рус музеенда булдылар.

* * *

Шигърият һәм Туган тел бәйрәмнәре кысаларында республикабызның Тукай районы Суыксу авылы Мәдәният йортында да әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда район китапханәчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, мәктәп балалары жыелган иде. Тамашачылар хозурында Казаннан килгән шагыйрьләр Р.Корбан, Р.Рахман, Чаллыдан язучылар В.Имамов, Р.Бәшәр h.б. чыгыш ясады.

## ТУКСАН ЕЛЛЫК ХӨРМӘТЕНӘ

Мәскәүдә Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Вәкаләтле вәкиллегендә ТАССР оештырылуга 90 ел тулу уңаеннан кабул итү тантанасы булды.

Анда Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм ТРның РФдәге Вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин катнашты. Юбилей тантанасы шатлыгын төрле федераль структуралардан: Россия Президенты администрациясеннән, РФ Хөкүмәте, Федерация Советы һәм Дәүләт Думасыннан, шулай ук Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе хөкүмәтләреннән 50дән артыграк дус-партнерларыбыз, дипломатлар, РФ субъектлары вәкиллекләре житәкчеләре уртаклашты.

Тантаналы кабул итүгә шулай ук Мәскәү төбәгендә яшәүче танылган милләттәшләребез: сугыш һәм хезмәт ветераннары, атаклы ижтимагый эшлеклеләр, актерлар, спортчылар, язучы, эшлекле даирәләр вәкилләре дә чакырылган иде.

## ИСЕМНӘРЕН ОНЫТМЫЙБЫЗ

«Ватанны каләм һәм корал белән саклаган Татарстан журналистлары истәлегенә. 1941-1945». ТР Журналистлар берлеге йортында Бөек Ватан сугышында катнашып һәлак булган журналистлар хөрмәтенә татар һәм рус телләрендә шундый текст язылып, Мәңгелек ут сурәте уелган истәлек тактасы ачылды.

ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, ветераннар һәм яшь журналистлар, газета-журналларның баш мөхәррирләре катнашындагы тантананы башлап, сугышта катнашкан ветеран журналистларны Жиңү көне белән котлады һәм аларга ныклы сәламәтлек теләде.

Тантанада чыгыш ясаган ТР Министрлар Кабинеты карамагындагы «Хәтер китабы» редакциясе баш мөхәррире Анатолий Иванов жәмәгатьчелеккә яңа гына дөнья күргән «Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан» дип аталган китапны тәкъдим итте.

## ИКЕ ЕЛГА ИКЕ БҮЛӘК

Казан Кремле тыюлыгындагы Татарстан табигате тарихы музее В.Потанин хәйрия фонды бүләгенә лаек булды. «Үзгәрүчән дөньяда үзгәрүче музей» бәйгесендә быел Россиянең 71 төбәгеннән 345 музей катнашкан. Жюри шулар арасыннан 22сен сайлап алган. Табигать тарихы музее әле ике генә ел эшләвенә карамастан, бу—музей яулаган икенче грант.

## ЯҢА ТАЛАНТЛАР КИЛӘ

26 апрельдә Казанның Муса Жәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында «Татар моңы» яшь башкаручылар фестиваленең гала-концерты үтте. Быел

бу фестивальдә Казаннан, республиканың башка шәһәрләреннән һәм районнарыннан, күрше төбәкләрдән һәм БДБның кайбер илләреннән 800дән артык кеше катнашырга теләк белдергән. Әлеге концертта фестивальнең өч турыннан узган «иң-иннәр» генә чыгыш ясады. «Татар моңы» Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев фатыйхасы белән беренче мәртәбә узган ел үткәрелгән иде. Аны оештыручылар фестивальне башта ике елга бер мәртәбә генә уздырырга ниятләсә, катнашырга теләүче яшь талантлар бик күп булганга, ел саен үткәрмәкчеләр. Чыннан да, яшьләр арасында татар көйләрен жиренә житкереп башкара торган көчле һәм моңлы тавышлы талантлар күп икән: гала-концерттагы һәр чыгышны тамашачы исе китеп тыңлады һәм алкышларга күмде. Иң соңыннан, «Татар моңы»ның лауреатларына һәм дипломантларына акчалата бүләкләр тапшыргач, бар халык аягүрә басып, «Туган тел»не жырлады.

### ЯЗУЧЫНЫҢ ИЖАТ БӘЙРӘМЕ

«Казан» милли-мәдәни үзәгендә Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы Вакыйф Нуруллинның 75 яшьлеге уңаеннан юбилей кичәсе узды. Ул үз заманында повесть һәм хикәяләре белән укучыларга билгеле әдип. В.Нуруллин—25 китап авторы. Аларның кайберләре рус, украин, тажик телләрендә басылып чыккан. Аерым әсәрләре казакъ, мари, чуаш, каракалпак, әзәрбайжан телләренә тәржемә ителгән.

Юбилярны Мәдәният министрлыгының сәнгать бүлеге башлыгы З. Салихова, Президент аппараты каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды житәкчесе Н. Вәлиуллина тәбрикләде. Язучыга «Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен» дигән күкрәк билгесе тапшырылды. Язучыны котларга Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәех, заманында университетта бергә укыган сабакташы профессор Тәлгат Галиуллин, Балык Бистәсеннән якташлары килгән иде. Әдип укучыларны кызыксындырган сорауларга да җавап бирде.

### ЯГЪФӘРОВ ФИЛЬМНАРЫ

Режиссер Илдар Ягъфәров исеме кино сөючеләргә яхшы таныш. Аның «Бәхеткәй» фильмы Америкада узган «Дөнья халыклары мәдәнияте» фестивалендә гран-при яулаган иде. «Казан эрмитажы» үзәгендә Илдар Ягъфәровның иҗат кичәсе узды. Аның «Күктән» һәм «Брелок» фильмнары күрсәтелер алдыннан режиссер, актерлар, оператор үзләре турында һәм кинонын ничек төшерелүе хакында кызыклы фактлар сөйләделәр. Соныннан тамашачылар үзенең фикерләре белән уртаклашты.

Шунысын да әйтеп узу кирәк: күптән түгел Илдар Ягъфәров үзенең «Брелок» фильмы белән дөньякүләм дәрәҗәле саналган Канны халыкара кинофестивалендә дә катнашты.

### ТИНЧУРИНЛЫЛАР ИЛ ГИЗӘ

К.Тинчурин театры артистлары кабат Себер якларында гастрольдә булып кайтты.

Театр директоры Фәнис Мөсәгыйтов тырышлыгы белән 2006 елдан бирле Себер белән Тинчурин театры арасында дуслык элемтәләре урнаштырылды. Былтыр театр ике тапкыр Себердә булып кайткан иде. Быелгы маршрут «Себер-2010» дип аталды һәм бу юлы Ижау, Пермь краеның Күнгәр бистәсе, Екатеринбург, Төмән, Омск, Куйбышев, Томск, Ачинск, Лесосибирск, Красноярск, Кемерово, Юрга, Новосибирск, Чаны, Аслана, Чиләбе, Уфа шәһәрләрендә спектакльләр куелды.

Әлеге гастроль Бөек Җиңүнең 65 еллыгына багышланды һәм тамашачыларга тәкъдим ителгән спектакльнең үзәк темасы да сугышка багышланган. Ул—Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Исламия Мәхмүтованың «Син бит минем бер генәм» комедиясе.

Һәрбер спектакльгә сугыш, тыл ветераннары кунак буларак чакырылды. Театр тарафыннан аларга бүләкләр тапшырылды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* «Борынгы сабантуй». **Рафаэль Кадыйров** һәм **Салават Гыйләҗетдинов** эше.

*Дүртенче биттә:* язучы **Ринат Баттал**.

# Яңа китаплар




Каһарман каләме. Төзүчеләре—Вакыйф Нуриев, Лилия Сафиуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010 ел.—223 бит. Тиражы—2000 д.

Бу китапта Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучыларның тормыш юлы турында мәгълүматлар һәм аларның иҗатыннан үрнәкләр туплап бирелгән. Шунда ук татар халкының—татар сугышчыларына, татар сугышчыларының татар халкына язылган, уртак уй, гамь белән сугарылган, аларның җан авазы булган мөрәҗәгате һәм хатлары, фронтовик язучыларның, Татарстан китап нәшриятының фронтта катнашкан хезмәткәрләренең исемнәре дә бирелгән. Китап Бөек Җиңүнең 65 еллыгы уңае белән чыгарылган.

Кереш сүзне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов язган.




**Марсель Галиев.** Талисман: публицистик язмалар: Татар. кит. нәшр. 2010 ел.—453 бит. Тиражы—1500 данә.

Бу китапка күренекле язучы Марсель Галиевнең соңгы дистә елларда язылган әсәрләре туплап бирелгән. Монда—халкыбызның атаклы шәхесләре турында әдәби сурәтнамәләр дә, интервью-әңгәмәләр, тарихыбыз, сәнгатебезгә караган фәлсәфи язмалар, авыл кешеләре турында очерклар урын алган. Өч бүлектән торган бу китап әдәбият сөючеләр өчен кызыклы булачак.



Ринат Баттал

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)